ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

12.2006



# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ

## «Татарстан Республикасы халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирү турында



Татар әдәбиятын үстерүдәге зур казанышлары өчен шагыйрь **Әгъләметдинов Мөдәррис Зөфәр** улына (Мөдәррис Әгъләмгә) «Татарстан Республикасының халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирергә.

Татарстан Республикасы Президенты **М. Ш. ШӘЙМИЕВ**

*Казан, Кремль. 2006 ел, 24 октябрь № ПУ-447*

**Казан утлары**
**Qazan utları**

*2006*

**12**

**(1010)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Нур ӘХМӘДИЕВ. Дәрдеменд. *Поэма.* ..... 5
Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ. Соңгы сугыш. *Повесть.* ..... 12
Роберт ӘХМӘТҖАН. Кичке тәрәзәләр. *Шигырьләр.* ..... 29
Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Үзем хөкем итәм. *Роман.* ..... 35
Басыйр РАФИКОВ, Равил ШӘФИГУЛЛИН, Рәис САФИН,
Римир СӘЛИМГӘРӘЕВ. *Шигырьләр.* ..... 78
Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Уяну. *(Хикәяләр конкурсына.)* ..... 86

**ӘДӘБИ МИРАС**

Рафис ӘХМӘТ. Акын, чичән, шагыйрь... *(Мифтахетдин Акмулланың тууына 175 ел.)* .. 91
АКМУЛЛА. Робагыйлар. ..... 95

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Рафаэль ХӘКИМ. Татар рухы. ..... 102
Мәҗит ВӘЛИУЛЛИН. Җәмгыять һәм мәктәп. ..... 131

**ТАТАР ТЕАТРЫНА 100 ЕЛ**

Ач пәрдәңне, галиҗәнап Театр!.. *(Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры директоры* Шамил ЗАКИРОВ *белән* Рәйсә ЮСУПОВА *әңгәмәсе).* ... 107
Әзһәр ШАКИРОВ. Язмыш һәм узмыш. ..... 114

**ТАТАРСТАН КИТАП ПАЛАТАСЫНА 80 ЕЛ**

Миләүшә ШАКИРОВА. Татар китабының алтын сандыгы. ..... 122

**«МИЛЛИ КИТАП» НӘШРИЯТЫНА 10 ЕЛ**

Ирек ҺАДИЕВ. Үз нәшриятыбыз. ..... 128

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Ләйсән ИШМИЕВА. Символлар сере. ..... 139

**СӘНГАТЬ**

Тәлгат НӘҖМИЕВ. «Туган җирем дә, туган көнем дә – икәү...» ..... 143

**ХӘТЕР**

Миркасыйм ГОСМАНОВ. Сират күперендәге уйлар. ..... 149
Мөхәммәт МӘҺДИЕВ. Көндәлек сәхифәләре. ..... 163

**ЮМОР-САТИРА**

Әхәт САФИУЛЛИН. «Бүген ничәсе?». ..... 177

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Миргазиян ЮНЫС. Кунакханә маҗарасы яки рәшәткәле купе. ..... 166

2006 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге. ..... 183

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман Р. МИР-ХАЙДАРОВА «Судить буду я» (продолжение); повесть Г. ГИЛЬМАНОВА «Последняя битва»; рассказ Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ «Пробуждение»; поэма Н. АХМАДИЕВА «Дэрдмэнд»; стихи Роб. АХМЕТЗЯНОВА, Б. РАФИКОВА, Р. ШАРИФУЛЛИНА, Р. САФИНА, Р. САЛИМГАРАЕВА.
«Литературное наследие»: статья Р. АХМЕТА к 175-летию М. Акмуллы; рубаи АКМУЛЛЫ.
«Публицистика»: Р. ХАКИМ. «Метаморфозы духа» (продолжение); М. ВАЛИУЛЛИН. «Общество и школа».
«К 100-летию татарского театра»: интервью Р. ЮСУПОВОЙ с директором театра имени Г. Камала Ш. ЗАКИРОВЫМ; воспоминания А. ШАКИРОВА.
«К 80-летию Книжной палаты Татарстана»: М. ШАКИРОВА. «Золотой фонд татарской книги».
«К 10-летию издательства «Милли китап»: И. ХАДИЕВ. «Наше издательство».
«Литературная критика»: Л. ИШМИЕВА. «Тайна символов».
«Искусство»: статья Т. НАЗМИЕВА о скульпторе Кадиме Замитове.
«Память»: статья М. УСМАНОВА о М. Гайнуллине; М. МАГДЕЕВ. «Страницы из дневника».
«Рассказы из жизни»: М. ЮНУСОВ. «Билет с приключением»
Библиографический список произведений, опубликованных в 2006 году.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Татарский государственный академический театр имени Г. Камала; писатель Рашит БАШАР.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

Prose and poetry: novel by R. MIR-HAYDAROV I will judge (continuation); story by G. GILMANOV Last fight; story by E. SHARIFULLINA Awakening; poem by N. AHMADIEV Derdemend; verses by Rob. AHMETZYANOV, B. RAFIKOV, R. SHARIFULLIN, R. SAFIN, R. SALIMGARAEV.
Literary heritage: article by R. AHMET to 175th anniversary of M. Akmulla; rubais by AKMULLA.
Publicism: R. HAKIM. Metamorphoses of spirit (continuation);
M. VALIULLIN. Society and school.
To 100th anniversary of Tatar theatre: interview of R. YUSUPOVA with director of theatre named after G. Kamal Sh. ZAKIROV; memoirs of A. SHAKIROV.
To 80th anniversary of Book chamber of Tatarstan: M. SHAKIROVA. Gold fund of Tatar book.
To 10th anniversary of publishing house Milli kitan: I. HADIEV. Our publishing house.
Literary criticism: L. ISHMIEVA. Secret of symbols.
Art: article by T. NAZMIEV about sculptor Kadim Zamitov.
Memory: article by M. USMANOV about M. Gaynullin;
M. MAGDEEV. Pages from diary.
Stories from life: M. YUNUSOV. Ticket with adventure.
Bibliographic list of works published in 2006.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Tatar state academic theatre named after Kamal; writer Rashit BASHAR.

* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 23.11.2006 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ 3—1034 Тираж 6032.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2006 ел.



Нур Әхмәдиев

# ДӘРДЕМӘНД

ПОЭМА

*Каләм! Кальбеңдә ни сер бар—гаян ит,*
*Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.*
Дәрдемәнд. «Каләмгә хитаб».

*Урал таукайлары киртләч-киртләч,*
*Бөркет куна кыя ташына.*
*Тәкъдиренә ниләр язылганын*
*Беләме соң егет—башына?*

*Урал таукайлары киртләч-киртләч,*
*Бөркетләре куна кыяга.*
*Бәхет өчен артык күп кирәкми,*
*Ләкин бәхет, гүя, пыяла,—*
*Тотып өлгермисең—уала.*

**...Бәхет кемне кайда сагалыйдыр,**
**Белсә белер моны бер Алла.**
**Кемнәргәдер Зәй буйлары якын,**
**Ә кемнеңдер бәхет—Уралда.**

**Кара диңгез, Шәрекъ илләренә**
**Дөнья буйлап татар таралган.**
**Әллә үзе бик йөремсәк халык,**
**Тәкъдирдәме шулай каралган?**

**Рәмиләрнең ерак бабалары**
**Тайсуганда гомер кичергән.**
**Кырларында иген үстергән дә**
**Зәй суында атлар эчергән.**

**Алар белем алган мәдрәсәнең**
**Тарихларда калган аты бар.**
**Рәмиләрнең, кайда яшәсә дә:**
**—Тайсуганнан!—дияр хакы бар.**

**Мактаныйрлар...**
**Ничек мактанмасын:**
**Батырша* бит шунда укыган.**
**Фетнә оештырып, ул уяткан**
**Сәрхуш Русияне йокыдан.**

**Пугачевка кадәр булган фетнә,**
**Тарих үзе бирсен бәһасен.**
**Бер кеше дә килми мәңгелеккә,**
**Батырларның рухы яшәсен!**

**Габдуллага, юкса, бәлеш ашап,**
**Дога кылып ятса, ни була.**
**Түзәме соң яшь мулланың җаны—**
**Хаклык өчен яуга ыргыла...**

**Хак мөслимин җаннан артык күрә,**
**Таптамыйча саклый иманын.**
**Кыйнасаң да үзен, түзәр әле,**
**Иманына тимә син аның!**

*Батырша—Габдулла Галиев. XVIII гасыр урталарында чукындыруга каршы кузгалган восстание җитәкчесе.

Нур ӘХМӘДИЕВ (1946)—*шагыйрь, прозаик; дистәдән артык китап, шул исәптән дүрт томлы «Сайланма әсәрләр» авторы. Әлмәттә яши.*

Чукынырга гына кушма аңа,
Ислам өчен фида җаны да.

Дин юлында шәһит киткәннәрнең
Билгесездер җирдә саны да...

* * *

Батыршаның яшел әләменә
Татар-башкорт күпме иярде.
Ярлыларның ике аягы бар,
Хәллерәкләр—атлы-иярле.

Шөлләп калды патша җәнаплары:
Чыкмагае уймак уеннан.
Тарих белә: хаклык, ирек даулап,
Кеше башы күпме кыелган.

Крепостьлар, төрмә, каторгалар
Корбан санын, бәлки, беләдер.
... Адәм балалары киләчәккә
Сөякләргә басып киләдер.

Ул сөякләр кайсы халыкныкы
Һәм никадәр?.. Кемнәр санаган?
Гаделсезлек һәрбер адымда да,
Кабатлана Тарих—яңадан.

Калалардан бунтлар сирәк чыга,
Шикләнергә кирәк саладан.
Фетнә арты фетнә туып тора,
Төшкән кебек коймак табадан.

Ә Русия—тоташ сала иле,
Шәһәрләре кайчан уяныр?
Бер уянса, бүтән мәрткә китмәс,
Башаяктан канга буялыр.

* * *

—Әйдә, малкай, алга карап атла,
Зәй буйлары, инде хушыгыз!
Сандугачлар, таңда сайраганда,
Исемнәрне җырга кушыгыз...

Рәхимколдан килгән затлы нәсел
Китеп бара синнән, Тайсуган.
Сәлим, Исмәгыйльне[1] әйткән дә юк,
Атларына кадәр ярсыган.

Ярсымыйча, алда, ымсындырып,
Яңа җирләр көтә аларны.
Күрерләрме кабат бу оланнар
Зәй буенда үскән талларны?

Бу китү соң әллә мәңгелеккә
Хушлашумы туган як белән?
Алда әле күпме очрашулар,
Танышулар җиде ят белән.

—Әйдә, малкай, барыр юллар ерак,
Йөрәк янса, дөнья тар сыман.
Кайтмасалар, син онытa күрмә
Рәми оныкларын, Тайсуган!

Зәй буенда үскән карт тирәкләр
Фатихасын бирде аларга.
«Чабаталы морза»лары китә,
Ямансудыр хәтта талларга...

Бәндәләрне йөртә үз ризыгы,
Тәкъдирдә ни язган—риза бул.
«Чабаталы» атын йөртсәң дә бит,
Морза икәнсең син,—морза бул!

Халык әйтә: «Тәвәккәл таш яра»,
Тәвәккәлгә диңгез тубыктан.
Исмәгыйль һәм Сәлим Рәмиевләр
Ырынбурга нигә юл тоткан?

Бу якларны үзләштерү кирәк,
Патша шундый указ чыгара.
Иксез-чиксез дала-сулар көтә,
Хәзинәләр көтә Уралда.

Ырынбур—ул төбәк башкаласы,—
Ел үсәсен үсә бер айда.
Мәчетләрдә татар дога кыла,
Рәхмәтләрен әйтеп Ходайга.

Ә базарда Шәрекъ белән Гареп
Сәүдә итә, анда бар да бар.
Кемдер алдый, кемдер алданадыр,
Шуның өчен дә бит ул—базар!

Ә Садыйк бай үткер күз карашын,
Иҗтиһадын төби Уралга.
Борынгы тау хәзинәсен ача,
Башланмаган яңа чор алда.

[1] Сәлим, Исмәгыйль – Рәхимколның уллары. Исмәгыйль – Закир Рәмиевнең әтисе Мөхәммәтсадыйкның бабасы.

**Бәхет бит ул кемгә битен куя,**
**Ә кемгәдер куя сыртын да.**
**Алтын шавы...**
**Юлык1[2] качмас,**
**Затлы өенә дә,**
**Ходай кушып, булмас чуртым да!**

**Сабын заводында сабын кайнар,**
**Эшкәртелер тире-күне дә...**
**Күсәй[2] эргәсендә алтын базы**
**Ничек тынгы бирсен күңелгә?**

**Ничек тынгы бирсен—алтын бит ул,**
**Төшләренә кемнең кермәгән!**
**Зинданнарга илтеп керткән дә ул,**
**Йолкып алган үзе төрмәдән.**

**Садыйк байга йоккан алтын чире**
**Гомер буе аннан китмәде.**
**Фәрештәләр юлын күрсәткәндер,**
**Хәләл булсын җыйган икмәге.**

**Ике улы: Шакир белән Закир—**
**Икесе дә тырыш, уңганнар.**
**Иң мөһиме, берсе өчен берсе**
**Җан бирергә әзер туганнар.**

**Кайдан килгән Рәми нәселенә**
**Үҗәтлек һәм шундый сабырлык?**
**Сабырлыктан татар кешесенә,**
**Һич шикләнми һәйкәл салырлык.**

**Ул салынса, таштан каты булыр,**
**Чыдамлырак булыр тимердән.**
**Тырышканнар—ташка кадак каккан,**
**Ә ялкаулар—терсәк кимергән.**

**Язмыш сиңа бер елмайсын өчен,**
**Көч куярга кирәк мең тапкыр.**
**Мал-маяны туплау җиңел түгел,**
**Туздыруы гына ансаттыр.**

**Фәкыйрьләр дә кичә, байлары да,**
**Бу дөньяда кем соң мәңгелек?**
**Шуңа күрә исән чакларыңда**
**Яшәү кирәк мәгънә, мән белеп.**

**Атасыннан калган бер тиенне**
**Ике итә Садыйк уллары.**
**Тыныч ятсын ата: улларының**
**Зиһене саф, ныклы куллары.**

**Бисмилласын укып, Садыйк Рәми**
**(Фәрештәләр әллә булышкан),**
**Тәвәккәлләп, алтын базы ала**
**Бөлгенлеккә төшкән урыстан.**

**Алтын чире кемне шаштырмаган—**
**Чокыр-чакыр Урал битләре.**
**Үзеңнеке авыз ачып торса,**
**Бик тиз хуҗа була читләре.**

**Тимашевлар алтын базы тоткан,**
**Дашковлар да кимен куймаган.**
**Урал алтыннары кыйнаган да,**
**Бәхет елмайганда—сыйлаган.**

* * *

**Җегәр китсә, малын улларына**
**Бүлеп бирер һәм дә үкенмәс**
**Һәркемдә дә тик бер генә гомер,**
**Ә бер гомер ике үтелмәс.**

**Шул гомерең үкенмәслек булсын,**
**Телмәсен һич әрнү камчысы.**
**Куанычлар чәчәк атып торсын,**
**Читләп узсын тормыш ачысы.**

* * *

**Эш дигәндә ялны онытталар,**
**Шакир, Закир бер дә тик тормый.**
**Ялкауларны бәхет үги итә,**
**Койрыгын да хәтта тоттырмый.**

**Бәхет бит ул кылдан нечкә нәрсә,**
**Солы саламыдай шома да.**
**Күпләр аны белми, сизми кала,**
**Кадрен белми кала шуңа да.**

* * *

**Җыерчыклы Урал тау битендә**
**Алтын эзләүчеләр бихисап.**
**Тауны сырып алган кәсепченең**
**Һәрберсендә бардыр бер исәп...**

**Ләкин алтын йөзен сирәк ача,**
**Һәркемгә дә бәхет елмаймый.**
**Рәмиевләр белә: язмыш кырыс,**
**Үзе егылганнар еламый.**

**Алтын кыйммәт, ул бит юлда ятмый,**
**Табар өчен шушы алтынны,**
**Кирәк әүвәл нык иҗтиһад итү,**
**Юлдаш итеп зирәк акылны.**

---

[1] Юлык—Мөхәммәтсадыйк 1862 елда килеп урнашкан авыл.

[2] Күсәй—хәзерге Башкортостанның, Баймак районындагы авыл.

Ниятләрен Ходай уң кылырмы,
Юл догасы инде укылды.
Шакир белән Закир ниятләрдә
Бер-берсенең булды уң кулы.

Фәрештәләр: «Амин!»—дигәннәрдер
Алар юлга чыккан чагында:
Алтыннарын Урал ачып салды
Шушы борадәрләр алдында.

Аталары, рәхмәт, улларына
Мал-мөлкәтне шактый калдырды.
Улларына язмыш гел елмайды,
Яуды күктән бәхет яңгыры.

Иш янына кушы килә торды,
Татар өчен нинди горурлык!—
Рәмиләрнең алтыннары хәтта
Падишаһка көндәш булырлык.

* * *

Бай булуы рәхәт, миллионнар
Кереп тора икән кесәңә,
Тик кемлегең алтын белән түгел,
Кылган эшең белән үлчәнә.

Шакир белән Закир борадәрнең
Камаштыра күзне алтыны.
Үзең бай бул—бусы ярты бәхет,
Бәхетле итү лязем халкыңны!

Өстәвенә Закир Рәми—шагыйрь,
Тәхәллүсе—Дәрдемәнд, ил белә.
Шигырьләрен бары уку кирәк,
Шагыйрь җаны—җырда, шигырьдә.

Ил корабын җилләр сөргәндә дә,*
Шагыйрь җаны тоташ сынауда.
Язмышыңа шөкер итү кирәк,
Ни фәтва сыктау, елауда?!

* * *

Ырынбурда зыялылар байтак,
Тәрәккыят өчен ни кирәк?
Гәҗит кирәк! Саллы журнал кирәк!—
Шушы тавыш чыга көчлерәк.

Язмыш һаман кыйнап торгангамы,
Кыйтгаларга татар сибелгән.
Кая барса, шунда мәчет салган,
Һәм чыкмаган Коръән сүзеннән.

Татар—көчле, татар—укымышлы,
Хәреф танымаган—сирәктер.
Бишегеннән сикереп төшсә бала,
Татар аңа гыйлем өйрәтер.

Бөтен халык алгарышны тели,
Артта калмас татар заманнан.
Татар—хәтәр!
Укыганы исә
Икеләтә хәтәр наданнан!

Шуңа күрә гәҗит, журнал өчен
Бер тиен дә таммый казнадан.
Гыйлем диеп бик нык адарынма,
Сикеренмә, татар, кал надан!

Татар—үҗәт,
Нинди кыенда да
Югалмаган, тапкан бер чара.
Падишаһтан ярдәм булмый икән,
Татарның үз бае коткара.

* * *

—Чыгарыгыз гәҗит.
Журнал кирәк—
Якты булсын барыр юлыбыз.
Акча бездән,—диләр Рәмиевләр,—
Милләт өчен кабул кылыгыз!

Риза казый, Фатих Кәримиләр
Сөендерсен әле халыкны!..
Ырынбурда менә шушы чорда
«Вакыт» белән «Шура» калыкты.

Һәм яндылар якты йолдыз булып,
Кадерледән алар кадерле.
Әй, син татар, үз бәхетең өчен
Үзең көрәшергә әзерме?

Тартылдылар яңа матбагага,
Ничек читтә калсын талантлар?!
Шәриф Камал килде,
Осталыкта
Галимҗан*ны кемнәр кабатлар?

* Дәрдемәндиең шигыренә ишарә
* Галимҗан—Галимҗан Ибраһимов

Рәмиевләр кебек юмарт затлар
Татар дөньясында бар бит ул.
Хөсәенев[1]ләргә мең мәрхабә,
Апанаев[2]—кем соң?—Татар бит ул!

Рәмиевләр байлар.
Татарларда
Андый байлар әллә бик күпме?
Ә Закиры?
Күрмәү мөмкин түгел
Шигырь күгендәге бөркетне.

Иҗатка юл—күктән иңгән бәхет,
Күктән иңгән татлы җәзадыр.
Дәрдемәнд бит язмый тора алмый,
Шигырьләрне шуңа язадыр.

Басыламы, әллә басылмыймы—
Бай шагыйрьнең анда эше юк.
Шигырь язса, Закир чиксез мәмнүн,
Бәхетлерәк аннан кеше юк.

• • •

Байларны да чирләр саклап тора,
Хәтәр сырхау Шакир Рәмидә.
Нервлары ничек кинәт тузган,
Ул зарланмый иде әлегә.

Тикшертергә Мәскәү табибыннан,
Профессор әйдә карасын.
Ырынбурдан менә шул Мәскәүгә
Ничек итеп тизрәк барасың?

Мәскәү ерак. Аңа Ырынбурдан
Илтеп җиткерәлми парахут.
Әле бит март, утыр да кит, Шакир,
Поездларга,—Мәскәү каратып.

Күңелләре, тизрәк сихәт алып,
Өйгә кайтырга дип ашкына.
Аһ үкенеч!..
Барып җитәлмичә,
Керде Шакир поезд астына...

Сәгать ике.
Мартның унбише бу—
Шакир байның сулыш өзелә.
Гомер тора табу, югалтудан,
Кайгы авыр, ләкин түзелә.

Уникенче елның март аенда
Шакир вафат, калды энесе.
Химаяче Закир—абруйлы зат,
Шагыйрь Дәрдемәнд—милләт күзгесе.

• • •

Ил корабын җилләр сөрәдерме,
Сикәлтәле әллә сәясәт?
Тыныч кына яшәп яткан җирдән
Россиядә купты гарасат.

Юк-юк, илгә җилләр кагылмыйдыр,
Җилнең кемдә нинди эше бар.
Тыныч кына яши беләме соң,
Тыныч яши белми кешеләр.

Бәйнәлмиләл ирек таләп итә,
Кан коймаган кайсы инкыйлап?
Ата улны, ана кызны белми,
Тәм табалар халык, ил кыйнап.

Әле аклар, әле кызыллары
Авыл саен ничә ураган,
Икесе дә юкны таптыра да,
Кырып-себереп ала бурадан.

Хәл үзгәрде: власть алмашынды,
Ярлыларга күчте хакимлек
Җиң сызганып, илгә ачлык килде,
Ачлык белән килде ятимлек.

Кичәге бай бүген урта хәлле,
Урта хәлле байый, йә бөлә.
Байның хәлен ярлы беләмени,
Ярлы хәлен әллә бай белә?

Кеше хәлен кеше кайдан белсен,
Үз хәлен дә юньләп аңламый.
Бушбугазлар оҗмах вәгъдә итә,
Әнә ничек шома алдалый.

Ораторлар оста бер-берсеннән,
Гавам гына түзсен,
Илгә—солых кирәк:
ВКП (б), Совет яшәсен!

[1] Хөсәенов, [2]Апанаевлар—татарның меценатлык белән дан казанган байлары.

Кайберәүләр китте горбәтлеккә,
Мөһаҗирлек әллә кызыкмы?
Илне ташлау—җан бирүдән авыр,
Бу бит кичү соңгы сызыкны.

Бу бит инде—бәхилләшеп китү,
Кире кайтыр юллар ябылган...
—Битем куям, җилкәй, ешрак ис
Туып үскән илләр ягыннан!

Алып килче Идел, Чулманнарның,
Җаек, Сакмар шавын безгә дә...
Кыш артыннан чәчәкле яз килә,
Яздан ерак калмый көзгә дә.

Максудиләр, Рәшит Ибраһимов,
Гаяз* җәнаплары ни күрә?
Мөһаҗирнең җанын сагыш ашый,
Сирәк хатлар ниләр китерә...

Бер-бер артлы алышына еллар,
Гомер уза, уза сагынып.
Сагынып һәм калган гомереңдә
Читләр кыйммәтенә табынып...

Әдәрдемәнд илне ташламады.
Сөт китсә дә, калды Ватаны,[2]
—Туган илем, син бит Атам-Анам,
Ничек ташлыйм Анам-Атамны!?

Яңа заман,
Коръән Кәрим үги,
Ленин—Алла, бүтән Алла юк.
Ленинизм—якты киләчәк ул,
Аннан башка бәхет алда юк.

Советларда көч-дәрт ташып тора:
Көн тудисә—яңа бер фәрман.
Вәзгыятькә җайлашуы авыр,
Ә Дәрдемәнднең кими көч-дәрман.

Аңа хәзер егерме яшь түгел,
Һәм утыз да түгел—яшь бара.
Кесәсендә җилләр сөрән сала,
Чигәсендә чәчләр чалара.

Өстәвенә илгә ачлык килде,
Хәерчеләр белән ил тулган.
Хәлсезләнеп, кичтән яткан кеше
Уяналмый иртән йокыдан.

Тифы дулый уңны-сулны белми,
Кабер арты кабер зиратта.
Шобаганы Әҗәл сала тора,
Йә кемнәр соң, кемнәр чиратта?!

...Үкенгәнме шагыйрь алтыннарын
Кырып-себереп барсын биргәнгә?
Кемнәргәдер аның бише дә күп,
Аз тоела мең дә бирәнгә.

Ач утырмый алтыннары барлар.
Акчаң булса ризык бетмәгән.
Бик күпләрнең үз хәле дә хәл бит,
Ярдәм көтеп булмый читләрдән.

Салкын кышны исән узу кирәк,
Үлән чыгар, җитсен яз гына.
Дәрдемәнд тә шигырь язар әле,
Икмәк булса иде аз гына!

* * *

Паровозлар сөйри вагоннарны,
Төтеннәре күккә тарала.
И Ходаем, йөрер юлыбызда
Бәхетсезлекләрдән арала!

Дәрдемәнднең хәзер вакыты күп,
Эшкә барыр иде—юк эше.
Әле менә, кызы хәлен белеп,
Орскидан кайтып килеше.

Совет вагоннары җил иркендә,
Суык җиле үтә бәгырьгә.
Шулай булгач ничек инде салкын
Тими калсын бөек шагыйрьгә?!

Чир-сырхауга нәрсә дан-дәрәҗә,
Ул карамый байга, ярлыга.
Үзәкләргә үтеп җил сызгыра,
Ядрә булып ява кар гына.

Тәкъдиреме,
Язмыш каршысында
Бер бәндә дә түгел тимердән.
Закир Рәми поезд вагонында
Терелмәслек салкын тигергән.

Тыныч кына өйдә ятар иде,
Сагынса да түзмәс идеме?—
Ырынбурда тифтан дөнья куйды
Газиз кызы Өммегөлсеме.

[1] Һади һәм Садрый Максуди, Рәшит Ибраһимов, Гаяз Исхакый—горбәтлеккә киткән татар зыялылары.

[2] Дәрдемәнд шигыреннән.

Кызын җирләп кайтып килә иде,
Ник бармасын—ата хакы бит.
Ә тормышның кануннары каттый,
Язылганнан шактый каты бит.

Ул да хәзер меңнәр кебек фәкыйрь,
Янчыгында җилләр туй итә.
Ачлык һәм тиф игезәкләр икән,
Бергәләшеп җирне селкетә.

Аямады күкләр үз бәндәсен,
Бакыйлыкка Закир юл алды...
Шагыйрь вафат, язылмаган шигырь,
Җырланмаган күпме җыр калды.

Орскида зират кылында ул
Гали затның гали җәсәде.
Ә кешелек гомер бакыена
Хатирәләр белән яшәде.

Хәтер белән кем дә шаярмасын,
Хәтер саклый яки оныта.
Хәтер саклый бары узаманны—
Халкы өчен кемнәр ут йота.

Ул оныта ханнар, патшаларны,
Гасырларга күчә Кол Гали.
Чын бәһане бары Тарих бирә:
Кемнәр гади булган, кем—гали!

Вакыт или, Вакыт гел җилгәрә,
Туктый алмый Вакыт, ашыга.
Ашыкмас та иде, колач җәеп,
Яңа заман килә каршыга...
Егерменче гасыр тәмам.
Яңасының
Капкалары киереп ачыла.

Җиз иләктән үтмәгәннәр керми,
Төшеп кала күзгә күренеп.
Ә Дәрдемәнд атлый бүгенгегә,
Шигырь ефәгенә төренеп.

Дөнья тора тоташ үзгәрештән:
Айкалыр да, дөнья чайкалыр,
Тик хакыйкать өстен барысыннан:
«Ватан китәр», китәр, «сөт калыр».

Хакыйкатьне күзгә бәрү кирәк,
Мөмкин түгел аннан качарга:
Замандашым булып аяк басты
Шагыйрь Дәрдемәнд яңа гасырга.

Гасырларны кичеп бара кораб,
Төшеп калмас өчен корабтан,
Хак Тәгалә адәм балаларын
Иҗтиһадлы итеп яраткан...

Закир алтыннары җилгә очты,
Кичте вакыт, узды гомерләр.
Вакыт узган саен кыйммәтләнә
Закир Рәми язган шигырьләр.
Дәрдемәнд язган даһи шигырьләр...

*2001—2006*

**Шагыйрь Нур Әхмәдиевкә бу айда 60 яшь тула. Укучыларыбыз исеменнән аны ихлас котлыйбыз, сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез.**

**Редакция.**



Галимҗан
Гыйльманов

# СОҢГЫ СУГЫШ

ПОВЕСТЬ

*Ходай Тәгалә әйтте: "Мин бер халыкның да хәлен үзгәртмәм, әгәр ул үзенең хәлен үзе үзгәртмәсә,"—диде.*

Хәдис

## Пролог

Зәкәрия карт үләргә җыенды. Шомландырса да, үлем куркытмый аны. Ул озын, бәхетле гомер яшәде. Бәхетне ничек аңлыйсың бит... Аны тигез гаиләдә туу, үсү дип тә, яшьлек бүләк иткән матур мәхәббәт дип тә, бөтен гаилә исән балалар исәнлеге дип тә, хәтәр сугыш сынавы үтеп, җиңү яулау исә шул җиңүләрдән соң туган җиренә тугры хезмәт итү дип тә аңларга мөмкин. Зәкәрия күпне күрде, күпне кичерде, кешедән калмады—партиясенә дә керде, соңгы гомерендә мәчет карты булып та йөрде. Иң мөһиме, хәләле Өммегөлсем белән ике ул, бер кыз үстереп, ил каршында да, табигать каршында да төп бурычын үтәде. Дөрес анысы, ата-баба гадәтенчә, башка чыгарып, улларын үз янында, җирдә калдыра алмады. Авылда хәзер эш юк, колхоз таралды, тирә-як басуларны шәһәр байларының икешәр, өчәр катлы йортлары тутырды. Шуңа да малайлар якындагы Яр-Чынлы шәһәренә китеп урнаштылар, кызлары Наилә исә аталарын, аналарын тәрбия кылып калды. Анысының үз язмышы, үз гыйбрәте—байлар йортында җыештыручы булып йөргәндә, кияүгә чыкмыйча гына бала тапты. Кай арада үсеп җиткән диген—оныгы Камиләгә дә унҗиде яшь инде. Ул да, мәктәпне тәмамлауга, шәһәргә китәргә чамалап тора.

Зәкәрия карт үләргә җыенды. Карчыгы китеп барганга да ярты ел узган икән. Әле дә хәтерендә: Өммегөлсемнән соң яшәүнең кызыгы беткән кебек булды. Кинәт кенә күктә кояш сүнде, күңелдә дәрт бетте, тәннән дәрман китте... Янында кызы Наилә белән оныгы булмаса, нишләр иде икән ул;

---

Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ (1957)—*прозаик, тәнкыйтьче, шагыйрь; «Тозлы яңгыр», «Көмеш тарак», «Албастылар» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

бу кадәр озак яшәмәс тә иде, мөгаен... Зәкәрия аларны үзе дә бик ярата. Шәһәргә китеп, бизнес дигән жиргә кереп, елга бер-ике мәртәбә генә кайтып киткәләгән улларына караганда да ныграк ярата. Әллә шул ярату үлемгә бирми тора микән аны? Мәхәббәт үлемгә караганда зуррак бит...

Зәкәрия карт үләргә жыенды. Аның якын кордашлары күптән Аллаһ катына китеп бетте инде. Элек урам тутырып, орден-медальләрен зыңгылдатып, мәктәпкә очрашуга баралар иде. Авылның берләнбер ветераны ул хәзер. Соңгы елларда Жиңү көнендә кәнсәләр алдында торган таш һәйкәл янына ул япа-ялгызы чыга, чүп үләне сарган сукмакта таптанып тора-тора да тын гына кайтып китә...

Нишләп ялгызы булсын?! Бу вакытта аны бала-чагалар сырып ала. Янәшәсендә—каяндыр, кояшта унган, кыршылып беткән пилотка табып кигән Гадел булыр. Бу күрше малае белә-белгәннән бирле аның тирәсендә бөтерелә. Зәкәрия карт аның анасын да, атасын да инде хәтерләп, күзаллап бетерә алмый. Нииндиер үтә дә акыллы, иманлы малай ул. Олыларча акыллы, житди. Көлми дә, хәтта елмаймый да, ахры. Әллә Ходай Тәгалә ишарәсе булып яшәүче бер изге затмы ул? Гаделлек, изгелек булып яшәүче... Исеме дә "Гадел" бит аның...

Зәкәрия карт үләргә жыенды. Юк, ул үлемнән курыкмый. Үткән сугышта күп мәртәбәләр әжәл белән күзгә-күз очрашкан өчен генә түгел. Ул үзенен бик карт көнеле белән тоя, хәтта аңлый: һәр туу—хакыйкатьне раслау ул, һәр үлем дә шулай ук хакыйкатьне раслау гына. Яшәү—үлемгә әзерләнү генә, башка берни дә түгел. Аннары... үлем—котылгысыз бит. Шуна күрә аннан куркырга һич ярамый. Курку үзе канны киптерә, гомерне өзә... Нигә куркырга? Үлү дә—яшәүнең бер мизгеле бит!

Үлем көтеп яткан Зәкәрия картның бу дөньяга үпкәсе юк. Ничек яшәлгән—шулай яшәлгән. Кыен чаклар булган икән—барысына да үзе сәбәпче, әйбәт чаклар булган икән—аның рәхәтен дә үзе күрә. Үпкәләргә ярамый, кем әйтмешли, үлгәч, үпкәле кешенең жаны кучеп китә алмый жәфалана, ди...

Зәкәрия картның бу дөньяга үпкәсе юк. Ләкин аның бу дөнья өчен бирәсе йөрәге, жаны бар...

Зәкәрия карт үләргә жыенды. Баштарак акрын-акрын гына йөрештерсә дә, хәзер бөтенләй түшәк иясенә әверелде. Көненә берәр мәртәбә ишек катына барып килә дә дога китаплары белән юанып тик ята. Ара-тирә генә, ишек башына кыстырылган кайракка күзе төшеп: "Быел печән дә әзерләнми калды, яланнарым көтә-көтә зар-интизар булып беткәннәрдер инде,"—дип уфтанып куя.

Кайчакта күршедәге карт-карчык кереп чыга, яисә мәчет хәзрәтләре хәл белергә килеп житә... Барысы да бер үк сорауны бирәләр, бер үк сүзне сөйлиләр... Аларның һәр сүзе Зәкәрия картка: "Кайчан китәсең инде, кайчан үләсең?" дигән кебек ишетелә, шуна да ул кеше керүен бик өнәп бетерми. Кемдер әйткән бит: "Мәңгелек юлы ялгызлыкны ярата,"—дигән.

Наилә әйбәт. Камилә дә "дәү әтием" дип өзелеп-өзгәләнеп тора. Ләкин ул өйдә сирәк була. Яшьлек бит, көнелнең иләсләнгән чагы, аның үз юлы, үз язмышы, дигәндәй...

Зәкәрия үләргә жыенды. Ул, мөгаен, шулай тыныч кына, үз жае белән, мәңгелек юлына китеп тә барган булыр иде. Күптән түгел генә аның көнеленә һәм тормышына яңа гамь, борчу килеп иялəште. Әллә шул борчу аңа бу якты дөньядан кубарылып китәргә ирек бирми торамы?

Соңгы вакытларда күршедәге ялан-басуларда барлыкка килгән "Поле чудес" яшьләре Акбүре авылының тынычлыгын алдылар. Әле берсен кыйнап китәләр, әле икенчесенә ябышалар... Түбән очтагы ике кызны бозганнар, дигән хәбәрләр дә чыкты.

Зәкәрия картны үлем шикләндерми. Ул инде үләргә әзерләнеп бетте. Кызы Наилә, оныгы Камилә өчен, күршедәге Гадел өчен, тагын бик күпләр өчен өтәләнә ул...

Милиция дә чакыртып карадылар. Якын-тирәдәге ун авылга берүзе күз-колак булып йөрүче участковый: "Нишләп тә булмый, начальник балалары!"—дип, жилкә сикертүдән узмады. Сиксән йорттан торган, тузып-таралып бетә язган Акбүре авылы балаларының язмышы, көне-төне исереп, азынып-тузынып йөрүче шәһәр малайлары кулында калган бер мәлдә, Зәкәрия карт юлга жыенып бетте. Ләкин күнеле нидер сизенеп, һаман әле торып, кузгалып китәргә кыймыйча, үткәннәрен уйлап, тормышының ачысын да, татлысын да хәтереннән уздырып, жылы, йомшак түшәгендә ята бирде.

## Хәтәр

Зәкәрия сугышның авызында булды. Разведчик-диверсант иде ул. Ярты сугышны дошман тылында йөреп үткәрде. Күп мәртәбәләр үлем белән күзгә-күз очрашты, әмма ниндидер тылсым аны бәла-казалардан саклап килде.

Кырык өченче елда аңа Герой бирә яздылар. Ике айлык "сәяхәт"тән кайтып керүләре булды, берничә разведчикны алгы сызыкка—һөҗүм оештырырга килеп чыккан Жуков янына чакыртып алдылар. Жуковның үзен туры китерә алмаса да, фронт штабында Зәкәрияне Герой исеменә тәкъдим иттеләр. Хәтта, сорашып, әллә күпме документ тутырдылар. Ләкин барыбер бирмәделәр. Сугышчан Кызыл Байрак Ордены килде. Дөрес анысы, аның белән рейдта йөргән себер урысы Иван Соколик исә Алтын Йолдызын тагып йөри башлагач, кыенсынып, хәтта кимсенеп куйгалый иде Зәкәрия. Соколик исә дустын тынычландырмакчы була: "Син, Захар, миңа караганда геройрак, просто татарларга хәзер бирмиләр икән, шул хакта яшерен күрсәтмә килгән..."—ди.

Соколик аңа тагын бер серне ачты. Ул элгәрерәк тә: "Диверсантлар кеше күзенә күренергә тиеш түгел. Бер адәм затына гына күренсә дә, алар инде диверсанттан разведчикка әверелә,"—ди торган иде. Кайсыдыр рейдтан соң ул бик борчылып йөрде. Зәкәрия сораша башлагач, барысын сөйләп бирде.

"Беләсеңме,—диде ул, утлы күзләрен Зәкәриянең җанына кадәр батырып,—без ничә кешенең җанын кыйдык бу юлы?"

Зәкәриядә исәп-хисап төгәл иде. Ничә фашист дөмеккәнлеге, ничә эшелон сафтан чыкканлыгы, күпме күпер жимерелгәнлеге хакында ул шундук әйтеп бирде.

"Ә-ә, юк шул,—диде Иван... бармагын өскә күтәреп,—корбаннар моның белән генә бетми әле. Безне күреп, белеп, танып калган, хәтта безне каршы алган кешеләрнең дә юк ителгәнен беләсеңме соң син?"

Зәкәрия аңламыйчарак торда. "Ничек инде? Безне кундырып чыгарган Степан дәдәй белән Марфа апаны да, озатып җибәреп, каршы алган сержант Самойловны да, башкаларны да үзебезнекеләр үк юк иткәнме?"

"Әйе. Законы шундый."

Зәкәрия нишләргә дә белмәде. Ары бәрелде, бире сугылды, ниһаять, үзен-үзе күрәлмәс хәлгә килде. Сугышның никадәр хәтәр икәнен белә иде ул. Әмма бу чаклы канэчкеч һәм кешелексез булыр дип башына да китерә алмаган иде.

Зәкәриянең фронт капчыгында һәрвакыт көмеш көпшәле трофей револьвер йөрде. Иван Соколик белән сөйләшкәннән соң, шул револьверын алып, ничә мәртәбәләр генә, аның салкын көпшәсе белән чигәсен капшап карамагандыр... Барыбер курокка баса алмады. Авызын ыржайтып торган

сугышка тагын бер корбан бүләк итәргә теләмәде ул. Хәзер дә шул револьвер, киндер чүпрәккә төрелгән килеш, чормадагы яшерен шүрлектә ята...

Күрше малае килеп кергәндә Зәкәрия картның күз карашларыннан сугыш шәүләсе китеп тә өлгермәгән иде әле.

—Бабакай, беләсеңме, бүген сугыш булачак. Әнә, жыелалар инде. Авыл малайлары "Поле чудес" бандасы белән бәрелешәчәк... Вот кызык, ә?

Зәкәрия карт берни дә аңламады. Әмма авылның ниндидер бәлагә, хәтәргә юлыкканын күңеленең иң нечкә, нәзберек кыллары белән шундук сизенеп алды.

Терсәкләренә таянып, торып утырмакчы булды. Хәле житмәде. Тыны кысылып, тау кебек ястык өстенә шуып төште. Гадел килеп булыша башлагач, тагын бер мәртәбә көчәнеп карады, барыбер сөялеп утырудан ары уза алмады.

—Нинди сугыш? Кайда? Кем белән?

Гадел һәр сүзгә басым ясап, һич иренмичә кабат сөйләп бирде.

—Һай-ай-ай... Нинди нәмәрсә бу? Нинди кыямәт? Туктатырга кирәк моны! Кая, бир әле мина чөйдәге сырманы, тизрәк чыгып, акылларына күндерик үзләрен!.. Яле, бир, әнә, әнә... Шунсын!

Зәкәрия картның сырмасын китергәндә Гадел ялваргандай әйтеп куйды.

—Сина ярамый, бабакай, син авырыйсың... Ярамый...

—Ярамаса ярамый, ярамыйга карамый, ди идек без бәләкәй чакларда. Чыкмый булмый, балам. Башкалар да чыгарга тиеш. Чик куелырга тиеш бу хәтәргә...

—Бабакай, "Поле чудес"ларның кораллары да бар, ди. Атып үтерсәләр?.. Алар уйлап тормый, ата да куя... Бер көнне Илдарларның мунча бурасына атып уйнаганнар. Бозауларының аягына тигән... Суярга туры килгән...

Зәкәрия карт тагын да ныграк сагайды, хәтта, башын артка ташлап, берара тынсыз калып торды. Аннары кискен генә башын калкытты:

—Алайса... бигрәк тә чыгарга кирәк!..

Ләкин ул урамга чыга алмады. Бүген тән көче, ана ияреп жан егәрлеге дә, үч иткәндәй, әллә кая гына китеп югалган иде.

Кичке якта Гадел тагын ишек катында пәйда булды. Бу юлы ул шатлыгын кая куярга белмичә, авызын колагына кадәр ерып килеп керде.

—Бабакай, безнекеләр жинде! Тегеләр чак качып котылдылар. Мылтыклары да бар иде. Барыбер курыктылар...

Зәкәрия карт Гадел алып килгән шатлыклы хәбәргә куанмады. Хәтта жавап та бирмәде. Бөтен жан-йөрәге белән ыңгырашып кына куйды. Чөнки ул белә иде: жиңелгән явызлык тагын да хәтәррәк. Чын сугыш, хәтәр сугыш әле алда. Ул башлана гына...

Сугыш... Һаман сугыш... Кайчан бетә инде бу сугышлар... Мылтыклары да бар диме? Юк, бу сугыш тегесенә караганда күп мәртәбә хәтәррәк. Бу сугышны синнән соң яшәргә тиешле яңа буын үзе башлый. Димәк, киләчәк белән сугышырга туры киләчәк... Мондый сугышның мәгънәсе юк, мәгънәсе генә түгел, чиге юк, фронты юк. Әмма аның кануны шул ук: явызлык белән акыл көрәшен бары тик рух кына хәл итә ала. Әйе, явызлыкны акыл гына каплап куя алмый. Әмма сугышта рух жиңә. Шуңа күрә дә сугышта рух—язмышка тиң. Ходай Тәгалә дисезме? Рух ул—Ходай Тәгаләнең ихтыяры, әмма Үзе түгел! Чөнки Ходай Тәгалә жәза бирми, бары тик искәртә генә, кисәтә, куркыта гына...

Зәкәрия карт тыштан сөтле чиләк күтәреп килеп кергән Наиләне үз янына чакырып алды.

—Кызым, якынрак кил әле... Камилә кайда?

—Кайда булсын, урамдадыр... Үз эшләре беләндер... Айрат янындадыр...
—Нинди Айрат? Кем ул?
—Кем булсын, классташы. Икенче ел инде дус булып йөриләр. Әйбәт егет.
Сүзгә шунда мыштым гына утырган Гадел кушылды:
—Беләсеңме, бабакай, Айрат абый булмаса, безнекеләр җиңә дә алмас иде. Ул берүзе өч малайны чүмәләгә өеп куйды...
Зәкәрия карт сүзен бетермәгән икән әле:
—Камиләгә әйт, еракка чыгып йөрмәсен. Айрат та сак йөрсен. Хәтәр көннәр килә, сак булсыннар... Саклангнны гына саклармын, дигән бит...
—Ярый, әткәй, әйтермен. Соңгы вакытта бигрәк соңга калып кайта әле ул. Үзем дә нык кына тиргәрмен дип тора идем, син дә әйткәч, үзегенә үткәзеп сөйләшермен. Бер-бер хәл кылып куймасыннар тагы. Әллә нинди хәтәр хәлләр башланды бит авылда. Тиле чаклары, һич кенә дә алларын-артларын карап йөри белмиләр...
Зәкәрия картның сизгер йөрәге ялгышмаган булып чыкты. Ике-өч көн яра-җәрәхәтләрен ялап, йөрәкләрен ярсытып ятканнан соң, “Поле чудес”ның бандит егетләре кабат Акбүре авылына ябырылдылар. Иң элек авыл читендәге ташландык өй янды. Аннары авыл кешеләренең абзар-куралары, мунча-келәтләре төтен булып күккә оча башлады. Ниһаять, беренче кан да коелды—сагалап торып, Айратны имгәткәнче кыйнадылар, кешелектән чыгарып ташладылар. Аның хәлсез, буынсыз тәнен машинага салып, шәһәр хастаханәсенә алып киттеләр.
Ул көнне Камилә елап-шешенеп кайтып керде. Керде дә тоташ бер тәүлек түшәгендә капланып ятты. Зәкәрия карт бу юлы оныгын юатмады, хәтта керфеген дә күтәреп карамады. Камиләнең үзе сүз башлаячагын белә иде ул.
Шулай булды да. Бераз тынычланган, күңел ярсуларын җиңеп, гамьле дөньяга кайткан кыз килеп эндәшкәндә карт оебрак ята иде.
—Дәү әтием, ә, дәү әтием!.. Син йокламыйсыңмы? Юкмы?
—Юк, йокламыйм.
—Күзләрең йомык бит...
—Күзләрем йомык булса да, күңелем ачык минем... Барыгызны да күреп, тоеп торам...
—Дәү әтием...
—Кызым... мин барысын да беләм. Сиңа бу араларда өйдә генә утырырга туры киләчәк...
—Нигә алай дисең, дәү әтием? Ә Айратның үчен кем кайтара? Без малайлар белән уйлаштык инде...
—Кызым, бүтән болай сөйләшмә, ташла бу ниятеңне. Үчнең күзләре юк. Ул—дөм-сукыр. Шуңа күрә, ялгыш кына кагылса да, ул шундук харап итәчәк.
—Нишләргә соң миңа? Безгә нишләргә? Ә, дәү әтием?—Кыз тынычланырга уйламады да. Аның әрнүле, рәнҗүле карашларында чарасызлык чаткылары белenә башлаган иде инде.
—Түзәргә. Сабыр итәргә. Көтәргә. Бу хәл барыбер бер бетәргә тиеш. Дөнья тынычланырга тиеш...
—Дәү әтием! Син кайсы гасырда яшисең? Нинди дөньяда яшисең? Нинди сабырлык хакында сөйлисең син?! Авылда йортлар яна, малайлар имгәнә, кызлар урамга чыгарга курка... Ә син, түзәргә кирәк, дисең... Болай тик утырсак, бу җирдә берни дә калмаячак. Нидер эшләргә кирәк, нидер кылырга кирәк, беләсеңме, болай ярамый!
Бу юлы да оныгының йөрәк ярсулары картның күңелен кузгата алмады.

—Милиция берни эшли алмаганны, без нишли алабыз соң, кызым? Мин нишли алам? Минә бит—кыймылдарга да хәлем юк...

—Авыл малайлары барыбер сугышачак, дәү әтием. Айратның булмавы гына тотып тора. Ул булмагач, көчебез нык кимеде хәзер...—Бераз тын калып, монсуланып торганнан соң Камилә тагын башын күтәрде. Аның күзләрендә ике бөртек яшь һәм... көчле рух чаткысы бар иде.—Менә син, дәү әтием, илебезне яклап сугышып йөргәнсең. Бер дә, түзәргә кирәк, дип уйламагансың. Бу шундый ук сугыш. Шундый ук хәтәр сугыш. Акбүре—безнең ил. Шуңа да без аны сакларга, якларга тиеш... Бу бит бик борынгы авыл, беренче татарлар шушыннан чыккан. Мәктәптә шулай сөйләделәр...

—Әйе, без бүре нәселеннән. Ләкин барыбер дөрес түгел бу. Сугышу дөрес түгел. Өйләр яндырып, мылтыктан атып, кеше имгәтеп йөрү дөрес түгел. Монда фронт юк бит. Фашистлар да юк. Кем өчен, нәрсә өчен соң бу сугыш? Менә син, ил өчен, авыл өчен, дисең... Кайда ул—син әйткән ил? Колхозны бетереп, басуларны ташландык хәлгә китергән ил—илме инде? Ярты халкы—читтә, калган яртысы эчеп ята. Мәктәбен бетерделәр, балалар бакчасын кибеткә әйләндерделәр... Нинди ил бу, нинди ватан? Нәрсә өчен сугышырга? Әйт, нәрсә өчен? Кем өчен?

—Нәрсә өчен булсын? Аңлашыла бит инде...

—Нәрсә аңлашыла?

—Нәрсә дип... Белмим... Мин белмим, дәү әтием!.. Бу сугышның нинди сугыш булуын белмим!..

Бу юлы авыл малайлары җиңелде. "Поле чудес"тан төшкән утызлап малай Акбүре авылында бер кич, бер төн буе "пәри туе" ясап йөрделәр. Күп өйләрнең капкалары каерылды, тәрәзәләре ватылды, качып котыла алмаган уңлап малай түшәк иясе булды, түбән очта торучы кызны, төне буе мәсхәрәләп, иртән генә кайтарып җибәргәннәр...

Аннары, болытларын куертып, хәтәр яңгыр килде.

Авыл өстен генә түгел, акбүреләләрнең күңел күген дә кара хәсрәт басты... Бала-чагасыннан башлап карт-корысына кадәр кайсы кая качып беттеләр—кем, капкасына аркылы такта кагып, шәһәргә улларына китеп барды, кем күрше авылларга—туган-тумачасына сыенды... Болай да сирәкләнеп калган көтү бөтенләй чыгудан туктады, ярым җимерек ферма абзарлары бикләп куелды, ике-өч скотник, эчкә ябылып, арык малларын карап, начар көмешкәдән мингерәүләнеп, көне-төне шунда яттылар...

Теге каһәрле төн белән генә чикләнмичә, Акбүре нәселеннән булган халыкны ээзрлекләүче әтрәк-әләмнәр һәр кичтә, авылга төшеп, әвәрә килеп йөри башладылар, меннәрчә ел буе табигый дөнья белән дә, илаһи дөнья белән дә тату яшәгән татар авылына бер атна эчендә хуҗа булып өлгерделәр.

Зәкәрия картта бүтән кайгы—үлем кайгысы иде. Ул бу көннәрдә әҗәл белән якалашып ятты. Әҗәл ана үткән сугыштагы фашист-мәлгуньнәр булып та, полицайлар, сатлык җаннар яисә үз солдатларын күрәлтә үлемгә җибәрүче генераллар булып та төшенә керә иде. Ә бер төшендә әҗәл ана авыл читендәге "Поле чудес" ягыннан үрмәләп килде. Елгыр, житез хәрәкәтләр белән, кача-поса килүче бу хәшәрәт аеруча нык гайрәтен чигәрде Зәкәриянең.

Кем генә килсә дә, барыбер картны чит-ят дөньяга китәргә күндерә алмады. Бер кулына печәнгә йөртә торган кайрагын, икенчесенә трофей револьверын тоткан килеш, ишек яңагына терсәген терәп, карышты да карышты ул...

Шулай да, бу дөньядан бөтенләй аерылып җитмәгән әле аны күңеле. Зиһене ачылыбрак киткән мәлләрдә шундук Наиләне яисә Камиләне

чакырып ала, сораша башлый, ишеткән борчулы хәлләрне эченнән кичереп, йөзен чытып куя, ләкин, ләм-мим сүз дәшмичә, башын артка ташлап, көннән-көн тоныклана барган күзләрен йома... Дөнья карты булса да, үлемгә, димәк хакыйкатькә бүтәннәргә караганда якынрак торса да, Зәкәрия карт әлегә нишләргә, ни кылырга икәнен белми. Шулай да, нindидер рухи ныклык һәм тәвәккәллек аның авыру тәнендә изаланып, үрсәләнеп яшәгән җанына көннән-көн күбрәк инә бара иде. Мондый көч-егәрлек һәм тәвәккәлек, хәтта үҗәтлек, моңа кадәр булса да, бары тик соңгы Ватан сугышында, немец илбасарларына каршы сугышып йөргәндә генә шулай аермачык һәм максатлы булгандыр.

Дөресен генә әйткәндә, Зәкәрия карт үткән сугыштан ераклашкан саен ана ныграк якыная бара иде...

## Көчләү

"Поле чудес" малайларының һөҗүме һаман ешайды, алай гына да түгел, көннән-көн миһербансызрак, хәтәррәк була барды. Яклаучысыз калган йортларны эзәрлекләү, талау белән генә чикләнмичә, алар ялгызак хатын-кызларга, хәтта үсмер балаларга ябыша башладылар.

Бердән-бер көнне Наилә ачы күз яшьләре белән елап, шешенеп кайтып керде. Башта берни дәшми-нитми, мунча ягарга чыгып китте, аннары нindидер үлән суы кайнатып эчте. Кичкә табан, бераз тынычлангач, барысын да сөйләп бирде. Ул өй караучы булып эшләгән йорттагы бай малае, тагын ике дустын да котыртып, аны көчләп, мәсхәрәләп җибәргән. Наилә бу хәшәрәтләр астына ятмаган да булыр иде, тегеләр аның колагына: "Югыйсә кызыңны чиратка салабыз,"—дип тукып торганнар.

Зәкәрия карт Наиләнең хәбәрен авыр кабул итте. Ләкин, барыбер, ике дөнья чигендә яшәгән килеш калды. Үлмәде дә, терелмәде дә. Ходайдан сабырлык, түземлек һәм шәфкатьлелек сорап, догаларын укып ятты. Кызына:

—Аллаһы Тәгалә барысын да күреп тора, кызым. Ничек тә түзәргә, түзәргә тырыш. Камилә хакына булса да түзәргә туры килә...

Наилә Ходай Тәгалә хакында ишетергә дә теләмәде:

—Күргәч, ни өчен бу хәтәр хәлләргә тыныч кына карап тора, алайса? Чынлап та бармы соң ул? Әллә юкмы? Булса, хет аз гына булса да мәрхәмәтен күрсәтер иде!..

—Алай димә, кызым. Гөнаһысына кермә. Боларның барысын да сынау итеп кенә кабул ит. Илаһи Ходаебыз үзе яраткан, сөйгән адәмнәрне генә сыный ул...

Наиләнең хәлләрен Камиләгә сиздермәделәр. Элеккечә тыныч кына, кеше күзенә бәрелмичә, кеше теленә кермичә яшәүләрендә булдылар. Наилә, башын тотып, өч көн, өч төн түшәктә ятты да, "Поле чудес"тагы эшеннән чыгып, шәһәргә китә торган юл буена сөт, бәрәңге, алма сатарга чыгып утырды.

Кеше тәнен җәрәхәтләү, мәсхәрәләү белән генә чикләнмичә, "Поле чудес" бандитлары утлы корал белән шаяра башладылар. Баштарак каз, үрдәк ише йорт кош-кортлары күпләп кырылды, аннары көтүдәге ике мәхлук сыер кан коеп егылды, ниһаять, бердән-бер көнне Чатан Шәмсиләр йортына "адашкан пуля" килеп керде, өй хуҗасының янбашын яралады. Җәйге кыска төннәрдә авыл артындагы имәнлектә мылтыктан атышкан тавышлар гадәти хәлгә әверелде, бу тавышлардан аптырап, авыл тавыклары күкәй салудан туктадылар, сыерлар кысыр калдылар...

Зәкәрия картның өйдә кадере бетте. Кызы да, оныгы да үлем көтеп

яткан карт янында сирәк булалар, булганда да, эшләрен тиз-тиз генә бетереп, үз борчуларына төелеп китеп баралар. Бигрәк тә Наиләсе үз эченә йомылды, ул көннәр буе урамнан кайтып кермәде. Бәрәнге сата алмаган көннәрендә дә борчылмады, бер уч акча тотып кергән чакларда да әллә ни ах итмәде... "Яшәсәм дә яшим, яшәмәсәм дә яшим", дигән кебек, тормышның ямен югалтып, дулкын өстендәге йомычкадай, салмак һәм хәсрәтле язмыш белән яшәвендә булды.

Зәкәрия карт кызы белән берничә мәртәбә сөйләшергә тырышып карады. Ләкин Наиләнең күнелен дә, тәнен дә, телен дә җан сызланулары ныклап ябып-томалап куйган иде. Кызы белән берни дә барып чыкмагач, Зәкәрия карт оныгына күчте, дога сүзе белән дә, әфсен-төфсен белән дә аны бәла-казадан, бәхетсезлектән аралап, саклап калырга теләде.

—Куль агузү бираббиль-фәләкъ. Мин шәрри мәә халәкъ. Уә мин шәрри гаасикын изәә уәкаб. Уә мин шәррин-нәәффәәсәәти филь-гукад. Уә мин шәрри хәәсидин изәә хәсәд...

Камилә көлә генә:

—Дәү әтием, бу догада нәрсә хакында сүз барганын беләсеңме соң?

Дәү әти булган кеше бу догада нәрсә хакында сүз барганын төгәл генә белми иде. Алай ук укымышлы түгел шул ул. Бу дога сүзенең яман күз тиюдән укыла торган дога икәнен генә белә Зәкәрия карт...

—Куль агузү бираббин-нәәс. Мәликин-нәәс. Иләәһин-нәәс. Мин шәрриль-уәсуәәсиль-ханнәәс. Әль-ләзии йувәсвисү фи судурин-нәәс. Минәль-җиннәти уән-нәәс.

Камиләгә тутырып карарга да курка Зәкәрия карт. Күздә нилә булмас. Нәрсә генә күрмәгән бит алар шушы аккан су кебек гомердә...

Бигрәк чибәр шул кызый. Әммегөлсемгә—дәү әнисенә тартымрак. Ул да авылда бер кыз иде. Барыбер каратты аны Зәкәрия. Болынга печән чабарга төшкәч каратты. Авылның беренче чалгычы егете бул да каратма, имеш... Үзе еландай елышып килде, минсинайтим... Ходай Тәгалә бар ул, бар. Әнә бит—оныгы Камилә сурәтендә булса да күз алдында йөртә халәлен...

Бәхете генә булсын инде. Айратны кыйнап ташлагач, бераз басынкыланып калды, ямансулап йөри башлады ул. Әллә... Әллә берәр юньсезлекне, бәла-казаны алдан сизеп борчыламы?

Зәкәрия карт авыр уйларын тизрәк төйнәп куярга ашыкты. Менә ул, йоласына туры китереп, "яман күз" догасыннан соң өч тапкыр укылырга тиешле "Фәләкъ" һәм "Ән—Нәс" сурәләрен күнеленнән үткәрде дә көзге каршында боргаланып торган Камиләгә эндәште:

—Балакай, берәр кая җыендыңмы әллә? Соң бит инде, кара аны...

—Әле без бу вакытта яши генә башлыйбыз, дәү әтием. Борчылма, яме. Синең укыган догаларың мине бөтен-бөтен әшәкелекләрдән саклар, менә күрерсең дә торырсың...—Чыгып китәм дигәндә генә, ишек катына җиткән Камилә тагын бер мәртәбә дәү әтисен ирештереп алды.—Бүген иске клуб каршында дискотека була, әйдә минем белән, чыгасыңмы?

Камилә, гомердә булмаганча, көлә-шаяра чыгып китте, аның артында ишек ябылырга өлгермәде, Гадел килеп керде. Керде дә, исәнләшеп тә тормыйча, Зәкәрия картның аяк очына килеп утырды.

—Нәрсә, бию буламыни бүген?

Малайның җавабы баш кагудан узмады.

—Ыһы.

—"Дискәтик" дигәне нинди нәрсә соң аның?

—Әй... Селкенеп торалар шунда...

—Сиңа ошамыймыни?

—Юк, ошамый.

—Алай икән... Авылда ниләр бар соң?

—Һаман шул инде. "Поле чудес"лардан куркып яталар.

—Һаман атышалармы?

—Атышалар... Кичә үр буеннан мәчет аена атып уйнаганнар. Пуля тиеп, манара башындагы ай кыйбла ягына чиккә борылган, ди... Бер дә әйбәт нәрсә түгел, ди, бу... Хаммас абый менеп төзәтмәкче булган, егылып төшеп билен кузгаткан... Бүтән менүче булмаган... Хәзер картлар мәчеткә барырга да куркалар икән. Кичә җомга намазы да булмый калган. Ае кыйблага карамагач, дөрес булмый, ди...

—Мәхшәр көн шушы була микәнни?

—Минем әби дә шулай ди. Бабакай, нәрсә соң ул—"мәхшәр"? Ә "кыямәт", "ахырзаман" нәрсә? Шул вакытта бөтен кеше җирдән кубарыла, ди, дөресме шул? Әби әйтә, гөнаһлар күп булганга шулай була, ди... Барыбыз да кубарылып китсәк, җир нишләр? Ә, бабакай?

Зәкәрия карт күрше малаена җавап кайтарганчы, иң элек эченнән ихлас сөенеп куйды. Аның кебек борчылып яшәүче тагын бер җан иясе бар икән әле. Юк-юк, гади малай-шалай гына түгел, бәлки, нииндидер акыл иясенә, пәйгамбәри затка тиң адәм баласыдыр бу... Ходай Тәгалә сабыйлар теле белән сөйләшә, диләр иде, шушылай була икән...

—Һи, мәхшәрне күрергә язмасын, балам. Изге китап сүзе булса да, тормыш мантыйгына бер дә сыешып бетми ул. Күңел теләгән нәрсә түгел, диюем. Ходаебызның куркытып куюы кебек кенә... Ә бит Ул бик акыллы; мин сезгә кысылмыйм, үз хәлегезне үзегез күрегез, ди. Мин бары тик сезнең күңелләрегезне иман нуры белән яктыртам, сез шул иман яктысында үз язмышыгызны үзегез хәл итегез, ди... Белмим шул, мәчет аена мылтыктан ата башлагач, адәм баласын иман нуры гына коткара алыр микән? Ходай Үзе төшсә дә авырга туры киләчәк әле монда... Төшмәс шул, Аның үзенең дә гайрәте чигеп барадыр инде бу адәм балаларыннан...

Гаделгә Зәкәрия картны аңлау кыенрак иде бугай. Шулай да ул, бөтен дөньяны сискәндереп, дөрес сорау бирде:

—Алла әйбәт булгач, нигә соң Ул «Поле чудес» малайларын тыймый? Нигә күрми ул аларның нәрсә эшләгәнен?

—Шулай сыный ул үзенең адәми затларын. Җирдә үк сират күпере аша үткәреп карый...

—Кемне? Безнеме? Әллә «Поле чудес» тагыларнымы?

Бу юлы Зәкәрия карт аптырабрак калды. Шулай шул, кемне күбрәк сыный соң Ходай Тәгалә? Акбүрелеләрнеме, әллә теге килмешәк әтрәк-әләмнеме?

Бу сорауны җавапсыз калдыруың хәерлерәктер. Зәкәрия карт бик яхшы аңлый,—илаһи сынау кешенең канын кою, җанын кыю аша эшләнергә тиеш түгел. Һәр кыелган җан—ул инде үзе үк җәза, йә гыйбрәт, йә... искәртү!

Зәкәрия картның хәле авыраеп китте. Ул борчулы уйлардан, борчулы тормыштан тәмам арган иде. Шулай да, хәлсез сулышын җыеп, соңгы сорауны бирә алды:

—Нинди йомышың бар иде соң, балам?

—Камилә апа хакында әйтергә кергән идем.

—Нәрсә булган Камилә апаңа?—Карт дөньяның үзе кебек авыр керфекләрен күтәрде.

—Аңа "кара кәрт" чыккан, дип сөйләнделәр. "Поле чудес" тагылар авылга хәбәр җибәргәннәр. Шуны әйтергә кергән идем...

"Кара кәрт"нең нәрсә икәнлеген аңлап бетермәсә дә, Зәкәрия карт үзенең догалы, Аллаһлы күңеленә нииндидер билгесез, үтә дә шомлы, хәтәр бер шаукымның ургылып керә баруын тойды. Ул, тагын нидер сорамакчы булып,

чыгып киткән Гадел артыннан кузгалып, торып утырмакчы булган иде дә, буынсыз, тынсыз калып, тагын түшәгенә авып төште. Үзенен уйларында булса да нидер кылырга, каядыр барырга, кемгәдер зарланырга, кемнәндер ярдәм сорарга теләде. Авылына, гаиләсенә төшкән афәт, гүя, анын кадакланган кебек үлем түшәгендә ятуыннан тора кебек иде.

Зәкәрия карт бу юлы да төне буе саташып чыкты. Ләкин ул бүген, чын разведчик кебек, тавыш-тын чыгармыйча, эчтән генә кичереп, борчылып, үрсәләнеп ятты, шуна күрә дә анын күнел ярсуларын чоланда урын әмәлләгән Наилә дә, мәчет бакчасында исерек байбәтчәләрнен жирәнгеч тәннәре астында бәргәләнгән Камилә дә ишетми калды...

Зәкәрия төне буе үзенен фронтташ дусты Иван Соколик белән бергә, бөтен ялан-кырны тутырып килүче немец-фашистларга каршы атышып чыкты. Ябырылып килүче дошманнын иге-чиге юк, шуна да карамастан, Зәкәрия белән Иван үз траншеяларыннан чигенмиләр, окоп каршында калыккан һәр фашистны берәмләп чүпли торалар...

Шулвакыт Зәкәрияләр янына каяндыр Камилә килеп чыкмасынмы?! Өс-башы, йөз-битләре канга, пычракка буялып беткән. Үзе хәлсез тавыш белән: "Әйдә инде, дәү әтием, кайтыйк, мин шундый ардым, авырдым, кайтыйк инде!"—ди. Зәкәрия әйтә, имеш: "Әнә бит, әле күпме дошманны дөмектерәсе бар, ничек кайтыйм инде?"—ди. Камилә берни дә әйтми, окоп читенә чүгәләп, яшьле керфекләрен йома...

...Кызнын мәсхәрәләнгән, көчләнгән гәүдәсен иртә белән мәчет артыннан табып алдылар. Жаны чыгам-чыгам дип торган сылу тәнне шундук машинага урнаштырып, Яр-Чынлыга озаттылар, ана ияреп, Наилә дә хастаханәгә китеп барды. Зәкәрия карт, мәнгелек белән күзгә-күз карашып, япа-ялгызы торды да калды. Анын үлемгә бу кадәр якын килгәне юк иде әле. Сонгы сәгате сугар алдыннан адәм баласына илаһи көч кереп ала, диләр, дөрес икән, Зәкәрия карт та, оныгы хакында ишетү белән, шундук сикереп торып утырды, бушап, котсызланып калган өй эчен бер мәртәбә карашлары белән сөзеп, күздән кичереп чыкты да, жәһәт кенә кузгалып, киенә башлады...

## Фронт

Зәкәрия карт, яшьрәк чагында, Жинү көне житү белән, сугыштан киеп кайткан, күп юудан агарып-унып беткән гимнастеркасын киеп чыга иде. Күптән кигәне юк иде инде, бүген ул шул гимнастеркасын эзләп тапты. Түрдә эленеп торган яна костюмыннан орден-медальләрен салдырып, шул гимнастеркасына күчереп такты. Биленә солдат каешын буып, чал башына тараебрак калган пилоткасын киеп куйгач, чып-чын фронтовикка охшады да куйды Зәкәрия карт. Ул бу минутта көчләнеп ташланган оныгы хакында да, жәберләнгән, бәхетсезлеккә дучар ителгән кызы, мәсхәрәләнгән, түбәнлеккә төшерелгән авылы, бөре нәселеннән килеп тә, эт типкесендә яшәүче татары, шул татарнын ин борынгы бишеге булган туган жире хакында да уйларга тырышмады. Зәкәрия картнын нәфрәт тулы йөрәгендә үч гаме генә калган иде. Ин мөһиме, ул бу минутта нәрсә эшләргә кирәген төгәл белә иде. Дошманынын кем икәнен белә. Чын сугыштагы кебек!

Менә ул түшәк читенә утырып бераз хәл алды, сулышын тигезләгәндәй итте, аннары, тиз-тиз генә чоланга чыгып, чормага менеп китте, сугыштан алып кайткан револьверын эзләп тапты, аны сөрткәли-сөрткәли тагын өйгә керде. Стенада эленеп торган сурәтләр каршына килеп басты. Үрелеп, кытыршы, авыр эштән чатланып, гарипләнеп беткән бармаклары белән Өммегөлсемнен фотосын сыйпап куйды, аннары дүртесе бергә төшкән

"бәхетле фотога" озаклап карап торды. Буыннары йомшап, тагын түшәгенә чүкте, тәне белән түгел, күбрәк җаны, күңеле белән хәл җыйды...

Зәкәрия карт бу минутта дога укырга кирәклеген белә иде, ләкин ул бүген Аллаһы белән аралашырга теләмәде, дөресен генә әйткәндә, ул Ана үпкәле, хәтта ачулы иде. Анынча, шулкадәр догада утыруына, Ходай Тәгалә аңа һәм аның гаиләсенә мәрхәмәтлерәк, шәфкатьлерәк булырга тиеш иде, бәхетле үк итмәсә дә, аларны бөтенлектә һәм иминлектә яшәтергә тиеш иде... Картның сугыш гаме томалаган күңелендә илаһи хисләргә урын юк иде, ләкин бу әле аның күңелен иман ташлап киткән дигән сүз түгел; ул илаһи тойгы бары тик авыр уч, бетмәс-төкәнмәс нәфрәт хисе белән томаланып, бастырып куелган хәлдә иде.

Бил каешына револьверын кыстырып, аркасына юл капчыгы асып, урамга чыгып баручы Зәкәрия картка әлеге дә баягы Гадел очрады. Ул үлем түшәгендә ятучы картны хәрби киемнәрдә күреп, тәмам каушап калды, хәтта, бер як читкә тайпылып, аны үткәреп җибәрде, шуннан соң гына исакылына килеп:

—Бабакай, син кая?—дип сорый алды.

Картның тавышы көр, карары нык иде:

—Фронтка, балам, фронтка!

Гадел инде иркенәеп сөйләшерлек хәлгә килгән.

—Сугыш күптән беткән бит инде, бабакай, шуны да белмисеңмени? Фашистлар юк хәзер...

—Фашистлар беткән, минә сугыш бетмәгән...

—Бабакай, шундый кызык! Мине дә иярт әле,ә?

—Сиңа ярамый. Син яшь әле. Бар, өеңә кайт, сөйләндереп вакытымны алма...

Һәркемнең үз юлы шул, үз язмышы. Аны адәми зат кына билгели алмый.

Зәкәрия карт нык адымнар белән фронтка чыгып китте, бераз арткарак калып, аңа Гадел иярде. Алар, бер-берсенә бәйләнгән кебек, Акбүре авылының үрге ягына чыктылар, язгы су төшкәндә убылып, яргаланып калган ерганак-ярлар янына килеп чыктылар. Авылның чиге нәкъ шушыннан үтә. Окоп-траншеяларны хәтерләткән бу кара чокырлар үзләре үк сугышка чакырып торган кебек, гүя алар сугышның нәрсә икәнен беләләр, ул гына да түгел, аны сагынып көтәләр...

Бер елны Казаннан археологлар килеп, җәй буе казынып ятканнар иде. Нәкъ шушы чокырларда әллә күпме чүлмәк ватыклары, ук очлары, пычак, хәнҗәр ише әйберләр таптылар. Бүре башы, аның артыннан ук бүре тешләреннән тезелгән дисбе килеп чыккач, үзләренчә нәтиҗә ясадылар. "Акбүре нәселе шушында сугышкан, димәк, бу авыл—татарның иң борынгы иле,"—диделәр.

Зәкәрия карт үзе артыннан ияреп килүче малайга күзләрен кысып, болай да сырланып беткән йөзен тагын да ныграк җыерып, карап-карап алса да, аны кире борып җибәрергә кыймады. Аннары ул белә иде: сугышта иптәш кирәк, дөресрәге, япьтәш кирәк. Үткән сугышта Зәкәриянең Ваня дусты—Иван Соколигы бар иде. Гадел аның белән тиңләшә алмый, әлбәттә. Әмма батырлыкта, зирәклектә аңардан ким дә түгел...

Фронтовик, чын окопны хәтерләткән, чирәмлекне кеше буе чокып кергән бер уйсу ярны сайлап алды да урнашу ягын кайгырта башлады: үрелеп күзәтү өчен аяк астына кәсләр түшәде, "окоп" алдына да берничә кәс куйды. Анысы бруствер була инде. Күзәтү пунктларында шулай иде бит—шушы ике кәс арасындагы ачыклыктан көннәр буе дошман позицияләрен күзәтеп ятасың, минсиңайтим, күзләр чәчрәп чыгардай була, билләһи!

Позиция мәсьәләсен хәл итеп бетергәч кенә Зәкәрия карт билендәге

каешын салды, көмеш көпшәле трофей револьверын яр читендәге чирәмлеккә куйды, кулъяулыкка төрелгән бер уч патронын да шунда ук урнаштырды.

Янәшәдәге яр читендә утырган Гадел барысын да аңлап-төшенеп алган, күрәсең, бераз мыштым гына карап-күзәтеп торгач, Зәкәрия картның каршына ук килеп, олыларча әйтеп куйды:

—Әле алар йоклыйлар. Кичке якта гына торып чыгалар...

Карт гүя ишетмәде дә. Ул үзенең сугышчан позициясен камилләштерү белән мәшгуль иде. Малай аның дәшмәвен аңлашу билгесе итеп кабул итте, ахры, тәмам үз булып, Зәкәрия картка фронтташ, көрәштәш булып сөйләп китте:

—Бездә ау мылтыгы бар. Әткәйдән калган. Аның унике патроны да бар. "Финка" да бар, анысын үзем таптым, көтү көткәндә. "Поле чудес" малайларыннан төшеп калган. Апкилимме?—Инде сүзе беткәч, тагын җанланып, картның револьверына ишарәләп әйтеп куйды.—Моның белән генә каршы торып булмаячак. Аларда корал—менә моннан!—Гадел нәни учларын баш түбәсенә кадәр күтәрде.—Кирәк икән, үзем дә ата беләм мин...

Карт бу юлы да дәшмәде. Ул үз тирәсендә бөтерелеп йөргән бу күрше малаен ишетми дә кебек. Аның бөтен күңеле, күз карашлары авыл читеннән үк башланып киткән "Поле чудес" бистәсендә. Биек коймалар артыннан берсен-берсе узып калыккан бу ике-өч катлы йортларда ниндидер котсыз, яман затлар яши кебек. Алар кинәт кенә килеп чыгарлар да бистә белән авыл арасындагы барлы-юклы бер чакрымны чабып үтеп, мең ел торган Акбүре иленә ябырылырлар сыман... Юк, бу юлы тиз генә ала алмаслар. Наиләне дә, Камиләне дә, башкаларны да бүтән бирмәячәк аларга Зәкәрия! Ул бүгеннән явызлыкка, вәхшилеккә, кешелексезлеккә каршы сугыш ачты. Явызлык белән иминлек арасында, үлем белән яшәү арасында фронт бар хәзер. Утлы позиция бар... Бу фронт белән гвардия сержанты, биш сугышчан орден, жиде медаль кавалеры, разведчик, «смертник» Зәкәрия Вәлиәхмәтов командалык итә. Аның командасында кеше күп түгел. Дөресрәге, ул үзе генә. Аннары Гадел исемле малай бар. Ул фронт командующиена әйбәт ярдәмче була ала. Их, Иван Соколик булса! Һһ та итмәс иде Зәкәрия, дошманына туры карап яуга күтәрелер иде. Исән микән ул? Бер күрешеп, сөйләшеп тә булмады, ичмасам. Сугыштан соң бергә кайтканнар иде, югыйсә. Казанда юллары аерылды, Ваня Төмән ягына китеп барды, Зәкәрия—үз авылына. Адреслар да алмашканнар иде, язмыштыр инде,—ул язулы кәгазьне Казан вокзалында очраган иң беренче патруль алып калды. Шикле адрес, янәсе. Төмәнгә барып, нинди диверсия корырга йөрисең, янәсе. «Дустымның адресы ул,»—дип тә карады. Ышанмадылар. Бер көн каталажкала тоттылар да, частеннән унай хәбәр алгач, чыгарып җибәрделәр. Тик барыбер адреслы кәгазьне бирмәделәр. Хәтта укытмадылар да. Бер күз төшерү белән исендә калдырыр иде, югыйсә...

Зәкәрия карт уйларын уйлап бетерә алмый калды, каяндыр Гаделнең йомшак, әмма олыларча җитди тавышы ишетелде:

—Бабакай, мин авылга кайтып килдем. Синең хакта Ибраһим абзый белән Исмәгыйль абыйга да әйттем. Аларның малайларына да «кара кәрт» чыккан...

—Син боларны каян беләсең соң, малай актыгы?!—Гаделнең беллекле булып кылануы, ниндидер сәер мавыгу белән «үлем уены»на керә баруы Зәкәрия картны шактый ук үрти башлаган иде.

—Каян булсын, бөтен кеше сөйли... Менә, әткәйнең мылтыгын да алып килдем, «финка»ны да... Кирәге чыгар әле...

Бу юлы «фронт командующие» малайны ачуланмады, авыр мылтыкны

алып, затворын тартып карады, көпшәләрен тикшерде, курокка басып алды, аннары бруствер өстенә—револьверы белән янәшә куйды, Гадел сузып торган патроннар янчыгын да, дәшми-нитми генә алып, мылтык белән револьвер арасына урнаштырды. «Финка»ны алмады, кире малайның үзенә бирде. Эшнең ана кадәр үк барып җитмәячәген белә иде ул.

Тагын бер мәртәбә үзенең сугышчан позициясен күзаллап, өйрәнеп чыкканнан соң, Зәкәрия карт, окоп читенә чүгеп, аркасын үлем салкынлыгы бөркеп торган кызыл балчыкка терәде...

Соңгы ун-унбиш елда беренче мәртәбә аның үтереп ашыйсы килде. Ул кесәсенә тыгылды, юл капчыгын капшап чыкты, әмма ирен читенә куярлык та ризык таба алмады...

—Гадел балам, ашарга юнәтәсе иде безгә.

—Ә мин юнәттем инде.—Гадел шунда ук аркасындагы мәктәп сумкасын салып чирәм өстенә куйды, тезләнеп, актарынырга керешә, сөт тутырылган шешә, берничә пешкән йомырка, кабыклы бәрәңге һәм кыяр-помидорлар чыгарып куйды. Иң ахырдан кып-кызыл ике алма алды. Окоп эченә тәмле, хәтта татлы табигать исе, яшәү исе таралды...

Зәкәрия карт бәхетле иде. Аның иреннәренә ризык тәме кайтты. Ул бу минутта яланга җил алып килгән бөтен хуш исләрне дә сизә, яшәүнең ямен, дөньяның гамен тоя башлаган иде...

Көч-егәрлеге, дәрт-дәрманы, яшьлеге шулай кабат кайттымы әллә? Әллә рәнҗетелгән якыннары арасындагы җан һәм кан бәйләнешләре шулай аның гомерен озайттымы? Әллә... Әллә күңелен томалап алган чиксез, чамасыз нәфрәт, дошманнарыннан үч алу тойгысы аны көчле, бәхетле итәме?

Зәкәрия картның күңел ярларында бу тойгыларның барысы да бар, ә менә илаһи догалар аша инә торган изгелек әлеге давыллы, шаукымлы күңел дәрьясының иң ерак чоңгылларына төшеп яткан иде...

Кеше тормышында шундый минутлар була: бервакыт ул төштәге кебек кенә яши башлый. Зәкәрия карт белән дә шулай булды, ахры. Корал тотып "фронтка" чыкканнан бирле ул, гүя, үз тормышы белән яшәми, икенче бер адәм баласының язмыш юлына төшеп, бөтенләй чит-ят гомер яшәп ята... Шуна күрәдерме, Наилә белән Камилә дә бик борчымый кебек аны, бары тик авылга каныккан бандитлар өере белән канлы, хәлиткеч сугыш гаме, көрәшкә генә түгел, җиңүгә ымсыну хисе яшәтә, ахры.

Гадел фронтта сакта торган арада Зәкәрия карт окоп читенә чүгәләп, черем итеп алды. Ләкин фронт командующиена озак юанырга туры килмәде, часовой аны сак кына төрткәли башлады:

—Бабакай... Киләләр...

Зәкәрия шушы хәбәрне көтеп кенә торган диярсең, яшьләрчә җәһәт кенә сикереп торып, гимнастерка чабуларын тарткалый башлады, изү төймәләрен эләктерде, пилоткасын рәтләде. Аннары окоп алдында яткан коралларын сыйпаштырып алды, шуннан соң гына карашларын "Поле чудес" ягына күчерде.

Баштарак ул беркемне дә күрмәде. "Поле чудес"нең мәһабәт йортлары бөтен офыкны шыплап тутырып, томалап куйганнар иде. Шул мәлдә Зәкәрия картның зиһенен бер сукбай уй сызып үтте: "Бүгенге байлар йортларын ни өчен тау кадәр итеп салалар икән дисәм. Әйе шул, күп бүлмәле, иркен, якты булсын өчен түгелдер, бүтәннәр алар янында үзләрен кечкенә итеп, мескен итеп, түбәнсетеп тойсыннар өчендер..."

Әнә алар... Унлап егет, кулларындагы шешәләрдән сыра чөмерә-чөмерә, йөз кешелек шау-шу, ыгы-зыгы куптарып, авылга алып керә торган бердәнбер юл буенча киләләр иде.

Бу гайре табигый күренештән Зәкәрия карт йөзен чытып куйды. Аннары

яр читенә таянып калкынды да фронт сызыгын күзәтә башлады.

Карап торышка шундый ук адәм балалары—авыл малайларыннан берни белән дә аерылмыйлар. Ә кыланмышлары... Кыланмышларында адәми затларның әсәре дә юк. Барыбер алар да инсан нәселеннән, аларның да өйләрендә өзелеп көтеп торучы аналары бардыр, зур, җаваплы эшләрдә эшләүче аталары бардыр, сөйгән ярлары, дус-ишләре, яраткан шөгыльләре, укый торган китаплары, җырлый торган җырлары, хыяллары бардыр...

Ә бәлки... болар өчен бер генә изге әйбер дә калмагандыр?..

Шулвакыт каяндыр җир төпкеленнән, әллә күк катыннанмы, оныгы Камиләнең кайтаваз кебек кенә тавышы ишетелгәндәй булды. "Кызганма син аларны,—ди иде бу тавыш.—Алар мине төне буе интектереп, газаплап чыктылар, сафтин-саф тәнемне, ихластин-ихлас җанымны мәсхәрәләделәр... Алар яшәргә тиеш түгел, дәү әтием... Ходай эшли алмаганны үзең эшлә—дөмектер шуларны. Минем хакка дөмектер. Ялварып, ялынып сорыйм..."

Зәкәрия, үзен-үзе белештермичә, җәһәт кенә револьверын алып, дошман ягына төбәп тә куйды. Ләкин шундук, кулы пешкәндәй, кире тартып алды, утлы коралын чирәмгә ташлады. Аннары, окоп төбенә тезләнеп, якында гына яткан чыбык сыныгын алды да очына ак кулъяулыгын бәйли башлады. Менә ул бәйләп бетерде, торып басты, кабат револьверын алды, аны баш очына күтәреп, һавага атып җибәрде. Шуннан соң гына, ак кулъяулык бәйләнгән чыбыкны болгап, окоп читенә менәргә талпына башлады. Бу кадәресенә түзеп торган Гадел аның янына йөгереп килеп тә житте.

—Китер, бабакай, үзем сөйләшергә барам. Сиңа ярамый...

—Нишләп ярамасын?! Менә сиңа ярамый. Син бала гына әле. Баласеннән баш-аяк...

—Сиңа ярамый!—Малай олыларча үҗәт иде.—Син китсәң, фронт буш кала. Аннары... командирлар парламентер була алмый. Кинода күргәнем бар—дошман белән сөйләшергә гел аларның ярдәмчеләре йөри.

—Анысы шулай... Курыкмыйсыңмы соң?

—Ник куркыйм ди... Мин аларны болай да күн саен күреп торам. Нәрсә дип әйтергә соң?

—Нәрсәме?—Зәкәрия карт кешелекләрен югалткан бу яшьләр өеренә ни-нәрсә әйтергә икәнен әлегә белеп бетерми иде. Мылтык аткан тавышка сискәнеп, юл очында туктап калган дошманга төбәлгән килеш, ниһаять, нәрсә әйтергә кирәклеген уйлап тапты.—Акбүрене фронтовик Зәкәрия Вәлиәхмәтов саклый, әйбәтлек белән кире үзләренең "Чудес"ларына кайтып китсеннәр. И бүтән монда күренмәсеннәр. Шулай дип әйт, Зәкәрия Вәлиәхмәтов тора, диген. Гвардия сержанты, диген... Аңладыңмы? Нәрсә сөйләргә онытмассыңмы? Яле, әйтеп кара!

—Аңладым инде, бабакай, нәрсәсен кабатлап торырга аның... Вакыт та юк, әнә тегеләр бу таба килә башладылар... Тизрәк бир ак флагны, киттем...

—Гадел балам, сак кылан, яме. Синең белән минем җаным да китә.—Җиргә тезләнеп, Зәкәрия карт малайның күзләренә тутырып карады.—Тегe сугышта булса, мин сине үз отрядыма алыр идем, ей-богу, боец... Гадел...

—Рядовой Гадел Исламов!

—Рядовой Гадел Исламов...

—Разрешите идти?

—Разрешаю...

—Есть!

"Поле чудес" егетләре очына ак чүпрәк бәйләнгән таяк күтәреп килүче малайны сәерсенеп каршы алдылар. Шулай да килгән унайга куып та җибәрмәделәр. Күренеп тора: Гадел сүзне сөйләшә белә иде. Ләкин

килмешәк егетләрнең түземлеге чиксез-чамасыз түгел иде, ахры, алар берәм-берәм дә, парлап та малайга уктала башладылар. Кайсыдыр, кесәсеннән пистолет чыгарып, янап та куйды. Ниһаять, сүз алып барганы, атаманнарыдыр инде, Гаделне төрткәли башлады, бер-ике мәртәбә суккалап та алды. Гадел аңа игътибар да итмәгән кебек, авылга төбәп күрсәтә-күрсәтә, үз сүзен сөйләвендә булды.

Ниһаять, ул кайту ягына борылды. Аның артыннан кемдер шаркылдап көлеп, кемдер сүгенеп, янап калды. Ә берсе, Гадел бераз китү белән, пистолетын алып, малай артыннан ата башлады. Гадел Зәкәрия фронтына таба йөгерергә тотынды.

Бу хәлгә фронт битараф кала алмый иде инде. Зәкәрия карт револьверын төбәп атып җибәрде. Гадел артыннан атып калган егет, сул кулы белән уң янбашын тотып, сыгылып төште. Аның янына башкалар йөгереп килде. Яралы дусларын килгән юллары буенча "Поле чудес"ка таба алып та киттеләр. Үзләре авыл ягына карап, йодрык күрсәтә-күрсәтә, кычкырырга, янарга да онытмадылар...

Бераздан авыл белән бистә арасында үлем тынлыгы урнашты.

—Кайтып киттеләр...—Шунда Гадел үзенең исән икәнлеген сиздереп куйды. Карт, сискәнеп, малайга табан борылды, җәһәт кенә кузгалып, аның сипкелле йөзен күкрәгенә кысты, аркасыннан сөеп тәкърарлый башлады:

—Сугыш әле башлана гына... Башлана гына... Башлана гына...

Зәкәрия карт белә: яралы ерткыч хәтәррәк. Сугышның башы гына әле бу, фаҗигаләрнең башы гына...

Чынлап та, ярты сәгатьләп вакыт үтәр-үтмәс, әллә кайлардан гына, берәмтекләп тә, төркем-төркем дә «Поле чудес» капкасы янына ир-егетләр җыела башлады. Күбесенең кулында мылтык, обрез ише кораллар, тимер кисәкләре, күсәк тотканнар да бар...

Менә алар, өч төркемгә бүленеп, иелә-бөгелә Зәкәрия белән Гадел тоткан фронт сызыгына табан килә башладылар. Егермеләп булыр...

—Егерме өч.—Гадел санап та өлгергән икән.

Зәкәрия хәлнең мөшкел булуын аңлап алган иде инде. Аның ул кадәр патроны да юк. Ул чаклы патронны атасы да килми аның. Әнә, берсен яралады да инде. Исән калса гына ярар иде. Акылга утырса, шул житә. Юк, болар акылга утырырга охшамаганнар. Әнә бит ничек киләләр. Сугышта "СС" дивизиясе солдатлары гына шулай акырып-бакырып киләләр иде.

Урталыктагы төркемне башы кырып алынган, киң җилкәле бер егет алып килә. Аның кычкырып команда бирүе аерым-ачык ишетелеп тора.

—Уратып алыгыз, уратып!.. Исән калдырмагыз, үзе казыган окобына терeләй күмегез!

Зәкәрия карт, озаклап төбәп торды да курокка басты. Теге атаманга охшаганы, чалгы белән чапкандай, җиргә кыелып төште... Чәчрәп барып төшкән башлыкларын күреп, калганнар бермәлгә каушап, тукталып калдылар, әмма шундук, кем ятып, кем тезләнеп, тәртипсез рәвештә атарга керештеләр.

Берничә пуля Зәкәрия картның колак очыннан гына сызгырып үтте. Ул моңа әлләни игътибар итмәде. Ләкин, кызыксынуын баса алмыйча, үрелеп ялан ягына карарга маташкан Гаделне ярның төбенә үк төртеп төшерде.

Атыш кызганнан кыза барды. Зәкәрия карт, бөтен шартын китереп, позициясен алыштырды. Ике атып, тагын бер дошманны җиргә чүгәргә мәҗбүр итте. «Их, бер патрон әрәм китте,»—дип баш чайкап куйды.

Сугышта һәрвакыт шулай: рух җиңә, кеше җиңелә. Егермеләп дошманга берүзе каршы тора алмаячагын белә Зәкәрия карт. Бу сугышның соңгы

сугыш булуын аңлый. Шуна да ул үзен тыныч тотты—түшәктә ыңгыраша-ыңгыраша җан биргәнче, дошман белән көрәшеп башны салу—мең мәртәбә әйбәтрәк!..

Кинәт кайдадыр якында гына—авылның ун як очында—мылтык аткан тавыш ишетелде. Зәкәрия карт шундук чамалап алды—авыл ягыннан аталар. Димәк, Акбүрене якларга тагын кемдер чыккан...

—Ибраһим абзый бу, әйттем бит, ул да кушылачак, дип... Хәзер барып киләм.

Гадел, тирән ярга ышыкланып, ун як күршедәге фронтка китеп барды, Зәкәрия исә, атып, тагын бер әзмәверне җиргә калалдырды.

Ул арада сул якта да кемдер ата башлады. «Монысы Исмәгыйль булырга тиеш,—дип уйлап алды карт.—Аларның йорт-җире шул якта... Молодец Гадел! Тынлата алган бит, ышандыра алган!"

Шулвакыт Зәкәрия картның култык астын нидер чәнчеп алды. Карт "ыһ!" итеп куйды да тагын фронт гаменә бирелде, инде шактый якынаеп өлгергән дошманга соңгы патроннарын атты. Аннары кулына Гадел күтәреп килгән ау мылтыгын алды. Әмма берничә мәртәбә атуга, аяк астында җир убыла башлады; менә ул хәлсезләнеп окоп читенә чүгәләде, карашларын кызыл кабер балчыгына төбәп тынып калды.

Юкка чыгып торган Гадел килеп җитмәсә, нишләр иде икән ул? Шулай япа-ялгызы чокыр төбендә җан очырган булыр иде, мөгаен. Янында Гаделнең кабат пәйда булуы Зәкәрия картка хәл кертеп җибәрде. Ул тырыша-тырмаша кабат торып басты, мылтыгына үрелде...

Сулышын тигезли алмый торган Гадел рапорт бирергә ашыкты:

—Бабакай... Иптәш... сержант... Рөхсәт... итегез...

—Ниләр бар анда, балам? Фронт нишли, нык торамы?—Зәкәрия картның тавышы хәлсез иде.

—Фронт үз урынында... иптәш сержант... Ибраһим... абзый белән Исмәгыйль абыйлар үз окопларында геройларча сугышалар. Бөтен авыл белә бу хакта. Озакламый халык сугышка кузгалачак. Хәзер ду килеп корал җыялар...

—Менә монысы кирәкмәс иде. Күрәләтә ут эченә керү кирәкмәс. Безгә ярый—без фронтовиклар... Бар, кайтып әйт үзләренә, бу якта ялгыш та күренмәсеннәр...

—Бабакай, ни сөйлисең син?! Патронсыз-нисез сугышып була димени? Менә, Исмәгыйль абый ике патрон бирде, бүтән бирә алмыйм, диде...

Гадел тагын каядыр китеп барды. Зәкәрия карт кабат үз урынына басты, ун-унбиш адым читтәрәк кенә мылтыгын төзәп булашкан таза гәүдәле, тулы битле, кысык күзле егеткә атып җибәрде. Атуын атты, әмма үзе дә, буынсыз булып, окоп төбенә шуып төшеп китте... Шулай һәр аткан саен аның хәләл каны, каны белән бергә яшәү көче дә кабат кайтмаслык булып чыгып бара иде...

Гомердә булмаганча, Зәкәрия картның бик тә, бик тә яшисе килде. Бу соңгы сугыш аның карт, авыру тәнендә, арган, талчыккан, гаҗизләнгән күңелендә шулкадәр көчле яшәү дәртле уяткан иде, дымлы,салкын чокыр төбендә канга батып утырган килеш, кызы Наилә, оныгы Камилә, шәһәрдәге уллары белән озачак бәхетле гомерен күз алдына китерергә тырышты...

Шул мәлдә вакыт тукталып калды һәм серле, сихри мәңгелек башланды... Ә мәңгелектә кеше гел бәхетле. Үлеп барган фронтовик карт бу минутта үзенең никадәр бәхетле булуын белми дә, тоймый да иде. Ул көрәштәшләре Ибраһим белән Исмәгыйльнең "Поле чудес" бандитлары тарафыннан атылып үтерелүләре хакында белмәве белән бәхетле иде. Авыл тыкрыкларының берсендә күзенә пуля кереп, канга батып яткан, соңрак дөм сукыр калачак

Гадел хакында белмәве белән дә бәхетле иде ул. Шулай ук оныгы Камиләнең аңына килә алмыйча җан тәслим кылуын, кызы Наиләнең, акылыннан язып, тиләләр йортына җибәрелүен, анда санитарлар тарафыннан көчләнеп, өченче каттан ыргытылуын белмәве белән дә бик бәхетле иде. Мең еллык Акбүренең, перспективасыз авыл дип, җир йөзеннән мәңгелеккә юк ителүен, халкының көчләп Яр-Чынлыдагы иске тулай торакларга күчерелүен, авыл урынына затлы коттеджлар төзелүен дә күрми, белми калды Зәкәрия карт. Ул шуның белән дә бәхетле иде...

## Эпилог

Кайчандыр Акбүре авылы торган үр куенында бүген дә ике истәлекле урын бар. Икесе дә авылның чит-ят куллар кагыла алмый торган бердәнбер җирендә—иске зират эченә урнашкан. Аларның берсе—каберстандагы мәһабәт мәрмәр таш. Аның төн кебек кара йөзлегенә, чокып: "Татарның иң борынгы авылы", дип язылган. Шунда ук тагын язу: "Татар яугирләренең Явыз Иванга каршы соңгы сугышлары булган урын."

Икенче истәлек ташы фронтовик, гвардия сержанты Зәкәрия Вәлиәхмәтов истәлегенә, аның кабере очына куелган. Җыйнак кына ак таш. Язуы да бар: "Дошман белән алышта һәлак булган соңгы ветеран Вәлиәхмәтов Зәкәрия Мөхәммәтгали улы", диелгән.

Бу кабергә еш кына өч ир кеше кайта. Аларның икесе—гүр иясенең үзенә бик охшаганнары—аңлашыладыр, мәрхүмнең үз уллары. Өченчесе—кара күзлек киеп, кулына озын таяк тотканы—кайчандыр шушы авылны яклап фронтка чыккан Гадел исемле малай булыр. Хәзер кем ул? Кайда? Ничек? Янына барып сорашасы килә. Әмма үтә дә житди ул, хәтта усал да кебек... Бу начар түгел. Түгел! Әле усал булырга туры киләчәк. Әле күпме сугышлар булачак, күпме соңгы сугышлар!.. Батырлык, тәвәккәллек, үҗәтлек бик тә кирәк булачак татарга.

Күзләр дисезме? Татарның маңгай күзе күптән сукыр инде. Ләкин аның күңел күзе маңгай күзләреннән дә әйбәтрәк күрә, әйбәтрәк тоя... Аның моңлы, гамьле булуы да шуннан килә, күрәсең...

Бердәнбер көнне бу өч кешегә дүртенче берәү—ап-ак чәчле, шундый ук ак, куе мыеклы, зирәк, әмма моңсу карашлы карт килеп кушылды. Фронтовик. Ветеран. Герой. Түшендәге орден-медальләрнең исәбе-хисабы юк. Инде аңлашылгандыр, Зәкәрия Вәлиәхмәтовның фронтташ дусты Иван Соколик бу. Соңгы юлга чыгып китәр алдыннан, җан дусты белән саубуллашу өчен, кайчандыр күңел дәфтәренә язып куйган адресын табып, мең чакрым ара үтеп килгән. Килгән дә монда булган хәлләрне ишетеп таң калган. Аның күзләреннән туктаусыз яшь ага. Бу яшьтә яшь буламыни, дисезме? Яшь түгел ул, җан ул, җан! Күз яше булып җаны суырылып ага аның, гомере ага...

Менә ул, тирә-яктагыларны сискәндереп, кызу-кызу чишенә башлады. Плащын салды, шарфын чишеп элде... Ботак-чатаклы бармаклары белән нәкъ күкрәк өстендә балкып торган Алтын Йолдызны эзләп тапты, аны җәһәт кенә ычкындырып, Зәкәрия Вәлиәхмәтовны үз куенына алган чирәм җир йөзлегенә куйды. Һәм җан тавышы белән иң кирәкле сүзләрне әйтте:

—Прости меня, друг! Я хочу к тебе!

*2005 ел*



Роберт
Әхмәтҗан

# КИЧКЕ ТӘРӘЗӘЛӘР

### Әле ярый...

**Мин шушында туган, елый-елый,—**
**Үкенепме әллә туганга?**
**Мин куанып елаганмын, алда**
**Күрәселәр бик күп булганга!**

**Өметләргә кул тимәгән, алда**
**Башланмаган Тормыш торганга...**
**Әнкәмнән дә алда мине язмыш**
**Төреп алган бәхет-юрганга!**

**Еламаганмындыр, сабыйларча**
**Күрәчәктән, бәлки, көлгәнмен...**
**Гаепләме сабый—мин, күрәмсең,**
**Үләсемне алдан белгәнмен...**

**Мин шушында туган, елый-елый,**
**Әйтерсең лә дөнья кубарган!..**
**Как матчага эткәм бишек аскан,**
**Җырлар җырлап әнкәм сугарган.**

**Әле ярый, мин шушында туган,**
**Белгәнмен бит кайда туасын!..**
**Әле ярый, туып эш бетмәгән,**
**Булган икән дөнья куасым!**

**Әле ярый, мин, шушында тугач,**
**Давылларга каршы баралдым.**
**Минем белән туган телем туган,—**
**Мин телемнән меңгә таралдым!**

Роберт ӘХМӘТҖАН (1935)*—шагыйрь; "Идел-йорт", "Таң шәһәре", "Җәяүле күбәләк" һ. б. китаплар авторы; Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Беркем кушмый гына, бу туфракка
Тирән киткән безнең тамырлар...
Күкләр күкрәп җиргә бәхет иңгән,
Бәрәкәтләр койган яңгырлар!

Әле ярый, мин шушында туган,—
Таныш миңа бар да тумыштан:
Миңа монда тәпи басар өчен
Ай-кояшлар төшеп булышкан!

Җилфер-җилфер җилләр җитәкләгән,
Һәм, киңлекләр җәйгән кочагын...
Тауны ярып, чишмә чәчрәп чыккан,
Һәм дөрләгән гомер учагым!..
Туйдырмадың, җирем! Ә шулай да
Ярар иде күккә күчалсам.
Ярар иде...
кечкенәдән гашыйк
Бер йолдызын алып төшалсам!..

Мин шушында туган... Ярар иде
Галәмнәрдән кайтсаң, дим, урап...
Әле ярый җир җибәрми мине.
Әле ярый...
күкләр...
бик ерак!..

## Өрегез!

Таң беленгәч, төрле сукмаклардан
Җыелдылар туңып, бөрешеп.
Җыелдылар бергә өрешеп тә,
Чын этләрчә хәлләр белешеп.

Күтәрелеп чыкты алар таңда
«Бүген әле исән без!—диеп,
Ходай үзе эт көнен бит язган,
Туган икән—үсәрбез!» диеп...

Төне буе җил дә яңгыр булды,
Беләм, нәнәм, юкка өрмисез.
Хуҗаларыгыздай, фатир сорап,
«Ипотека» диеп йөрмисез.

Гомерем буе мин дә риза булдым
Табигатьтән тамган өлешкә.
Күтәрелеп өрмәгез сез, этләр,
Керәсем юк сезнең өлешкә!

Җыелгансыз Савин якларыннан
Баш саныгыз артса дистәдән,
Теләктәшләр булып, яңа дуслар
Аваз салыр яңа Бистәдән!

Сез кояшны уяттыгыз бугай,
Йоклаганнар йоклый, зарар юк.
Таң алдыннан этләр өрмәсен, дип,
Шәһәр Советыннан карар юк!

Берни дә юк монда кот очарлык,
Милли мәсьәлә дә түгел бу.
Һич югында мәнсез хуҗаларга
Өреп бушанырлык күңел бу!

Эт күңеле сөяк кенәмени,—
Кем сөт бирсен нәни үксезгә?
Өрегез сез, бу бит Чечня түгел,
Фәләстин дә түгел бу сезгә!

Сез этләрнең кайбер хуҗалары
Һич ким түгел Мәскәү баеннан!
Кайсыгызның хуҗасыдыр, баеп,
Мансард алды яңа районнан.

Берсе күчте яңа коттеджга
(Сыяр иде аңа бер авыл!),
Монда инде супер бурзай кирәк,
Торалмас бит Бобик караул?!

Өреш ярышында соңгы вакыт
Активлашты Савин этләре!
Утыз тугызынчы кварталның
Кай тирәдә бетә чикләре?..

Өрүдә бит бөтен хокуккыгыз,—
Өралганда өреп калыгыз!
Җиде төннәр уртасында, өреп,
Хуҗагызны искә алыгыз!

Ачык йөз бит бездә тәрегә дә!—
Толерантлык безнең фиркада...
Этләр бәйле булып торсын мени,
Бездәй бәйсез,
Демократик республикада?!

## Теләү

...Булмаганнар булмаса да,
булганнар булсын иде.
Уңмаганнар—гомер уңмас,—
уңганнар уңсын инде!

Карурманда абагалар
шау чәчәк атсын иде.
Илгә хаклык кайтты!—диеп,
пакъ җаннар кайтсын иде.

Җаһил җаннар, гаҗәпләнеп,
күзен акайтсын иде.

Җир белән бергә тоташтан
күкләр шаккатсын иде!

Коелсыннар соры кортлар—
ил бәхетен имүчеләр.
Торсыннар иде тәхеткә
җиңелгән җиңүчеләр!

Азды хәшәрәт!—дөньяда
бер күкрәү кирәк иде.
Искеләр бетте искереп,
Әллә яңадан инкыйлаб,
бер тетрәү кирәк инде?!

* * *

*Р.Г.*

Нечкәреп кала икән рух,
Җил җыры булып кала,
туган җир моңы була ул,
гөл моңы булып тама...

Шигырь таҗындагы илһам,
тылсым эчендә тылсым!
Сихәте иңсен җаныңа,
каныңа тәңгәл булсын...

Төн димә, уят, былбылым,
арыган күңелем йокласа.
Күр, сездәге саф энҗеләр
тирәндә икән ласа!..

Күрегез, сезнең шәрәфкә
мин бал эчтем бер касә.
«Алмады» мине, дим, юкка,—
алмас,—
хиссең йокласа!..

## Атланмаган атым

...Мирәт болыннан төнге атлар кешни.
Шулар кешнәгәндә күңел әллә нишли!..

Кайтып булмас көннәр, ел артында еллар,
Тавышлары килә, тик бикләнгән юллар!

Без картайгач, дускай, яшьләр өйләнделәр.
Без пошаман булгач, көлеп кинәнделәр...

Без ашыйсы ашны беркем бездән алмас.
Мең яшәлгән гомер бездән генә калмас.

Өмет атын җигеп, олы юлга чыктык,
Бары—булган инде! Куып килә юклык...

Кичергәннәр төште җанга көек булып.
Бездән күчергәннәр үсте бөек булып!

Без күрәсе күкне күрә алмас беркем.
Күрмәгәннәр күрсен, дөнья шундый иркен!

Гомерем аты бармый салган эздән генә,
Бүтәннәрдән калган—калмас бездән генә...

...Мирәт болынында төнге атлар кешни,—
Атланмаган атым...
авызлыгын тешли!..

## Югалттың...

Уйнап кына юкка чыктың сыман,
авазың юк... иске рәсемеңдә
елмаюлы калган чыраең...
Син ялгыштың бугай: элеккечә
эзләп табар бу, дип, мөгаен...

Ышанасы килми: кирәк булсам,
син үзең дә мине югалттың...
Мин үземне, килеп, тәрәзәмнән
елмаерсың диеп юаттым...

Таң җиле гөлләреңне тарады,
кызарып кояш чыкты да,
тәрәзәдән карады:
Яз килде—син юк!...
Ә каршыда песнәк сайрады...

Менә инде... сары яфрак оча,
тын беленә
күзге салкында...
Таң тудымы,
чакыра мине гүя
бер шәмәхә йолдыз балконда...
Көннәр буе тәрәзәмә карый,
талпына,
синең гөлең...

## Балачак хатирәсе

...Үсәбез шулай, дигәндәй, шатланып шушы җирдә,
солылар шаулый кыр тулып, солылар зеңли җилдә!

Моңлы әргән тавышлары, замана сагышлары,
нярең кыр җилләренә, берсе дә ялгышмады!..

Шушыннан гүя иң нмин хәбәрләр таратыла...
Җәй, әйләнеп, үчти итә тегермән канатында!..

Карабодай кырларында аңкып тора бал исе!
Төлке койрыгыдай тары! Килә шуны тарыйсы!..

Кыйгаклый казлар инештә, суы гүя көмеш лә!
Атылам әнкәй каршына, үзе кайтып килешкә!

Инде күптән сугыш беткән, кайтмады шул этиләр.
Кайтып килсә, каршысына чабар идем тәпиләп!

Болында гөлләр тирбәлә, җил исеп куйган саен.
Җилләргә кушылып җырлый каеным, апакаем!

Юл читләре әрем-кура, апайлар урак ура.
Һәр кич саен сыер эзлим, камыллар ера-ера...

Кыр капкасына килде Җәй. Анда Көз көтеп тора.
Канатлы аюдай шаулый, ни даулый Төклетура?

Җәй, әйләнеп, «гүләйт итә» тегермән канатында.
Балачагым җырлап калды көнбагыш арасында...

## Озату

Яшьлек китте...
урманнарга кереп,
Ә артыннан шаулап җыр калды...
тугайларда офтандылар җилләр,
бөгелә-сыгыла арыш чайкалды!

Башаклары болытларга тиеп,
офыкларга чапты дулкыннар...
Көн үзәге. Түбәсенә җитеп,
боек кояш торды сулкылдап...

Карап калдым киткән юлларына,—
китте Яшьлек синең рәвештә!
Син яшьлекнең үзе булып киттең,—
гарешләргә аштың, фәрештә...

Карап калдым киткән юлларыңа,
күзләремә тозлы яшь тулып...
Шаңгырап тора урман шул моңнардан,
сары яфрак коела яшь булып!

Тирән сулап бер көрсенде алан,
һәм, ухылдап куйды усаклар...

Кемне көтәм?
Урманнарның зәңгәр сукмагыннан
килеп чыкмас микән шул чаклар?..

*2005— 2006 еллар*

♣

Рауль
Мирхәйдәров

# ҮЗЕМ ХӨКЕМ ИТӘМ

РОМАН

## XVII

Америка гражданы Гвидо Лежаваны азат итеп прокуратурага кайтканнан соң, Камалов көтелмәгәндә килеп туган бу вакыйганы җентекләп тикшерде. Ул бигрәк тә Японецның үз теләге белән планлаштырылмый-нитми генә юлда оештырган күзгә-күз очрашу турында уйланды. Мондый очрашу турында прокурор күптәннән хыяллана, ничек тормышка ашырырга икән, дип баш вата иде. Булып үткән вакыйгаларны кайсы яктан карасаң да, алар Камалов файдасына иде, бары тик дөрес файдалана белергә генә кирәк. Шуңа күрә, ул беренче катта эшләп утыручы Татьяна Георгиевнага шылтыратты, кызны, прокурорның үзе шикелле үк, барысы да Танечка дип кенә йөртәләр иде. Бүлекнең агымдагы эшләре белән кызыксынгач, ул: «Прокуратураның әлеге яңа бүлегенә Канзафар Рөстәмов ничек карый?»—дип сорады. Танечка:

—Әйе, ул бик төпченергә тырыша, әмма сак кылана,—дип җавап бирде.

—Бик яхшы,—диде канәгатьләнеп прокурор, аннары елмаеп дәвам итте:—Мин егетләрнең кайберләре белән сөйләшеп алырмын, аның сезнең янга еш килеп йөрүеннән көнләшмәсеннәр.

Татьяна үпкәләп башын күтәргән иде, яңаклары алсуланып чыкты. Прокурор моны сизенде һәм килешүчән итеп кенә:

—Үпкәләмәгез, мин шаяртып кына әйттем, бернинди хыянәтче дә сезнең йөрәгегезне яулап ала алмаячак, мин моны еш күреп-сизеп торам,—диде.—Ә хәзер җитди сүзем шул: аның сезнең бүлеккә ешрак килеп йөрүе кирәк, ниндидер вакыйгаларның чишелүе якынлаша, Канзафаров аша дошманнарыбызга үзебезгә кирәкле ялган мәгълүматлар бирә алырбыз. Әүвәл сезгә үтенечем бар: бүген үк аңа сүз уңаенда гына бер мөһим вакыйга турында әйтегез, моны әле бик азлар гына белә. Сез кичә телевизордан «Шәрекъ» банкы ачылуны караган идегезме?

—Әйе, әлбәттә,—диде Шилова, прокурорның сүзне кайсы якка таба борганын аңлап җиткермичә.

—Шул презентациядә чыгышы белән грузин бер Америка гражданы, элекке мәскәүле, банк хуҗасының күптәнге дусты зур суммага «Шәрекъ» банкы акцияләрен сатып алды.

—Әйе, хәтерлим,—дип раслады Татьяна.—Ярты миллион долларга диярлек...

—Дөрес. Менә шул кешене банкет вакытында урлап киткәннәр. Шубаринның үз куркынычсызлык хезмәте дә бар, хәзер бит һәр җитди

Дәвамы. Башы журналыбызның 10, 11 саннарында.

оешма шулай эшли, шул егетләр барлык мөмкин булган элемтәләре, бигрәк тә җинаятьчеләр аша, төне буе шәһәрне айкап, астын-өскә актарып чыгалар, әмма американы таба алмыйлар. Урлау турындагы бу мәгълүмат рәсми булмаган чыганаклардан шунда ук полковник Жураевка барып ирешә, ул исә тиз генә минем янга килде. Америкалы бер-ике көн табылмый торса, барыбер бу эш белән рәсми рәвештә безгә шөгыльләнергә туры килер иде. Калган нечкәлекләрен сөйләп тормыйм, әмма без Шубаринның кунагын кем урлаганын ялгышусыз исәпләп чыгардык һәм аны азат итәргә булыштык... Менә шул. Сезнең бурычыгыз: бу яшерен серне оста гына итеп Рөстәмовка чишегез, Шубаринга бу эштә республика прокуроры белән угрозыск начальнигы булышканлыгын әйтегез. Бу хәбәр сезнең ике арагызны якынайтырга тиеш. Без сезгә тиешле шартлар булдырырбыз—төштән соң бүлектәге башка кешеләрне, төрле йомышлар кушып, таратып бетерербез.

Шубарин Мюнхеннан кайтып төшкәннән күп алдан, үзе әле хастаханәдә ятканда ук, Камалов Сенатор белән Миршаб һәм Японец арасын бозарга ныклы карар кылды. Хәзер аның өчен икеләтә кулай вакыт иде: ике якны да бер-берсенә каршы дошманлаштырырга яки ким дигәндә араларында ышанычсызлык тудырырга җай чыкты. Әлбәттә, Сенатор белән Миршабның кан дошманнары булган республика прокуроры һәм угрозыск начальнигының Шубаринга шундый бәяләп бетергесез хезмәт күрсәтүенә тегеләр шатланмаячак. Сенатор да, Миршаб та тормышта «син—мина, мин—сина» дип, үз файдаларын гына күрүчеләр буларак, Камаловның тик торганнан гына Японецны коткаруын аңламаячаклар. Шубарин аларга хокук саклау органнарының көтмәгәндә ярдәмгә килүләрен күпме генә аңлатырга тырышса да, тегеләр барыбер ышанмаячак, берәр төрле хәйлә-мәкер бар дип уйлаячак. Ә прокурор нәкъ шулай булуын тели дә иде. Шубарин кебек абруй-дәрәҗәле кеше белән Сухроб Әкрәмхуҗаев, Сәлим Хашимовларның дуслыклары зур куркыныч тудырырга мөмкин.

Тагын шунысы да әйбәт, Артур Александрович, Германиядә банк эшенә өйрәнеп яши-яши, Ташкентта инде бер ел булганы юк, элекке дуслары белән элемтәләре өзелгәндер, ә вакыт дигәнең үзара мөнәсәбәтләргә үз төзәтмәләрен кертә тора. Ул мөнәсәбәтләр яңарып киткәнче, тизрәк алар арасына кара мәче җибәрергә кирәк, чөнки хәзер банкир Шубарин Сенатор белән Миршаб өчен бигрәк тә ымсындыргыч затка әверелде бит. Әлбәттә, Канзафар Рөстәмов бүген булмаса, иртәгә бу яңалыкны Сухроб Әхмәтовичка илтеп җиткерер, ул аның өчен бик мөһим хәбәр булыр. Ә Сенаторның докторлык диссертациясе белән мәрхүм прокурор Азлархановның игълан ителмәгән эшләрен прокурор бик тәфсилләп өйрәнде, жентекле итеп язмача бәя дә бирде, шуны чит ил кунаклары китүгә үк тапшырырга кирәк иде. Камаловның уенча, бу хәлләрне ачыкларга иң әүвәл Шубарин ташланыр. Сенаторга исә ашыгудан файда юк, ул Японецка американлы Гвидо Лежаваны азат итүгә кемнәр булышканын, мөгаен, әйтмәстер, Сухроб Әхмәтович Японецның республика прокуратурасы белән элемтәләре турында, читләтеп булса да, мәгълүматларны түзем генә көтеп-эзләнеп торыр. Чөнки прокуратурада үз кешесе—Канзафар Рөстәмов тә бар бит әле.

Прокурор Камалов шунысын да яхшы белә—Россия халкы да, Үзбәкстанныкы яки башка күршеләрнеке дә бу үзгәртеп кору елларында законнарга һич тә ышанмый башлады. Россиядә булсын, Үзбәкстанда булсын, Брежнев вә Рәшидовлардан соң бер генә хөкүмәт тә җинаятьчелеккә каршы көрәш турында уйламады, җинаятьчелек шәһәр-авылларны күмеп китте. Камалов шунысын да ишетеп белә: завод-фабрикаларда, авыл җыеннарында гади халык бу җинаятьчелек турында, законнарның йомшак булуы, җинаятьчеләрнең хәзер рәхәтләнеп яшәве турында сүз кузгата да: «Прокурор

хет үзен якласын, хатыны белән улын үтергән кешеләрне эзләп тапсын»,— ди. Әлбәттә, Ташкентта күпләр республика прокурорының гаиләсе һәм үзе белән булган фаҗиганы яхшы белә иделәр. Гаделлек юклыгына ышанган кешеләрнең аһ-зары аны әле ныгып житмәгән саулыгы белән дә көрәшкә дәшә, әмма ул нинди генә аулар кормасын—барысы да юкка: эре корбаннар аның җәтмәләреннән бик оста кача бара иде. Туган ягыннан озак еллар аерылып торганга күрә, ана мондагы хәлләрне аңлау кыен иде, ә биредә барысы да бер тыгыз йомгак булып бөтәрләнгәннәр икән... Хәзер, үзгәртеп кору дигәннәре җимерелеп төшкәч, кешеләр өметләрен өзгән, беркаян да ярдәм көтеп булмый, бары тик үзенә һәм үзен шикелле көрәштәшләренә таянырга гына кала—безнең аллабыз бер генә бит—Закон. «Лидо»да сөйләшеп-килешергә тырышкан кешеләр арасын бозарга теләгән Камалов эчке сиземе белән абайлады: Шубаринга да тирә-яктагы бу мәхшәр ошамый, бу акыллы кеше илнең кай якка тәгәрәгәнен күреп тора, хакимияткә нинди намуссыз, карак кешеләр килеп ябышканын күрә. Кайбер көннәрдә Камаловта Японецны үзенә теләктәш итеп күрү теләге дә уяна. Әмма Камалов, әле хастаханәдә ятып чыкканнан соң да аңлый: чөнки банк эшләре белән мәшгуль кеше буларак, Шубарин намуслы эшмәкәрләр белән эш итәргә тели иде. Шуңа күрә, Артур Александрович соңгы кунакларын озатып бетерүгә, аның банкта икәнен белгәч, шунда ук шылтыратып: «Берәр сәгатьтән «Шәрекъкә» кереп карарга ярыймы?»—дип сорады.

—Безнең банкта исәп ачарга телисезме?—дип кызыксынды Шубарин.

—Мин бай кеше түгел,—диде Камалов.—Ул яктан кызыксынмассыз. Мин сезгә кайбер кирәкле булырлык кәгазьләр бирергә телим,—диде.

Нәкъ сәгать бердә Камалов элекке рус-Азия банкы бинасында иде инде. Кергәндә үк, хезмәтчеләр киемендәге егет, сакчы булса кирәк, лифт ишегенә таба ишарәләде, Камаловның таныклыгына карап та тормыйча:

—Рәхим итегез, прокурор әфәнде, Артур Александрович сезне өченче катта көтә,—диде.

Иркен зур керү бүлмәсендә күз бөтен диварны инләп алган рәсемгә төртелә, ул танылган үзбәк рәссамы Баһадир Җәләловның Көнбатышта күп тапкырлар күрсәтелгән, ә Японинядә, ике мәртәбә күргәзмәләрдә күрсәтелеп, бик танылган журналларда кабат-кабат басылган эше иде. Ниһаять, ул да үзенә лаеклы урын тапкан икән.

Гадәттә секретарь кыз утыра торган урында яшь егет иде, ул, кергән кешегә бер генә күз йөгертеп чыкты да, башы белән залга үтәргә ымлады, прокурор аның зәвыклы костюм кесәсендә корал барлыгын да чамалап алды. Вашингтонда куркынычсызлык хезмәте егетләре совет миссиясен саклаганда Камалов та шулай киенеп йөри иде. Аңа хәтта хәзер яшь егетләрнең берсе инглизчә дәшәр кебек тоелды. Әмма егет русчалатып ягымлы гына:

—Сезне көтәләр, прокурор әфәнде,—дип калын имән ишекне ачып җибәрде. Банк хуҗасының кабул итү бүлмәсендәге диварлар да түшәмгә кадәр шундый матур-шома итеп эшләнгән иде.

Прокурор ишектә күренүгә, Шубарин, урыныннан күтәрелеп, ана каршы атлады:

—Исәнмесез, Хөршид Азизович! Бу кабинетта мин иң беренче сезне кабул итәм, дип исәпләгез. Шәрекътәгеләр әйткәнчә, аягыгыз җиңел булсын!

—Амин, шулай булсын,—диде прокурор.—Ләкин без сезнең белән шундый эшләргә кереп буталдык, гадәти кешеләрчә яшәүгә тиз генә кайтып булырмы икән әле? Мин үзем башаяк буталган дөньяда яшим кебек, әмма сезгә һәм эшегезгә уңышлар телим.

—Рәхмәт!—дип, хуҗа тәрәзәсе ишегалдына карап торган урындагы ике тирән кәнәфигә ишарәләде.

Өстәлдә гадәттәге «Пахта» чәй-чинаяклары тора, чәйнек борынынннан сизелер-сизелмәс кенә хуш исле чәй пары бөркелә иде. Алар гадәттәгечә хәл-әхвәлләр, гаилә-балалар турында да сорашып тормыйча, беравык тын гына утырдылар. Болай сораштырып утыруның кирәге юклыгын һәр икесе дә аңлаганлыктан, Шубарин чәй ясарга кереште, ә Камалов аяк астындагы атташе-кейсны күтәреп тезләренә салды да, чырт-чырт итеп йозакларын ачты. Ул аннан күзгә бик бәрелеп тормаган, бер күләмдәгерәк ике папка алды да, аларны Шубаринга табарак этеп сөйли башлады:

—Ташкентка килгәннән бирле мине бер нәрсә интектерде: Үзәк Комитет вәкиле Сухроб Әкрәмхуҗаев минем шефым бит, менә шуның телдән сөйләгәннәре белән язып чыкканнары арасында бер бәйләнеш тә юк шикелле. Аның танылган юрист, газетларда кузгатырлык мәкаләләр авторы, фәннәр докторы булуы белән көн дә үзе белән аралашкандагы фикерләре һич кенә дә ярашмый бит. Баштарак мин моңа игътибар да итмәгән идем, чөнки, китапларын бик матур тел белән язсалар да, тормышта юньләп сөйләшә белмәүче язучыларны да, киресенчә, бик шәп сөйләп, рәтле яза белмәгән кызыл авызларны да күп күргәнем бар. Әмма ләкин Сухроб Әхмәтовичның үз теоретик хезмәтләреннән тормышта бик ерак торганлыгын күрергә туры килде. Монысы мин Аксайда, Акмал Ариповны кулга алганда килеп чыкты, шуннан мин аның тормышы белән җентекләбрәк кызыксына башладым. Аңа күзем ачылуның кайчан булганын сез беләсез инде. Бүген иректә йөрсә дә, ул минем өчен барыбер җинаятьче һәм кеше үтерүче булып кала бирә. Үзе исә гаепләүче төп шаһит Бармаксыз атлы Артем Парсегянның үлеменнән соң үзен бер гаепсез дип санап йөри. Ә Бармаксызның үтерелүе Хашимов кулы белән эшләнгәнлегенә иманым камил. Парсегян аның өчен бик куркыныч кеше иде. Мин ышанам, әле яңа дәлилләр, шаһитлар да табармын, ул үз дусты белән барыбер рәшәткә артына кереп утырачак әле—безнең арадагы мөртәтләр теләсә нинди җинаятьчеләрдән дә куркынычрак бит.

—Гафу итегез,—дип аның сүзен бүлдерде Шубарин.—Боларны нигә миңа сөйләп торасыз? Мине Сухроб Әкрәмхуҗаев белән Сәлим Хашимовларның тормышы һич кызыксындырмый, сез белмәгән ак таплар булып, үзем белсәм дә сөйләмәс идем. Минем гадәтләрем башкачарак, үзем дә бер гөнаһсыз фәрештә түгелмен, хөкемдар була алмамдыр. Минем хакта сез ялгышрак фикердә шикелле.

Прокурор кабинет хуҗасының бу сүзләрен, әйтерсең, көтеп кенә торган, тыныч кына дәвам итте:

—Нәтиҗәләр ясарга ашыкмагыз әле, Артур Александрович. Кемгә килгәнемне белеп килдем бит. Мин сезне дорфа рәвештә ишеткән-күргәннәрегезне миңа хәбәр итеп торырга кыстамыйм. Күптән түгел сезгә бер мөһим хезмәт күрсәткәнем өчен генә килгәнмендер дип тә уйламагыз. Вакыйга шулайрак килеп чыкты шул, мин сезнең кунагыгызны урлап алып китәчәкләрен алдан күрә алмадым, аңлыйсыздыр. Бу кәгазьләрне сезгә күптәннән бирергә җыенып йөри идем. Лежаваны урлау—бары тик вакытны һәм ике араны гына кыскартты.

—Гафу итегез, прокурор,—дип аның сүзен бүлдерде Шубарин.—Бу кәгазьләр Сухроб Әхмәтовичка кагылышлы булса, кире алыгыз, мин аларны ачып та карамаячакмын.

—Кайнарланмагыз әле, Артур Александрович. Мин бу ике папкада нинди кәгазьләр икәнен әйтәм, ачып карарсызмы-юкмы, анысы сезнең эш. Берсендә—партия Үзәк Комитетының административ органнарының элекке мөдире Әкрәмхуҗаевның докторлык диссертациясе, икенчесендә—Азлархановның төрле елларда язылган хезмәтләре. Бу ике материалның бер-берсенә бер тамчы кебек охшашлыгы турында минем бәяләмәм. Мин дә

фәннәр докторы бит, КГБның ябык уку йортларында төрле фәннәр укыткан идем, угрозыскыда эшләгәндә авыр яралангач, шунда күчкән идем. Һич башыма сыймый, ничек итеп үтерелгән Азлархановның бу хезмәтләре Сенатор кулына барып кергәндер, Әкрәмхуҗаевның бу кушаматы билгеледер дип уйлыйм. Алар беркайчан да таныш булмаганнар, монысын жентекләп ачыкладым. Кайвакыт, Әмирхан Даутовичның ул хезмәтләре Азлархановны прокуратура ишек төбендә үтергәндә анын дипломатында булгандыр ул, шул ук төнне аны Сенатор урлап алгандыр дип тә уйлыйм...

Прокурор әңгәмәдәшенә күтәрелеп карамыйча, ашыкмый гына сөйли, ул, әйтерсең, үзенә-үзе анлата шикелле, шулай да соңгы сүзләренең Шубаринга тәэсир иткәнен абайлап алды. Шубарин үзен тота белә, дулкынлануын сиздермәскә теләде, әмма барыбер йөзенә чыкты. Прокурор фикерен дәвам итте:—Ә бәлки, сезнең дустыгыз Азлархановны үтерүдә Сенаторның катнашы бардыр? Шуңа күрә бу кәгазьләрне сезгә тапшырырга уйладым да. Калдырыйммы, Артур Александрович, әллә Азлархановны сезнең дустыгыз дип ялгыштыммы?

—Юк, ялгышмадыгыз. Әмирхан Даутович минем дустым иде, бу кәгазьләрне карап чыгармын...

Камалов хисләнебрәк әйтеп куйды:

—Боларны сезгә биреп, мин мөнәсәбәтләребезне ачыклый төшәргә телим, без күп нәрсәләргә бер үк каланчадан карыйбыз шикелле...

—Алданмагыз, прокурор,—кабинет хуҗасы көлеп җибәрде.—Ә кәгазьләр өчен рәхмәт. Хәер, мин дә мактаныйм әле: Әкрәмхуҗаевның сөйләгәннәре белән язганнары арасында зур аерма барын сизенә идем инде.

—Әллә нәрсәләргә өметләнмим,—диде прокурор, урыныннан кузгалып.—Сез гадәти эшмәкәр һәм банкир гына түгел. Әгәр дә безнең яна эшлекләрнең чит илләрдә сезнең кебек дуслары булса, шуның өстенә финанс мөмкинлекләре һәм телләр белүләре дә булса, алар күптән чыгып шылган булырлар иде инде. Хәзер бит бөтен байлар төшләрендә дә Флоридада яки Майамида яшәүләрен күрәләр. Һич югында Хайфада яки Тель Авивта. Ә сез ун-унбиш ел элек үк чит илләргә гаиләгез белән дә еш чыгып йөрдегез, үзгәртеп коруның беренче елларында ук рәсми рәвештә үз миллионнарыгыз турында белдердегез. Сез хәтта, Мәскәүгә дә китеп бармыйча, Ташкенттагы гади үзбәк мәхәлләсендә йорт житкереп кердегез, анда сезне карты да, яше дә бик хөрмәт итә, ә әниегез кыз туганнарыгыз белән һаман әле Бохарада яши. Күрдегезме, мин сезнең хакта барысын да беләм бит. Бу төбәк, бирелдәге халык сезнең өчен чит-ят түгел дип ышанам...

Камалов саубуллашырга кулын сузды да, атташе-кейсны оста гына эләктереп, ишеккә юнәлде. Ишек төбенә барып житкәч, туктап Шубаринга дәште. Шубарин компьютерлы, телефонлы һәм тагын прокурорга таныш булмаган приборлар тезелгән өстәле янында иде инде.

—Мине һаман бер сорау борчый: әйтергәме-әйтмәскәме дип баш ватам. Хәзер менә әйтергә булдым. Әле тагын кайчан күрешербез, әллә бер дә күрешмәбез дә. Сез хаклы: без ике як ярда торабыз. Менә нәрсә әйтергә теләгән идем. Мин дә, полковник Жураев та сизенә—Талиб артында торучы кешеләр дә, ул үзе дә сезне тынычлыкта калдырмаслар. Ул, әлбәттә, махсус исемлектә тора, хәзер аерым исәптә тотарбыз. Сез бит беләсез, җинаятьчеләр юридик яктан бик белемле хәзер, аларга танылган адвокатлар кинәш бирә, шуңа күрә үзләрен эләктереп алу да җинел түгел. Гвидо Лежава кайтып киткәч тә, без аларның сездән нәрсә таләп итәргә теләгәннәрен белә алмыйбыз. Бары шунысы гына билгеле—алар акча каерырга да теләмәгәннәр, бернинди шарт та куймаганнар. Әгәр дә без Талиб Солтановның Мюнхенга сезнең белән очрашырга ни өчен килгәнен белә алсак, нишләргә икәнен чамалар

идек. Сез Жураев белән бездән ничек кенә читләшергә теләсәгез дә, барыбер сезнең дошманнарыгыз—безнең дә дошманнарыбыз. Яна заман яңа жинаятьчеләрне тудыра тора. Сезнең банк тирәсендә яна жинаять төене төйнәлеп килә, без аны чамаласак та, тәгаен генә белә алмыйбыз әле—алар сиздереп куйдылар инде. Безгә бер-беребезгә булышырга кирәк. Ышаныгыз, үзегез генә ерып чыга алмассыз. Хезмәттәшлек итик, димим, анысына өметләнмим дә. Әгәр дә Гвидо Лежава белән булган шикелле берәр житди хәл килеп чыкса, сез шундук безгә хәбәр итәргә тиешсез. Сез Германиядә йөргәндә, биредә хәлләр кискен үзгәрде. Бер жинаятьче әйткәндәй, сез башка илгә кайтып төштегез. Сезнең дошманнарыгыз жинаятьчеләр арасында гына булмаска мөмкин. Сизгер булыгыз. Сезнең банк бик күпләр өчен мавыктыргыч, сез беләсез, бездә әзерне эләктерергә генә торалар.

Юлда очрашкач, мин сезгә визиткамны биргән идем, анда эш телефоным да, өйнеке дә бар. Әгәр дә алай элемтәгә керергә теләмәсәгез, исегездә тотыгыз—минем шоферым Нортухта исемле, ул ышанычлы, тикшерелгән кеше. Аны табарга тырышырсыз, ул безгә жиде төн уртасында да очрашу оештырыр. Кирәк булса, диюем. Онытмагыз—егет Нортухта исемле...—прокурор ачылган ишеккә таба атлады.

## XVIII

Прокурор чыгып киткәч, Шубарин, телефон шылтырауларына да игътибар итмәстән, иркен кабинетында шактый озак арлы-бирле йөренде. «Бу «мәскәүле» үз вакытында банкта төрле яшерен эшләр башкарылуы турында үзенә мин хәбәр иткәнне чамаладымы икән әллә? Мин бит банк түрәләренең ришвәтче икәнлекләрен, ялган кооперативлар оештырып, илне талауларын, миллионлаган акчаларны үзләштереп, илне бөлгенлеккә, икътисадны жимерелүгә китерәчәкләрен хәбәр иткән идем,—дип уйланды ул. Үзе үк жавап та бирде:—Юк, чамаламады. Бу хакта прокурор белсә, сөйләшү дә башкачарак булыр иде». Аның хат-хәбәреннән соң Мәскәүдә дә, Ташкентта да байтак кешеләр кулга алынып, төрмәгә ябылды. Ул вакытта әле прокуратура бик көчле иде, кулына кергән мәгълүматлар буенча тиз һәм белеп эш йөртте, ә Шубарин бик саллы мәгълүматлар тапшырган иде. Ул үз хәбәренең бәясен дә белә, нәтижәләре ничек буласын да анлый. «Мөртәтлек, сатлыкжанлык бездә аеруча каты жәзага тартыла—аңа гомерең белән дә жавап бирергә туры килә»,—дип язган иде ул.

Ул, сонлап булса да, шунысын анлады: аның хаты да, башкаларның шундый йөзләрчә хатлары да илне коткарып кала алмаячак, айдан-айга, елдан-елга тәүлекләр буе ватанны талау, аның бар байлыгын чит илгә чыгару дәвам итә. Камалов «сул» һәм «уң» матбугат вәкилләренең, либералларның, яңа «демократлар»ның, бигрәк тә коммунистларның Горбачевка бер генә сорау бирмәүләренә гажәпләнә: «Илнең алтын запасы кайда?»

Горбачев хакимияткә килгәндә, илнең алтын запасы өч йөз илле тонна булып, ул хакимлек кылганда еллык табыш та кырык тоннадан ким түгел иде. Инде Горбачев киткәндә ул запас нибары егерме-утыз тоннага гына калды. Кая китеп бетте сон ул? Горбачев заманында да халык, бер генә көн дә бәхетле, тук тормышта яшәмәде бит. Ул бәндәдән тагын күп нәрсәләр сорарга мөмкин булыр иде. Ул түрә булып утырган биш ел эчендә Көнбатышка газ һәм нефть үткәргечләрдән көн-төн газ һәм нефть акты. Шунда ук көн-төн эшелон-эшелон урман, мәгъдән, металл китеп торды. Ил, бер генә мех сату аукционын да калдырмыйча, миллионлаган ин кыйммәтле мехлар—тиреләрне шунда озатты. Кайда сон аларны сатудан килгән акчалар?

Әйе, Горбачев һәм аның иярченнәреннән бик күп нәрсәләр турында жавап

таләп итәргә булыр иде. Ләкин ул буш куык, кызыл авызга борылып та карыйсы килми. Әмма ни-нәрсә генә уйлама, ни-нәрсә генә эшләмә—шул мөртәтнең «эшчәнлегенә» барып төртелә, аны һич читләтеп үтеп булмый... Бу әле бик озак, дистәләрчә елларга сузылачак. Шубарин банкир буларак моны бик яхшы анлый. «Шунысы ярый,—дип уйлый Шубарин,—без Горбачевка бәяне Камалов белән бер төрле бирәбез. Прокурор аның турында: «Югары урынга үрмәләгән убыр»,—дип бик дөрес әйтә. Ул белеп сөйли инде, гомере буе шундый убырларга каршы көрәшкән бит.

«Юк, Камалов минем прокуратурага язган хатым турында белми, белсә, кыюрак эш итәр иде. Әйтик, Миршаб белән Сенаторны тотып бирүне үтенер иде. Прокурор алар турында Шубаринның бик күп нәрсәләр белгәнлеген сизенә, төп гаепләү шаһиты Парсегян да ул кадәр белмидер әле.

—Беләме-белмиме,—дип үртәлә башлады Шубарин,—анардан мина ни җинеллек? Бөтен яклап уратып алдылар—җинаятьчеләре дә, элекке коммунистлар да, ә хәзер житмәсә прокурор койрыкка басты. Сизенәме, әллә белә үк микән—анын әле туып кына килгән банкы тирәсендә болытлар куера башлады бит... Беләдер, беләдер!

Хәзер, Камалов көтмәгәндә килеп киткәч, Сенатор белән Миршабка карата да анык бер фикергә килергә кирәк. Чынлап та, үтерелгән Азлархановның фәнни хезмәтләре ни рәвешле Сенатор кулына килеп керде икән? Сенаторның докторлык диссертациясе белән Азларханов хезмәтләре бер үк икәненә Шубарин шикләнми иде. Аның прокурор бәяләмәсен дә, үзенең элекке юристконсульты Азлархановның баштагы хезмәтләрен дә укып карыйсы килде, ул журналлар өстәлчеге янына юнәлде. Кулына эләккән беренче папка Сенаторның докторлык диссертациясе булып чыкты, ул аны ачып та карамыйча кире куйды, чөнки анын белән «мәскәүле»дән дә алда күптән танышкан иде инде, әмма прокурорга ул турыда әйтеп тормаган иде. Икенче папканы алып, андагы кәгазьләрне сәгатьтән артык укып утырды. «Мәскәүле» биргән бәяләмә белән танышкач, үзенең дусты прокурор Азлархановның мәкаләләрен, чыгышларын тагын бер кат күздән кичерде, Азлархановның алдан күрүчәнлеге, фикерләү тирәнлеге, сизгерлеге тан калырлык, һәр язган юлы заманча, янача укыла иде. Шикләнерлек урын юк: Сенатор элекке юристконсультның хезмәтләрен үзләштергән.

—Их, Әмирхан Даутович...—диде ирексездән Шубарин, дулкынланып янә бүлмәсе буйлап йөри башлады. Азларханов хәзер ана бик кирәк, ана гына түгел, бөтен җәмәгатьчелеккә кирәк иде!

«Аның каберенә барып килергә кирәк булыр,—дип, банкир папкаларны тимер сейфка бикләп куйды.—Мина бу ачышым нәрсә бирә соң? Мин нәрсә эшләргә тиеш? «Мәскәүле» нигә мина ярдәм итәргә тели дә, нигә Сенатор һәм Миршаб белән араны бозарга җыена? Мин ана ни өчен кирәк икән?— Шундый сораулар белән ул Сенаторның серен саклаган папкаларны тиз генә кузгатмаска карар кылды.—Бәлки, Сенатор белән Миршабның көннәре санаулы гына калган дип уйлыйдыр? Ул бит аларны туп-туры җинаятьчеләр, кеше үтерүчеләр дип атады. Мөгаен, ул әлеге «сиам игезәкләре»нең үзенә мәкер әзерләгәннәрен беләдер, анда мин дә катнашырга тиештер дип уйлыймы әллә? Шуна күрә мине алардан аерып алырга телидер. Үзе белән көрәштә кемдер җинәргә тиеш бит. Яки-яки, тәгәлрәге: кем-кемне? Юк, ул мина үз дошманнары белән аралашмаска дип кистереп әйтмәде, үз ягына авышырга ачыктан-ачык тәкъдим дә ясамады, әмма кемнең кемлеген анларлык итеп әйтте,—дип Камалов белән сөйләшүен тикшерүендә булды Артур Александрович.—Ә минем тормышымны ул яхшы белә, юкса Сенаторның докторлык диссертациясен мина бирмәс иде, минем өчен Азлархановның кем булганын да анлый. Минем Бохара белән Ташкентта куйдырган кабер

ташларын да белә. Бу хакта ана, әлбәттә, полковник Нураев сөйләгәндер, ул да бит яшьрәк чакта Әмирхан Даутович белән бергә эшләгән. Әмма Мюнхенның «Бавария» стадионында аның Талиб Солтанов белән очрашканын ул каян белгән? Талибның фамилиясен, кем икәнен Шубаринга беренче булып прокурор әйтте бит. Моны кичекмәстән ачыкларга кирәк иде. Ә бәлки, прокурор Уралдагы лагерьда утыручы «мамык Наполеоны»нын да Германиягә килеп киткәнен беләдер.

Әгәр дә анысын да белсә, Шубаринның банкы турында да яңа мәгълүматлары бардыр, монысы күңелсез хәл, билгеле. Прокурор, шуңа күрә дә банкка килеп, ике арада әйбәт мөнәсәбәтләр урнаштырырга телидер. Шубаринга баш ватарлык хәлләр бар шул—Камалов кебек кешеләр тиктомалдан гына очрашып йөрмиләр. «Мәскәүле» аның тормышы турында нәрсәләр белә дә, нәрсәләрне белми—болар Шубарин өчен табышмак булып кала әле. Бер нәрсә ачык: ул аз белми, тагын да күбрәге турында да сизенәдер. Камалов барысын да дөрес чамалап бетермидер бетерүен, Азлархановның үлеменә дә Сенатор гаепле дип ялгыша, аны Коста үтергән бит. Коста атарга мәҗбүр булган—Әмирхан Даутович, яраланса да, кейсны кулыннан ычкындырмаган. Аны Сенатор урлап алган.

Камалов турындагы уйлары артка чигенде. Ул, ниһаять, Азлarханов белән Сенатор беркайчан да очрашмаган булсалар да, Азлархановның кәгазьләре соңгысы кулына ничек килеп эләккәнен аңлады. Күрәсең, Әмирхан Даутович буш вакытларында теоретик эзләнү-тикшеренүләр белән дә шөгыльләнгәндер, Шубарин белән Заркәнтнын «мамык Наполеоны» ашыгыч кына яшерен рәвештә Лас-Вегастан китеп Нукуска барган сәгатьләрдә Азлархaнов үз карашынча иң кирәкле, иң кыйммәтле документларны гына үзе белән алгандыр. Алар да бит кинәт кенә үлеп киткән Рәшидов янына беренчеләрдән барып житәргә ашыкканнар. Коста кейстагы әнә шул кәгазьләр өчен Азлархановны атып үтергән дә, ил күләмендә ришвәтчелек һәм җинаятьчел икътисадка караган ул документлар арасында танылган юрист һәм рәсми кешенең күп еллар эшләгән тәҗрибәсе тупланган фәнни хезмәтләр дә булган.

Республика прокуратурасы бинасында Азлархановның үтерелүенә ирексездән шаһит Сенатор аның кейсы төнгелеккә икенче каттагы сейфта калганын белгәч, аны урларга карар кылган. Ләкин, кейсны урлагач, ул аны шундук Шубаринга тапшырмаган, бары дүрт сәгатьтән соң гына биргән. Прокуратурага һөҗүм итеп, анда ике кешене атып үтерү бәрабәренә генә кейс аның кулына килеп эләккән.

Шулай итеп, Сенаторның докторлык диссертациясенең сере хәзер генә ачылды. Әмма бу ачыш Артур Александровичны бер күңелсез уйга да этәрде: Сенатор аны бик кыю һәм каты алдаган. Ул үтерелгән прокурорның хезмәтләрен урлап кына калмаган, Шубаринга тапшыргaнчы, аларның барлык күчермәләрен дә алган. Төп документларны Шубаринга биреп, ул аның ышанычын казанган. Әлбәттә, Шубарин йозакланган сейфны алып алданган, андагы кәгазьләрнең күчермәләрен ксерокста төшереп алу мөмкинлеге турында уйламаган да. Ксерокс ул заманнарда сирәк очрый торган прибор, аның район прокуратурасында да булганлыгын Шубарин соңлап кына, бөтенләй башка бер очрак белән белде. Ләкин бу бик саллы дәлил иде. Ә Сенатор, ул юклыктан файдаланып, Тулкун Назаровичны бугазыннан алган һәм бик тиз генә партия Үзәк Комитетында җылы урынга үрләгән. Хәзер инде бу вакыйгада кейстагы кәгазьләрнең нинди роль уйнаганы ачыктан да ачык.

«Бу нинди күңелсез ачышлар көне соң!—дип сүгенеп куйды Шубарин, өстәле янына килеп. Соңлап күзе ачылу аның өчен рәнҗүгә тиң иде, аны бер малай шикелле итеп алдадылар бит. Ә хәзер андый документларның бәясе бермә-бер арта. Элек, ныклы хакимият барында, кискен үзгәрешләр,

житәкчелеккә яна кешеләр килеп тулу мөмкин булган хәл иде. Бүген исә, хакимиятне янача бүлгәләү заманында, кайбер документлар хөкүмәт кризисын яки жылы урыныннан колак кагуны да китереп чыгарырга мөмкин. Хәзерге хәбәрдарлыкта кейстагы кәгазьләр үтергеч көчкә ия иде. Ә хәзер алар дан сөючән, намуссыз Сенатор белән Миршаб кулында. «Мин моны белми йөрим дип уйлыйлардыр әле»...—дип үз фикерен ныгытып куйды Шубарин.

Прокурорның көтмәгәндә килеп китүе Артур Александрович белән аның банкы тирәсендә әлегә билгесез вакыйгалар куерганын сөйли, димәк, сак булырга кирәк. Өстәлдәге телефоннарның әле берсе, әле икенчесе шылтырап торса да, Шубарин аларга әйләнеп тә карамады, ул әле һаман да Камаловның килеп китүе турында уйлана иде. Аны бигрәк тә прокурорның чыгып барганда әйткән сүзләре сагайтты: «Вакыйга кискен үзгәреш алды... Үзегез генә ерып чыга алмассыз...»—диде Камалов. Вакыт-вакыт кулы телефонга үрелә, Сенаторның өенә шылтыратып, аны «Лидо» ресторанына чакырасы, гадәти урында туп-туры: «Ни өчен син, Азлархանов хезмәтләрен урлап, аларны үзеннеке итеп бастырдың? Ни өчен аның яшерен документларының күчермәләрен алдың?»—дип сорыйсы килә. Ләкин соңгы мизгелдә аны бу ниятән нәрсәдер тотып кала: Шәрекъта алай маңгайга бәреп сорау гадәте юк, башка юл эзләргә кирәк иде. Әмма нинди юл?! Башына бер юньле уй да килми. Телефоннарының берсе һаман да үҗәтлек белән шылтыравын дәвам итә, әйтерсең, шылтыратучы аның өйдә икәнлеген белә иде. Телефон саннарын күрсәткечтә күргәч, Үзәк Комитеттан кемдер шылтыратканын аңлады: беренче «395» саны бары тик Ак йортныкы гына иде. Ул ялгышмады, Хрущев заманнарында ук үрли башлап, бу үзгәртеп кору елларында да жылы урынын саклап кала алган карт төлке Тулкун Назарович иде бу.

—Хәерле көн, Артур. Банкың ачылу белән котлыйм!—диде бу үтә хәйләкәршома кеше.

Шубарин аның белән күптән, инде елдан артык күрешмәгән иде, әмма тегенең тавышы һаман да һавалы-дәрәжәле ишетелде. Шулай да ялагайлану да сизелә иде. Японец бер вакытта да ялгышмый, кешенең тавышыннан ниңәрсә турында сөйләргә теләгәнен аңлый, ә бу Шәрекъта бик күпне аңлата, күп очракта сүз сөйләп тору да кирәк булмый.

«Нәрсәдер сорарга жыена бугай»,—дип уйлады Шубарин һәм хаклы булып чыкты.

—Артур, ярдәмең кирәк,—диде Тулкун Назарович.—Көтмәгәндә Төркиягә командировкага бару жае чыкты. Истанбулга дәүләт хисабыннан бармый калу гөнаһ булыр. Ә командировка акчасы—көненә ун доллар гына, мине беләсең—бу бит минем өчен тиеннәр генә. Сина ниндидер америкалы ярты миллион доллар биргән, диләр. Булыш әле...

Шубарин башта Германиядә өйрәнгән гадәте буенча «Юк бит»...—димәкче иде, ләкин шунда ук үзенең Мюнхенда түгел, ә Ташкентта икәнлеген исенә төшерде. Тулкун Назарович үтенечен кире кагып булмый торган кешеләрнең берсе иде. Аннары Шубарин прокурор киткәннән соң, үзен борчыган сорауларга Ак йорттагы бу бай хәзер үк ачыклык кертергә мөмкин икәнлеген абайлап алды.

—Сезгә мең доллар житәрме?—дип сорады ул кыска гына.

—Бик житә,—диде тегесе, куанып.

—Алайса, хәзер үк килеп алыгыз, иртәгә мин Мәскәүгә китәрмендер.

Шубарин аның, долларлар алгач, теләсә нинди сорауларга да жавап бирәчәгенә ышана, ә аның жаваплары мең долларлык булырга да мөмкин иде. Телефон трубкасын куйгач, ул янадан сейфның шифрлар санын жыйды да, башланган йөз долларлыклар төргәгеннән менен санап алды. Өстәле янына килеп, аны үз банкы исеме язылган конвертка салып куйды.

Үзәк Комитет кешесе озак көттермәде, чөнки машинасы гел ишегалдында гына тора, ә банк янәшәдә генә. Артур Александрович телефоннан хезмәтчеләренә чәй әзерләргә кушып та өлгермәде, диварда таныш тавыш ишетелде, шунда ук ике катлы ишекне дөбер-шатыр ачып, бүлмәгә кунак килеп керде.

—Әй-яй, шәп җиһазлагансың син бу апартаментларыңны! Гел көзге, гел кызыл агач, шомартылган җиз, бәллүр люстралар... Болай байларча кылануың өчен элек беренче партбюрода ук кирәгеңне бирерләр иде,—диде ул кирә-керешкә.

—Бирмәсләр. Бу бит шәхси банк. Бернинди партиягә дә буйсынмый ул. Бюро, пленумнар, съездлар минем өчен куркыныч түгел,—диде хуҗа һәм кунакка каршы атлады—Шәрекъ гадәтләренә буйсынырга кирәк иде. Алар кочаклашып күрештеләр, хәл-әхвәл сораштылар.

Шубарин кунагын тәрәзә буендагы өстәлчек янындагы биек ике кәнәфи ягына янына чакырды, анда әле яңа гына пешерелгән чәйле чәйнек тора иде инде. Тулкун Назарович моннан ике сәгать чамасы элек кенә прокурор Камалов утырган кәнәфигә барып утырды. Ә бүлмә хуҗасы язу өстәле янына килеп, долларлар салынган конвертны кулына алды. Ул аны Ак йорт кешесе алдына салып елмайды да:

—Истанбулда матур көннәр үткәрүегезне телим, анда шундый гүзәл каһвәханәләр бар... Илләре дә гел яшеллеккә төренгән, табигате йомшак, дүрт диңгез ярлары буенда бит...—диде.

—Кызганыч, минем белән бара алмыйсың,—дип, Шубарин кулыннан хуш исле кытай чәе салынган пиаланы алып җавап бирде кунагы.

—Борчылмагыз, хәзер заманалар башка, сезнең дә кесәгездә даими чит ил паспорты бар. Мин сезне, һичшиксез, үзем белән Европага алып барырмын әле. Банк эшләре буенча миңа анда еш чыгып йөрергә туры килер...—Шубарин чакырылган кунагын шунда ук эшлекле сөйләшүгә тартты:—Мин сездән күптән булып үткән бер вакыйга турында сораштырырга тели идем. Хәзер инде ул, вакытлар үтү белән, алай зур әһәмияткә дә ия түгелдер. Әмма кызыксынуымны һич җиңә алмыйм, архивтагы барлык эшләргә дә нокта куясым килә. Минем табигатем шундый инде, гафу итегез,—диде. Кулына көтмәгәндә долларлар килеп кергәннән башы әйләнеп киткән кунак аңа ярдәм итәргә ашыкты:

—Кадерле Артур, ике арабызда нинди серләр булырга мөмкин? Сиңа теләсә нинди томанлы вакыйганы ачып бирергә әзермен. Шат кына булачакмын.

—Ә вакыйга, чынлап та, күптәнге, ул элекке район прокуроры Әкрәмхуҗаевның бик тиз генә өскә үрләвенә кагыла. Мин ул вакытта Парижда идем, кайтсам,—ул инде Ак йортта утыра! Мондый үрләүләр безнең якларда еш булмый. Ул ымсынган һәм алган җылы урын сездән тора иде. Ни өчен сез ярдәм иттегез, ни өчен ул сездә яклау тапты? Тагын да катырак итеп әйтсәм—сезгә каршы аның нинди дәлилләре бар иде? Ни өчен сез аңа теләктәш булдыгыз? Ничек итеп бу җылы урынны аңа бирдегез?

Уйлары белән инде Истанбулда йөргән кунак рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

—Артур, сиңа гаҗәпләнүдән туктый алмыйм, бигрәк зирәк-сизгер кеше син. Ул мине ике сәгать буе куркытып-өркетеп торганда, син өстәлем астында утыра идеңме әллә?

—Куркытып?—дип ирексездан ычкындырды Шубарин.

—Әйе, куркытып һәм бик белеп, әйтсәм-әйтим!

Японец кәнәфигә ята төште:

—Рәтләбрәк сөйләгез әле,—диде.

—Әлбәттә. Юкса, син бер нәрсә дә аңламаячаксың. Хәзер, туй үткәч, дөмбергә, дигәндәй, аңладым инде: алар Миршаб белән бик шәп

әзерләнгәннәр, мина гына түгел, барлык туганнарыма карата да мәгълүмат туплаганнар. Бигрәк тә син яхшы белгән туганым Үткүр турында. Ул вакытта Сухроб белән Миршаб синен булышлыгын белән Югары судта эшли иделәр инде. Көннәрдән бер көнне эшемдә телефон шылтырый. Сухроб бик үтенеп үзен кабул итүемне сорый. Шуннан ул ике папка күтәреп килеп керә дә, Үзәк Комитеттагы бер жылы урынга урнаштыруымны таләп итә. Мин: «Булмый»,—дигәч, шул ике папканы алдыма этәрә, аларда туганым Үткүр турындагы документлар икән. Бигрәк тә куркынычлысы Үткүргә кузгатылган жинаять эшенен соңгысы иде. Ул инде үзгәртеп кору чорында, Горбачев реформаларыннан һәм хәбәрдарлектән исергән автобаза кешеләренен барысы да диярлек төшемле рейс өчен директорлары алардан акча жыйганны сөйләп, ана карата жинаять эше кузгатуны сорагач булды. Ә Үткүр өлкәдәге ин зур автобаза белән житәкчелек итә, анын кул астында рефрижераторлар, күп йөк йөртә торган тагылмалы автомашиналар бар иде. Алар йөк төяп күрше республикаларга, хәтта чит илләргә дә бара иделәр. Ләкин ул вакытта Үткүрне син яклап калдын, дөресрәге, Ашот белән Коста кешеләре—алар шоферларны гаризаларын кире алырга мәжбүр иттеләр. Сухроб белән Сәлим, әгәр дә мин аларга үзләре теләгән жылы урыннарга утырырга ярдәм итмәсәм, ул жинаять эшен янадан казып чыгарабыз, дип яный башладылар. Бу мине куркытырга теләү түгел идемени?—Кунак бераз тынып торды да сүзен дәвам итте.—Хәер, башлагач, әйтеп бетерим инде—Үткүрнең ришвәтчелеген фаш итүдән куркып кына түгел, бигрәк тә хокук органнарында үз кешемне булдырасым килә иде. Сухроб үзе, әгәр ярдәм итсәм, мина турылыклы булачагын сиздерде. Шунын өстенә, ул мина кызыклы шәхес булып та күренде, анын матбугатта чыккан мәкаләләрен сокланып укый идем. Аннары, Ак йортыбыз сәләтле, тирәнтен уйлый торган, демократик карашлы кешеләргә мохтаж иде—ә ул мина нәкъ шундый булып тоелды да.

—Ә соңыннан анын турындагы фикерегез үзгәрдеме?—дип тыныч кына сорады Шубарин, әмма аны жавап бик кызыксындыра иде.

—Ул акыллы, тиз тотып ала торган кеше—анысы бар, ләкин шуннан артыгы юктыр. Сонрак, үзе белән бергә эшли башлагач, мин анын мәкаләләрендәге тирән карашларына, ә көндәлек тормышта бик тар фикерле булуына гажәпләнә бардым. Мин бит, ул безгә килгәч, үзгәртеп кору чорында таулар күчербез—законнарны, хәтта Конституцияне нигезеннән үзгәртербез, дип көттем. Хакимияттәге түрәләрнең хокук мәсьәләләрендәге наданлыклары турындагы мәкаләләре искиткеч иде бит! Соныннан аңладым: үз вакытында мина да язып биргән шикелле, ана да докторлык диссертациясен нindидер акыллы-белемле кеше язып биргән булырга тиеш. Мин хәтта үз элемтәләрем аша ул кешенең кем икәнлеген белергә тырышып карадым. Ләкин мина, андый кеше безнең республикадан булмас, әмма бездәге хәлләрне яхшы белә, дип жавап бирделәр. Артур, әйт әле, Сухробнын Ак йортка ничек, нинди юллар белән килеп керүе ни өчен кызыксындыра сине?—дип кинәт кенә сорап куйды Тулкун Назарович. Анын күнелендә йокымсырап яткан карт төлке уянып, Истанбулда үткәрәчәк матур көннәрен да оныттырды.

Артур Александрович үзенең кем белән эш иткәнен яхшы белә, шуна күрә әңгәмәдәшенең вакытлы сокланууларына шаккатмый, анын ни өчен банкир тиктомалдан Сенатор турында кызыксына дип уйланачагын аңлый иде. Ул хәтта анын соравына шатланып та куйды: ялгызы калып, фаразлар корып яки өченче кешеләр аша мәгълүматлар жыйганчы, менә хәзер күнелле минутларда жавап алуы Тулкун Назарович өчен кулай иде, әлбәттә.

—Сез беләсезме икән, әллә юкмы—ул бит күптән түгел генә төрмәдән кайтты. Хәзер ул эшсез, алай да элекке дәрәжәсен кайтарырга хыяллана, ә хәзергә минем банкта яхшырак берәр эштә эшләп торырга тели. Шунын

өчен анын ничек, нинди юллар белән Ак йорттагы бер кәнәфигә утырганын беләсем килә. Әйе, мин ана да, Миршабка да Югары судта лаеклы вазифалар алырга ярдәм иттем. Әмма, сезне бугазыгыздан алганда, ул безнен күптәнге дуслар икәнлегебезне белгән булырга тиеш. Миннән яшереп, астыртын гына минем дусларымны куркытырга теләүче булуы мина ошамый,—дип сүзен тәмамлады Шубарин.

—Борчылма, Артур, күптән булган хәл, мин аны оныттым да инде. Безнен бөтен тормышыбыз үзара килешүләрдән тора бит. Әгәр дә прокурор Камалов булмаса, Сенатор, мөгаен, шактый югары үрмәләр иде. Хәзер инде, чынлап уйлаганда, шул ук Камалов аркасында ул артык күтәрелә дә алмас. Камалов республика прокуроры булганда, ирektә йөрсә дә, Сухробны ирекле кеше дип санарга ярамый. Мин Камаловны беләм, ул сөйләшү-килешүләргә бара торган кеше түгел. Кинәшем шул: рәсми рәвештә Әкрәмхуҗаевны үзенә якынайтырга ашыкма, шәхси аралашып, акча белән яки башкача ярдәм итәргә ярыйдыр. Алда күз күрер, хәзер бит вакыйгалар тиз үзгәреп тора: йә арба ватылыр, йә ишәк, йә падишаһ үлеп китәр...—кунак сүзләрен беткәнгә санап, урыныннан күтәрелде, күрәсен, вакыты кысан иде: Истанбулга самолет атнага бер генә—чәршәмбе көннәрдә генә, димәк, иртәгә оча.

Кунак чыгып китүгә, Шубарин кулындагы «Роллекс» сәгатенен ак алтын телләренә күз салды—әбәткә әле шактый ерак иде. «Әй, көн! Дөресрәге, көннәр»...—дип авыр сулады Шубарин. Ташкентта шулчаклы җигәрләр дип уйламаган иде, ә бит Мюнхеннан кайтканына бишенче көн генә әле. «Әйе, карт төлке мен долларны эшләде дә эшләде инде»,—дип уйлап куйды Артур Александрович. Сенаторнын кем икәнлеге тулысынча ачылды: аны шаулаткан диссертациясе дә, матбугаттагы мәкаләләре дә элекке юристконсультныкы булып чыкты, тоткан да урлаган, моны Тулкун Назарович та раслады. Шулай итеп, Сенатор турындагы төрле фаразлар, гөман итүләр, шик-шөбһәләр үзләреннән-үзләре коелдылар да төштеләр.

## XIX

Канзафар көтмәгәндә генә шылтыраткач, Сенатор беразга чемодан тулы долларлар турында да онытты. Шубаринга Камалов булышкан икән. «Нәрсәне анлата сон бу?»—дип, ул тирән кәнәфигә чумып, озак уйланып утырды.—Мафия кулыннан коткарып калган, ди,—ул үз-үзенә сөйләнә иде.—Димәк, бу юлы да Жураевтан башка эшләнмәгәндер. Берүзе коткара алмас иде, бик хәтәр эш бит бу...

Жураев Шубаринны яхшы белә, аларнын уртак дуслары—мәрхүм прокурор Әмирхан Азларханов бар иде. Шунын хезмәтләре мина бик ярап куйды бит... Ә хәзер угрозыск начальнигы Камалов белән тыгыз элемтәдә, алар икесе бергә булганда мина куркыныч яный,—дигән нәтиҗәгә килде Сенатор.—Димәк, Японец икесе белән дә фикерләшә. Ачыкларга кирәк әле: алар кайчаннан бирле укмашканнар икән дә, прокурор белән полковник ни өчен банкирга ярдәм иттеләр икән? Сәбәбе нәрсәдә монын? Бу ярдәмләшү Шубарин Германиягә барганчы ук булганмы, әллә очраклы гына килеп чыкканмы? Ни әйтсән дә, Америка гражданын урлаганнар бит».

Боларнын барысын да ашыкмыйча, сак кына белешергә кирәк: хәзер бай Шубарин да, республика прокуроры да, угрозыск начальнигы да көчлеләр. Сонгысын хәтта эчке эшләр министры яки Милли куркынычсызлык министры итәргә дә җыенганнар, дип сөйлиләр. «Ләкин ничек, ни рәвешле белешергә боларны?»—йорт хуҗасы, борынгы Австрия кәнәфиенен таза күнен шыгырдата-шыгырдата, гаҗиз калып озак утырды.

Кинәт башына бер уй килде. Японецнын абруй-дәрәҗәле кунагын урлап

китүчеләрне табарга кирәк—моны берәр акылсызы гына, яки үзен Шубаринга тиң, хәтта аннан да көчлерәк дип исәпләгән кеше генә эшләргә мөмкин. Әйе, көчлерәк дип исәпләгән кеше, чөнки башкалар Артур белән тартышырга кыймас иде: Ташкентта аның кем икәнен җинаятьчел дөнья яхшы белә. Әгәр ул Сенатор белән Миршабка әйтми-нитми генә «мәскәүле» белән элемтәгә кергән булса, аның банк эшчәнлегенә башта ук комачауларга тырышучылар белән якынаерга кирәк. Бигрәк тә болганчык заман шул хәзер...

Шуна күрә ашыкмаска, саклык белән генә эш йөртергә туры килә. Шубарин тиз генә кул селтәүчеләрдән түгел—үзен утырган ботакка балта чабарга ярамас. Әгәр, чынлап та, Артур Александрович «мәскәүле» белән бергәләп эш йөртә башлаган булса, анардан йөз чөерергә дә мөмкин... Ә хәзергә... иң әүвәл Миршаб белән очрашып ана бөтенесен дә сөйләп бирергә кирәк. Хаҗәте чыкса, Канзафар һәм җинаятьчел элемтәләр аша Шубарин белән кем тартышырга теләгән дә, америкалы кунагын кем урларга җөрьәт иткән, шуны ачыкламый булмас.

Шул фикергә килгәч, Сенатор бераз тынычланды, чемоданны исенә төшереп, урыныннан сикереп торды:—«Күпме доллар салганнар икән, әле салган булсалар...»—дип уйлады ул. Чемоданның авырлыгына караганда, «агач» акчаларны кызганмаганнар бугай, кер бавы белән аркылы бәйләнгән чемодан бу юлы шактый авыр күренә иде. Аны ачып җибәргәч, Сенатор ахылдап куйды: чемоданга шыплап... хәзер сирәк очрый торган шоколад конфет тутырганнар! Ул бер мизгелгә югалып калды—бу нәрсә диган сүз инде? Аннары кулын чемоданның төбенә батырды, кулы каты төргәккә барып төртелде. Алса—төргәк эчендә ун кап йөзлек долларлар икән! Йөз мең доллар! Ә бәлки, тагын да бардыр әле? Ул, кабалану-дулкынлануы белән каударланып, чемоданны келәмгә каплады, ләкин башка долларлар юк иде. Шулай да сумнар шактый күп, Сенатор күз карашы белән генә чамалап алды: «Бер унбиш миллионнар булыр»,—дип куанып уйлады. Хан Акмал сумнарның да, долларларның да бәясен яхшы белә икән.

Сенаторның күнеле күтәрелеп китте, Япониецның үз кан дошманнары белән элемтәдә булуы ихтималы да күнелен борчымый башлады. Аксайдан килгән әлеге миллионнарны яңадан чемоданга тутыра-тутыра: «Хакимлек белән акча кешегә бик нык тәэсир итә шул»,—дигән фәлсәфи фикергә килде ул. Долларларын ул ике тумбалы борынгы язу өстәленен оста гына сейф итеп ясалган махсус тартмасына салып куйды. Ул бит Сабир-бобога, Мәскәү адвокатлары белән очрашканнан соң, башкалага үзе барырга вәгъдә итте. Хан Акмалны КГБ казаматларыннан коткаруга үзе җитәкчелек итмәкче иде, менә шунда бу долларлар да, миллионлаган «агач» акчалар ярдәм итәргә тиеш.

«Агач» акчаларны чемоданга, долларларны сейфка җыеп куйгач, Сенатор: «Келәмдәге конфетларны үзем җыештырыйм микән, әллә өйдәгеләрнең берәрсенә кушыйм микән?»—дип уйланып торганда, телефон янә шылтырый башлады, шылтырау бу юлы чит шәһәрдән шикелле иде. Ул телефонга ташланды. Миршаб шылтырата икән. Ул, исәнлек-саулык та, «ничек барып кайттың?»—дип тә сорашып тормады, бер сәгать элек Канзафар борчылгандай, борчылулы тавыш белән:

—Бик мөһим яңалыгым бар. Бер ярты сәгатьтән барып чыксам, каршы килмәссеңме?—дип сорады.

Сенатор «ярар» диюгә, сөйләшү шундук өзелде. «Бу нинди көн булды соң? Һәр яңалык начарлык китерә»—дип сүгенеп куйды ул һәм кухняга ашыкты. Иртәнге аш әзерләргә һәм идәндәге конфетларны җыеп алырга әйтәсе бар иде.

Миршаб сөйләшенгән вакыттан алданрак килеп керде. Турылыклы фикердәшенең борчулы йөзен Сухроб Әхмәтович тәрәзәдән үк күреп алды,

ул аның өр-яңа машинасы ишеген дә бәреп кенә япканыннан да кәефсез икәнлеген чамалады. Ә бит Сәлим үзен нинди хәлләрдә дә кулында тота белә. Бер дә Шубариннан ким түгел. Шубаринның ихтыяр көче исә боларга үрнәк булырлык иде. Шулай да, өйгә кергәч, Миршаб Әкрәмхуҗаевның хатыны белән ягымлы гына исәнләште, балаларны шаяртып алды. Өр-яңа киемле, елмаеп кына сөйләшә торган бу кешенең дә нинди борчулы уйлары, хәл ителмәгән мәсьәләләре бардыр дип һич әйтмәссең. Бервакыт Шубарин Сенаторга: «Ир-ат үз борчуларын түкми-чәчми эчендә сакларга тиеш, синең борчуларың өйдәгеләргә дә, туган-тумачаларына да өстәмә борчылу гына китерә»,—дигән иде. Өйгә керүгә Миршабның елмаюы сүнде. Ул, әлбәттә, язу өстәле янындагы чемоданны бик тиз күреп алды, хәтта күтәреп тә карады, анда Аксайдан алган акчалар икәнен чамалады, ләкин сораштырып тормады.

Миршаб арыган кыяфәт белән кәнәфигә ауды да, үзен борчып торган хәбәрне әйтергә ашыкты:

—Син Аксайга киткән кичне мин үз кешеләрем аша искитәрлек яңалык ишеттем: «Лидо»да Шубаринның банкын тәкъдир иткән вакытта аның бик зур кунагын урлаганнар. Теге, синең белән мәҗлестә янәшә утырган американны. Син Сабир-бобо белән очрашкан көнне Шубарин шәһәрнең астын-өскә китереп шул кунагын эзләгән, әмма таба алмаган: американны җир йоткан диярсең. Шуннан искитмәле хәл килеп чыга: республика прокуроры белән угрозыск начальнигы да ничектер моны белеп алалар, юкса американның югалуы турында берниндидә белдерү булмый. Камалов белән Жураев урлануны гына түгел, кем Артур Александровичның кәефен бозарга теләгәнен дә белеп алалар да, Шубаринга ярдәмгә ашыгалар. Мине бу бик сагайтты: ни өчен әле Камалов Японецка шундый яхшылык эшләргә алынган? Ул бит безнең аның дуслары икәнлегебезне белгәндер, ә миңа яңа ел алдыннан ресторанда туп-туры әйтте: «Сенатор белән сез миңа күп этлек эшләдегез, мин хәзер сезгә исәп ачам»,—диде. Бәлки, Артур Александрович безгә сиздерми генә прокурор һәм борынын теләсә кая тыгарга яраткан полковник Жураев белән бер җырны җырларга җыенгандыр? Әгәр шулай булса, без Японец белән бик сак эш итәргә, «мәскәүле»гә карата булган уйниятләребезне сиздермәскә тиешбез. Чемоданның авырлыгына караганда, Камаловның язмышы хәл ителгән дип уйларга кирәк—Сабир-бобо өчен прокурорның үлеме хан Акмалның тормышына тиң...

Миршаб кинәт тынып калды, аннары өстәлдәге үзләре оныткан чәйнеккә үрелде..

—Әйе, Сабир-бобо бу эшкә акчасын кызганмаган,—диде Сенатор, үзенең Аксайга барып кайтуы һәм, иң мөһиме, долларлары турында сөйләүдән котылганына куанып. Әмма кинәт кенә, нинди дер серне аңлагандай, сискәнеп сорап куйды:—Камалов бу урлануны махсус үзе оештырмадымы икән? Артурга якынаеп, безнең араларны бозу өчен, дим. Бу эшкә полковник Жураев та катнашкан булса, булыр да. Ул шундый табышмаклар оештырырга оста. Безгә барысын да истә тотарга кирәк... Артурны ычкындырсак, күп нәрсә югалтачакбыз, бигрәк тә хәзер, ул банкир булып Европага барып чыкканнан соң.

Миршаб фикердәшенә сәер генә карап алды, уйлап та тормыйча:

—Син матур фикер йөртәсең, мин дә ул хакта уйланган идем, әмма борчылырга кирәкмидер. Юлдан кайтып керешеңә сине борчыйсым килмәде, шуның өчен Шубаринның койрыгына кем басарга теләгәнен белеп тә куйдым.

—Йә, кем инде ул шундый кыю кеше?

—Законлы карак Талиб Солтанов. Нәргиз яши торган эшчеләр

шәһәрчегендә яши. Теге америкалы грузинны да шунда яшереп тотканнар.

—Димәк, Артур кунагын түләп алырга теләмәгән булып чыга. Алайса Талибка шундый шикле эшкә бару ник кирәк булган?

—Ашыкма. Башта мин дә шулай уйлаган идем. Әмма хикмәт шунда: беркем дә кунак өчен хак таләп итмәгән. Артурны беләсең, дусты өчен акчасын кызганмаган булыр иде. Хәер, соныннан, кунаклары китеп беткәч, бик каты кыланыр иде—Коста белән Карен хәзер бик дәрәҗәлеләр. Аннары шунысы да билгеле: төнлә Артур дустының эзен күрсәтүчегә ике йөз илле мең вәгъдә итсә, иртән инде хакны ярты миллионга күтәрә. Юк, эш биредә акчада түгел.

—Акчада булмагач, нигә урлаганнар соң? Гадәттә шулай эшлиләр бит.

—Мин дә шуны аңлый алмыйм шул, ачыкларга туры килер—ни өчен? Артурның бездән яшерен серләре күбәеп бара. Хәер, прокуратура белән утрозыскның урлауга мөнәсәбәтләре юклыгы көн кебек ачык.

—Әйе, хикмәтләр бар... Дөресен әйтим, син шылтыратканчы ярты сәгать алдан ук мин моны белгән идем инде,—дип, Сенатор кунагын гаҗәпкә калдырды.

—Ничек белгән идең?—Миршабның исе китте.

—Хәтта кем урлаганын да белдеңме?

—Юк, анысын белмәдем, әмма Артурның юлына аркылы төшәргә кыюлык итүчеләрне белешергә тырыштым. Кайбер очракларда аларның безгә кирәге чыгуы бар. Без аларны үзебезнең кубызга да биетә алырбыз.

—Ә сиңа кем хәбәр итте?—дип түземсезләнеп сорады Миршаб.

—Канзафар.

—Мин аны ничектер онытып та җибәргәнмен әле. Егет икән! Ана без прокурорны җентекләбрәк күзәтергә кушарбыз. Бәлки, Камаловның ни өчен банкирга ярдәм иткәнлеге дә ачыкланыр.

## XX

Канзафар Рөстәмов Сенаторның «Матросская тишина» төрмәсеннән кайтуына бер дә сөенмәде. Юк, хәзер үзенә тәвәккәл эшләр артачагын аңлаган өчен генә түгел. Ана аның үпкәсе көчле иде: тегесе бит Үзәк Комитетта дәрәҗәле урында эшләгәндә аны башкаланың берәр районына яки, өлкәфәләнгә булмаса, берәр шәһәрнең прокуроры итеп тә күчерә ала иде—ләкин вәгъдәсендә тормады. Ә хәзер Сенатор үзе портфельсез калды—беркем дә түгел ул, шулай да, прокуратурадагы мәгълүматларны житкереп торырга кушачак. Хәтта элеккедән дә күбрәк сораячак, чөнки Камалов прокурор чагында, Сенатор иректә булса да, үзен иркен тоячак. Сенатор бу дөньяда күп гөнаһлы, хәтта кайберләре өчен аңа иң югары җәза да аз булмас иде. Төп шаһит Парсегянның үлеме генә Камаловны чигенергә, бирелергә мәҗбүр итмәс—аңдый кеше түгел. Сухроб Әхмәтович «Матросская тишина» төрмәсендә утырганда, Миршаб Канзафарны бик күп борчымады, бәлки, Канзафар Сенаторга хезмәт иткән өчендер, ә бәлки, Югары суд кешесенең аны уйлап торырлык вакыты юктыр: Камалов аның да койрыгына баскандыр, ул бит Сенатор белән Миршабның студент елларыннан ук аерылмас дуслар—фикердәшләр икәнен белә. Прокурор аларны төрмәдәшләр дә итәргә телидер, моны күпләр сизенә иде.

Татьяна Шиловадан шакккатарлык хәбәр—америкалы грузинны урлап китүләре һәм иң мөһиме—аны табуда банкир Шубаринга прокурорның ярдәме тиюе турында ишетүгә, Канзафар тиз генә Сенаторга шылтыратты, аңдый хәбәрләрнең бәясен белә иде инде ул. Шулай итеп, ул үзенең йоклап ятмаганын, уртак эш өчен йөргәнен аңлатты. Аның әле тагын бер уе бар иде:

Сенатор Японлыны прокуратура белән бәйләнешледер дип уйлар да, Канзафарны озакка тынычлыкта калдырыр, янәсе. Калдырды ди, сиңа!

Икенче көнне үк эшендә телефон шылтырады: Сенатор аны кунакка чакыра, имеш, күптән күренмәгәннәр, бер табактан пылау ашамаганнар икән. Әмма Канзафар анда үзен ничек кунак итәселәрен чамалый иде. Хәер, яңа суелган сарык ите белән кызыл дөгедән пешерелгән пылау бар иде барын. Кунакта ул бер үзе генә булып чыкмады, Хашимов та килгән иде.

Табын янында эш турында сөйләшмәделәр, өстән-өстән генә үткәннәр, хатын-кыз, аш-су турында гәп корып утырдылар. Сәясәт, димәк, бүгенге һәм иртәгеге көн турында сөйләшүдән юри тыелып тордылар. Әмма Сенаторның иркен бүлмәсенә күчеп утырыуга, сүз нәкъ менә сәясәт, хәл итәсе житди мәсьәләләр, бүгенге һәм иртәгеге көнгә борылып китте. Үзен пылау ашарга гына чакырмаганлыкларына шикләнә башлаган Канзафар шундук ялгышын аңлады, әйе, аны ниндидер бер эш өчен дәшкән иделәр. Сухроб Әхмәтович күчешсез-нисез анардан сораштырырга тотынды:

—Мине кулга алыр алдыннан без синең белән прокуратурада яңа бүлек—оешкан җинаятьчелек белән көрәшү бүлеге булдырылуы турында сөйләшкән идек. Камалов ул бүлеккә КГБ хезмәткәрләрен җыйган, дидегез. Ул бүлек безне шул чакта ук кызыксындырган иде, хәзер дә кызыксындыра, прокуратурада ул—Камаловның төп таянычы. Син ул бүлек хезмәткәрләре белән якынлаша алдыңмы? Шунда күчеп эшләргә берәр җаен таба аласыңмы?

Канзафар үз фаразының дөреслеген аңлады: «мәскәүле» белән исәп-хисапны өзмичә, Сенатор тынычланмаячак. Бу көрәштә тигезлек булмас—кем кемне җиңәр? Әлегә белгән юк. Камалов үзен тезләндерергә ирек куймас, ул андый кеше түгел, аны үлем генә туктата алыр. Канзафар үзе корган тозакта үзе һәлак булган атаклы снайпер Ариф язмышын да, Домбайдан махсус китерелгән «альпинист»ның хастаханәдә ата да алмый харап булуын да белә иде. Юк... Канзафарның яшисе килә әле.

Әмма Рөстәмов хәвефле эшләрдән турыдан-туры баш та тарта алмый—Сенатор белән Миршабтан кызгану көтмә, алар маңгаеңа да, аркаңа да пуля утыртырга бик мөмкин. Шуңа күрә ул:

—Кич мин сезгә житкергән мөһим хәбәрне нәкъ шул бүлектә ишеткән идем,—диде.—Хәтерегездәме, мин анда үземә таныш кыз—Таня Шилова эшли, дигән идем. Сез аны бервакыт «Лидо» ресторанында минем белән күргән дә идегез. Менә шул сүз арасында гына ычкындырып җибәрде.

—Бик шәп! Димәк, ул бүлеккә баш тыгар җаең бар. Ә хәбәрегез, чынлап та, бик мөһим. Без аны тиешенчә бәялибез дә—Сенатор өстәлгә алдан ук сөлге белән каплап куелган меңәр сумлык акчалар салынган төргәкне алып Канзафарга сузды.—Алыгыз, ал, сез аңа гына лаек хәзер,—диде.

Канзафар бу кадәр юмартлыкны көтмәгән иде, акчаны рәхмәт әйтеп алды да пинжәгенең эчке кесәсенә яшерде. «Йөз мең! Әз түгел, әмма бу тагын да хәвефлерәк эш башкарту өчен алдан түләп кую шикелле. Сизгер булырга кирәк»,—дип уйлады ул, аннары кычкырып сөйләп бирде:

—Әйе, мин ул бүлеккә ачкыч ярattым шикелле инде—Таняны анда хөрмәт итәләр. Ләкин көтелмәгән хәл килеп туды: аңа КГБның элекке хезмәткәре, шунда ук эшләүче бер егет—Костя Васильев гашыйк булды. Кыз да аңа битараф түгел булса кирәк. Менә шул капитан, хан Акмалны кулга алганда төп төркемгә җитәкчелек иткән егет, Камаловның да сөйкемле сөяге. Шул каһәр минем эшне бозды да ташлады. Хәзер минем ул бүлеккә күчү мөмкинлегем дә калмады. Камаловның шәхси боерыгы булса гына инде, юкса мине анламаячаклар. Ә ул мине өнәп бетерми, нәрсәдер сизенә шикелле, кайвакытларда шундый сөзеп карап-карап ала...

—Әйе, туган, күңелле хәл түгел...—дип авыр сулап куйды Хашимов.

—Инде максатына ирештен дигәндә генә!—дип ачынып, анын сүзләренә кушылды Сенатор.—Тик син югалып калма, күнеленне төшермә, хатын-кыз күнеле тиз үзгәрүчән була. Һаман да игътибар күрсәт, чәчәкләр, бүләкләренне кызганма, белмәссен... йомшап та китәр. Шуннан соң ул бүлеккә күчүен аңлашылыр да.

Гәп үзеннән-үзе сүрелде, кызыксынулар бетте шикелле. Канзафар аларның үзенә биргән акчаларны кызганганнарын сизенде, әмма акчалар анын кесәсендә шул инде—шунысы куандыра, күнелен жылытып тора иде. Яшел кытай чәе «лунь-цзинь»ны мактый-мактый, тагын чәй эчтеләр. Чәйләп утыру тәгәлләнеп килгәндә генә, Миршаб кинәт сорау бирде:

—Канзафар, син Артурга шундый этлекне кем эшләгәнен ишетмәгән иденме?

Кунак: «Юк, белмәдем, ишетмәдем»,—дип жаваплады. Шунда Сенатор да үзен кызыксындырган соравын әйтеп ташлады:

—Ә син Талиб Солтановны белмисенме? Ул күптән түгел генә Мюнхенда булып кайткан...

Икесе дә жавап көтеп Канзафарга төбәлделәр. Әмма үзен кесәсендәге йөз мең акча белән кәрт уйнарга утырган итеп тоючы Канзафар аларның түземсезләнгәннәрен сизмәде дә. Ул ваемсыз гына:

—Талибнын Мюнхенда булганын ишетмәдем, ул анда нишләсен, ди? Үзен исә яхшы беләм, ул жинаятьчеләр арасында дәрәжәле кеше.

Бу жавапка ышана алмыйчарак кына, Әкрәмхужаев:

—Ә сез танышлармы?—дип сорады.

—Әйе, әлбәттә. Ә сезгә Талиб нигә кирәк булды әле? Мин анардан да кәттәрәк егетләрне дә беләм,—дип жанланып китте Канзафар. Анын прокурор Камаловка, жинаятьчеләргә күбрәк якынаясы килә иде. Юмартлыклары өчен хужаларын шатландыру да комачауламас.

Миршаб белән Сенатор карашып алдылар, ни-нәрсәдер ымлаштылар, әйтерсең, кәрт уйнап утыралар. Сенатор, дустының ризалыгын аңлап, кырыс кына әйтте:

—Шубаринның кунагын шул Талиб урлаган инде.

Канзафар агарынып китте: «Тагын берәр юньсез эшкә буяламмы әллә?—дип уйлап алды. Ул бу ике дусның Шубаринга яхшы мөнәсәбәттә икәнлекләрен яхшы белә иде. Шубарин аларга нык ярдәм итте бит. Димәк, алар Канзафарны да шул эшкә катнашкан дип уйлыйлар.

—Нигә соң ул Шубаринга теш кайраган? Ташкентта Японецка теше үтәрдәй кеше дә юктыр. Коста бер үзе «узи» автоматыннан Лютыйның бандасын кырып салганын шәһәр халкы яхшы хәтерли. Тегеләр «Лидо» ресторанына салым салмакчы булган да, Коста аларны кырып-яндырып та ташлаган. Аңламыйм,—дип башын чайкады Рөстәмов.

—Менә безнең дә беләсебез килә, ни өчен ул Талиб безнең дуска, димәк, безгә дә кул күтәрергә батырчылык иткән? Анын артында кем тора?—дип сүзгә кушылды Миршаб, аннары Канзафар гына түгел, Сенатор да көтмәгәндә пинжәгенең эчке кесәсеннән нәкъ теге төргәк шикелле йөз меңлек төргәк тартып чыгарды да, аны әләкчегә таба этәрде:—Бу сина—миннән. Белешергә тырыш, ул Талиб безнең дуска каршы ни-нәрсә мәтәштермәкче икән? Ләкин... Ул белгәннәрен Артурның тормышына кагылышлы булса да, ин элек безгә ирешергә тиеш. Шубаринны вак-төяк белән борчырга кирәкмәс, ул бик зур эш башлап жибәрде. Ә Талиб белән нәрсә эшләргә кирәклеген без үзебез белербез. Аңладыңмы?

—Аңладым. Мин сезнең Артур Александрович белән дус икәнлегегезне беләм. Ул мина да ошый. Мин Коста белән дә дус, ул төрмәдә утырганда, бик булыштым да үзенә,—диде каушабрак калган Канзафар, әмма акчаны алып кесәсенә яшерергә ашыкты.

«Ни өчендер бүген бик юмарт әле болар»,—дигән хәвефле уй бер мизгелгә генә чагылып узды, ләкин ни өчен икәнен уйлыйсы да килми, кесәсендәге ике йөз мең сум күнелен рәхәт кытыклап тора иде.

—Инде кадерле дустыбыз Артурны хәвеф-хәтәрдән саклап калу мөмкинлеге тугач, амин тотсак та ярыйдыр,—дип, кулын күтәреп битен сыпырды Сенатор. Өчесе дә табын янынннан кузгалдылар.

## XXI

Кирәкле мәгълүматны Канзафарга җиткергәч, Таня Шилова үзенең дә җитди көрәшкә тартылганын аңлады, ул да үзенә йөкләнгән бурычны үтәргә тиеш иде. Ул шулай ук республика прокуроры башлап җибәргән бу көрәштә килешү дә булмаячагын төшенде: эш бик тирәнгә киткән иде шул. Камаловка рәттән өч тапкыр һөҗүм оештырылу да шуны раслый иде.

Хәзер генераль прокурорның дәрәҗәсе чиксез әһәмияткә ия булды. Гоголь урамындагы бинада зур кабинетта утырган Камалов республиканың һәм сәяси, һәм икътисади тормышында үзәк урын тота башлады. Шуна күрә аның кәнәфие күпләрне кызыктыра, шунда менеп утырып, закон кулы белән көндәшләренне һәм дошманнарынны җиңүдән дә ләззәтле эш булырмы икән?

Камалов көннән-көн төрле яклап үзенә ясала торган басымны тоя, билгеле. Әмма аның чит күзләргә күренми торган ныклы таянычы да бар—аны республиканың законлы рәвештә сайлап куелган беренче президенты яклый. Ә ул шактый кырыс, алдан күрүчән хаким. Әйтергә кирәк, союздаш республикалар җитәкчеләре арасыннан иң элек ул Горбачевның хыянәтен аңлап алды. Экономист һәм финансист белеме булган, дәүләт һәм хуҗалык эшләрендә зур тәҗрибә туплаган бу җитәкче үзенең анык сораулары белән кызыл авыз Горбачевны һәрвакыт унайсыз хәлгә куя килде. Анын эшкә ашмас маниловча хыялларын тар-мар итеп, наданлыгын ачып бирә иде. Үчлекле Горбачев моны тиз төшенде, шуна күрә аны үзеннән ерак тотты, үз тирәсенә вәгъдәсез, һәр сүзгә тиз ышанучан кешеләрне туплады. 1991 елнын августында Горбачевны яклап союздаш республикаларның бер генә Үзәк Комитеты секретаре дә авыз ачмады.

Оешкан җинаятьчелек белән көрәшү бүлеге киңәшмәләрендә Камалов еш кына: «Безнең бу карарыбызны президент та хуплар дип уйлыйм»,—ди торган иде. Татьяна боларны гел ишетеп торды. Кыз көрәшнең тегәлләнеп килүен, вакыйгаларның куеруын тоеп тора. Мөгаен, Канзафарга даими рәвештә ялган мәгълүматлар биреп торырга туры килер. Ләкин Камаловка иң кирәк чакта көтелмәгән хәл килеп чыкты, прокурорның бөтен планнары чәлпәрәмә килә язды. Таняга бүлектәге хезмәттәше Костя Васильев чын-чынлап гашыйк булды. Моны тирә-юньдәгеләр, шул исәптән Канзафар да сизеп алдылар. Танянын хезмәттәшләре белән Канзафар арасында элек тә якынлык юк иде, хәзер инде яшьтәшләре янына—ул бүлеккә бер йомышсыз кереп йөрергә җай да калмады. Һәммәсе дә Таня белән Костя турында гына сөйләгәндә, Канзафар анда артык кашыкка әйләнде. Ә Таня Костяга Канзафарның мафия белән бәйләнеше барлыгы, үзенә ана ялган мәгълүматлар биреп тору бурычы куелганлыгы турында сөйли дә алмый. Ә болай Костя көнләшү галәмәтләре күрсәтә дә башларга мөмкин.

Холык-табигате башка кызларныкы шикелле булса, Таня да, бу ике егетне күзеннән ычкындырмыйча гына, бик якын да җибәрми тота алыр иде. Кызлар һәрчак шулай итә, әмма Шилова кыланчыклана белми, аңа шуна күрә кыенга килә. Кызга егерме биш яшь иде инде, аның Урта Азиядәге күпчелек яшьтәшләре балаларын мәктәпкә әзерләгәндә, аның әле чын-чынлап беренче гашыйк булуы гына иде. Моңа кадәр үзенә ошаган берданбер ир-ат Камалов

булды, ләкин бу хисен ул берәр кино героена яки киноартистка мәхәббәт шикелләрәк кабул итте, чөнки ике арада тулы бер чорга тин вакыт ятканын аңлый иде. Ә Костяда ул, үзе кебек үк, бурычка тугрылыкны, Камаловка бирелгәнлекне тойды. Егетнең житди ирләр эше белән мәшгуль булуы, башкалар арасындагы абруе кызда горурлык хисләре тудыра иде. Хезмәттәшләре дә аларны бертавыштан бер~берсенә пар килгәннәр дип таптылар, бу исә Шилованың хәлен тагын да катлауландырды. Ул үзенең Камаловка: «Гафу итегез, мин Канзафар белән уен уйный алмыйм, минем шәхси хисләрем башкачарак»,—дип әйтә алмаячагын да аңлый иде. Үзенә ошаган Костяны да югалтасы килми, шул ук вакытта Камаловның да ышанычын акларга кирәк иде.

Татьяна, хатын-кыз буларак, Канзафарның үз бүлегендәге егетләрдән куркыбрак йөргәнен сизенә иде, ул моны әле Костя белән аңлаша башлаганчы ук тойды, ә инде үзләре турында «пар килгәннәр» кебек сүзләр ишетелә башлагач, шымчы Канзафар алар бүлегенә бөтенләй керми башлады. Әмма мондый чакта шәхси хисләрен хезмәтеннән өстен куйса, тәгәлрәге—хезмәт бурычын онытса, Шилова Шилова да булмас иде. Гажизлектән үртәлеп йөргән мизгелләрендә, кыз Костя белән үпкәләшү жаен да эзли, бөтенләйгә түгел, әлбәттә, бары тик ике-өч айга гына. Шул арада вакыйгалар бер эзгә төшәр, бик кирәкле эш өчен генә хыянәтче шымчыны прокуратурада тотмаслар, бу хакта бервакыт Камалов үзе дә әйткән иде. Күрәсең, Канзафар Рөстәмов прокурор Камаловның ниндидер яшерен максатларын тормышка ашыру өчен генә файдаланылмый, аны гаепләрлек дәлилләр жыялар булса кирәк. Гадел хөкемнән, Сенатор кебек, шуып чыкмасын тагын—Камаловның авызы бер пеште бит инде. Прокурорның уенча, Канзафар КГБ подвалларында агулап үтерелгән Артем Парсегян урынына гаепләүче төп шаһит була алыр иде, мөгаен. Кыскасы, Канзафар да, Татьяна да араларын бозмаска тиешләр, аларга шулай кушылган. Ләкин моны ничек тормышка ашырырга соң?

Беренче булып Татьяна Шилова Канзафар белән даими очрашып тору жаен тапты. Юристлар эше бик мәшәкатьле-матавыклы эш; төрле карарлар, закон проектлары, указлар, күрсәтмәләр язу өчен генә дә тау-тау кәгазь сарыф ителә; ә инде жинаять эшләренә багышланган күп томлы документлардан күчермәләр, өземтәләр алулар турында әйтеп торасы да юк. Татьяна эшли торган бүлектә дә кәгазь боткасы, анда да әле берәр күчермә, әле берәр өземтә гел кирәк булып тора, житмәсә, аларны югарыга сәгатеминутында ук, ашыгыч әзерләп тапшырырга кирәк—хет ярыл шунда! Хажәте чыккан саен Шилова прокуратура подвалында күбәйтә торган техника белән эш итүче егет янына йөгереп төшә. Әмма анда бер ул гына йөгерми, башкалар да йөгерә—барысына да кәгазьләр бик тиз кирәк. Элегрәк Таня мондый чакта Канзафардан ярдәм сорый иде. Чөнки Канзафар көчле ксерокс аппаратында эшләүче Олугбәкне еш кына юл уңаенда үз машинасы белән йә эшкә алып килә, йә алып кайта иде. Шул ксероксны исенә төшергәч, Шилова Канзафарны үз максатларында файдалану жаен тапты да инде. Ул, шикшөбһә уятмыйча гына, күбәйтеп алу өчен диген булып, ялган мәгълүматларны ун-егерме минутка ксероксга калдырып торачак. Канзафарга алар белән танышырга шул вакыт житәргә тиеш. Әмма моны башта Камалов белән сөйләшеп-килешеп эшләргә кирәк булыр.

Шундый карарга килгәч, кыз бу эшне сынап карарга булды. Канзафарны күрмәгәненә дә айдан артык иде, ә Камаловның Рөстәмовка бирелергә тиешле ялган мәгълүматлары тагын жыелгандыр, бәлки. Костяның юк чагы—ул ике республика читендәге бер аяусыз рэкетирлар бандасын тоткарларга чыгып киткән иде.

Кәгазьләре арасыннан «Яшерен» дигән тамга сугылмаган берсен алып,

алдан шылтыратып-нитеп тормыйча гына, Таня Канзафар эшли торган өченче катка күтәрелде—аның егет янына кинәт кенә барып керәсе килде. Рөстәмов ишеген ул ваемсыз елмаюлы йөз белән ачып җибәрмәкче булып үзенә таба тартты. Ләкин ишек бикле булып чыкты, юкса әле ярты сәгать элек кенә ул Рөстәмовның прокуратурага кереп килгәнен күргән иде. «Берәр түрә чакырткандыр, мөгаен, үзен»,—дип китеп бармакчы гына булган иде, бүлмәдә кемнендер кыштырдаганын ишетте. Бүлмә эчтән бикләнгән икән. Ул ишекне шакыды:

—Канзафар, бу мин!—дип күңелле генә кычкырды.

Эчтә нииндидер тимер бәрелгән тавыш ишетелде, өстәл шыгырдап куйды, аннары кемдер ашыгып ишеккә таба атлады да, аны ачып җибәрде. Ул Канзафар иде, йөзендә бераз каушау да шәйләнә.

—Ә мин сине берәр чибәркәйне шкафына яшереп маташасын дип торам тагын,—диде Татьяна, бүлмәгә керә-керешли, аннары өстәл астына иелеп караган булды.

Аның кыланышлары бик табигый, матур килеп чыкты, Канзафарның йөзен картайтып торган каушавы да бетте.

—Әйе, менә чалбарның «молния»се кәҗәләнә иде, шуны төзәтеп маташтым,—диде ул, ниһаять, исенә килеп һәм Татьянага утырырга урын тәкъдим итте.

«Чалбар төзәтү өчен артык зур тавыш булды шул»,—дип уйлады Шилова, үзе булмаганча кыланчыкланып гозерен әйтеп салды: янәсе, менә шушы кәгазьне тизрәк күбәйтеп аласы иде. Үзенең: «ишек бикләп, син юньсез нәрсә эшли иден, өстәл тартмаңа нәрсә яшердең?»,—дип бик сорыйсы да килде. Өстәл өстендә нииндидер приборның «Сони» дип язылган капкачы ята иде. Аның Канзафар яшергән әйбернеке икәнен сизенсә дә, кыз ни-нәрсә икәнен тәки аңлый алмады. Артык кыланчыкланып, елмаеп торырга теләге юк иде инде, чыгып китәргә җыенып, урыныннан кузгалды. Канзафар исенә килгән иде инде, Сенатор белән Миршабның өйрәткәннәрен хәтерләп, Танядан китми торуын сорады. Ачык сейф ишеген гәүдәсе белән каплап, бик матур тартмалы итальян конфеты «Амаретто»ны алды да кунагына сузды:

—Бик тәмле, диләр, чибәр кызлар өчен махсус эшләнгән...

Татьяна, рәхмәт әйтеп, бүләкне алды да чыгып китәргә ашыкты, хәзер инде егет белән яңадан теләсә кайчан аралашу мөмкинлеге туган иде. Канзафар да шундыйрак уйда булды, шулай да дивар аша тыңлар өчен ясалган аппаратның капкачын яшергәндә, борчылып та куйды: Шилова өстәлдә яткан капкачны күреп, шикләнмәдеме икән соң? «Молния» төзәттем» дигән сүзләргә дә ышанып житмәгәндер инде.

## XXII

Телевидениедән «Шәрекъ» банкының ачылу тәкъдирен күрсәткәннән соң, ун көн үтте дигәндә, Шубаринга ишелеп-ишелеп тәкъдимнәр, төрле җирләрдән үз капиталларын-байлыкларын шул банкта сакларга теләүчеләр ташкыны агылды: шылтыратгалар, шәхсән үзләре килеп чыгалар, факс аша тапшыралар иде. Бу кадәр көтелмәгән тәкъдимнәр Артур Александровичның күңелен күтәреп җибәрде, ул бит, Гвидо Лежаваның урлануы киң катлауга ишетелсә, әле ачылып та житмәгән банк изоляциядә калыр дип курыккан иде. Бәлки, америкалы грузинны урлау да нәкъ шул максатлардан чыгып эшләнгәндер—житди, саллы байлыгы булган кешеләрне читләштерергә теләгәннәрдер, әгәр шулай булса да, ул мәкер барып чыкмады: акча су кебек агып керә торды. Артур Александрович, аларның кайсы төбәкләрдән, кемнәрдән булуына карап, республиканың бик куәтле оешмалары аның белән хезмәттәшлек итәргә

җыенганын анлады. Компьютер дисплеенда һаман да арта барган исемлекне күреп куана иде Шубарин. Ул өлкәдәге теге яки бу зур завод, берләшмә, эше гөрләп бара торган хуҗалык, трест, концерннарның кемнәр кулында икәнен яхшы белә. Тәкъдимнәр анын үзен күреп белгән Ташкент, Бохара, Җизак кебек җирләрдән генә түгел, ин ерак төбәкләрдән—Каракалпакстан, Харәзм, Сурхандәрья, Кашкадәрьялардан да керде. Хәтта Кыргызстан, Казакъстан, Алтайда яшәүче немец җәмгыятьләреннән дә хәбәрләр бар иде. Ул инде пай тотучыларның еллык җыелышында төбәктәге күп кенә абруйдәрәҗәле кешеләрне үз күзләре белән күрде. Байтак кына көндәш төркемнәрне дә аралаштыра һәм берләштерә торган көч акча икән! Һаман арзаная барган акчаларын һәммәсе дә югалтмаслык эшкә салырга тели, һәммәсе дә булган байлыгын икеләтергә-өчләтергә хыяллана, валюта табышы алырга омтыла.

Теге чакта, чит илгә китүчеләрнең беренче дулкыны белән, Шубаринның күләгәле икътисадта озак еллар бергә эш йөрткән дусты Гвидо Лежава Америкага китеп барды. Киткәндә Шубарин ана, яна урында эш башлап җибәрергә дип, әҗәткә өч йөз мең доллар бирде. Бу акчаны Гвидо бик оста, әйтергә кирәк, хәтта талантлы тотты. Шул ук елны Мәскәүдә бер уңышлы эштән соң Шубаринның долларлары миллион ярымга житте, ул шул санда тукталып калды. Үзенә файдасыз бу акчалардан чит илләргә китүче дусларына сирәк кенә әҗәткә дә биреп торды, әмма Гвидога биргән чаклы зур сумманы башка беркемгә дә бирмәде.

Банкның һәм үзенең шәхси финанс хәлләре өчен Шубарин кайгырмады, дөресрәге, ул аны гына ерып чыгарлык иде. Аны банк тирәсендәге ыгы-зыгы борчый, озакка сузмыйча, шуны хәл итү мөһим иде. Прокурор Камаловның банкка килеп китүе һич уеннан чыкмады. Прокурор белән мөнәсәбәтләрне дә тизрәк чишәргә кирәк. Ул Шубаринга ярдәм кулы суза, бар белгәнен, бигрәк тә «Шәрекь» банкы турындагы мәгълүматларны әйтеп бетермәсә дә, хезмәттәшлек итәргә чакыра. Хәер, прокурорга үпкәләп торасы юк, Шубарин үзе дә законлы карак Талиб Солтановның Мюнхенга ни өчен килеп киткәнен әйтмәде бит. Ни өчен Гвидо Лежаваны урлаганнары турында да—ләм-мим! Ә Камаловны нәкъ менә шул «ни өчен» күбрәк борчый иде. Ләкин Шубарин үзе, Сенатор белән Миршабның киләчәк планнарын белмичә торып, прокурор ничек кенә теләсә дә, банкка нинди генә куркыныч яныса да, ана эчендәгесен сөйләп бирергә теләмәде. Ул һәрвакыт үз көченә генә таяна, үзенә генә ышанырга гадәтләнгән, бер вакытта да дәүләткә ышанмады, аннан ярдәм көтмәде. Ул бит хәзер дә, сәбәпсез-нисез генә, Камаловка үзе Мюнхеннан кайтканнан соң ана бер билгесез кеше шылтыратканын, күптән түгел «Бавария» стадионында кем беләндер очрашканын исенә төшереп, хәзер, банк житәкчелеге тупланганда, идарә әгъзалары арасында аларның да бер кешесенә урын даулаганын сөйләп бирә алмый иде.

Теге әрсез кеше белән Шубарин кискен сөйләште, аны сүзендә тотарга тырышып:

—Ә кем өчен ул урын?—дип сорады.

Әмма бу юлы анын әңгәмәдәше тәҗрибәле кеше булып чыкты, ул тыныч кына җавап бирде:

—Сезнең ризалыгыгызны алгач әйтербез. Хәер, ул кеше, бәлки, сезгә таныш та булып чыгар.

Шубаринга бер-ике көн уйланганнан соң гына сөйләшергә кирәк иде, ә ул шунда ук шактый кискен-каты сөйләшә башлады:

—Банкны кайбер илләрдә чиркәүгә тиңлиләр, ә чиркәүдә кеше серләрен ачмыйлар. Минем өчен дә болар изге нәрсәләр. Шулай икән, идарәдә түгел, гади урында да сезнең кеше булмас, мин үз командам белән генә уйныйм. Ә

инде Мюнхендагы стадионда очрашуга килсәк... Әгәр дә анык тәкъдимнәрегез булса, керегез, сөйләшербез. Банк якын көннәрдә ачылачак.

Үзе янына шулай чакырып, ул койрыгына баскан кешеләрне белергә теләде. Аларны матур итеп кенә каршы да алыр иде. Ләкин аның чакыруын кабул итмәделәр, рәхмәт әйтеп, сүзне бетерделәр.

Икенче көнне, чама белән шул ук вакытта, янадан телефон шылтырады, кичәге тавыш яна тәкъдим ясады.

Шубарин каян шылтыратканнарын белергә теләп, номер күрсәткечтән юкка гына эзләп маташты—кичәге кебек үк, телефон-автоматтан шылтыраталар иде. Бу юлы да сүзне бик артык озайтмадылар:

—Без, Артур Александрович, киңәштек тә,—диде телефондагы тавыш тыныч кына,—шундый карарга килдек: әгәр сез безнең вәкилне эшкә алмыйсыз икән, ул чагында үзегезгә акча салып торучылар һәм акционерлар турында безгә даими хәбәр итеп торырга тиеш буласыз. Сүзнең ни-нәрсә турында икәнен аңлыйсыздыр: аларга акча каян керә, алар аны кая күчерәләр? Күп акчалар кайсы көннәрдә керә дә, кайсы көннәрдә алына? Һәм, әлбәттә, вакыт-вакыт күп акчалар күчерелә торган безнең ике-өч фирмага да күз-колак булырга кирәк.

Шубарин, ачуыннан кайнап чыгарлык булса да, тыныч кына тыңлады, «Бавария» стадионында сөйләшкән кебек, тыныч кына җавап та бирде:

—Без янадан кичәге сөйләшүне кабатлыйбыз шикелле, ә кичә мин сезгә кистереп әйттем—юк! Әгәр дә мин сезнең шымчыгызны алмыйм икән, ни өчен шул ук мәгълүматларны хәбәр итеп торырга тиеш әле? Мин бит банкның минем өчен чиркәү шикелле үк изге булганын, ни-нәрсә генә булса да, мәхәлләмә йөрүчеләрне сатмаячагымны әйткән идем инде.

—Сезнең кирелегегез кыйммәткә төшәргә мөмкин,—дип бүлдерде аны телефондагы кеше.

—Бәлки, шулайдыр. Мин анысына да әзер. Кабатлап әйтәм, мин бары тик Мюнхенда булган сөйләшүгә генә кайта алам, калганына—юк.

—Кара аны, Японец, оттыра күрмә, иң әүвәл без синең бәйрәмеңне бозарбыз...—шуннан соң сөйләшү көтмәгәндә өзелде.

Шубарин, әлбәттә, «Лидо» ресторанында куркынычсызлык чараларын күргән дә иде, ләкин барыбер Гвидоны урлап алып киттеләр. Теге каһәрләр тәки сүзләрендә торды, хәзер җавап гамәлне ул эшләргә тиеш иде. Әгәр прокурор Камалов Талиб Солтановның Шубаринны Мюнхенда эзләп тапканын белешкән булса, казна караклыгы өчен Урал төрмәсенә унбиш елга утыртылган Заркәнт партия өлкә комитетының элекке секретаре Әнвәр Абидовичның да килеп киткәнен дә исәнгән булырга мөмкин. Моны турыдан-турыммы, әллә читләтепме, тиз генә ачыкларга кирәк иде. Хәер, прокурор Камалов килеп киткәч, Японец, Әнвәр Абидович белән даими очрашып торучылардан сорашып, мамык Наполеонының исән-сау, элеккечә каптеркада кием-салым биреп торганын белде. Ул кешеләр исә тоткынның Мюнхенда булганын уйларына да китерә алмый иде. Шулай булырга тиеш тә, чөнки Әнвәр Абидовичның Германиягә килүен югары дәүләт мәнфәгатьләре белән әзерләгән иделәр. Дөресрәге, бик көчле махсус оешмалар эше иде бу. Алар тотынса, нык тотына инде, КПСС Үзәк Комитетының элекке эшләр идарәсе управляющие Николай Кручинаның сәер үлеме дә шуны раслый. Тагын шундый күп белүче зур түрәләрнең дә берничәсе җан тәслим кылдылар ич. Ләкин СССР таркалганнан соң, Шубарин да булышырга вәгъдә биргән шикле эшләргә Әнвәр Абидовичны тарту бик хәтәр иде.

Әнвәр Абидовичның Мюнхенга барып кайтуы турында уйларга да уйларга кирәк әле, ул бит карак Талиб Солтанов түгел сиңа. Әгәр дә Камалов мамык Наполеоны белән очрашканны белеп, банкка шәхсән үзе килеп чыгарга

уйлаган булса, мөгаен, Японецны кемнәрдер яки ниндиләр вакыйгалар китереп кысыкандыр. Монысы да бик булырга мөмкин. Ләкин Камалов банкирның Сенатор һәм Миршаб белән якынлашуын теләми, ике арага таяк тыгарга тырыша. Шуна күрә ул, прокурор Азлархановны Сухроб Әкрәмхуҗаев үтергән булырга да мөмкин, дигән фикергә ишарәли, анын докторлык диссертациясен тикшереп, дәлилле бәя бирә.

Талиб Солтанов турындагы мәгълүматларны да җыеп бетерәсе бар. Анын Радиальная урамындагы Гвидоны яшереп тоткан йортыннан чыгып киткәндә, Камалов ана янап әйтте бит: «Ә синен белән без әле сонрак сөйләшербез, хәзергә синен кайгын юк»,—диде. Әйе, Талиб өстеннән җитәрлек мәгълүматлар җыелган иде инде, ләкин ин кирәклесе әле юк: анын артында кем тора икән? Шуны ачыклыйсы бар. Ә кичә Коста Талибнын көтмәгәндә генә Мәскәүгә очканын хәбәр итте. Әгәр дә ул шуннан Германиягә сыпыртырга уйласа? Банк ачылды бит инде, Шубарин аны тәкъдир итү алдыннан телефоннан сөйләшкән тавышы таныш түгел кешегә: «Әгәр эшлекле тәкъдимнәрегез булса, «Бавария» стадионындагы сөйләшүгә әйләнеп кайтырга әзер мин—кирәгез»...—дигән иде. Димәк, Мәскәүдәге чеченнар белән элемтәгә керергә туры килә, алар күптәннән инде халыкара «Шереметьево» аэропортын үз кулларында тоталар, Талибнын немецларга очып киткәнен да күреп калганнардыр, шәт. Әйе, Мәскәүдә яшәүче чечен егете Хуҗа белән кичекмәстән бәйләнешкә керү зарур.

Инде Ташкентка кайткач, Гвидо китеп, прокурор Камалов белән очрашканнан сон, Шубарин ин югары даирәләрнен ярдәменнән тыш үз ниятен—КПСС акчаларын чит илдән кайтаруны хәл итеп булмаячагын ачык анлады. Ана булышырлык кеше әлегә бер Камалов кына, әгәр ана мөрәҗәгать итсә, банкнын бу эшләре турында да сөйләп бирергә кирәк булачак. Ул эш исә беркем тарафыннан да тикшерелмәскә, телгә кермәскә, бары тик дәүләт мәнфәгатьләре белән генә бәйле булырга тиеш. Ләкин прокурор Камаловнын шундый карар кабул итәрлек вәкаләтләре бармы икән сон?!

Шубаринны борчып торган бу мәсьәлә көтмәгәндә кинәт кенә бик кискенләшеп китте, ана уйланып торырлык вакыт та калмады. Бер көнне эш бүлмәсендә телефон шылтырады, таныш тавыш ишетелде:

—Эшләрен ничек, Артур? Банкын ачылу белән котлыйм, безнен сөйләшүне онытмадынмы? Кире уйламадынмы?

—Юк, онытмадым...

—Яхшы. Алайса, алдагы атнанын ахырларында синен Италиягә барып кайтуын кирәк булыр. Анда бер бик абруй-дәрәҗәле банк үзенен өч йөз еллыгын үткәрә. Сина, Үзбәкстан финансисты буларак, рәсми чакыру килер. Ул банк күптәннән безнен өчен эшли, без аны ике мәртәбә бөлгенлектән коткарып калдык. Миланга матур гына барып житүенне телим, бәлки, шунда очрашырбыз да әле...—сөйләшү ничек башланган булса, кинәт шулай өзелде дә. Рәсми рәвештә төрмәдә утырырга тиешле Әнвәр Абидович—мамык Наполеоны шылтырата...

Телефон трубкасын куйгач, Шубарин өстәл календарена карап алды—Италиядә очрашырга алты атна калган икән. Вакыт житәрлек шикелле дә, ләкин анын ниятләрен тормышка ашырырга әзрәк шул. Әлбәттә, чынлыкта ул халыктан талап җыелган акчаларны КПССка кайтарып бирергә җыенмый, бары тик илгә кайтару кирәк иде. Мәсьәлә шунда—ничек кайтарырга? Анын бер кинәшер, уй-ниятләрен уртаклашыр кешесе дә юк шул, ә сораулар туа тора.

Ташкентка кайтып керүгә үк ул суверен дәүләт башкаласына кайтканлыгын тойды: бу һәр адымда сизелә, вакытны бушка үткәрмәгәннәр икән. Ул беренче көннәреннән үк яна хакимиятнен эш-гамәлләрен, анын ин кирәкле

даирәләрен аңларга-ачыкларга тырышты. Ул белгән кешеләрдән бары прокурор Камалов кына үз урынында нык утыра, шул гына Шубарин гамәлгә ашырырга тиешле эшнең зурлыгын бәяли алыр иде. «Камалов президент белән якынрак мөнәсәбәттә булса икән»,—дип уйлый кайчакларда Шубарин, «мәскәүле», кирәксә-кирәкмәсә җитәкчеләр күзенә күренеп, Ак йортка еш барып йөрүне яратмый. Кем президентка иркен кереп йөри ала, кемнәрне ул якын итә—болар бик тиз беленә, ә Камалов андыйлар рәтендә түгел, хәер, президент аның эшенә дә канәгатьсезлек белдерми. Бәлки, Ак йортның каты куллы хуҗасы республика прокуратурасында үз эшен яхшы белгән, холкы белән аңа тартым кеше утырганын тоядыр. «Әгәр дә мин президентны элек Рәшидовны белгән кебек яхшы белсәм, минем ниятемне ничек кабул итәр иде икән?»—дип уйлады бервакыт Шубарин, ләкин бу фикереннән шундук кире кайтты. «Якламастыр, мөгаен»,—диде. Талап җыелган байлыкны чит илдән кайтару теләгеннән хупласа да, аннары хәл итеп булмаслык мәсьәләләр һәм күңелсезлекләр генә килеп чыгар. Яшь республикага һәм аның беренче президентына зыян гына килер. Бездә шулай бит: ит яхшылык—көт явызлык.

Шубаринның башында ни өчендер «Чернобыль афәте» дигән сүзләр әйләнә иде. Нәкъ шул көннәрдә бер яшьләр газетының беренче битендә симез хәрефләр белән эре итеп җыелган мәкалә исеменә тап булды ул: «Урта Азия республикаларында һәм Казакъстанда «Чернобыль» дип атала иде ул мәкалә. Сүз Урта Азия һәм Казакъстанда яшәүче халыкларның бишеге булган Арал диңгезе һәм аның фаҗигасы турында бара иде. Шубарин үз күзләренә үзе ышанмый торды—бу бит нәкъ ул эзләгән әйбер. Арал күле үлеп бара, дөньяга танылган галимнәр фикеренчә, Арал фаҗигасенең тәэсире бик еракларга таралачак, ул да Чернобыльга тиң булачак, хәзер үк инде ерактагы Алтай халкы да, Оренбург якларындагы игенчеләр дә, Әзәрбәйҗанның Ленкораньдагы яшелчәчеләре дә җәфалана—кибеп барган күл төбеннән купкан тозлы тузан давыллары ул тирәләргә дә барып җитә икән.

Мәкаләдә бу экологик һәлакәтнең гаеплесе КПСС икәнлеге, аның хуҗалык итә белмәве, кешеләргә һәм табигатькә төкереп каравы, үзбелдекләнеп, надан карарлар кабул итүе дә ачык әйтелгән иде. Гөлчәчәкләргә күмелеп утырган төбәккә Хрущев чорында бер генә үсемлек—мамык утыртылып килде. Төбәк терлекчелектән, бакчачылыктан, игенчелектән, чөгендер игүдән йөзем үстерүдән мәхрүм калды. Йөзләгән мең гектардагы алма бакчалары, чикләвек әрәмәләре, тәмәке басулары, көнбагыш, житен, киндер кебек май бирә торган үсемлекләр, алар белән бергә умартачылык та юк ителде. Яр буйларында яшәүче кешеләрне ашатып-эчертеп торган Сырдарья белән Амударья—Урта Азиянең ике бөек елгасы бер җәй эчендә үз суларын тамчысына кадәр мамык игүгә биреп бара башлады. Бу елгалар эчке диңгез дип аталган Аралга гасырлар буе коеп торганнар, шул тирәләрдә иркен-мул, ямьле тормыш алып барырга ярдәм иткәннәр. Ә хәзер, аларның суы килми башлагач, Арал күз алдында кибеп бара. Су аның элекке ярларыннан дистәләрчә, ә кайбер урыннарда хәтта йөзләрчә чакрымнарга киткән, хәзер инде елгалар да үзләрен коткаруны көтәләр. Мәкаләдә халыкара белгечләрнең Аралны терелтү өчен кешелек дөньясы күпме капитал сарыф итәргә тиешлеген күрсәткән саннар да бирелгән. Иң арзаны дигәненә дә, әгәр кайтарып алып булса, КПСС урлап туплаган акчаларда бер өлеш эшкә генә житәсе икән. Кешелек большевикларның тәҗрибәләрен ерып чыгу өчен озак еллар интегәчәк әле.

Бу газет мәкаләсе Шубаринның күңелен күтәреп җибәрде. Аралны коткарып калу идеясе, бәлки, прокурор Камаловны хөкүмәт дәрәҗәсендә яклау эзләп карарга да этәрер, калган ягын, тәвәккәлләп, Шубарин үзе майтарып чыгар иде. Тагын бер әһәмиятле шарт бар: чит илләрдән беренче зур суммалар кайтартылу белән Әнвәр Абидович төрмәдән азат ителергә

тиеш, монысын Миланда сөйләшүләрдә ачыклап бетерергә кирәк. Әлеге тоткынны йә Мюнхенга, йә Миланга китерүне бернинди киртәләрсез-нисез башкарырга көчләре житкәч, Әнвәр Абидовичны азат итү дә котелмәгән хәл булмастыр. Хәзер бит бик күпләр, хәтта үлемгә хөкем ителгәннәр дә ирекка чыкты. Әгәр Үзбәкстан прокуратурасы элекке КПСС акчалары дип, банкның законсыз валюта эшләрен тыйса, ул акчалар артында торучылар иң әүвәл мамык Наполеонын юк итәчәкләр. Чөнки ул бит шундый хәтәр эшне ерып чыга алырлык кеше Шубарин дип ышаныч белдергән иде. Шуңа күрә Шубарин Әнвәр Абидовичны өенә кайтарып, аннары ышанычлырак урынга яшермичә торып, акча эшләрен түгәрәкләмәскә булды. Бу вариантны ул Миланда гына түгел, Ташкентта да Камалов белән сөйләшеп хәл итәргә җыена иде.

## XXIII

Хан Акмалның Мәскәү адвокатларын Сухроб Әхмәтович өч көн көтте— әллә башкалада тоткарландылар шунда, әллә Сабир-бобо үзләренә бирәр яна сынау оештырды, ә бәлки, ач башкаладан соң Аксайда типтереп яталардыр. Мәскәүдә хәзер бик рәхәт түгел, иксез-чиксез илнең һәр почмагыннан муллык елгалары агып тормый, ә Аксайда һәрвакыт ханнарча кунак итәләр. Бер-ике көн тауларда, тыюлыкларда саф һава сулап өч-дүрт шарлавыкны карап туйгач, бай табын—дәстархан янына кайтып утыру күңелле, әлбәттә—хәзер мондый мәҗлесләрне кесәсе бик калын байлар гына үткәрә. Сенатор үзе дә Аксайда үткәргән көнен татлы итеп искә ала, тауларга менеп, аучылар йортында булырга вакыт калмавы гына кызганыч. Аны кайчандыр хан Акмал үзе шунда кабул иткән иде, һәм, ниһаять, бер-берләре белән аңлашып кул сугышкан иделәр.

Ниһаять, дүртенче көнне, ул инде Сабир-бобо белән элемтәгә керергә җыенганда, иртән иртүк телефон шылтырады. Мәскәү юристлары Нәманган поезды килеп туктаган Көньяк вокзалдан шылтыраталар һәм очрашырга телиләр икән. Бер сәгатьтән соң Сухроб Әхмәтович аларны табын янында сыйлап утыра иде инде. Сенатор хаклы булып чыкты: кунакларның сый-нигъмәтле Аксайдан тиз генә китәселәре килмәгән, алар, бер-берләрен бүлдерә-бүлдерә, үзләрен ничек кабул иткәннәрен сөйләп утырдылар. Аннары самолетка утырып киткәнче, мәхәллә чәйханәсендә, Сухроб Әхмәтович пешерткән пылауны ашап алырга гына бүленеп, көне буе хан Акмалны нинди юллар белән азат итү мөмкинлеге турында сөйләштеләр.

Вакыт та, вакыйгалар да Акмал Арипов файдасына иде. Әгәр дә аны— партиянең Зәркәнт өлкә комитеты секретарен хөкем иткән шикелле, тиз кулдан гына хөкем итсәләр, бәлки, иң югары җәзага да тартырлар иде. Бик күп елларга хөкем итсәләр дә, ул чагында Арипов чиксез шат булыр иде, чөнки алты ел элек тә суд өчен материаллар җитәрлек, үз сүзләрендә нык торучы шаһитлар да йөзләгән булды, әмма СССР Прокуратурасы ашыкмады. Ул вакытта тиздән илне таркатырлар, Ариповны тәп гаепләүче булган СССР Прокуратурасы да ил белән бергә юкка чыгар, дигән уй беркемнең дә башына килә алмас иде. Озын-озакка сузылган тикшерү дәвамында прокуратура хан Акмалга алты йөз томлык җинаять эше кузгатып, йөзләгән шаһитлар эзләп тапты. Адвокатлар менә шул шаһитларны ныклап талкырга тиеш булдылар. Барлык томнарны җентекләп өйрәнеп, күзгә-күз очрашуларның видеоязмаларын карагач, алар үз сөйләгәннәрен үзгәртергә мәҗбүр итеп булырлык шаһитларның исемлеген төзеделәр. Хәер, дөресен әйткәндә, Аксай хуҗасына каршы сүз сөйләрдәй кешеләр үзгәртеп кору елларында кимегәннән кими бара иде. Адвокатлар төзегән исемлектә күбесенчә хан Акмалга ниндидер

үче булган иң үҗәт кешеләр генә торып калды. Шаһитлар нигездә Аксайдан һәм якын кышлаклардан иде, Нәманганның хан Акмал тарафыннан бик каты кыйналган берничә түрәсе дә бар. Тагын Ташкенттан һәм өлкә газетыннан килгән бер-ике журналист орденлы хуҗалыкта хөкем сөргән тәртипсезлекләр турында нәрсәдер язарга уйлый иделәр.

Шаһитларның исемлеге күптән, әле адвокатларның Аксайга беренче килүләрендә үк, Сабир-бобога бирелгән иде. Тынлаусызларын «тәрбияләү» өчен. Бу исемлектән тыш Сабир-бобо Акмал Ариповка каршы сөйләгән шаһитларның чыгышларын да алды. Хәзер инде бер дехкан да аңа: мин болай дип сөйләмәдем, хәтерләмим, дип әйтә алмаячак. Тикшерүчегә ике катлы ишек артында сөйләгән сүзләренең Сабир-бобога билгеле булуы аларны шаккатыра иде. Алар көчле белән көрәшмә, дигәннең хак булуына янә бер кат ышаналар. Берәрсе өстеннән жалу язсалар, шул ук кеше жалуынны үзе тикшергәнен күрә иделәр. Үзгәртеп коруның барып чыкмавы кешеләрнең күңелләрен төшерде, ә бит аңа зур өметләр багланган иде. Димәк, һәммәсе дә үзенең иске эзенә кайтып төште.

Кешеләр, Сабир-бобо бик басым ясамаса да, ул кинәш иткәнчә язып бирделәр, ә аны Мәскәү адвокатлары өйрәтеп куйган иделәр. Шулай да кайсыберләрен куркытырга, кемнәргәдер чаралар күрергә дә туры килде. Икенчеләрен юмаладылар: кемгәдер сарык бирелде, кемгәдер—акча, кемгәдер—берәр җылы урын, кемнәрнеңдер балаларын институтка урнаштырырга булыштылар. Шаһитларның барысы да диярлек үзләренең элекке сүзләреннән баш тартты, шул хакта үз куллары белән язып та бирделәр; хәтта журналистлар да, мәкаләләрен кире кагып, безне бутаганнар, илнең алдынгы хуҗалыгындагы тирән үзгәрешләрне аңлап җиткермәгәнбез, дип язып чыктылар: кыскасы, Мәскәүдәме, Ташкенттамы суд була калса, адвокатлар аңа әзер, гаепләү эшен бик нык какшаттылар, әгәр, дөрес хәрәкәт итеп, үзләре һөҗүмгә күчсәләр, һәммәсен дә сәяси яктылыкта күрсәтергә булыр—димәк, эшне алар отачак иде.

Сенатор, Мәскәү адвокатларына вәгъдә иткәнчә, кирәкле кәгазьләрен өч көндә әзерләп бетерде дә юлга җыена башлады. Вакыйгалар шул кадәр тиз алмашына, кем әйтмешли, «абыстайлар куерган»: тагын берәр түнтәрелеш булса, бернинди яклаулар-юлламалар да,—ялганнарын әйткән дә юк инде,—хан Акмалга ярдәм итмәс, шуны белгән Сухроб Әхмәтович шуңа күрә ашыга иде. Ләкин, Мәскәүгә китеп барганчы, Сенатор Шубаринның Камалов белән мөнәсәбәтләрен ачыкларга теләде. Әгәр дә алар арасында бәйләнешләр булып, алар нинди дә булса бер фикергә килсәләр, ул шунда Мәскәүдә үк яки әле самолетта ук Шубаринны хан Акмал алдында начар яктан күрсәтергә тырышыр, аларның араларын бозар. Ирекка чыккач, Аксай хуҗасы янадан үз көченә керер. Сухроб Әхмәтович моның шулай булырына шикләнми, шуңа күрә дә җәберләнгән Ариповны «Матросская тишина» төрмәсенең капка төбендә үк каршы алырга тели иде. Ләкин Шубарин белән Камаловның бәйләнешләрен капшап, нинди дә булса шикләнерлек эшләрен, никадәрле тырышып караса да, Канзафар таба алмады, үзенә йөкләнгән бурычны үтәп чыгарга җай тапмады. Хан Акмал белән Шубаринның араларын бозу ниятен Сухроб Әхмәтовичка калдырып торырга туры килде. Беренчедән, тегеләрнең аралашулары күптәннән килә, икенчедән, Аксай хуҗасы Шубаринны һәрвакыт югары бәяли, аның көчен белә, тагын иң мөһиме шул: ул анык дәлилләр китерүне сораячак, ә дәлилләр юк иде. Аннары, вакыйгаларны ашыктырмау да хәерле, ашыккан-ашка пешкән, ди.

Сенаторның көч-җегәре ташып тора иде, Мәскәүгә китеп барганчы, ул Шубаринны икенче яктан капшап карарга булды: Талибны күреп сөйләшергә теләде. Максаты ике төрле иде: әгәр Талиб Солтанов Шубарин яклы

булса, аларның ниятләрен бозарга кирәк, әгәр дә инде Артур Александрович белән аралары салкынайган икән—моны үзен хакимлеккә күтәргән кешегә каршы юнәлтергә була.

Билет алгач, Сухроб Әхмәтович Шубаринны эшендә күреп чыгарга уйлады, берочтан газетлар бик күп язган элекке «Рус-Азиат банкы» хәзер нәрсәгә әверелгәнен дә белер. Үзенен Мәскәүгә бару сәбәбен, Сабир-бобо адвокатларнын эшен тизләтеп жибәрүне сорады, дип аңлатыр. Ул Югары судтан алган яклау-юллама хат турында да, Югары суд исеменнән үзләре оештырган ялган хат турында да сөйләүне кирәк тапмады. Кем белә, әгәр дә ул үзләренен кан дошманы булган прокурор Камаловка ишетелә-нитә калса—бер ялган хат аркасында гына да хан Акмалны «Матросская тишина»да озак тотарга мөмкиннәр. Сенатор «Шәрекъ» банкынын төзәтелгән-янартылган бинасына барырга жыенып йөргән көннәрдә, иртән өендә телефон шылтырады.

Бу Шубарин иде, Шәрекь гадәтенчә, хәл-әхвәлләрне, саулык-сәламәтлекне, гаилә-бала-чагаларны, кәефен сораштырганнан сон, ул Сухроб Әхмәтовичнын үз банкына кереп чыгуын үтенде. Сенатор: «Әгәр каршы килмәсән, берәр сәгатьтән керермен»,—диде. Шулай килештеләр дә. Бу сөйләшү Сухроб Әхмәтовичның күнелен кузгатты, ул бүлмәсе буйлап бик озак әрле-бирле йөренде. Бер сәгатьтән ул көтмәгәндә генә үзе Шубаринга барып чыгарга теләгән иде—булмады инде. Японец, әйтерсен, аның уйларын укыган, дилбегәне үз кулына алды. Моны Сенатор, хәерлегә түгелдер дип, ни өчендер борчылуга биреллде.

Бер сәгатьтән Карден теккән ефәк костюм кигән һәм кычкырып торган итальян галстугы таккан Сухроб Әхмәтович банкка килеп керде. Яндырылган кызыл кирпечтән салынган ялгыз иске йортны ул бары тик мангаендагы «1898» дигән язуыннан гына таныды—бина һәм анын тирә-ягы танымаслык булып үзгәргән икән. Бина үзе ачык төстәге жирле мәрмәр белән бизәлгән, йөз еллык тар тәрәзәләрне дюраль рамлы бик зур тәрәзәләр алыштырган, ул бик кырыс, рәсми төс алган иде. Ә тәрәзәләрдәге кулдан коеп куелган тимер рәшәткәләр үткән гасырларны хәтерләтә, ул заманнарда шулай матур итеп төзи белгәннәр бит. Ә хәзер һәр газет киоскасынын тәрәзәләрендә дә тимер рәшәткәләр. Банк алдындагы зур булмаган мәйдан һәм кечкенә бакча шул кадәр тырышып, ялап куелгандай жыештырылган ки—һәр үткән-барган, башын күтәреп, кем шулай тырышкан икән, дип караса, бина мангаендагы «Шәрекь банкы» дигән сүзләрне укыр иде.

Сенаторны банкның эче бигрәк тә сокландырды. Ул үзен бөтенләй башка дөньяда итеп тойды. Банкны төзекләндергән-янартканнарын ишеткән булса да, күзләре күреп туя алмады: яхшы шомартылган кызыл агач белән капланган биек түшәмнән борынгы бәллүр люстра асылынып тора, беренче катнын түгәрәк иркен алгы ягына чыга торган эш бүлмәләренең ишек тоткалары бронзадан икән. Гөлт итеп яктыртылган озын коридор диварларындагы рәсемнәрне дә тукталып карап узмыйча булмый. Коридор иданенә шәрекьчә итеп келәм юллар сузылган. Бер Сенатор гына түгел, бирегә беренче тапкыр килеп керүчеләрнең һәрберсе шулай таң калып тора торганнардыр. Аны көтәләр икән инде, ишек төбендәге хезмәткәр, бернинди документ-фәлән сорап тормады, юл күрсәтте.

Сухроб Әхмәтович үзенең акыл кешесе түгел, ә хис кешесе икәнлеген белә иде. Ул мин алдан күрдем, дип бик сирәк әйтер, күбрәк мин сизендем, дияр. Менә бүген дә ул беренче кат белән икенче кат арасындагы иркен баскыч мәйданчыгында борынгы кисмәктә үсеп утырган, яңа юылган пальма белән янәшәдәге бронза алиһә Ника янында тукталып калды. Ника, имеш, акчалы байларны яклый, дигән ышану да бар, ләкин Сенаторның куркынычны сизү хисе уянды. Пальманы караган булып, уйлап алды: әллә кермәскәме

икән? Ләкин бер минуттан ул исенә-аңына килде—чигенергә урын юк, пинжәге астыннан коралы да күренеп торган ишек төбендәге сакчы Шубаринга хәбәр итеп өлгергәндер, Шубарин аны көтәдер инде. Чыгып китсән, әле Миршабтан да яшереп килгән усал ниятләреңне таныдың, дигән сүз булачак. Шуңа күрә ул тиз генә өскә күтәрелә башлады.

Банк хуҗасы, чынлап та, аны көтеп тора икән, Сенатор килеп кергәндә, секретарь кыз кулыннан чәйнек белән пиалалар куелган подносны алып маташа иде. Шубарин, киң елмаеп, аны тәрәзә буендагы кәнәфиләрнең берсенә утырырга чакырды, ике кәнәфи арасындагы кечкенә өстәлгә чәйле подносны да китереп куйды.

Әкрәмхуҗаев ике кәнәфинең берсенә килеп утырды, нәкь шул кәнәфидә бер атна элек Ак йорттагы Тулкун Назарович утырып, Шубаринга бервакыт үзен Сухроб Әхмәтович китереп кысканын бәян иткән иде. Карт сәясәтченең элекке сөйләнүләре дә үзенә бер мең долларга төшкәнен хәтерләп, Шубарин ирексездән елмаеп куйды.

Сүзне Сенатор башлады. Ул әүвәл кергәндә үзе күреп сокланган бизәлешне мактап узды, шулай итеп, үзенең киеренке халәтен йомшартып җибәрде. Хәзер ул үзен ышанычлы тота иде инде.

Шубарин аның сокланып та, ялагайланып та банкның бизәлешләре хакында сөйләгәннәрен тыңлаганнан соң, үз чиратында саулык-сәламәтлеген, гаиләсен сорашты, эшендә хәлләр ничегрәк икәнен белешкәч, акчалата ярдәм кирәкмиме, дип тә кызыксынды. Шунда Сухроб Әхмәтовичның йөрәге дертләп куйды: ул бит Сабир-бобо чакыргач, Аксайга барып кайтканын әйтмәгән иде. Хәзер инде, Шубарин акчалар турында сүз кузгаткач, хан Акмал янына барганын, акча яклары хәл ителгәнен әйтми булдыра алмады. Сенатор бу сәяхәтен Японец белгәндер дип уйлады һәм барысын да сөйләп бирде, хәтта иртәгә Мәскәүгә очасын да яшермәде.

Кайсыдыр бер мизгелдә Сенатор Шубаринның сөйләшүне ирексездән сорау алуга күчергәнлеген сизеп алды. Шубарин да моны искәрде, икесе дә Сухроб Әхмәтовичның эш бүлмәсендә беренче тапкыр очрашканнарын искә төшерде, анда да хуҗа барыбер Шубарин йогынтысында калган иде. Ул чакта да Сенатор җай чыгудан файдалана алмады, хәзер дә сүз җебенең кулыннан ычкынганын гына чамалады. Шубарин моны шунда ук сизеп алды.

Хәл-әхвәл белешүләрне түгәрәкләгәч, Шубарин сүзне коры тотты:

—Кадерле Сухроб Әхмәтович,—диде ул,—без күрешми торган арада тирә-юньдәге вәзгыять тә үзгәрде, без үзебез дә хәзер кайчандыр язмыш очраштыргандагы кешеләр түгел инде. Без хәзер башка илдә яшибез, башка дөнья чолганышында. Сезнең хан Акмалга барып кайтуыгыз да моны раслый. Ә бит Аксай хуҗасы һәрвакытта бөтен төбәк язмышын үз кулында тотарга уйлап яшәде, аның бу теләге әле һаман да сүнмәгән, хәзер инде Рәшидов дәрәҗәсендәге сәясәтчеләр дә юк, ә калганнарын ул үзенә көндәшләр дип тә санамый. Мин Аксай хуҗасын яхшы беләм,—диде.

Игътибар белән тыңлаган Сухроб Әхмәтович әллә ризалашты, әллә юк—баш кагып кына куйды.

—Бу елларда беренче очрашканда сөйләшеп омтылган барлык теләкләрегезгә дә ирештегез,—дип дәвам итте Шубарин.—Сез инде танылган кеше, хәзер, электәге шикелле, яклавыма да мохтаҗ түгелсездер. Мин сизенеп торам, безнең юлларыбыз аерылачак. Сез, бер мәртәбә хакимлекне татыган кеше буларак, аны кайтарып алырга тырышачаксыз, димәк, баш-аягыгыз белән сәясәткә кереп чумарсыз. Элегрәк мин дә шуңа тартылган идем, чөнки һәр эшчәнлекне партия күзәтеп торды. Хәзер инде икътисад кануннары эшне хәл итә, безнең тормышыбыз да тиз көннәрдә сәясәттән азат булыр, юкса безне чираттагы тупыйк көтәчәк. Мин ныклап торып финанс эшләре белән

шөгыльләнергә телим. Мин үзгәчә яшәргә телим, бу хакта күптәнге дусларыма да ачыктан-ачык әйтәм. Бәлки аларның ниятләре башкачарактыр, мине бик хуплап та бетермиләрдер. Өстәп шуны әйтәсем килә, киләчәктә дә мине куркытмаслар дип беркем дә әйтә алмый, мин анысын да аңлыйм. Минем юлыма аркылы төшәргә теләүчеләр булса, ныклап уйлап карасыннар. Мин бирәү белән дә көрәшергә теләмим, Үзбәкстан өлешенә дә төшкән тарихи мөмкинлектән файдаланырга гына телим—мин һәрвакыт банкир булырга хыяллана идем. Кыскасы, үзем дә, банкымны да якларга көчем җитәрлек әле. Сез мине аңлыйсызмы?

Сухроб Әхмәтович тагын баш кагып кына куйды.

—Мин,—дип сүзен дәвам итте Шубарин,—үземә каршы кешеләргә дә үткәндәге элемтәләремне тикшерергә мөмкинлек бирәм. Соңыннан гайбәт сөйләшеп йөрмәсеннәр, дим. Мәсәлән, Сухроб Әхмәтович, безне бит гади хезмәттәшлек белән кыска гына очрашып алуыбыз гына бәйләми, без бит гомуми бер мөлкәткә ия кешеләр. Мин гөрләтеп яшәп, безгә табыш китереп торган «Лидо» ресторанын турында әйтәм. Хәзерге хәерчелек заманында бу аз түгел. Нәргиз белән Икрам Мәхмудович әйбәт хезмәткәрләр булып чыкты, әгәр дә сез безнең мөнәсәбәтләргә шик-шөбһә белдерәсез икән, яки нинди дә булса ризасызлыгыгыз бар икән—әйтегез, мин сезне тыңларга әзер. Ходай Тәгалә күрә, мин танышлыгыбызның беренче көннәреннән үк сезнең белән ачык булдым, мин җентекләп тикшермичә, сез минем даирәмә шулай гына килеп кергән бердәнбер кеше идегез. Яшермим, сезнең кайбер эшчәнлегегез миндә шикләнүләр дә тудыра иде, әмма мине һәрвакыт сез республика прокуратурасыннан алган документлар салынган дипломат шикләремне юкка чыгара килде. Мин аларны очраклылык, яки сезнең озак еллар өскә чыга алмый яткан эшчәнлегегез нәтиҗәсе дип кабул иттем.

—Мисалларыгыз...

—Мисалга, сезнең яшерен генә Аксайга баруыгыз,—дип тыныч кына җавап бирде Шубарин.—Сез, миңа әйтми-нитми генә, хан Акмалдан сәяси яклау да, акча да алырга теләгән идегез. Сез бит безнең аның белән күптәнге бергә эш йөртүчеләр икәнлеген белә алмый идегез. Сезнең бу уйланмаган адымыгыз үзегезне чак кына үлемгә китермәде... Шундый адымыгыз миндә шикләнү тудырмаска тиеш идеме?

—Артур Александрович, сез хаклы,—диде башын игән Сенатор.—Мондый адым мине дә сагайткан булыр иде...

—Әлбәттә,—диде Шубарин,—мин ул кадәрле беркатлы кеше түгел. Барысын да очраклылыкка яки сезнең хислегегезгә кайтарып калдыра алмыйм. Сез сәяси эшчәнлегегез өчен Аксайдан биш миллион алып кайтканны белгәч, мин сезнең хакта башта ук мәгълүматлар җыймаганыма үкендем, юкса, һәрвакыт шулай эшли идем бит. Мине гаҗәпкә калдырган икенче хәл дә озак көттермәде. Ул хәтта сезнең дустыгыз Миршабны да аптырашта калдырды шикелле.

Әкрәмхуҗаевның бу сүзләрдән соң тын да алмый утырганын күреп, Шубарин юри сүзеннән өзелеп торды. Нәкъ шул вакытта язу өстәленә алдан ук кертеп куелган телефон шылтырады. Шубарин сөйләшеп алгач, сорап куйды:

—Без кайда туктаган идек әле, Сухроб Әхмәтович?

Үзенең горурлыгын югалткан Сенатор, ашыгып кына ачык бизәкле галстугын төзәтеп алгандай итте дә:

—Сезнең икенче кат аптырап калуыгызда...—диде.

Ул, чынлап та, алга таба сүз кай тирәдә барасын белми иде. Ә Артур Александровичны һәрвакыттагыча аңлап бетереп булмый.

—Ә, әйе,—диде ул.—Мин сезнең докторлык диссертациягез һәм матбугатта чыккан канун һәм хокук турындагы мәкаләләрегезне күздә тотам. Шулар бит сезне өлкәдә танылган юрист иттеләр. Безнең беренче очрашуыбызда сез, үзегезгә фәнни эшләрдә мөмкинлек бирмиләр, мин инде бик җитди фәнни теоретик эшләр яздым, докторлык диссертациям дә әзер, дигән сүзләр сөйләмәгән идегез бит. Сез миннән ул вакытта бары тик акча гына сорадыгыз, ә бу фәнни эшчәнлегегез турында ләм-мим, бер сүз дә әйтмәдегез. Дөресен әйтим, сезнең тормышыгыздагы андый юнәлешләр дә барлыгын мин башыма да китермәс идем. Сезнең матбугаттагы чыгышларыгыз турында, сокланулы бәяләрдән тыш, булырга мөмкин түгел, дигән сүзләр дә ишеттем. Сезне якыннан белгән кешеләр докторлык диссертациясе яза алуыгызга да, мәкаләләрегезнең бер генә юлына да ышанмаучылар булып чыкты. Алар, берәр акыллы белемле кешене яллагандыр, диделәр. Чит кеше кулы белән язылган докторлык диссертациясе безнең якларда сирәк күренеш түгел, киресенчә. Шулай эшләгән кайберәүләр, бары тик юридик фәннәр докторы исемен алып, республикада иң җайлы-җылы урыннарга үрмәләргә генә тели иделәр.

Иң әүвәл мин сезнең докторлык диссертациясен юнәтеп, укып чыктым: бик профессионал, гыйльми, кирәкле хезмәт. Әмма укыган саен моңа охшаш хезмәтне әллә укыган, әллә ишеткән идем, дигән хистән арына алмадым. Телдән сөйләүче Әкрәмхуҗаев белән язма эшләр авторы Әкрәмхуҗаев арасында аерма зур иде, мин сездән шәхси сөйләшкәндә, яки кануннар, хокук турында сүз чыкканда, бер дә андый фикерләр ишетмәдем...

Шубарин Сенаторны читтән генә күзәтеп утырды, әмма теге сүзсез-нисез, кәнәфиенә таш булып берегеп каткан иде.

—Кызыксынуым арта төште, мин зур түрәләргә докторлык хезмәтләре «пешереп» бирә торган кешеләргә килеп чыктым. Үземне аптыраткан сорауга тиз генә җавап табармын дигән идем дә, нәтиҗә көтелмәгән булды: хезмәтне югары бәяләделәр, авторы, шиксез, үзебездәге кешедер, эчке проблемаларыбызны яхшы белә, диделәр. Әмма авторын берәү дә әйтә алмады. Кире нәтиҗә кайвакыт унаеннан да кыйммәтрәк була. Мин һаман ешрак сезнең докторлык хезмәтегез үтерелгән прокурор Азлархановы белән булган сөйләшүләребезне хәтерләткәнен искәртә бардым. Мин Әмирхан Даутовичтан ул вакытта әле артык кыю булган фикерләрне күп ишеттем. Җентекләп тикшереп җыелган мәгълүматларым буенча, сез беркайчан да таныш булмагансыз, аралашмагансыз, ул елларда дәрәҗәләрегездә зур аерма булган, сезнең үзара бәйләнешегез булмавы да мине кызыксындырды. Тагын мин бер нәрсәгә игътибар иттем: докторлык диссертациясе язу, ныклы әзерлек һәм төпле белем булган очракта да, җитди китапханәләрдә еш казынуны таләп итә. Сезнең хезмәтләрегездә атаклы философларга, хокук белгечләренә мөрәҗәгать итү, юридик яктан тотрыклы Англия, Италия, Греция, Германия кебек киң танылган илләрнең хокукый хезмәтләреннән сөземтәләр алулар шактый күп. Мин хәтта үземдә булган сирәк китаплардан кайбер цитаталарны да эзләп таптым—өтерләренә чаклы туры килә. Ләкин шунысы ачыкланды, сез бервакытта да дәүләт яки университетның юридик факультеты, яки республика прокуратурасы китапханәләреннән дә файдаланмагансыз, өегездә дә андый китаплар юк икән. Сәер түгелме бу, Сухроб Әхмәтович?

Сенатор ирексездән куырылып төште, үзен бик унайсыз тота башлады, ләкин җавап бирергә теләмәде. Ана Японецның үтә яшерен документларыннан күчермәләр алганлыгы билгелеме икәнен белү мөһим иде. Үзенә хакимиятнең югары катламнарына үтеп керү мөмкинлеген шул кәгазьләр бирде бит. Үтерелгән прокурор Азлархановның фәнни хезмәтләрен, мәкаләләрен урлап файдаланганы фаш булу Сенаторны артык борчымый иде. Ул бу гөнаһын

танып, тәүбә итәргә дә әзер, үткән эшкә—салават, диләр. Аның докторлыгын раслаган аттестация комиссиясе дә юк хәзер.

—Мин биографиягездәге шундый мөһим фактларны яшерер сәбәбегез юк, дип уйлаган идем,—дип сүзен дәвам итте Шубарин.—Минем аңлыйсым килә, шундый зур гыйльми дәрәҗәгез нинди серне саклый, нигә аны миннән яшерәсез? Сез бит мине ышанычлы кеше, хәтта дустыгыз итеп саныйсыз. Менә шушы ваклыклар мине сезнең хезмәтләрегезне кат-кат өйрәнергә мәҗбүр итте дә. Сез бит минем табигатемне беләсез, кызыксынган сорауларыма җавап тапмый торып, мин чигенә торган кеше түгел. Танылган юристлар арасында сезнең хезмәтегезнең авторы турында ышанмаучан фикерләрне янә ишеткәч, башымда шундый уй туды: сезнең хезмәтләрне түгел, ә Әмирхан Даутовичның иҗади мирасын өйрәнергә кирәктер, бу табышмакның җавабы, бәлки, шундадыр, дидем. Шулай эшләдем дә. Иң әүвәл Азлархановның Мәскәүдә яклаган кандидатлык диссертациясен эзләп алдым. Шунда ук аның башка хезмәтләре дә табылды. Үзбәкстанда прокурор булып эшләгән елларында ул даими рәвештә илнең иң эре юридик журналлары белән хезмәттәшлек итеп торган. Кызыклы проблемалы мәкаләләрен ул әле үзе исән чакта ук чыгарып өлгергән, аларның вакытыннан элек басылып, җәмәгатьчелек тарафыннан кабул ителмәве генә кызганыч. Үзе өлкә прокуроры һәм республиканың Югары Советы депутаты булып торганда, ул илдәге законлылык һәм хокук хәлләре турында тәфсилле мәгълүматларны соңгы елларында да биреп барган. Ул республика прокуратурасына һәм Югары судка яза, Үзбәкстанның Югары Советына мөрәҗәгать итә—тормышыбызның бик кызыклы якларын ачып сала тора. Гомеренең соңгы елларын ул Лас-Вегас шәһәрендә үткәргән, анда да кайбер хезмәтләре табылды. Ул анда да республиканың яна законнары өстендә җитди эшләгән, аның тиздән суверенитет алачагын сизенгән, күрәсең.

Артур Александрович кинәт кенә урыныннан күтәрелде дә, язу өстәле янына килде, аннан пөхтә итеп тегелгән кәгазьләр салынган папканы һәм тагын аерым ятучы, шулай ук тегелгән документларны алып, журнал өстәле янына кайтты.

—Алыгыз,—диде ул Сенаторга, калын папканы сузып.—Сезне кызыксындырырга тиеш бу.

Шубарин, икенче документларны кулында тоткан килеш, кәнәфиенә килеп утырды: бирергәме-юкмы дигәндәй, уйланып торды. Аннары документларны янәшәсенә куеп, сүзен дәвам итте:

—Әмирхан Даутовичның барлык мирасын туплагач һәм өйрәнеп чыкканнан соң, ышанып раслый алам—сезнең хезмәтләрегез прокурор Азлархановның хезмәтләрен генә кабатлый, сез шуннан күчереп кенә алгансыз,—диде.

Озак сүзсез утырган Сенатор түзмәде:

—Сезгә әллә нәрсәләр дә күренер!—дип кычкырып җибәрде.—Фәнни ачышлар, идеяләр, фикерләр дөнья тулы. Канунга, хокукка, дәүләтчелеккә карашларыбыз уртак булуы да мөмкин безнең...

Артур Александрович кулына янәшәсендәге папканы алды:

—Мин риза, алай да булырга мөмкин. Ләкин сез мине, прокурор Азлархановның белән дус булуым аркасында гына сезгә каныга дип, гадел булмаган бәя бирә дип гаепләмәвегез өчен докторлык диссертациягезне һәм үтерелгән прокурорның эшләрен, фамилияләрен күрсәтми генә, билгеле, мин тикшерергә бирдем. Менә сезгә нәтиҗәсе: сезнең диссертациягез кычкырып торган плагиат, караклык!—ул Сенаторга өстәл аша әлеге папканы сузды. Анда фәннәр докторы, республика прокуроры Камаловның бәяләмәсе салынган иде. Дөрес, ул бәяләмә ксерокстан чыгарылган вариант һәм имзасыз гына иде.

Сенатор каударланып папканы эләктереп алды, әллә каушады, әллә җайсызрак тотты, папка кулыннан төшеп китте. Сөйләшүнең болай килеп чыгасын ул бер дә көтмәгән, аның югалып калганлыгы күренеп тора иде. Төшеп киткән папканы ашыгыч кына күтәреп алгач, нәрсәдер әйтмәкче булган иде, Шубарин аны кулы белән ишарәләп туктатты:

—Бәяләмә белән һәм Азлархановның мин җыйган хезмәтләре белән танышмый торып, каршы сөйләп маташмагыз. Минем вакытым кысан, сезнеке дә, сез бит иртәгә Мәскәүгә очарга җыенасыз. Инде без ямьсезләнептәмсезләнеп шулай эчкәре кергәнбез икән, мин сүзләремне әйтеп бетерергә тиеш, сезгә әле тагын бу бәяләмәдән дә җитдирәк дәгъваларем бар.

Нишләргә белми аптырашта калган Сенаторга игътибар белән карап алгач, Шубарин пиалага чәй агызды да аңа этәрде. Йомшый төшеп:

—Тынычланыгыз, үзегезне кулга алыгыз. Мин сезне матбугатта чыгыш ясарга, диссертациягез һәм мәкаләләрегезнең прокурор Азлархановныкы булуын танырга мәҗбүр итмим. Мин хәтта «Лидо» ресторанын үзем белән бергә тотучы кешенең танылган сәясәтче булып китүенә, дустым Әмирхан Даутович эшләрен урлап тормышка ашырганына да сүз әйтмим. Бердәнбер беләсем килгәне шул: ни өчен бу эш миңа әйтми эшләнде? Мин шундый ышанычсыз кешеме инде?

Шубарин янә Сенаторга текәлеп карады, үзенең соңгы сүзләреннән соң тегенең тынычлана төшкәнен күрде. Ул һич тә Сенаторның гасабиланып елый башлавын теләми, ә хәл шуңа таба бара иде шикелле. Әмма бу Артур Александровичның оста алымы гына—әле утка, әле суга салуы гына. Шубарин Сухроб Әхмәтовичны шулай тинтерәтеп, бутап бетерергә теләде. Чөнки иң соңыннан ачыклыйсы килгәне тегенең ялган докторлык диссертациясеннән мөһимрәк иде. Шуңа күрә ул, Әкрәмхуҗаевка аңга килергә ирек бирмичә, җилнең каян искәнен сиздерергә теләмичә, янә кырыс кына сүзен дәвам итте:

—Бер ачыш икенчесен тартып чыгара, диләрме әле? Биредә дә шулай булды. Бер нәрсә эзләдем, бөтенләй икенче нәрсә таптым, үземә бик тә ямьсезен таптым. Менә шул табыш бүгенге очрашуыбызга төп сәбәпче дә инде.

Сенатор кәнәфиендә янә куырылып калды. Шубарин аның сүзнең нәрсә турында барачагын сизенгәнен аңлады. Шуңа күрә турыдан-туры, болгатмыйча гына сөйли башлады:

—Бервакыт миңа Миршабтан сезнең прокурор Азлархановны белүбелмәвегез турында сорарга җай чыкты. Ул: «Юк»,—дип җавап бирде. Минем аңа ышанмаска нигезем юк. Башка мәгълүматлар аша да сезнең беркайчан да Азлархановбелән таныш булмаганлыгыгыз беленде. Сез аралашмагансыз, юлларыгыз кисешмәгән, ә танылган юристның иҗади мирасы сезнең кулга килеп кергән. Аның сезгә ничек килеп кергәнен генә ачыклыйсы калган иде. Мин бу хакта бик озак баш ваттым, сезнең белән танышлыгыбызны көнен-көнгә хәтеремә төшерә бардым. Сез, төнлә прокуратурадан документлар салынган кейсны урлап чыкканнан соң, үзегезнең эш бүлмәгездән миңа бары тик биш сәгать үткәч кенә шылтыраттыгыз, юкса бик яшерен документлар салынган дипломатны минем кешеләрем эзли башлаганын яхшы белә идегез. Шулай итеп, табышмак чишелде. Бу юлы, сезнең докторлык хезмәтегезгә бирелгән шикелле, анык бәяләмә юк-югын. Шулай да...

Сухроб Әхмәтович Шубаринны бүлдерергә, арага берәр сүз кыстырырга кыҗрап утырды. Шулай эшли алса, бәлки, сөйләшүне икенче юнәлешкә дә алып кереп китәргә булыр иде дип уйлады ул. Әмма банк хуҗасы аңа сүз кыстырырга мөмкинлек бирмәде. Сенатор, сөйләшүнең соңы килеп җиткәнен сизенеп, үзен кулга алырга тырышты, юкса, аны бөтенләй сытып изәчәк иде Шубарин.

—Азлархановның,—дип һөҗүмен дәвам итте Артур Александрович,—Рәшидов үлгән көнне Лас-Вегастан кайтып киткән чакта, ин мөһим, ин кирәкле кәгазьләрне генә алган. Ул документларда республиканың миннән акча алып торучы югары түрәләре турында мәгълүматлар тупланган иде. Азлархановның эш кешесе иде, аның өчен бары тик закон гына әһәмияткә ия иде. Бик саклап тотылган распискалар салынган сейфта ике миллион сумнан артык акча да бар иде. Ул исә алардан бер тәнкә тә алмаган. Ә менә сезгә югарыга үрләргә нигез булган хезмәтләрен алган, күрәсен, кайткач аларны дәвам итәргә уйлаган булгандыр. Алар сезнен кулга шулай килеп кергән, Сухроб Әхмәтович.

Сенатор янә нәрсәдер әйтергә талпынды, әмма бу юлы да Шубарин аны кул хәрәкәте белән туктатты:

—Хикмәт тә менә шунда шул... Миршабка да күрсәтмичә генә дипломатны ачкач, сез Азлархановның хезмәтләренә төртелгәнсез, аның әзер фәнни хезмәт икәнен шунда ук төшенеп, алып яшереп куйгансыз. Ике докторлык эше якларга җитәрлек булса да, сез бу хакта Миршабка—ләм-мим... Сезнен кызыксынуыгыз аңлашыла: шул кейс аркасында прокуратура ихатасында бер тәүлектә өч кеше үтерелде бит. Сез кейс эчендә нәрсә барлыгын белергә теләп, аны урлагансыз да. Шул рәвешле, республиканың югары түрәләренә кагылышлы мәгълүматлар да сезнен кулга килеп кергән. Алар сезгә югары үрләргә юл ачкан. Ләкин кейсны хуҗасына кайтарып бирмичә ярамый, бирмәсәгез, тормышыгызны куркыныч астына куясыз булып чыга. Костаның кулдашларына полковник Жураев оештырган засада турында аларны кисәтеп, сез ялгышкансыз, шуның белән үзегезне ачкансыз ич. Костаны травматология бүлегеннән урлап алып китеп тә ачылдыгыз—иртәме-соңмы без барыбер сезнен эзгә килеп чыккан булыр идек. Нәргиз йортында кыласы эшегез алдыннан сез минем машинадагы, өемдәге, эшемдәге телефон номерларын белгәнсез инде, аларны сезгә Коста хәбәр иткән. Сезнен ниятегез искиткеч булган: прокуратурадан дипломатны урлап аласыз да, документларның күчермәләрен ксерокс аша чыгарып, дипломатны янадан хуҗасына кайтарып бирәсез. Ул исә яхшылыгыгызны онытмас иде. Прокуратураны басудан алып эш бүлмәгезгә мин килеп җиткәнче үткән вакыт сезгә шуның өчен кирәк булган да. Мин, әлбәттә, таныш дипломатның бикле икәнен күргәч, куандым, андагы яшерен серләрнең бәясе бик югары иде, бигрәк тә Рәшидов урынына кем куелу мәсьәләсе хәл ителгән көннәрдә. Ул заманнарда ксерокслар гамәлгә кереп кенә бара иде, район прокуратурасында аның берсе бардыр, дигән уй башыма да килмәде. Соңыннан мин Миршаб аша ачыклап белдем—сез аны ниндидер эш йөртүче шома бәндәләрдән тартып алган булгансыз икән. Шул ксерокста барлык яшерен кәгазьләрнең күчермәләрен ясап алгансыз.

Шубарин бер минутка тынып калды, чәйнеккә үрелде, аның эчәсе килә иде. Шунда Сенатор, үзен тагын бүлдерүдән куркып, ашыгып сорау бирде:

—Кызыклы фараз. Ә фактларыгыз, конкрет дәлилләрегез, шаһитларыгыз бармы? Сез һаман да дустым Миршабка гына ишарәлисез. Әмма ул...

—Фактлар бар,—диде Артур Александрович.—Мондый сөйләшүләр уйланмыйча гына эшләнми, Сухроб Әхмәтович. Мин бары тик шунысын гына белмим, сездә ничә күчермә бар икән? Ә, бәлки, Миршаб та, кирәге чыга-нитә калса дип, берәр данәсен эләктергәндер—ул бит астыртын кеше, аныкын белмәссең. Ә шаһитларга килгәндә... Бер бик йогынтылы кеше бар, әле бер атна гына элек ул сез утырган кәнәфидә утыра иде. Менә шул кеше бик тәфсилләп сезнен әле коммунистлар заманында ук партия Үзәк Комитетында ничек итеп җаваплы урын алуыгыз турында, түкми-чәчми, барысын да сөйләгән иде. Сез аны бик куркытып тоткансыз, ә аның серләрен шул урланган кейстан алгансыз, андый мәгълүматлар урамда аунап ятмый,

аларны жиде йозак астында саклыйлар. Тулкун Назарович белән әңгәмәне тыңларга телисезме? Ул үзе бүген Ташкентта юк әле, ике атнага Истанбулга китеп барды...

Шунда Сенатор урыныннан кискен генә кузгалды да, һәр сүзен чатнатып, кычкыруга күчмәскә тырышып, әйтеп бирергә ашыкты:

—Мин икебезне кем һәм ни өчен ачуланыштырырга теләгәнен белмим. Бу тузга язмаган нәрсәләрне сезгә кем сөйләде икән? Вакыт барысын да хәл итәр, һәр нәрсәне үз урынына утыртыр. Тулкун Назарович ише кешеләргә ышанырга ярыймы соң? Аңа Төркиягә барырга кирәкле долларларны түләүчегә ул теләсә кем турында теләсә нәрсә ялганлый алыр иде.

Үзенең ачулы сүзләрен сөйләп бетерүгә, Сухроб Әхмәтович жил-жил атлап ишеккә юнәлде. Шубарин аның болай ашыгып качып китүен көтмәгән иде. Барыннан да бигрәк Сенаторга унайлы булган сөйләшүне басарга кирәк булды, шуңа күрә Шубарин аны кычкырып туктатты:

—Очрашуыбызны ничек кенә бәяләсәгез дә, мин сезгә нәкъ ун көн вакыт бирәм, анысы да Мәскәүгә барып кайтасы булган өчен генә. Сез миңа Миршаб күз алдында документларымның барлык күчермәләрен дә китереп бирерсез. Юкса, мин кирәкле кешеләргә ул кәгазьләрнең сездә булганлыгын һәм сезгә ничек килеп эләккәннәрен сөйләп бирәчәкмен. Башка тәкъдимнәрем юк. Сау булыгыз!

## XXIV

Сенатор чыгып китүгә, Артур Александрович секретарь кызны чакырып кертте дә, чәй китерүен сорады—ни өчендер тамагы кипкән иде. Аннары ул, мәйданга карап торган тәрәзә янына килеп, аны киереп ачып жибәрде, дүртенче катка шунда ук шәһәр шау-шуы кереп тулды. Банктан ерак түгел генә Ташкентның борынгы уку йорты—авиатехникум бар иде, матур милли күлмәк кигән яшь кызлар төркем-төркем булып шунда кереп-чыгып йөриләр, әйтерсең лә, дингез дулкыны бер килеп бәрелә дә, бер кире чигенә. «Ни өчен әле бу үзбәк кызлары кинәт кенә авиациягә тартыла башладылар?»—бу уй кабынды да шунда ук сүнде. Ул әле һаман да баягы сөйләшү тәэсиреннән котылып житмәгән иде, һаман да: «Сенаторның ашыгып качып китүе нәрсә аңлата икән?—дип уйлый иде. Димәк, Сухроб Әхмәтович шул рәвешле үзе үк ни-нәрсә эшләргә кирәклеген күрсәтте. Әгәр дә ул, Мәскәүдән кайткач, теге документларны кайтарып бирмәсә, чынлап та, кайбер кешеләргә аларның серләре Әкрәмхужаев кулында икәнлеген әйтергә туры киләчәк.

Яңадан хакимияткә кайту өчен Сенатор беркемне дә кызганып тормас. Әгәр дә ул, тәүбәгә килеп, кулындагы документларны тиешле кешеләренә кайтарып бирмәсә, алар, икеләнеп тә тормыйча, аны Камаловка тоттырачаклар—Шәрекъттә дошманнарыңны чит куллар белән юк итәргә яраталар, тиешле сәбәбен дә табарлар. Аста шаулап торган фонтанга да, банк янына килеп-китеп йөргән чит ил машиналарына да игътибар итеп тормастан, Шубарин шулай фикер йөртте. Документларны кайтарырмы-юкмы—бер нәрсә ачык: Сенатор ышанычсыз кеше булып чыкты, алга таба аның белән эш йөртү ярамастыр, зур эшләр рәтле-тәртипле кешеләр белән генә эшләнә. Шул ачык тәрәзә янында ул көтмәгәндә генә ресторан мәсьәләсендә анык бер фикергә килде: барлык жепләрне дә өзеп бетерү мәслихәт, табышлы-төшемле урын дип, кызганып торып булмас. Ничектер әлеге «сиам игезәкләре»—Сенатор белән Миршаблар өчен алтын йомырка салучы тавык урынында калып, шул ук вакытта алардан бөтенләйгә аерылуны да теләү урынсыз иде. «Лидо» ресторанны нинди генә табыш китермәсен, Шубарин өчен үз мәсләге һәрвакыт мөһимрәк булды, акча аның тормышын беркайчан

да томалап тормады, аннары шунысы да бар: банк ачып җибәргәннән соң, акчасы да көннән-көн үсә-арта тора бит. Аның паен сатып алучылар, алырга теләүчеләр теләсәң күпме, хәзер Ташкентта да рәсми миллиардер байлар ишәйде, ә шулай да ул үз өлешен теләсә кемгә бирмәстер. Ул Костага да пай тәкъдим итәр иде, ләкин Джиоевны ресторан бер дә кызыктырмый, аның фикеренчә, ул эш чын ирләргә лаек түгел, юкса бик күпләрнең хыялында шул бит. Шубарин үзенен иң зур паен Нәргиз белән Икрам Мәхмүтовичка бирер, алар «Лидо» өчен бик күп көч түктеләр, Артур Александровичның да юмартлыгын онытмаслар—алар башкаладагы иң яхшы ресторанның ни-нәрсә икәнлеген яхшы аңлыйлар бит.

Шубарин өстәл календарен үзенә якынрак тартты, алдагы айның беренче чәршәмбесе симез кызыл фломастер белән түгәрәкләп алынган иде. Артур Александрович бу көннең нәрсә аңлатканын исенә төшерергә теләде, кинәт кенә бу атнада кәефе ни өчен шулай күтәренке булуының, гомумән, Мюнхеннан кайтканнан бирле кәефле йөрүенең сәбәбенә төшенде. Фломастер белән түгәрәкләп куелган көн аның Миланда буласы көне иде. Анда ул үзенең элекке кулдашы Әнвәр Абидович белән очрашачак, ә тегесе аны партиянең яшерен валюта хисапларын үз кулларында тотучылар белән таныштырачак. Әмма кояшлы Италиягә бару гына шатландырмый, аның анда булганы бар, хәзер исә хатынын да алып барырга тели, икесенә дә күңелле булыр, бер уңайдан үзен анда көтеп торучы махсус оешма кешеләренең дә игътибарын читкәрәк юнәлтергә тырышыр, алар бит аны якыннанрак күзәтергә телиләр. Шубариннар ниятләгән эш бик җитди-зур да, законсызрак та бит. Янында хатыны булгач, ул алар белән гел генә аралашып тормас, хатынының Италиядә беренче тапкыр булуын сылтау итәр, аны калдырып йөрү килешмәс, дияр.

Календарьда кызыл фломастер белән түгәрәкләп билгеләнгән көн бик тиз якынлашты, менә-менә Италиядән рәсми чакыру һәм визалар килеп җитәргә тиеш, билетларны да кайгыртасы, хатынына чит илгә чыгу өчен паспорт артыннан да йөрисе бар. Әмма иң әүвәл Хөршид Камаловтан хәерфатиха алырга кирәк, хәзер Шубаринның мәнфәгатьләре дә, кеше буларак аны якын итү дә Генераль прокурор ягына авышкан иде инде. Очрашуны кичектерүдән мәгънә юк: Талиб Ташкентта түгел, «сиам игезәкләре» белән мәсьәлә ачык. Камалов кинәт кенә берәр командировкага да китеп барырга мөмкин, ашыгырга кирәк... Шубарин телефонга үрелде, ләкин соңгы минутта гына трубканы яңадан куйды. Камаловның бу кабинеттан чыгып киткәндә әйткән сүзләрен исенә төшерде: «Әгәр кинәт кенә минем белән очрашырга теләсәгез, минем шоферымның исеме Нортухта, ул ышанычлы кешем, очрашуны ул көндез дә, төнлә дә оештыра ала, ана таяныгыз. Исегездә тотыгыз, егетнең исеме—Нортухта...»—диган иде Камалов.

Шул ук көнне, эш сәгате бетәр алдыннанрак, күзгә бик бәрелеп тормаган ачык төстәге «Волга»сының арткы тәрәзәләрен сөртү белән мәшгуль булган шофер янында көтмәгәндә генә бер яшь кеше пәйда булды. Машина прокуратура ишеге төбендә тора иде. Яшь кеше шоферга эндәште:

—Нортухта, берне кабызыйк әле.

Шофер таныш булмаган бу кешегә сынаулы караш ташлады да, ана сүзсезнисез генә шырпы кабы сузды. Шунда Нортухта сизми дә калды, кабын ачып шырпы алган арада кап эченә пөхтә генә итеп төрелгән язу кисәге дә салынган иде инде. Тәмәкесен кабызгач, тегe кеше рәхмәт әйтте дә юкка да чыкты. Машинасына кереп утыргач, Нортухта язуны алып укыды: «Бүген төн уртасында сезнең йорт почмагындагы телефон-автомат янында булырмын, әгәр кирәк тапсагыз, сезнең белән очрашырга әзермен. Мөһим эшләр бар». Имза урынына ике генә хәреф куелган—«А.А». Шофер моның Шубарин кешесе икәнен аңлады, хуҗасы ана ашыгыч эш булганда, синен аша очрашырга

туры килер, дигән иде. Күрәсең, шул сәгать житкәндер. Камаловны көтеп тормастан, Нортухта өске катка күтәрелде, очрашу өчен нииндидер кәгазьләрне алырга кирәк иде.

Нәкъ төн уртасында Дархандагы Аэрофлот үзәк кассалары каршысына моторы тавышсыз гына эшләп торучы күрексез генә «Волга» килеп туктады. Рульдә Коста утыра иде. Шубарин буш телефон будкасы яныннан килеп чыгуга, караңгылыктан ана таба спортчыларга охшаш яшь егет атлады. Якын ук килеп житмичә, егет әкрен генә, әмма ачык итеп әйтте:

—Минем исемем Нортухта, мин сезне озатып куярга тиеш. Шеф сезне өендә көтә...—Бераз тынып торгач, өстәп куйды:—Очрашу урыны сезгә ярармы?

—Ярар,—диде Шубарин һәм Камаловның шоферына ияреп ишегалды түренә таба атлады.

Караңгы йорт ишегеннән кергәч, егет:

—Өченче кат, сулдагы ишек...—диде. Үзе ишек төбендә басып калды, күрәсең, ана очрашуны саклап торырга кушылган булгандыр.

Күзгә-күз очрашу, шулай итеп, ике яктан да саклана булып чыкты, шунда якында гына Коста да бар иде бит.

Лифт ишеге ачылып китүгә, Шубарин сул яктагы бүлмәнең дә ишеге ачылганын күрде. Бусагада Камалов басып тора иде, ул кулы белән ишарәләп кенә өйгә үтәргә чакырды. Барып кергәч, Артур Александрович бирedә хатын-кыз кулы булмавын абайлады, бар жирдә чисталык, тәртип булса да, бу тәртип ирләрчә, казармадагычарак иде. Өстәл өстендә гадәттәге чәй генә түгел, бер шешә «Үзбәкстан» коньягы белән төсле юка корсаклы ике рюмка да бар иде. Шубаринның үткен күзе тәрәзә буендагы язу өстәлендә «Оливетти» язу машинкасы белән таралып яткан кәгазьләрне күреп алды: йорт хужасының эшләп утырганы сизелә, күрәсең, ул—төн кошы, ябалак иде. Хөршид Азизович кул биреп күреште, шунда ук өстәл янына чакырды да, ничектер үз итеп әйтте:

—Эт булып арыдым бүген, көн авыр булды. Берәр чәркә жибәрергә теләмисезме? Теләгем булса да, бер ялгызым гына нигәдер эчә алмадым.—Бераз тынып торгач, елмаеп өстәде:—Зыян итмәс, дип уйлыйм. Сизеп торам, сөйләшү гади генә булмастыр, хәер, мин аны үзем дә теләгән идем...—диде.

Артур Александрович ризалык белдереп баш какты—хужаның ихласлыгы күренеп тора иде. Шубарин хокук органнарындагы югары түрәләрне яхшы белә, алар гадәттә болай ихлас булмыйлар. Берне эчеп, капкалап алдылар. Хужа чәй ясады, кулына пиаласын тотып, нәрсәдер көткәндәй, урындык аркасына сөялде, кунакның сүз башлавын көтә иде ул. Шубарин, төннең артык озын булмавын аңлады, чөнки иртәгесен һәр икесен гадәттәгечә мәшәкатьләр белән тыгызлап тутырылган көн көтә иде.

—Мине сезгә дәүләт дәрәҗәсендә бик мөһим бер гадәттән тыш хәл китерде,—дип башлады сүзен Шубарин.—Мин башта бу эшкә очраклырак тартылган идем, аннары ул күңелемне биләп алды, сезнең дә аны хуплавыгыз, аңа хәер-фатихагыз кирәк, шулай уйламасам, сезгә мөрәҗәгать тә итмәс идем. Әмма мин, никадәр югары булса да, сезнең вәкаләтләрегез генә житмәстер дип шикләнәм. Бәлки, бергәләп эзли торгач, кирәкле вариантын табарбыз бу эшнең. Хикмәт шунда ки, шушы көннәрдә мин Италиянең иң күптәнге банкларының берсенең юбилеена рәсми чакыру алырга тиешмен...

—Ул инде Тышкы эшләр министрлыгына килде, шуна таяна аласыз,—дип, аны йомшак кына бүлдерде Камалов, үзе, әңгәмәнең озак һәм житди буласын төшенеп, жайлабрак утырды.

Шубарин аның сүзләренә гажәпләнмәде, югалып та калмады, бер күз сирпеп кенә алды да сүзен дәвам иттерде:

—Мин ул банкны белмим, аңа бервакытта да эшем дә төшмәде, әмма мине ул юбилейга башка кунакларга караганда да ныграк көтәләр, юбилей үзе чынлап та зурдан, шулай унай килеп кенә чыкты. Сезне көттереп тормыйча, хәзер үк барысын да әйтәм: эш партиянең чит илләрдәге яшерен валюта хисапларына бәйле. Бу хакта кайбер матбугат чараларында төрле имеш-мимешләр күренгәли иде, әмма бернинди дәлилләре дә юк. Искәртеп куям, мин дә бик аз беләм, әмма мина ул акчаларның язмышын хәл итүдә шактый зур бурыч йөкләнә. Кайчан, кайда һәм ни рәвешле ул суммалар барлыкка килгән, дип баш ватмыйк—алар бар, монысы чынбарлык, шуны аксиома итеп кабул гына итик. Бәла башкада булып чыкты. Партиянең гаять зур байлыклары, асылда дәүләт белән халык байлыгы, чит илләрдәге күп кенә күчми торган милке, төрле сәбәпләр аркасында, чит ил кешеләре кулында булып чыкты. Алар үз заманында марксизм-ленинизм идеяләре белән мавыккан булганнар яки мавыккан кыланганнар, кыскасы, яшьлекләрендә сул фикерләр корбаны булганнар. Хәзер Көнбатышта да, Көнчыгышта да—һәркайда коммунистик идеяләр җимерелеп төшкәч, салкын сугыш дигәннәре һәм ачыктан-ачык капма-каршы торулар бетерелгәч, КПССның ул акчалары эзсез югалырга мөмкин. Инде ул акчаларны саклаучыларның кайберләре, фирмаларын ябып, миллионнарны үз кесәләренә салганнар да, билгесез якларга сызганнар. Бүген партиянең иң ышанычлы кешеләре һәм махсус оешмаларның җаваплы хезмәткәрләре житди борчылу кичерәләр. Ахыр чиктә, тиктомалдан гына Көнбатышка миллионлаган долларларны бөтенләй намуссыз һәм карак кешеләр генә бүләк итәргә мөмкин. Ә партиянең намуслы әгъзалары ул байлыкларның бер өлешен генә булса да туган илгә кайтаруның тормышка ашардай планын эшлиделәр...

—Менә хикмәт нәрсәдә икән! Димәк, лагерьда утыручы Әнвәр Абидович Тилләхуҗаев сезнең янга Мюнхенга шуның өчен килеп чыккан,—дип ихластан көлеп җибәрде прокурор.—Ә мин тагын: «Ни өчен һәм ничек ул төрмәдән «чыгып керергә» рөхсәт алган да сездән аңа ни-нәрсә кирәк булды икән?»—дип баш ватам.

Хәзер инде Шубарингә гаҗәпләнер чират житте, ул тыела алмыйча сорады:

—Ә сез, димәк, безнең Мюнхенда очрашуыбыз турында күптән белгәнсез. Шулаймы?

—Әйе, күптән. Ләкин ышаныгыз, бары тик шуны гына белә идем, артыгын һич юк. Гафу итегез, сүзегезне бүлдердем, тыелып кала алмадым. Минем өчен чишелмәслек табышмак иде ул. Сөйләгез әйдә.

—Партиянең шул акчалары серен белүчеләр нинди юллар белән минем банкымның Көнбатыштагы акча кертүчеләргә йөз тотканлыгын, элекке СССР чикләрендә яшәүче этник немецләргә хезмәт күрсәтергә җыенганлыгын белеп алганнар. Германия ул немецләргә ярдәм итәргә әзер, бары тик тарихи туган илләренә күпләп кайтмасыннар гына иде, ул чагында һәр ике ил өчен дә бик зур мәсьәләләр килеп туачак бит. Алар укмашып яшәгәндә, тагын да яхшырагы, немецләрнең Идел буендагы президент Ельцин кат-кат вәгъдә иткән автономиясе торгызылганда, Германия аларга йорт-жир төзергә дә, тормыш итү өчен кирәкле бар шартларны тудырырга да акчасын кызганмаячак, ул төбәкләрдә заманча сәнәгать предприятиеләре һәм эшкәртү комбинатлары булдыруга ярдәм итәчәк. Кыскасы, бу программа озак елларга ниятләнә, аңа миллиардларча акча сарыф ителәчәк. Күрәсең, алар минем хәзер Урал лагерьларының берсендә тоткынлыкта утыручы, партиянең элекке Заркәнт өлкә комитеты секретаре белән кайчандыр якыннан таныш булганлыгымны белеп алганнар. Әлбәттә, арадашчылык итәргә миннән дә яхшырак кешене таба алмаганнар...

Артур Александрович, тартып җибәрергә рөхсәт сорап, сигаретын алды, ләкин, аны кабызмады, вакытны әрәм итәсе килмәде шикелле. Ул сүзен дәвам итте:

—Әнвәр Абидович мине җентекләп эшкә кереп китәргә әзерләде, ул—белеме буенча экономист, банк эшен дә әйбәт кенә белә икән. Мин шунда ук ризалык бирдем дип әйтергә мөмкин, чөнки башка чарам юк иде: бу тәкъдимне мин кире каккан очракта, кәрт уенындагы шикелле, аның тормышына куркыныч янийсы иде, мин моны бик яхшы аңладым. Хәер, ризалашмасам, минем гомеремне дә беткәнгә санарга булыр иде, махсус оешмалар шаяртырга яратмыйлар, ә бу сернең бәясе—миллиардлар тора бит...

Ләкин монысы минем үз иркем белән ризалык бирүемнең беренче сәбәбе генә. Сонрак, әле Германиядә чагымда ук мин андый акчаларның кайсы немец банкларында икәнен белешә башладым, аларның эзенә дә төшеп өлгердем, ул миңа шактый чыгымнарга төште—Көнбатышта бигрәк тә андый яшерен мәгълүматлар беркемгә дә бушлай бирелми. Шунда, Мюнхенда ук, мин Әнвәр Абидович белән «Риц» отелендә сөйләшеп утыруыбызны кайта-кайта уемнан кичердем, мин аны ул отельгә, үзебезнең теге оешмалардан котылып тору өчен дип алып барган идем. Әле хәзер дә сөйләшүебезне диктофонга яздырып алмаганыма үкенәм. Шунда Әнвәр Абидович минем барлык сорауларыма да тәфсилле җавап бирде, ә төп сорауларым шундый иде—чит илләрдәге бу байлыкларыбыз ничек хасил булды? Ул исә КПСС тулысынча хакимият башында торганда, дәүләт байлыкларын партиянекеннән аерып карарга кыен булганлыктан, коммунистларның һәр нәрсәне үз милекләре итеп карауларын яшереп тормады. Ә мин әкренләп ныклы бер карарга килдем: бу акчалар бер дә КПССныкы түгел, ә таланган һәм алданган халыкныкы икән, аларны туган илемә кайтарып бирү—минем изге бурычым, дидем.

Прокурор Камалов, кинәт кенә урыныннан кузгалды да, гасабиланып бүлмә буйлап йөреп китте, аннары, өстәл янына килде һәм Шубаринга батырып карап сорады:

—Ә сезнең ялганыгызны-хәрәмләшүегезне сизсәләр, үзегезгә нәрсә буласын беләсезме соң? Мин инде, уйлаган эшегез барып чыкмаган очракта, дип сорап та тормыйм.

—Мин нәрсә ниятләгәнемне беләм, азагы ничек кенә булса да, ни-нәрсә белән түлисемне дә аңлыйм, әмма барыбер чигенергә исәбем юк. Үзем турында уйларлык урын калмады инде. Халыкка, туган илгә хезмәт итү мөмкинлеге һәр ир-атка да бирелмәгәнлеген сезгә аңлатып тору кирәкме икән?

—Ә сез, Артур Александрович, хәтерем алдамаса, инде икенче мәртәбә үзегезне куркыныч хәлгә куясыз,—дип, хуҗа аны аптырашта калдырды.

—Ә ни өчен икенче мәртәбә?—диде Шубарин. Әле һаман да уйларында Миландагы очрашу иде, ул һаман да көрәшкә омтыла иде. Камалов янадан үз урынына барып утырды, тәкъдим ителгән сигаретны бармаклары белән әвәләп йомшартты да ачыклап җавап бирде:

—Әллә соң сезнең минем исемгә прокуратурага юллаган хатыгыз тәвәккәллек түгел идеме? Сез бит хатыгызда Мәскәүдәге, Балтыйк буендагы, Ерак Көнчыгыш портларындагы һәм үзебезнең Ташкенттагы дәлилләнгән урлашулар, икътисади һәм валюта операцияләре турында хәбәр иткән идегез. Ул вакытта ялган кешеләр исеме белән чүт кенә өч миллиард сумны урлап китми калган иделәр бит. Ә ул акчалар бәла-каза күргән Кашкадәрья өлкәсенә җибәрелергә тиеш иде. Болар сезнең хәзерге яңа уйниятләрегездән тәвәккәллектә кимерәкмени? Без бит ул чагында катгыйкырыс чаралар күреп калдык, нәтиҗәләре үзегезгә дә билгеле. Ул вакытта да, хәзер дә түләүнең хакы бер генә—башыгыз белән җавап бирү. Мин

сезнен хатыгызның беренче җөмләләрен хәтерлим. Сез мине «икебез ике як кешеләре» дип кисәтеп, бик артык кызыксынмаска да киңәш иткән идегез. Янәсе, сез дәүләтне урлап бетерергә тырышучыларга тыныч кына карап тора алмыйсыз, бу очракта аерым бер хәлләрдә «безнең максатлар бер булырга да мөмкин» дип язган идегез. Мин безнең очрашачагыбызга ышанып йөрдем һәм сезнең җаваплы адым ясавыгызга бик шатмын. Без ил-ватанның язмышына икебез дә бер төсле карыйбыз икән...

Шубарин, кабызгычын яндырып, прокурорга сузды:

—Мин прокуратурага язган хәлләр дә сезгә күптән үк билгеле идеме?— дип сорады.

—Юк, беләсезме, ул хакта мин хәзер генә сизенеп алдым. Мин инде «Ватан», «дәүләт» дигән сүзләрне дулкынланып әйтердәй кешене бер ун еллар күргәнем юк иде. Хәзер мин күреп торам: хатыгыздагы ул сүзләр бүген дә сезнең авыздан нәкъ шулай хисле-авыртучан, кайгыртучан яңгырыйлар. Сез аларны зур итеп, баш хәрефтән язасыз һәм сөйлисез...

—Әле, мөгаен, бу хакта сөйләшергә дә булыр иде,—дип аны бүлдерде Шубарин.—Әмма төн кыска, ә минем сезгә сөйләр сүзләрем күп, рөхсәт итсәгез, дәвам итим...

Һәммәсе дә мин уйлаганча барып чыкса, акчаларымны үлеп яткан Арал диңгезен терелтүгә тотачакмын. Аның язмышы шул тирәдә яшәүче җитмеш миллионнан артык халыкның язмышына кагыла. Дөньяда бердәнбер эчке диңгез бит ул, аның һәлакәте элекке СССР төбәкләренә дә йогынтысыз калмастыр. Ташкентта инде берничә ел Аралны коткару комитеты дигән оешма эшләп килә икән... Мин кичекмәстән алар белән бәйләнешкә кердем, ЮНЕСКО өчен әзерләгән мәгълүматларын, докладларын алдым. Бигрәк тә мине халыкара белгечләрнең бу эшкә күпме суммалар кирәк булачагы турындагы мәгълүматлары кызыксындырды. Хәл шул кадәр җитди икән, мин нәтиҗәләрен дә көтеп тормастан, бу белгечләр хисабына дүрт миллион сумны күчереп тә куйдым. Көндәлек эшләре өчен... Монысы бу эшне тормышка ашыру барышында хәл итәлергә тиешле әхлакый мәсьәлә иде...

Икенче мәсьәлә—инде минем көчтән килә торганы түгел—ялгызым гына башкарып чыга да алмам. Ул да булса, сәяси вәзгыять аркасында ил-дәүләт чикләренең үзгәрүе. Элек бербөтен банк системасы бар һәм аның төп роле Мәскәү кулында иде. Бүген исә мин башка дәүләттә, үз банк законнарым буенча яшәргә тиеш, ә ул законнар әле тотрыклы түгел, хәтта оешып та җитмәгән. Һаман эзләнү бара, бер закон кабул ителә, икенчесе кире кагыла, һәрберсе дә эзләнү-хаталар аша эшләнә. Ә минем эшем исә андый очраклыкларга бәйле булмаска тиеш, аны кичектереп торырга да ярамый, юкса, минем белән хезмәттәшлек итүчеләрнең башка мөмкинлекләре дә бардыр, әз генә ялгышлык җибәрсәм дә, алар миннән йөз чөереп, башка банкларга китәчәкләр. Банк эшчәнлегенең мондый тотрыксызлыгы барында миңа дәүләт, хөкүмәт дәрәҗәсендәге яклау кирәк, ул яклау исә яшерен, шаулап йөрмәслек тә булырга тиеш. Кабатлап әйтәм, сүз миллиард доллар хакында бара бит. Аңлыйсыздыр, ришвәт алырга күнеккән беренче тикшерүче-ревизор ук мине яндырачак ич...

Шубарин тынып калды һәм яңадан чәйнеккә үрелде. Прокурор да сүзсез-нисез генә, ниндидер кәгазь кисәкләренә тиз-тиз генә ниндидер язулар язып утыра бирде.

Озакка сузылган тынлыктан соң:

—Хөршид Азизович, бу эшне якларга сезнең вәкаләтләрегез җитәрме? Ул законлы булырмы?—дип сорады.

Камалов, урыныннан торгач, кулына тоткан буш чәйнек белән кухняга барышлый, елмаеп әйтеп куйды:

—Төн уртасында сез, банкир әфәнде, бигрәк зур карбыз тәгәрәтеп чыгардыгыз. Моны яңа чәй һәм тагын берәр чәркәсез күтәреп булмастыр. Мин хәзер...

Ул кухняга чыгып китте, анда ут өстендә кечкенә чәйнек кайнап утыра иде, ул аны күтәреп керде дә, өстенә маржа кыяфәтендәге капкач каплады. Бокалларга бераз коньяк тамызгач, сүзсез генә эчеп куйдылар.

—Сез президент янына кереп йөрмисезме соң?—дип, үгезне мөгезеннән эләктермәкче булды Шубарин.

—Юк шул, кергәнем юк,—дип тыныч кына җавап бирде прокурор.—Бу очракта ул сезгә дә, миңа да мондый эшне тыяр гына иде. Ул яшь дәүләтнең абруй-дәрәҗәсе турында уйлыйдыр, ә безнең тәкъдимне төрлечә кабул итәргә мөмкин бит.—Шубаринның кәефе киткәнен күргәч, ул күнеллерәк итеп әйтеп куйды: борыныгызны төшермәгез, мин сез өметсез эшкә тотынгансыз, димәдем бит әле. Безнең язмышларыбыз гына ачык: оттырсак, сез тормышыгызны куркыныч астына куячаксыз, мин исә, күпләрне шатландырып, эштән китәргә мәҗбүр булачакмын. Әйдәгез, уйлашыйк әле, президентны борчып йөрмәс өчен, бәлки, сезнең башка тәкъдимегез бардыр...

—Сез Ташкентка килгәч, мафия белән көрәшү өчен оештырган яңа бүлегегез тулысынча КГБ кешеләреннән генә тора, ул гаять көчле оешманың житәкчеләре барысы да диярлек сезнең элекке студентларыгыз, дөресрәге, курсантларыгыз дип сөйлиләр...

—Әйе, оешкан җинаятьчелек белән көрәшү бүлекләре—минем докторлык диссертациямнең бер темасы иде. Ул, «Үтә яшерен» дигән тамгалы булып, Политбюродан һәм МВД, КГБның югары түрәләреннән ары китмәде. Мин 1975 елда ук докторлыгымны яклаган булсам да... Күпме вакытны нәтиҗәсез уздырдык бит...—Камаловның тавышы ачынулы иде.—Интерполда тәҗрибә туплап йөргәндә үк мин үзебезнең мафиянең Көнбатыштагы эзенә төштем, ул хакта бик тәфсилләп шул житәкчеләргә язып та җибәрдем. Минем хезмәтләрем бөтенләй эзсез калдылар, дип әйтмәс идем, мине оешкан җинаятьчелек белән көрәшү буенча житди программалар эшләү комиссияләренә җәлеп итә башладылар. Кыскасы, мафия буенча белгеч дип таныдылар. Эшләрем белән барысыннан да күбрәк Андропов җентекләп кызыксынган иде, мин аның белән күзгә-күз ике мәртәбә очраштым, тәкъдимнәремнең кайберләрен КГБ файдаланды да дип уйлыйм. Мәскәүдә район прокуроры булып эшләгән чагымда, мин Брежневка якын торган бер төркемнең койрыгына баскан идем, бик зур күнелсезлекләрдән мине Андропов кына коткарып калды. Ул мине Вашингтонга, безнең АКШтагы миссиябезгә куркынычсызлык хезмәте житкәкчесе итеп җибәрде, шуннан мине Ташкентка тартып чыгардылар инде. Әйе, мин күпмедер вакыт КГБның ябык уку йортларында махсус курс алып бардым, бердәнбер үзбәк укытучысы идем. Табигый ки, Үзбәкстаннан килгән студентлар миңа тартыла, өемә килеп йөри башладылар. Шулай килеп чыкты, республиканың хәзерге куркынычсызлык хезмәте шефы генерал Бәхтияр Саматов белән аның ике урынбасары да—минем элекке студентларым, алар миңа бик ярдәм итәләр. Бары тик Саматов ярдәме белән генә мин үз вакытында хан Акмалны кулга алган идем. Хәер, куркынычсызлык хезмәте безнең эшкә ни өчен катнашырга тиеш соң әле? Конституция буенча мин бит куркынычсызлык хезмәтеннән югарырак торам, ул прокуратурага буйсына.

—Сезнең озак вакытлар туган илдә булмаганлыгыгыз сизелә,—дип елмайды кунак.—Миңа билгеле булганча, Саматов белән президент икесе бер мәхәлләдән, бер елгылар, бер үк мәктәптә укыганнар, мәгълүм транспорт институтының экономика факультетын да бергә тәмамлаганнар. Инглизләр, мәктәп галстугы туганнарыннан да якынрак, диләр... Саматов, сыйныфташы

президент булганчы ук, КГБ шефы дәрәҗәсенә күтәрелгән, димәк, алар үз юллары белән бер юнәлештә атлаганнар, шуна күрә дә матур мөнәсәбәтләрдә яшиләр...

—Сезнең нәрсәгә ишарәләгәнегезне аңлыйм аңлавын, әмма президентка хәбәр итәргә иртәрәк, юкса, ниятләгән эшегезне харап итүебез дә бар...— Камалов бераз тынып торгач, сүзен дәвам итте:—Ә шулай да, тәкъдимегезнең төше бар. Хан Акмал белән хәл иткәнчә эшләрбез, югары хакимияткә белдереп тормастан, бу безнең вәкаләтләрдә дигән булырбыз. Генерал Саматов безнең яклы булыр дип уйлыйм, операция яшерен, дигән сылтауга таянып, аның белән икәү җаваплылыкны үзебезгә алырбыз. Моның өчен сез бүген иртәннән үк миңа һәм куркынычсызлык хезмәте шефы исеменә әле миңа сөйләгәннәрегезне хат рәвешендә язып бирерсез. Аралны коткару комитетыннан алган документларны да бергә теркәрсез, алар хәзер сезгә кирәк булмас. Ул документ яшерен булыр, сез кирәк тапкан һәрнәрсәне, дәүләт сере ул дип, кызыксынучылардан да яшерербез. Прокуратура ишеге төбендә гражданнар өчен махсус почта әрҗәсе тора, анардан бик теләп файдаланалар, ачкычы исә мафия белән көрәшү бүлеге хезмәткәре Татьяна Сергеевна Шиловада саклана. Әгәр дә мин ул документларны өйлә вакытына алып өлгерсәм, тиз генә генерал Саматов белән очрашырмын, нинди карарларга килүебез турында сезгә хәбәр итү юлларын табармын. Генералның сезнең белән дә очрашасы килүе, кайбер нечкәлекләрне ачыкларга теләве мөмкин, сез житди эш ниятләгәнсез, аны бик уйлап эшлисе булыр.

Бераздан Камалов уйчан гына әйтеп куйды:

—Ә мин генерал Саматовның президент белән сабакташ икәнлеген белми идем әле, ул бу хакта беркайчан да сөйләмәде. Хәзер миңа кайбер очракларда ни өчен үзлегемнән эшләргә мөмкинлек бирелүе дә аңлашыла, прокуратура эшенә тыкшынмыйлар... Саматов белән, һичшиксез, очрашырга кирәк. Сезгә гаиләгезне берәр илгә алып китеп торырга да туры килмәгәе, анда бер ике ел яшәргә дә туры килер, моны куркынычсызлык хезмәте булышлыгыннан башка эшләве җинел булмас.—Шунда ук, әзерлексез-нисез генә, мылтыктан аткандай, сорау яңгырады:—Ә сезнең янга Мюнхенга законлы карак Талиб Солтанов ни өчен килгән иде? Сез бары тик партия акчалары белән генә мавыгып киткәнсез, ә бу кешедән сезгә инде чып-чынлап куркыныч янарга мөмкин булгандыр.

—Анысын мин үзем ничек тә булса ерып чыгармын инде. Ә Талиб, өлкә комитетының элекке секретаре Әнвәр Абидович шикелле үк, минем банкым аша Европа наркомафиясенең акчаларын һәм җинаятьчелектән кергән табышларын юарга иде, дигән тәкъдим белән килгән. Хәзер Европада һәм Америкада андый эшләрне майтарып чыгару кыенлашканнан-кыенлаша бара, Интерпол һәркайда аларның койрыгына баса килә. Быел Англия белән Италиядә берничә эре банк шулай янды. Мондый гамәлләр өчен акчаны да аз каермыйлар, шуңа күрә безгә—Шәрекъкә өметләрен сузалар, яшь дәүләтебезгә долларлар бик кирәк булган чакта, шуннан файдаланып калырга телиләр. Бирегә бит аларның үткәне белән бик төпченеп тормаячаклар. Дөрес уйланылган эш, сүз уңаенда, Балтыйк илләрендәге күп кенә банклар шулай аякка баскан...

—Уңышлы барып чыкса, ул акчаларны нишләтерсез икән соң?—дип сакланыбрак сорады Камалов. Бер мизгелгә генә, гадәттәгечә—прокурорларча уйлап алды: Шубарин партия акчаларын кайтарып биргәне өчен үзенең җинаятьчел дөнья акчалары белән эш йөрткәненә ташлама ясамасלармы, дип тә өмет итәргә мөмкин иң. Алай эшләгәндә дә дәүләт казнасы отачак кына.

Хәер, мондый гамәлләрнең законсызлыгын раслау шактый кыен. Хәвеф-хәтәр булмасын дигәндә, хакимият банкның андый эшчәнлегенә күз йомып

карарга тиеш, шулай иткәндә генә сарыклар да исән, бүреләр дә тук булыр. Күп кенә зәгыйфь илләрдә, акча ничек булса да керсен өчен, шулай эшлиләр дә икән.

—Мин аларны партия акчаларын хәл иткән кебек үк хәл итәчәкмен—алар шушында, Үзбәкстанда калыр. Сез аларны рәсми рәвештә кулга алуны оештырырсыз, бөтен дөньяда шулай эшлиләр икән, мин белештем.

—Әйе, хәтәр эшкә тотынгансыз, тәвәккәл кеше икәнсез. Мафия белән ялгыз гына сугышырга телисезме? Ә сез беләсезме, кичә Талиб ялган паспорт белән Мәскәүдән Германиягә очып киткән.—Шубаринның сискәнеп куюын күргәч, прокурор сүзен дәвам итте:—Мөгаен, сез дә аны күзәтәсездер, аны ычкындырмау мөмкинлекләрем күбрәк булганлыктан, бу эш миңа уңайлырак. Бу юлы ул Мюнхенга китмәгән, аны элеккечә күзәтеп торачаклар. Мин сезне һәм сезнең банкыгызны җинаятьчел казынулардан сакларммын, дип әйткән идем. Хәзер шуны эшлим. Сез каршы килмисездер бит, Артур Александрович?

—Юк, каршы килмим. Әмма ачыклап китәргә телим, ике төрле уйларга юл калмасын, герой булып кыланасым да килми. Мин партия акчаларын да эзләп йөрмәдем, шулай килеп кенә чыкты—юлларыбыз кисеште безнең. Мин ирләрчә, кешеләрчә эшләргә, үземнең гражданлык бурычымны үтәргә телим...

Сөйләшү барышында Шубарин беренче мәртәбә төртелеп калды, ул үзен дөрес аңласыннар дип уйлый иде.

—Сез әйбәт әйттегез—гражданлык бурычы...—дип тынлыкны прокурор бозды. Бу сүзләр, кызганыч ки, хәзер музей сүзләре, тапталган иске сүзләр булып кына яңгырый. Әмма мин дә Вашингтоннан туган илемә шул бер сәбәп белән генә кайттым—гражданлык бурычымны шулай аңлыйм...—Аннары ул, гадәтенчә, кучеп-нитеп тормыйча, кискен генә сорады:—Әгәр алдан сөйләшенгән булгач, ни өчен соң сезнең американы дустыгызны урладылар?

Камалов барлык нечкәлекләрне белергә тырыша иде, ана бит генерал Саматовка да бу хәлне тәфсилләп аңлатырга кирәк булачак.

—Алар башта, хәлне белеп тору өчен, минем банкның җитәкчеләреннән берсенә үз кешеләрен төртмәкче булган иделәр.

—Фамилиясен әйттеләрме соң?—дип өметләнеп сорады прокурор.

—Юк. Әгәр мин ризалык бирсәм генә әйтәчәкләр иде. Икенче көнне алар яна тәкъдим ясадылар—мин даими рәвештә акча кертүче байларның кемнәр икәнен, акчаларның зур суммаларын, алар кайда йөри, ничек алына икәнлекләрен әйтергә тиеш идем. Куркытырга тырышсалар да, мин ризалашмадым. Мюнхенда башлаган сөйләшүне дәвам итәргә әзермен, анысы мине дә кызыксындыра, дидем. Шуннан соң, мине куркытырга теләп, Гвидоны урлап киттеләр.

—Әгәр дә Талибның, дөресрәге, аның артында торган кешеләрнең уйниятләре дәвамлы булса, сезнең, Артур Александрович, оттыруыгыз мөмкин, үзегез генә ерып чыга алмассыз, берәр ялгыш җибәрерсез. Сезне Италиягә Саматов кешеләреннән кемдер озата барасы билгеле, аның тел белүче кешеләре бар. Ул сезне күзәтеп йөрер, Әнвәр Абидович һәм сезнең белән тегеләймеболаймы бәйләнештә булган кешеләрне төшереп алыр. Шул рәсемнәрне карагач, барысын да картотекадан чагыштырып кемнәр икәнлеген ачыкларбыз. Бәлки, очрашудан сон сезнең кулдашларыгыз аралашкан кешеләрне дә тикшерербез. Мондый эш безнең өчен яңалык түгел. Без СССРдагы элекке хезмәттәшләребез белән бергәләп эшлибез, чөнки, Көнбатышның җинаятьчел дөньясы безнең мафиозилар белән үрелсә, аның нинди куркыныч нәтиҗәләр китереп чыгарачагын аңлыйбыз. Сезнең тормыш юлыгыз үзенчәлекле,

исемегез җәмәгатьчелекнең төрле катламнарында хөрмәт ителә, ә бергәләп җыйган мәгълүматларыбыз сезгә үз эшегезне ышанычлырак башкарырга булышыр. Инде Талиб мәсьәләсенә килик. Ул Германиядән кайткач, мөгаен, сезнең белән очрашыр, алар бит сезгә тәкъдимнәреннән башка үз серләрен ачмаган. Наркомафия акчалары турында ни-нәрсә булса да беленә калса, мин Мәскәүдән берничә тәҗрибәле белгечне чакыртырмын, алар үз эшләрен яхшы белә. Бәлки, аларны эшкә дә алырсыз, алар банк хәлләре белән яхшы таныш, даими сезнең янда булырлар, кирәге чыкканда, беркемне дә шикләндермичә генә, үзегез белән берәрсен чит илләргә дә алып йөрерсез. Әлбәттә, әгәр сез каршы килмәсәгез?

Хөршид Азизович ирексездән тәрәзәгә карап алды да гаҗәпләнеп:

—Яктырып килә икән,—диде.—Чынлап та, төнне теләгәнчә сузып булмый, ләкин без күп нәрсәләрне сөйләштек-киңәштек. Ниятләгән эшләрегездә уңышлар телим! Көндез рәсми мөрәҗәгать итүегезне көтәм...—Ул урыныннан кузгалып, кулын сузды.

Кысан коридорның ишек төбенә килеп җиткәч, бер-берләренә якынаеп, Шубарин кинәт кенә:

—Мин сезгә шуны әйтергә тиешмен, прокуратурада хыянәтче бар, мәгълүматлар читкә тарала. Кызганыч, мин аның кем икәнлеген белмим, әмма ул бар,—диде.

—Беләм. Хәзер аның турында мәгълүматлар җыябыз. Ул кеше ике уен уйный, без аны җинаяте өстендә тотарга һәм вафат булган Артем Парсегян урынына төп шаһит итеп кулланырга уйлыйбыз. Яшерен үткәрелгән тикшерү шуны күрсәтте: Парсегянны агулап үтергәннәр. Ләкин ничек итеп һәм кем моны эшләгәнне хәзергә кадәр билгесез.

—Ә, әйе, әйтергә онытып торам. Аның сөйләшкәнне дивар аша да тыңлый торган япон аппараты бар.

—Монысы җитди икән, рәхмәт. Аны шул әйберсе белән бергә эләктерәсе иде.

Прокурор ишекне ачып, кунагын чыгарып җибәрде.

*Ахыры киләсе санда*

# Басыйр Рафиков

## Эзләп тап

**Яр буйларын айкыйм, таллыкларны,
Тыңлыйм камышларның сагышын.
Ишеткәндәй булам бабамнарның
Гасырлардан килгән тавышын.
Нигә алар шулай якын икән,
Килеп сыенырдай йөрәккә?
Нәселемнең башы булгангамы,
Торгангамы шул ук төбәктә?
Ярый әле хәтер яши җирдә,
Ишарәсе аның—тирә-як.
Көндәлек сүз белән чикләнмичә
Халкың батырларын эзлә, тап!**

* * *

**Кайда гына барма, кайда китмә—
Очратасың татар егетен.
Ник илендә түгел, нәрсә эзли,
Күңеленә кочып өметен?
Нигә туган җире кыерсыткан
Җитеш тормыш бирми яшь чактан?
...Бу Донбаска киткән чордан килгән,
Шуны уйлап һаман баш ватам.**

## Җәй белән аралаш

**Җылы җил чәчәкләрнең
Әйләндерә башын.
Борылып селкә алар
Таҗ яфрагын—кашын.
Төрле якны күргәнгә
Чәчәкләр дә шатлар.
Күрше кырдан баш ия
Аларга башаклар.
Без гел ыгы-зыгыда.
Җәй!. Җәй үтеп бара.
Бу асыл мизгел белән
Аралашмый калма!**

* * *

Тетрәтә җаным кылларын
Авыл урамында моң.
Нигә бабамнар һөнәре
Миндә сакланмады соң?

Нигә мин дә киң кырларда
Тирләп иген икмәдем?
Нигә тормышның асылы
Җир икәнен сизмәдем?

Инде авыл әйди мине,
Зарлы моңнар чакыра.
Күрәсең, ул онытмаган,
Тели саубуллашырга.

## Үткәннең ялкынын ал

Борынгы хакыйкать раслый:
Үткәннең ялкынын ал!
Янып сүнгән учакларның
Көлләрен җирләргә сал.

Ялкын янса, кешеләрнең
Тормышлары сакланыр.
Үрнәк алып үткәннәрдән,
Тормыш-яшәү сафланыр.

Батырлыкларның ялкыны
Алмашка юллар салыр.
Халыклар шат булсыннар дип
Кояш та якты яныр.

*Чиләбе өлкәсе,*
*Троицк шәһәре*

---

# Равил Шәфигуллин

## Чыңлы тынлык

Дөнья тынды.
Гүя өнсез калды.
Калтыранып чыкты аксыл ай.
Мәгърибләрдә эреде болытлар,
Йоклый кырлар...
Йоклаган тугай.

Әйтерсең лә, сихри әкиятем...
Чыңлы тынлык.
Йоклый Җир-Ана.
Төпсез күктә ак йолдызлар гына,
Сызгырышып, атылып яна.

Ыгы—зыгы сүнде жир өстендә,
Сарып алды зәп-зәңгәр тынлык.
Күңел ялы,
Күңел бәйрәме бу,
Ләззәтләнәм, тынлыкны тыңлап.

...Офыкларда яшьни сүлпән яшен.
Эңгер-меңгер коча кул җәеп;
Соңгы ялдай, соңгы бәйрәм кебек,
Кичке тынлык җәелә җәен.

## Бөтенесе—үземнеке

Бөтенесе монда үземнеке—
Кайгы-шатлыкларның төрлесе;
Монда, хәтта, карак бүрәге дә—
Мин үстергән сарык тиресе.

Монда, күптән арып-талган жирдә,
Үсә иген, чайкап башагын;
Төрле мәшәкатьтән якташларның
Әйләнгәннәр монда башлары.

Монда тудым, монда—үз кеше мин,
Бөтен нәрсә—минем уемда;
Җиргә ятып, кинәт үлсәм дә мин,
Үләм ләса монда—өемдә.

Үләрмен күк тыныч җаным белән,
Тавышымны саклар, дип, кырлар,
Искә төшерерләр, диеп, мине
Сөйгәннәр һәм сөймәгән кызлар.

Үлсәм дә мин ышанып үләрмен,
Холкым калыр диеп улымда;
Каберемә карарлар дип дуслар,
Тукталышып зират юлында.

## Хәйрани Ил

Яшьлек илем кайчан артта калган,
Бәлки үзем йөгергәнмен алдан?
Ашкынганмын, яшьлегемне ташлап,
Упкыннарга атылырга ярдан.

Еракларда, һаман нурын сибеп,
Гөрли сыман яшьлек дөньясы;
Һаман әле, юлдан кире борылып,
Килә аңа кайтып торасы.

Белмисеңдер инде, яшьлек иле,
Онытkансың ерак балаңны.
Сиңа йозак элеп чыгып китеп,
Инде картайган бер бабаңны?

Күпме атласам да озын юлдан,
Бүтән яшьлек иле юк алда.
Арттагысы күптән иялэнгән,
Миңа кабат урын юк анда.

Яшьлек илем—хәйрани ил иде,
Тирә-ягы шыгрым гөл иде.
Кабат аны искә төшердем дә,
Күңелемә нуры сибелде.

*Ульяновск өлкәсе,*
*Димитровград (Мәләкәс) шәһәре*

---

## Рәис Сафин

### Шагыйрьгә

Утлы дәрьяларны гиздем,
Чайкалдым дулкынында.
Булдым җиде күк катында—
Мәхәббәт упкынында.

Кайттым бала чакларыма,
Күкләргә карап яттым.
Таптым яшьлек ярларымны—
Югалтканымны таптым.

Әткәм-әнкәм өр-яңадан
Бирде үгет-нәсыйхәт.
Әрнүләр алдым җаныма,
Алдым җаныма сихәт.

Ләззәтләндем шигъри моңның
Тылсымын, тәмен тоеп;
Гүя зәмзәм суын эчтем,
Чык тамчыларын җыеп.

Синең сүздән рухландым мин,
Гади һәм дә гали зат.
Рәхмәт сиңа, рәхмәт, шагыйрь!
Рәхмәт сиңа, шигърият!

### Йолдыз атыла...

Кара төннең күк пәрдәсен ертып,
Көтмәгәндә йолдыз атылды.
Әйтерсең, ул безнең баш очында
Бер мизгелгә таган атынды.

Әйтерсең лә, күкләр сәхнәсенең
Пәрдәләре кинәт ачылды.
Атынмады йолдыз, ул чынлап та
Галәм киңлегенә атылды.

Чәчрәп калды аның очкыннары,
Күрдегезме дуслар, сез аны?
Ни өчен соң шундый мизгелләрдә
Ныграк сизелә гомер узганы?

Кара төннең пәрдәләрен ертып,
Көтмәгәндә йолдыз атыла.
Көтмәгәндә никтер күңел тула,
Күзгә кайчак кинәт яшь тула.

Күп яшәгән йолдыз атылдымы,
Атылдымы яшь-яшь бер йолдыз?—
Күктән гүя аваз ишетелде:
«Яндым, янам!... Бәхил булыгыз!»

*Казан шәһәре*

---

Римир
Сәлимгәрәев

## Йолдыз атылганда теләк

Әгәр күрсәм йолдыз атылганын,
Юрыйм аны исән-саулыкка;
Берүземә генә теләп калмыйм,
Бәхет телим илгә, халыкка.

Әгәр күрсәм йолдыз атылганын,
Куркаклыктан мине сакла дим...
Куркак җаннар гына дустын сата,
Ә син һәрчак кыю атла дим...

Әгәр күрсәм йолдыз атылганын,
Иман нуры сорыйм Ходайдан,
Чөнки беләм: һәр атылган йолдыз
Шәфкать нуры белән уралган.

## Кем түзем?

Чишмә янына килгән дә
Кеше сөйләшә, имеш:
—Авырлыкка йөрәк түгел,
Акыл түзәргә тиеш.

Салкын чишмә телгә килеп,
Төзәткән аның сүзен:
—Йөрәгең дә аңлар сине
Түзем булганда үзең.

*Башкортстан,*
*Чакмагыш*

## *2006 ел—әдәбият һәм сәнгать елы*

**—Президентыбыз игълан иткән Әдәбият һәм сәнгать елы тәгәлләнеп килә. Безнең «Казан утлары» журналы әдәбият, мәдәниятебез тормышын игътибар үзәгендә тотарга тырыша. Җөмләдән, журналыбызның 3-нче санында баш редактор Равил Фәйзуллин белән Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевнең бүгенге мәдәниятнең торышы һәм перспективалары турында тәфсилле әңгәмәсе басылып чыкты.**

**Зур оешманың җитәкчесе буларак, Сезгә рәсми рәвештә мөрәҗәгать итәбез: Әдәбият һәм сәнгать елы ничегрәк узды дип саныйсыз, канәгатьлек хисе бармы? Сезнең тарафтан күңелгә хуш килерлек нинди әһәмиятле чаралар үткәрелде һәм нинди проблемалар күз уңыннан төшеп калды? Без, гомумән, әңгәмәдә дә әйтелгәнчә, Әдәбият һәм сәнгать елы аерым бер кампания рәвешендә генә түгел, һәрдаим дәвам итәргә тиеш дип саныйбыз.**



**Абрек АБЗГИЛЬДИН, *Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе:***

—Президент М. Шәймиев Указы белән Әдәбият һәм сәнгать елы игълан ителү рәссамнарыбызны да сөендерде һәм яңа иҗади эшчәнлеккә рухландырды. Безнең рәссамнар берлеге быел төрле масштабларда кырыкка якын күргәзмә ача алды. Әлбәттә, күргәзмә залыбыз бүгенге көндә бер дә мактанырлык түгел, ләкин хөкүмәт ярдәме белән без бу кыенлыкларны җиңеп чыгачакбыз дип уйлыйм. Ел азагында безнең әле Татарстан рәссамнары берлегенең 70 еллыгын да билгеләп узасыбыз бар.

Быелгы ел иҗади бәйрәмнәргә бигрәк тә бай булды. Габдулла Тукай һәм Муса Җәлилнең дөнья күләмендәге юбилейларына без үзебездән лаеклы өлеш кертә алдык дип саныйм. Моның мисаллары матбугатта үзенең бәясен алды.

Иҗат кешесе буларак безгә, рәссамнарга, бүгенге көндә яшәү һәм иҗат итү—җиңелләрдән түгел. Без хөкүмәт ярдәменә мохтаҗ. Бер карасаң, безгә күп тә кирәк түгел. Иҗади хезмәт өчен нибары остаханә бүлмәләре кирәк. Инде әллә кайчаннан бирле аларның яңалары төзелгәне юк. Искеләре исә искереп беткән, шуңа да карамастан, аренда бәяләре һаман якадан тота. «Матурлык дөньяны коткарачак» дип юкка гына әйтелмәгәндер. Әдәбият-сәнгатьтән башка кешелек беркайчан да алга таба бара алмастыр. Киләчәк буынны без әхлакый һәм эстетик яктан фәкать сәнгать әсәрләре аша гына тәрбияли алачакбыз.

Рәссамнарның остаханәсен булдыру мәсьәләсенә яңача караш ташларга вакыт. Бөтен ышаныч—хөкүмәт ярдәменә. Юкса безнең өлкәннәребез дә, яшьләр дә шактый унайсыз-җайсыз хәлдә калды. Сәнгать белән бүгенге көн бизнесы икесе ике читтә басып торалар. Иҗатчы үзенең төпле әсәрен еллар буе бөртекләп эшли. Ә инде заказ белән ашык-пошык рәвештә тудырылган киндер-полотнолар бернича көнгә генә хезмәт итәргә мөмкин.

Әлбәттә, Президентыбыз игъланын зур сөенеч белән кабул иттек, аңарга бары рәхмәт кенә әйтәбез. Бездәге 300 дән артык әгъзасы булган Рәссамнар берлеге алга таба кая барыр? Мәскәү һәм Санкт-Петербургтагы меңләгән рәссамнар гаскәре бу буталчык заманда үзләренә шома юл таба беләләр, билгеле. Болар—атаклы башкалалар исеменнән эш йөртә. Ә Казаныбыз—татарның башкаласы түгелмени? Шунысы кызганыч: шәһәребезнең үзәгендә һәм бистәләрендәге горурлык саналган байтак кына тарихи истәлекле йортлар, архитектура үзенең йөзен югалтып бара. Биредә, заманча караганда, акчалы бизнесменнар эшне күбрәк оста йөртә беләләр.

Сәгате сугып, якын вакытларның берсендә иҗат оешмалары турында берәр юньле закон чыгар дип өметләнәбез. Без егерме беренче гасырга аяк бастык. Безнең борынгы бабаларыбыз күпне күргән, күпне кичергән. Алардан калган һәм матди, һәм рухи гасырлык байлыкларны киләчәк буыннарга житкерә алсак иде. Иҗат газаплары безне шуна дәртләндерә.



**Рәшит КӘЛИМУЛЛИН, *Татарстан Композиторлар берлеге рәисе:***

—Президентның 2006 ел башында чыккан Әдәбият һәм сәнгать елы турындагы Указы, һичшиксез, сәнгать әһелләренә карата игътибар күрсәтү билгесе иде. Бу ел композиторлар тормышында байтак вакыйгалар белән истә калды. Әйтик, «Йосыф кыйссасы» дигән балетны иҗат итүчеләр белән берлектә, композитор Л. Любовский РФның әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге Дәүләт премиясенә, композитор Л. Батыр-Болгари РТның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды. «Бүгенге музыканың «Европа-Азия» халыкара фестивале» проекты өчен композитор Р. Кәлимуллин РФ Хөкүмәте премиясе белән бүләкләнде.

Югары художестволы әсәрләр иҗат итәр өчен композиторларга хөкүмәт булышлыгы кирәк. Авторларга гонорар түләү хакында республиканың Мәдәният министрлыгы тарафыннан музыка сәнгатенең төп жанрлары буенча конкурс үткәрүнең нигезләмәсе эшләнде, шуның нигезендә авторлар белән килешүләр төзелә. Безнеңчә, бу—бик вакытлы, нәтиҗәле чараларның берсе.

Дәүләт симфоник оркестры һәм иҗат коллективлары, башкаручылар катнашы белән композиторларның авторлык концертлары уңышлы үткәнен билгеләп китәсе килә. Композитор Александр Ключаревның 100 еллыгына багышланган юбилей концерты да истә калырлык булды.

Россия композиторларының IX съезды уңаеннан Казанда симфоник концерт үткәрелде (26 март); Д. Шостакович һәм А. Леман язмаларыннан тыш, анда Ш. Тимербулатов, А. Луппов, Л. Любовский, Р. Кәлимуллин әсәрләре дә яңгырады.

Татарстан Мәдәният министрлыгының матди ярдәме белән, ниһаять, «Татарстан республикасы композиторлары» дигән басма әзерләнде, ел азагында ул дөнья күрәчәк.

Шуның белән бергә, Композиторлар берлеге һәм башка иҗат оешмаларында тупланып килгән мөһим мәсьәләләрнең һәммәсен дә әлеге «махсус ел» гына хәл итеп бетерә алмый, билгеле. Композиторларыбызның партитура һәм нота җыентыкларын бастыру, туплау эше һаман да көн тәртибендә кала бирә. Кызганычка каршы, юбилярларның язмалары, кагыйдә буларак—анда да фәкать арабыздан китеп барган иҗатташларыбызныкы гына нәшер ителә. Композиторларның фонд өчен дигән иң яхшы әсәрләрен яздыру гамәлдә тукталып калды диярлек. Элегрәк күрше республикаларның композиторлар союзы белән аралашу мөмкинлекләре зур һәм колачлы иде, төрле төбәкләр белән концертлар алмашу да онытылып бара. Мәскәү һәм Санкт-Петербург шәһәрләрендә иҗади хисап концертларыбыз күрсәтелми. Финанс мөмкинлекләре чикләнү сәбәпле, мәктәп балалары, яшьләр, республикабызның шәһәр һәм авыл хезмәтчәннәре композиторлар белән очрашу шатлыгыннан мәхрүм. Күпмедер алга китешләр булса да, композитор һәм музыка белгечләренең авторлык хокукларын яклау буенча кайбер тирәнтен чараларны хәл итәргә вакыт.

Төрле кыенлыклар туып торуга карамастан, Мәскәү һәм Санкт-Петербург оешмаларыннан соң үзенең әһәмияте һәм әгъзалар саны ягыннан өченче урынны алып торган Татарстан композиторлар берлеге яңа иҗат планнары, проектлар белән янып яши.



**Харрас ӘЮПОВ, *Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире:***

—Әдәбият һәм сәнгать елы Татарстан китап нәшриятында да күтәренке рухта, киеренке тостә башланып китте. Алда торган күренекле даталар: Муса Җәлилнең 100-еллыгы, Габдулла Тукайның 120-еллыгы, Татар театрына нигез салынуга 100 ел тулуга һ. б. унаеннан күп төрле басмалар дөнья күрде. Габдулла Тукайның ике томлык сайланма әсәрләрен, аның әсәрләренең русча басмасын, Габдулла Тукай альбомын, шагыйрьнең «Шүрәле» әкиятенең 15 телдә чыккан басмасын, күренекле шәхесләрнең Г. Тукай турында фикерләрен, шагыйрьгә багышланган шигырьләрне туплаган «Тукай...» дип исемләнгән китапны, Г. Тукайның балалар өчен төсле рәсемнәр белән бизәп чыгарылган әкиятләрен һ. б. кая барсак та күрсәтә алабыз.

Әдәбият-сәнгать елында балалар китабына да игътибар зур булды. Балалар бакчаларыннан башладык эшне: 3-4 яшьлек балалар өчен ачык төсле матур рәсемнәр белән бизәлгән, кечкенә форматлы, катыргы кәгазьдә, татар һәм рус телләрендә китаплар дөньяга килде. Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен чыккан китаплар да игътибарга лаек. Менә мисал итеп, сабыйларның күзен кызыктырырлык итеп эшләнгән «Санарга өйрәнәбез» исемле китапны китерергә була. Яшь каләм ияләре белән эшне җанландыру максатыннан «Алмаш» дигән махсус серия ачып җибәрдек.

Соңгы елларда күренекле каләм ияләренең күптомлыкларын бастырып укучыларга җиткерү буенча эш җанланып китте. Узган ел Гомәр Бәширов, Равил Фәйзуллин, Гариф Ахуновларның басмалары дөнья күргән булса, быел алар янына Ренат Харисның да томнары килеп өстәлде.

Әдәбият-сәнгать елында композиторлар, җырчылар, рәссамнар иҗатын яктырткан альбомнарның дөнья күрүе дә куанычлы.

Республика җитәкчелегенең, аеруча Президентның татар китабына карата җылы мөнәсәбәттә булуы китап бастыру өлкәсендә яңа мөмкинлекләргә юл ача. Соңгы берничә елда китапларыбызны Республикада гына түгел, дөнья масштабында күрсәтү җае чыккан икән, бу әлеге кайгыртучанлык нәтиҗәсе дип карарга кирәк. Күптән түгел Германиянең Франкфурт шәһәрендә узган күргәзмәдә катнашкан идек. Быел исә сентябрь башында Пекинда үткәрелгән күргәзмәдә булдык, безнең китапларыбызның дөнья күләмендә дә йөзгә кызыллык китермәслек булуларына инандык.

Нинди проблемалар күз уңыннан төшеп калды? Без, татарлар—китаплы халык, дип сөйләшергә яратабыз. Әйе, бу шулай булган. Әмма бүгенге көндә дә китаплымы безнең халкыбыз, милләттәшләр яшәгән һәр өйгә барып җитәме китап нуры? Кызганычка каршы, моңа өздереп кенә уңай җавап биреп булмый. Ел буена бер китап та алдырмаган районнар бар. Әдәбият һәм сәнгать елында да кыл кыймылдатып карамадылар андый төбәкләрнең җитәкчеләре. Югарыдан күрсәтмә көтәләрме?

Әдәбият һәм сәнгать елына йомгак ясаганда һич тә телгә аласы килмәгән тагын бер мәсьәлә бар: без Матбугат йортын бушатырга тиешбез. Татар халкын гомергомергә китаплы итеп килгән нәшриятның, шулай ук 1 нче китап кибетенең биредән китүе, белмим кемнәргә кирәктер? Ә бит халык китапка дип иң элек Бауман урамына килә, ул шуңа өйрәнгән. Нәшриятка кучәргә тәкъдим ителгән урын—татар китабыннан, татар халкыннан көлүнең начар бер үрнәге ул...

Әйе, без укучыны китаптан аермаска тырышабыз. Бу безнең мәртәбәле һәм изге бурычыбыз. Шушы юнәлештә киләчәккә матур гына планнарыбыз да бар. Бүген алар турында тәфсилләп сөйләп торуның кирәге булмас, укучыларыбыз өчен сер булып калсын.

Пекинда булып узган халыкара ярминкә вакытында безгә Мәскәүдән күрсәтмә көтеп ятарга түгел, китапларыбызны дөньяга алып чыгу өчен үзебезгә көрәшергә кирәклеге аңлашылды. Ә моның юлы бер—әсәрләребезне чит телләргә тәрҗемә итеп бастыру. Бу—чор, заман безнең алга китереп куйган мәсьәлә. Әлегә кадәр мәсьәләләрнең чишелми калганы юк иде...

*Октябрь, 2006 ел.*



Эльмира
Шәрифуллина

## УЯНУ

Яшен утыдай якты нур булып чагылып үттең дә, күпме кызларга хәсрәт салдың. Сөю хәсрәте!

—Өйләнгән микән?

—Гаиләсе, баласы бармы?

—Бу хәтле дә чибәр кешенең берничәдер әле...

Табынучылар да, тагылучылар да булды үзенә.

—Бар, бар аның гаиләсе!

—Тагын томрап торган ике кызы да бар. «Әтием», дип өзгәләнеп, янында бөтерелеп кенә йөриләр, ди.

—Ә үзе нинди яшь чырайлы!

—Бер дә ике балалы ир, димәссең.

—Бәлки, гаилә камытын хатыны җилкәсенә ташлап, үз рәхәте өчен генә яши торган кешедер? Андыйлар күп бит хәзер.

Читтән карап, сокланып йөргән бу танышыма һич тә тел тигертәсем килмәсә дә, эндәшмәдем. Бары тик күңелемне дә, үземне дә еракkarак кына алып киттем. Еллар үтте. Һәрвакыт күз алдымда торган мәһабәт гәүдә тоныклана төште. Шулай, хисләремне йөгәнләп дигәндәй, сүлпән бер тынычлыкта калып яшәп ятканда, теге нур көлтәсе алдыма кабат килеп төште. Әйтерсең, җыры белән серен дә чиште.

Мәхәббәтем чакыра дип белеп,
Егылып төштем Күктән.
Куләгәнне Сөю диеп уйлап,
Ялгышканмын, иркәм!

Көтәм нурлы күзле—берне,
Көтәм якты йөзле—берне,
Көтәм сихәт сүзле—берне,
Көтәм, көтәм, көтәм!

Аерылган!..

Ә нигә ул? Бәлки сүз авторы аерылгандыр? Ә бәлки кемнеңдер соравы буенча язылган шигырьдер? Хәзер җыр сөюче акчалы эшкуарлар күп бит...

Бу урынсыз бәхәсне башымнан тиз кудым кууын. Ә йөрәк кузгалды... Үзем Аны тынлыйм, үзем эссе көндә йотлыгып эчелә торган чишмә суыдай,

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА—*шагыйрә, прозаик; "Мизгел", "Яңгыр җиле", "Таң чыгы" һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

голт-голт жыр йотам. Асылкош тоттыммени? Концерт тәмамлануга, шул кош канатлары белән жилпенеп, тамаша залыннан очып чыктым да, Ул пәйда булырга тиешле ишек ягына чаптым. Анда миннән күпкә алданрак килеп тезелгән кызлар, яшь хатыннар... Тик минем һич кенә дә исем китмәде. Әрсезләнеп, алар арасына да барып кысылмадым. Мина калса, менә-менә ул килеп чыгар да, аяк очларыма басып ишектәге һәр хәрәкәтне сагалап торган күзләремне күрер һәм бер көтү булып болганып торган әлеге «фәрештәләр»не куллары белән аралап, алай гына да түгел, аларнын берсенә дә илтифат итмичә, мина йөгерер, мина килер кебек тоелды. Чөнки, миндәгедәй сөю хисе, миндәгедәй тартылу—боларнын берсендә дә юктыр, дип уйладым. Килеп кочагыма керер дә: «Йөрәгең магнитмы әллә синең, тәки тартып алдың бит!..»—дип пышылдар күк. Әмма бу чынга ашмастай, фәкать мин күрергә теләгән төш кенә. Алай диюем дә дөрес түгелдер әле. Төшләр бит йоклаганда гына керә. Ә мин көпә-көндез дә төш күрәм шикелле. Аяк өсте йоклыйм микәнни? Йокыга тартым, һич кенә дә айный алмыйча хыялга чумып йөргән бу халәт—дөньяда тиңе булмаслык дәрәҗәдә гашыйк булуымнан иде! Дөресрәге, әлеге котылгысыз хиснең, киредән кайтып, бөтен барлыгымны бөргычлап алуыннан!..

Йөрәгем әйтеп-аңлатып булмаслык дулкынлану белән сөйде!
Акылым: тыел-тыел, житте-житте,—диеп, өзлексез миемне төйде!
Әмма... Ходай Тәгалә жанымны барыбер аның янына чөйде...
Бу хәл ничек булдымы?
Көтмәгәндә.

Әйе, көтмәгәндә куркыныч хәбәр житкерделәр: «Хастанәдә, хәле бик авыр. Кан да, тән дә кирәк икән»,—диделәр. Янына йөгердем. Андый талантларны бәллүр савыт эченә куеп, жил дә тигермичә сакларга кирәк тә бит,—дип типкән йөрәгем—хастаханәгә барып житкәнче үк бер башыннан ярыла башламады микән?..

Чынлап та, Ул юл һәлакәтенә очрап, хастаханәдә ята икән. Янган жирләрен ямарга яшь тән тиресенең кирәк булуы да дөрескә чыкты. Чиратка языдым. Тик шунда ук, бөтен вөжүдемне калтыратып, курку биләп алды. Кан бирергә теләүчеләр дә байтак. Әгәр кирәгем калмаса? Чакырып кертелгәннәрне узып ин алга барып бастым да, шәфкать туташыннан тәнемне карауларын үтендем.

—Зинһар өчен, минем тиремне алыгыз! Минем тирем аның тәнендә тиз савыгачак. Чөнки мин...

Шәфкать туташы йөземә күтәрелеп карады.

Мин аның саен батыраеп:

—Чөнки минем күзәнәкләрем аның тәнендә бербөтен булып яшәргә тели!—дидем.

Минем фамилиямне кечкенә-кечкенә кәгазьләргә яздылар. Дөресрәге, канымны, йөрәгемне, тикшерергә алып кереп киттеләр.

Менә мин Аның белән бер бүлмәдә, рәттән диярлек куелган койкада ятам. Арабыз һич кенә дә ерак түгел. Димәк, мин Ул сулаганны сулыйм, Ул күргәнне күрәм. Ә юк, Ул күрми бит әле. Бик тиздән мин дә күрмәс булдым. Шәфкать туташы кан тамырыма наркоз жибәрә. Бөтен көчемне куеп йокламаска, ни гамәл кылганнарын карап ятарга тырышсам да, күзләремне йомганмын. Ә уянганда?.. Хәтта минутка да тулмаган кебек тоелган теге илаһи бергәлек юкка чыккан иде. Мине башка бүлмәгә күчергәннәр. Күзләремне ачтым да, хәлсез исәнгерәү белән изелеп тын калдым. Янымда табиб белән берничә шәфкать туташы басып тора иде. Ниндидер шаярту сүзләре әйтеп көлдерергә, дуслык өчен утка да керергә әзер торуымны күпертеп күрсәтеп, көч бирергә тырыштылар булса кирәк. Ә минем уйларым үземнән бигрәк Аның турында. Ашыгып:

—Аңына килдеме? Тәненә яна тире текәннне аңладымы?—дип сорадым.

Соравымны үзләренчә кабул иттеләр булса кирәк.

—Савыккач, барысын да әйтербез. Икегезне бергә күрештереп, тирене сездән күчерүебезне дә сөйләрбез. Әле анын яралары ул гына түгел. Син, әйдә, үзен тизрәк ныгы!—дип күнелемне юаттылар. Алар чыгып киткәч, минем башыма: «Нишләп сорамадым инде, тагын нинди яралары бар икән, тагын нәрсә кирәк икән?»—дигән уй килде. Бөерем икәү, икесенен берсен бирергә риза. Күзләрем икәү—аларнын да берсен арттыра алам. Ә йөрәк кирәк булса? Бирә аламмы мин йөрәгемне?.. Ә нигә бирмәскә? Чөнки мин үлмим булып чыга бит. Тәнемне генә күмәләр, ә йөрәгем Анда, Анын күкрәгендә яшәп кала. Анын кул-аякларын хәрәкәткә китереп, Анын белән бергә җырлап, көлеп... Мин торырга, табибларга шул фикеремне житкерергә теләп урынымнан калкындым. Ярый әле, яраларымны кузгатмас өчендер, ятагыма нык кына итеп бәйләп куйганнар икән үземне.

Шулчак кемдер йомшак куллары белән жилкәмнән тотты да:

—Нәфисә апа, сезгә торырга ярамый. Нәрсә кирәк, әйтегез, барысын да үзем эшлим,—дип, баш очымнан чыгып каршыма басты. Карашыннан сылу мөлаемлык бөркелеп торган бу кыз-хатын, ак халат киеп куйса да, шәфкать туташы түгел иде.

—Сез кем?—дип сорадым мин аннан, чибәрлегенә тан калып.

—Кызы. Әтиемнен кызы!—диде ул, тагы да ягымлырак итеп. Аннан акланган сыман:—Мин ана үзем дә бирә идем тиремне, авырлы булгач, алмадылар,—диде.

«Шулкадәр яшь башыгыздан тормыштамы»,—дигән гажәпләнү тойгысы беләндер:

—Ә-ә, сез кияүдәме?—дип сорадым.

—Ирем белән бергә иде алар. Иремә берни булмаган, ә менә әтием...

—Талант ияләре үзләрен саклый белми,—дидем мин каршымда күз яшьләрен коеп басып торган ханымга. Минем аны елавыннан тизрәк туктатасым, уйларын икенче якка юнәлтәсем килде. Авырлы чагында борчылырга ярамый. Туачак балагыз турында уйлагыз, дип үгетләргә теләсәм дә:

—Исемегез ничек?—дип сорадым.

—Нургөл,—диде ул.

—Нургөл? Нур-гөл, кызык. Гөлнурлар күп, ә менә Нургөл дигән исемне беренче ишетәм. Бер карасан, бик матур, янача. Нигә һаман кешенекен кабатларга?—дидем мин.

Нургөл тагын да яктырыбрак китте. Тагын да назлырак итеп, мина тагын да якынрак килеп, хәтта күпмедер иелә төшеп:

—Әтием куйдырган исем ул. Әтием гел шулай матур һәм үзенчә яшәргә ярата иде,—диде.

«Иде» сүзе мине сагайта куйды. Куркынып:

—Хәле ничек әтиеннен? Әллә?..

Кыз үксүен арттыра төште.

Ходаем, үлмәгәндер бит?.. Шунда ук, андый очракта кызы минем янда басып тора алмас иде дип, үз-үземә жавап бирдем. Алай да, кискенрәк тавыш белән, ашыгып:

—Хәле ничек әтиеннен? Табиблар нәрсә әйтә?—дип, соравымны кабатладым.

Ул, елавыннан туктап, әтиемә шушындый тупас кешенен тиресен күчерделәрмени, дигәндәй, яшьле, сөрмәле күзләрен тутырып мина карады. Аннан:

—Бераз көтик әле. Йөрәге әйбәт тибә,—дип әйттеләр,—диде.

Мин, ниндидер эчке бер күтәренкелек һәм шатлык белән:

—Димәк, минем йөрәгем кирәк түгел,—дип әйтеп салдым. Аннан, кычкырып әйткән әлеге яшерен уемны:

—Йөрәге сау, димәк! Йөрәге исән булгач, үзе дә тереләчәк, Алла

боерса!—кебек җөмләләр белән акларга тырышып, йомгаклап куйдым.

Ләкин авыздан чыккан сүз—очкан кош, диләр. Үз колакларына үзе ышанмый басып торган Нургөл:

—Нәфисә апа, әллә сез йөрәгегезне дә бирергә уйлаган идегезме?—дип сорады.

Мин мондый сөальнен булу ихтималын алдан ук чамалаган идем. Җавабым әзер булганлыктан, бер дә каушамыйча:

—Нәзерем бар иде,—дидем.

—Нәзер? Хәтта йөрәгегезне бирергә нәзер әйттегезме?—диде Нургөл, тагын да ныграк гаҗәпләнеп. Аннан, тулы микән сон бу дигәндәй, йөземә текәлеп карады, башын чайкап,—сәер, бик сәер,—дип өстәде. Әлеге минутта Нургөлне мина күз-колак булу вазифасы түгел, әтисенен тәненә ниндидер тилемсә хатынның тиресе эләгүе борчый башлады шикелле. Борчылмассын?! Әнә, котырган эт тешләп, селәгәе генә эләксә дә...

Кыз шулай уйлагандырмы, юкмы, белмим. Болар минем күнелемә килгән шикләнүләр иде. Ә ул элеккечә ягымлы калып:

—Нәфисә апа, әтием урынында башка берәү булса, ана да йөрәгегезне бирер идегезме?—диде.

—Кан кирәксә—кан, җан кирәксә—җан бирермен,—дидем.—Җан—йөрәктән башка тәндә кала алмый бит инде,—дип киеренкелекне йомшартырга тырыштым.

—Ә сезне нәрсә шулкадәр дәрәҗәдә тетрәндерде сон? Хәтта җаныгыз, йөрәгегез белән саубуллашыр дәрәҗәдә?—дип төпченде Нургөл.

—Мәхәббәт,—дидем мин салкын гына.—Мәхәббәт.

—Әстәгъфирулла?! Сез дөньядан киткәч, биреп калдырылган ул йөрәк белән икенче яртыгыз нәрсә эшли ала инде?—дип гаҗизләнде.

Мин эндәшмәдем. Нургөлнен кайбер сорауларыннан әтисеннән көнләү билгеләре чагылып үтсә дә, анын инсафлы, яхшы тәрбия алуы аермачык күренеп тора иде. Тату, олы сөю белән яшәмәгән гаилә балага мондый күркәм тәрбия бирә алмый. Үземнен йөгәнсез хисләремә баш була алмаган очракта, әтисен өзелеп яраткан бу баланың бәхетенә нинди күләгә төшерә язуымны анлап, оялдым. Җир убылсын да, караватым-нием белән төшеп китсәм иде, дип уйладым. Аннан акылыма килеп:

Ә, нигә мин үземне җир йотуын телим сон әле? Нинди җинаять эшләдем?—дип гасабыйлана башладым. Мин бит фәкать гашыйк булдым! Бер күрүдә, беренче күрүдә! Беркемгә белгертмичә, беркемгә бернинди кайгы китермичә яшерен бер дөрләү, яшерен бер тетрәнү кичердем! Ярату һәм сөя алу гөнаһ була димени?! Нур агымы булып килгән бу илаһи сөю дә, айныту өчен җибәрелгән менә бу тән газаплары да Ходай тарафыннан тәгаенләнгән эштер, дип фаразладым. Һәм бу яну-көюләремнән вакытында тукталырлык сәбәп күрсәткәне өчен Ходаема рәхмәтемне әйтеп, үзем белгән «Әлхәм» догасын укып куйдым:

«Әлхәмдү лилләһи раббил гәләмин. Әррахмәнир-рахим...»

Шул вакыт безнең бүлмәгә табиб килеп керде. Минем уйга чумган йөз - кыяфәтемне күреп:

—Әллә яраларыгыз сызлыймы?—дип сорады. Беләзек турыннан тотып, йөрәк тибешен тынлап карады.

Мин:

—Түзәрлек,—дип җавап бирдем. Дөресен генә әйткәндә, яшьлек кайнарлыгым белән мин үземнен дә авыру икәнлегемне, мина да тынычлык, күтәренке кәеф зарур булуын бөтенләй онытып җибәргәнмен. Шулчак Нургөл табибка якын ук барып:

—Әтиемнен хәле ничек?—дип сорады.

—Беләсезме,—диде табиб, җанланып китеп,—алга китеш бар сыман.

Кычкырып әйтергә, дөресрәге, алдан вәгъдә итәргә ярамаган тау кадәрле бу шатлыкнын чынлыгын—анын елмаю кунган иреннәреннән, өмет очкыны

балкыган күзләреннән дә укырга була иде. Мин монда чиксез сөендем.

—Рәхмәт!—диде Нургөл, күккә күтәрелергә әзер кош баласыдай, канатланып.—Без әтиебезне шулкадәр дә нык яратабыз, аннан башка яшәүне күз алдына да китерә алмыйбыз. Сезнең кулларыгызның тылсымы алдында тез чүгәргә дә әзер без!

—Анысы кирәкмәс,—диде табиб, мәрхәмәтле елмаеп. Аннан сүзне миңа күчереп:—сезгә Нәфисә туташ, һичшиксез йокларга, ял итәргә кирәк! Нигәдер бик борчылган кебек күренәсез, шундый зур батырлык эшләгән кешегә болай бирешергә ярамый,—дип, чыгу юлына атлады.

Күңелле хәбәрдәндер, мөгаен, бәлки табибымның игътибарыннандадыр, давылдан соң килгән дымык көн кебек, җанымны йомшак бер тынычлану хисе биләп алды. Янымда утырган Нургөлнең ефәк кебек нәфис кулларыннан сыйпап:

—Әтиегез, һичшиксез, тереләчәк, Нургөл! Яшәтү теләге зур булган тәнне җан ташлап китә алмый ул!—дидем.—Амин, шулай булсын!

Сезгә дә бик зур рәхмәтебезне җиткерәбез, Нәфисә апа! Әнием исеменнән дә, сеңелем исеменнән дә рәхмәт сезгә!—диде Нургөл.

Тәнемне чымырдатып эсселек йөгерде. Яраларым тирәсендә нәрсәдер тартылды, нәрсәдер өзелгәндәй тоелды, күз алларым кинәт караңгыланды. Табибтан соң ук кереп җиткән шәфкать туташы бер-бер артлы берничә укол кадады. Күз кабакларым авыраеп, караңгылыкка чумдым. Уянганда, кояш чыгышы ягыннан тәрәзәгә якты нур бөркелә, ә Нургөл урындыгында тагын да сөйкемлерәк икенче бер кыз утыра иде.

---

## КОНКУРС ДӘВАМ ИТӘ

### «Яңа дәвер кешесе»

Мең яшьлек башкаласы булган татар дөньясына журналыбызның мең санын бүләк итү һич очраклы хәл түгел, чөнки «Казан утлары» Илебез тарихына, халык язмышына турыдан-туры бәйле.

Үткәнебез меннәр белән язылды. Яна меңьеллыкка—яңа дәвергә аяк басуыбызга да әле кайчан гына. Кем ул Яңа дәвер кешесе? Кальбе, яшәеше, кылган гамәлләре нинди? Яңа дәвердә кешелекне нинди могҗизалар көтә? Гел хөррияткә, үзгәрешкә, муллыкка, үсешкә омтылганда инсаният, әхлак, гаилә, мәхәббәт исән калырмы? Мөхтәрәм язучыларыбызны әлеге проблемалар борчыймы?

Яңа хикәяләргә ачык конкурс дәвам итә. «Яңа дәвер кешесе» бәйгесенә килгән хикәяләрнең күләме бер табактан артмаска тиеш.

Җиңүчеләрне акчалата бүләкләр көтә:

**I урынга**—25 мең сум
**II урынга**—15 мең сум (ике бүләк)
**III урынга**—10 мең (өч бүләк)

Хикәяләр 2007 елның декабренә кадәр кабул ителәчәк.

**«Казан утлары» журналы редакциясе**

Рафис
Әхмәт

# АКЫН, ЧИЧӘН, ШАГЫЙРЬ...

МИФТАХЕТДИН АКМУЛЛАНЫҢ ТУУЫНА 175 ЕЛ

Нәкъ чирек гасыр элек—1981 елда бөтен Ил тугандаш төрки өч халык—татар-башкорт-казакъларнын уртак улы—шагыйрь, акын, чичәне Мифтахетдин Акмулланың 150 еллык данлы юбилеен билгеләп үткән иде. Бәйрәм тантаналары Алма-Ата, Казан, Уфа, Мәскәү калаларында булып узды. XIX йөз татар шигърияте белгече буларак, миңа бу юбилейнын бөтен чараларында катнашырга, чыгышлар ясарга насыйп булды. Бу бөек шагыйрьнен тормыш юлын, мирасын өйрәнеп үземә дә аспирантурада уку елларымда (1973 елдан сон) Мәскәү, Алма-Ата, Уфа, Ленинград, Оренбург китапханәләре һәм архивларында еш һәм күп эшләргә туры килде. Табышларнын бер-икесен (Хәсән Гали һәм Дусмаил Качкынбаев җыйнаган материалларны) университеттагы остазым—профессор Миркасыйм Госмановка Акмулланың шигырьләр җыентыгын төзегәндә биреп тордым (ул ксерокопияләр әле дә үземдә саклаialар). Бу хакта ул 1981 елда дөнья күргән «Акмулла. Шигырьләр» китабынын «Аңлатма һәм искәрмәләр» бүлегендә (203 биттә) искә алып үтә. Шул ук елда Уфада Акмулла шигырьләр җыентыгын төзеп, аңлатмалар һәм баш сүз язып, башкорт әдәбиятын өйрәнүче галим Әхмәт Вильданов та әле яна чыккан ун табаклы китап бүләк итте. Ә 1986 елда казакъ галиме, мәрхүм Бөркет Искаков Алматыда «Жазушы» нәшриятында дөнья күргән «Акмолла. «Күндер мен түндер» китабын җибәрде.

М. Госмановнын җиде табаклы җыйнак китабы, шөкер, инде күптән таралып бетеп, сирәк библиографик әсәргә әверелде. Аннан сон әдәбият галиме Фәрит Яхин 2001 елда Акмулланын алты басма табак күләмендәге, кечкенә генә китабын (300 данәдә генә булса да) бастырып чыгаруга иреште!

Белгәнебезчә, Акмулланын Казанда 1892 елда «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе», 1904 елда Габдулла әс-Сәиди (Баттал), 1907 елда «Шәрәф» типографиясендә Троицкийдагы «Хезмәт» китапханәсе наширлегендә ике китабы дөнья күргән. Совет чорында исә Акмулла шигырьләрен Сәкен Сәйфуллин 1935 елда төзеп, Алматыда бастырып чыгарды. Совет чорында шагыйрьнен кушамат-псевдонимы («Акмулла») ук күпләрдә шик-шөбһә уята торган иде. Шуңа күрә китаплары сирәк чыкты.

Мифтахетдин Акмулланын (1831—1895) тууына быел 175 ел тула. Башкортлар арасында туып үскән яшь егет данлыклы Эстәрлебаш мәдрәсәсендә булачак бөек шагыйрь Шәмсетдин Зәки белән берничә ел бергә укыганнан соң, Троицк шәһәренә килеп, мәшһүр Зәйнулла ишан (әдип Атилла Расихнын бабасы) мәдрәсәсенә кереп, дин гыйлеменнән тыш шәрык (төрки, гарәп, фарсы) шигърияте серләренә төшенеп, бераздан үзе дә шигырьләр иҗат итә башлый.

Гомере буе казакъ даласында үзенен пар атында күчмә казакъларга гыйлем-мәгърифәт таратып, шигырь язып-укып йөргән бу кин күнелле, көләч-мөлаем, ачык йөзле, тирән белемле татар чичәненә халык үзе «Акмулла» дигән исем-кушамат тага. Шагыйрь үзе дә бу атама-псевдонимны хуп күрә һәм Казанда

дөнья күргән өч шигырь җыентыгында да үзен Мифтахетдин Акмулла дип атый...

Аның Шиһабетдин Мәрҗани һәм башка бик күп затларга багышланган шигырь-касыйдә, мәдхия, мәрсияләрен XIX йөз азагы—XX йөз башында гомер сөргән замандаш-ватандашлары яттан белгән һәм һәркайда сөйләп-көйләп йөргән.

Гәрчә Г. Тукай, М. Гафури, Н. Думавилар бу легендар затны сокланып телгә алсалар да, исеменнән үк кем икәнлеге күренеп торган бу шәхеснең исемен дә, иҗат мирасын да 1917 елдан соң үргә узучылар хуп күрмиләр.

Дөрес, тора-бара бу бөек шагыйрь исеме һәм мирасы төрки халыкларны берләштерүче маяк-хәзинәгә әверелә. Бигрәк тә 1981 елдагы юбилей тантаналары Акмулла мирасын яңа биеклеккә күтәрде.

Мифтахетдин Акмулла 1831 елның декабрендә Кыргыз-Миякә ягының Туксанбай авылында дөньяга килгән. Шагыйрьнең метрикасында аның әнисе саф татар, әтисе Камалетдин типтәр-башкорт дип язылган. Әмма Акмулла тора-бара казакълар арасында үзенең әтисен казакъ Мөхәммәдъяр дип йөри башлый.

Хәтеремдә Акмулланың 150 еллык данлы юбилеен уздырган чор бик яхшы сакланган. Остазым Мөхәммәт ага Гайнуллин белән бу юбилейны уздыру үтенече белән Ирек мәйданындагы обком бинасына күп йөрергә туры килде. Югары Совет, Министрлар советына да кат-кат мөрәҗәгать итеп карадык... Тик ул чорда обком түрәләрен шагыйрьнең исеме үк сагайта төште: Акмулла атлы бит! Ә ул чорда динчеләр, ишан-муллалар—совет хөкүмәтенен төп дошманнары санала иде...

Тик шунысы хак: тугандаш башкорт, казакъ халкы бөек мәгърифәтче чичән-акын юбилеен шаккатырлык итеп, зурлап бәйрәм итте. Бу тантаналардан Гариф Ахунов, Миркасыйм Госманов кебек әдип-галимнәр белән йөреп кайткач, бергәләп Акмулланың 150 еллык юбилеен Казанда үткәрү эшенә керештек...

Нәтиҗәдә, бездә дә өч тугандаш халыкның бөек мәгърифәтче шагыйренә багышланган фәнни конференцияләр һәм бәйрәм тантаналары булып узды.

Ул чор вакыйгаларыннан иң нык истә калганы шул булды: Уфага барып төшүгә үк без чын бәйрәмчә бизәлгән урамнарны, йортларны күреп куандык! Акмулла акынның сурәтен күреп таң калдык. Бөтен җирдә язма-тасма-плакатларда Акмулла «бөек башкорт шагыйре» дип исемләнгән иде. Фәнни конференциядә баштарак шул ук фикер хөкем сөрде. Ниһаять, трибунага мәшһүр профессор, үзе дә ерактан—Кытайдагы Уйгурстаннан чыккан Миркасыйм ага күтәрелде. Сүзен ул Акмулланың 1892 елда Казанда, университет типографиясендә басылып чыккан тәүге шигырь китабы—«Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе»ннән башлап җибәрде. Әйе, казакъ даласында гомер сөреп ятучы акын-шагыйрьнең беренче китабы нәкъ менә Казанда—татар башкаласында дөнья күргән бит һәм ул мәшһүр галим-мәгърифәтче, тарихчы имам Шиһабетдин Мәрҗанигә багышланып, аңа атап язган мәшһүр мәдхия-мәрсиядән тора!

Миркасыйм ага бу әсәрнең тәүге юлларын укып ук күрсәтте:

*—Казанда бер фазыйль чыкты алмас булып...*
*...Хәмде лиллаh, ду диярда бездән чыкды*
*Мәрҗани Шиhабетдин ахунд хәзрәт!*

«Казаннан, бездән» сүзенә аерым басым ясавы тыңлаучыларга үтә көчле йогынты ясады.

Акмулла, чыннан да,—өч тугандаш төрки халык—татар, башкорт һәм казакларның уртак улы, акын-чичән-шагыйре.

Нәкъ 25 ел элек миңа Башкортстанның Миякә районындагы Туксанбай авылында Акмулланың 150 еллык данлы юбилей көннәрендә катнашу бәхете тиде. Көнчыгыш Башкортстан төбәгендә урнашкан Туксанбай авылында шул чордан бирле Акмулланың музее эшләп килә. Бу якларда борын-борыннан катнаш татар-башкортлар көн күрә, халык аларны «типтәрләр» дип йөртә.

Татарлар бу төбәктә борынгы чорлардан бирле яши. Явыз Иван 1552 елда Казан ханлыгын җимергәч, байтак халык тибелеп-сугылып читкә куылган. Байтак татарлар шул авыр гарасатлы елларда, туган-үскән җирләрен ташлап, көнчыгышка—Себер урман-аланнарына, казакъ далаларына барып урнашкан. Туксанбайның үзендә без бу хакыйкатькә мең тапкыр инандык: әйе, Мифтахетдин—чын типтәр булган. Хәер, аның йөз-кыяфәтендә үк бу бик ачык чагыла. Дөрес, баштарак аның әтисе Сырдәрья буендагы Акмәчет (хәзерге Кызыл Урда) аймагы кешесе—казакъ Мөхәммәдьяр булган дигән версия кин таралган булган. Бар гомерен нигездә дала гизеп, күчмә казакълар белән үткәргән шагыйрьгә дә бу фараз бик отышлы булган, күрәсең. Ул да бит—казакъ, акын!

Ә менә әнисе Сәлим кызы Биби(өмме)гөлсем чыннан да саф татар кызы булган.

Мөхәммәдьяр-казакъ турында бик аз хәбәр сакланган. Шуларның берсе буенча Эстәрлебаш егете Нигъмәтулла Биктимеров Бохарада укыганда Сырдәрья буеннан килгән Мөхәммәдьяр исемле бер шәкерт белән дуслашып китә, ә укуын тәмамлагач, ярлы, мохтаҗ казакъ дустын үзе белән Эстәрлебашка алып килә. Алар икесе дә тирә-якка даны таралган Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укый башлыйлар. Нигъмәтулла ун елдан соң хәлфә булып китә, бераздан ул Мөхәммәдьяр дустын үзендә асрау хезмәтендә эшләгән Бибигөлсемгә өйләндерә. Мөхәммәдьяр да инде Дүсән авылында мулла хезмәтен башкара. Дусты тәкъдименә колак салып, өйләнә, әмма озак та үтми, авырып китә һәм вафат була. Япа-ялгызы калган Бибигөлсемнең бераздан улы туа, ана Мифтахетдин исеме кушалар. Нигъмәтулла ишан тол Бибигөлсемне Бәләбәй өязе Туксанбай авылыннан килгән яшь мулла Ишмөхәммәт улы Камалетдингә кияүгә бирә. Әтисе үги улын метрика дәфтәренә үз улы «Мифтахетдин Камалетдин улы» дип теркәп куя.

Сәләтле, тырыш малай башта Елдәр волосте Мәнәвезтамак мәдрәсәсендә укый башлый, аннан Карамалы волостенең Әнәс авылы мәдрәсәсенә күчә. Бераздан Эстәрлебаш мәдрәсәсенә килеп, мәшһүр шагыйрь Шәмсетдин Зәкидән дәресләр ала. Тора-бара Оренбург яклары, Җаек буе авылларында йөреп көн күрә һәм, ниһаять, күптән хыялында йөрткән Троицк каласындагы Зәйнулла ишанның абруйлы, дан тоткан мәдрәсәсенә урнаша. Укуын төгәлләгәч, казакъ далаларына китеп, балалар укытып йөрү эшенә керешә...

Мифтахетдин бик акыллы гыйлем иясе, тапкыр телле оста чичән генә түгел, алтын куллы балта остасы да була. Яшь, оста, өлгер-булган яшь егет унөч ел буена далада балалар укытып йөргәннән соң үги әтисе Камалетдин янына кайтып төшә. Күрәсең, үги егет әтисе күңеленә хуш килми, ул аны үз өенә сыендырмый. Егет янә Троицк якларына китеп, Карагыз казакълары арасында көн күрә, Батуч исемле казакъ баена ялланып, мулла булып йөри, әмма 1867 елда аймак башлыгы Исәнгилде белән сүзгә килеп, аның ачуын чыгара. Үчле, мәкерле түрә Мифтахетдин өстеннән «ул солдаттан качып йөрүче нугай (татар)» дип, донос язып бирә. Акмулланы шунда ук кулга алып, Троицк төрмәсенә ябып куялар.

Суд, тикшерү эшләре дүрт елга сузыла, ахырда аны ике ел ярымга арестантлар ротасына җибәрергә дип хөкем чыгаралар. Ярый әле күптәнге танышы Әхмәтбай Бакиров акча җыеп, 2000 сумлык залог белән 1831 елда аны порукага ала.

Мифтахетдин, дүрт ел төрмәдә утырып чыккач, янә Карагыз аймагына кайта, ә көзгә таба Оренбург якларына китә. Самарага кадәр үзенең арбалы атында килә. Казанга пароходка утырып юл тота. Үзе табынган, остазы дип санаган Шиһабетдин Мәрҗанине күрергә бик теләсә дә, аны яшәп яткан йортында туры китерә алмый, поездга утырып, Петербургка юл тота. Башкалада ул татар хәрбиләре ахунд-мулласы Гатаулла Баязитов белән казакъ бае Гобәйдулла Җиһангиров (Чыңгызхан) белән аралаша. Ниһаять, Александр II исеменә гариза язып, Мифтахетдин үзенә янаган суд хөкеменнән котылуга ирешә!

Кабат казакъ даласына кайтып, Кустанай, Акмулла, Петропавел якларында йөри, Себер татарлары арасында да булып ала. 1891 елда янә үзенә якын Троицк каласына килә, Таукарагайда Мактаган исемле бер казакъта яши.

1892 елда Акмулланың Казанда тәүге китабы—«Дамелла Шиһабетдин хәзрәт мәрсиясе» басылып чыга.

1895 елның 15 (27) октябрендә Акмулла Миасс белән Сарыслан авылы арасындагы бер тегермән янындагы буа буена килеп туктый. Атын тугарып, учак ягып, төн каршыларга җыена, йокыга түнә. Бераздан аны Исәнгилде байның дусты, башкорт старшинасы Бурангуловка ялланган Гафиятулла Байморат улы белән Дәүләтшаһ Нәдершаһ улы йоклаган җирендә пычак белән кадап үтерәләр дә, гәүдәсен суга ташлап, ат-арбасын урлап китәләр...

Данлы Акмулланың фаҗигале үлеме бөтен кешеләрне тетрәндерә. Аның исеме дә, җисеме дә, шигырь-тезмәләре дә халык теленнән төшми. Үзенә багышлап, берничә бәет чыгарыла. Акмулла шигырьләре әле байтак еллар телдән-телгә күчеп йөри. Халык, яраткан шагыйре әсәрләренә ияреп, әле хәзер дә шигырьләр чыгаруны дәвам итә. Бу хакта бер генә мисал китереп китәм. 2001 елда Котдус Хөснуллин «Мөнәҗәтләр һәм бәетләр» исемле 20 мең данә тиражлы, калын һәм затлы китабын чыгарды. Аны төзү, әзерләү эшенә безнең өлеш тә керде (автор турындагы белешмәне дә мин яздым). Бу китапның 210-213 битләрендә 22 строфалы «Бу дөньяда иң хөрмәтле—адәм, дигән» исемле мөнәҗәт урын алган. Баксаң, ул Акмулланың атаклы «Иң әүвәл кирәк нәрсә—иман дигән» шигыренә өстәп, ияреп язылган халык мөнәҗәте икән бит! 1981 нче елда М. Госманов төзеп чыгарган китапта бу әсәр (мөнәҗәт булып аның тәүге 6 куплеты гына йөри!) 162-170 битләрдә дөнья күргән. Шагыйрь мөселманга кирәкле, адәм баласына хас алты сыйфатка туктала: иман, күнел, гакыл, шөкер, әдәп, сабыр. Ә халык тарафыннан аларга гыйлем, холык, фикер, инсаф, хәя, тәүфыйк, шөкер, кәнәгатьлек, гадәләт, тәһарәт, нәзафәт, сәхавәт, биш вакыт намаз, руза, хаҗ сәфәре, итагать кебек төшенчәләр өстәлә. К. Хөснуллин атаклы шагыйрь Һибәтулла Салиховның «Тәндә җаным» (214 б.) шигыренә көйләнә торган мөнәҗәт белән янәшә (215 б.) «Синең биш асылың» дигән, янә Акмулла шигыренә ияреп язылган мөнәҗәт китерә. Монда биш төп сыйфат—намус, гакыл, әдәп, күнел, сабыр гына аталган. Бу мисаллар бер нәрсәне раслый: Акмулла иҗаты һаман да халык күнелендә яши бирә! Тукай шигырьләре кебек, алар гел халыкның янында-җанында көн күрә, безгә илһам, изгелек, савап бирә.

Инде үзе дә артта калып, тарих битләренә кереп калган XX гасыр күпләрнең хәтеренә бөек казанышлар—тиңсез югалтулар, данлы җиңүләр, канлы яу-фаҗигалар чоры булып, кешелек дөньясы хәтерендә мәңге сакланачак. Иске тормышны, дин һәм муллаларны адым саен сүгеп, тарихны бозып күрсәтүләр—үткән гасырның иң характерлы бер сыйфаты. Диннең үзен дә, аның әһелләрен дә тәнкыйтьләп, күпме китап язылмаган да, күпме спектакль куелмаган?! Мулла-мәзин, ишан, мөфти, хәтта рәсулулла үзе дә йөз елга якын тәнкыйть утында көйрәделәр бит!

Ә югыйсә, тәрәккъый мәгърифәт, әдәбият-мәдәниятне үстерүгә шул ук муллалар иң мөһим өлеш керткәннәр! Бездә Интибаһ-Янарыш дәверен дә Курсави, Мәрҗани, Насыйри, Фәхретдин кебек бөек затлар башлап җибәргән һәм гомерләре буе нәтиҗәле дәвам иткәннәр бит.

Мине бер нәрсә таң калдыра: зыялы затларның күбесе ата-бабалары, яки төбәк-авыл исемен йөрткәннәр: Курсави—Курсадан, Кормаши—Кормаштан, Кандалый—Кандалдан. Ә менә арада иң данлы, мәгърифәтле зат—мәгърифәтче-остаз, шагыйрьгә исемне халык үзе биргән: Акмулла.

Димәк, Мифтахетдин мулла үзе дә, кылган изге эшләре дә, ул язган тиңсез әсәрләр дә халык биргән исемгә бик лаек.

# РОБАГЫЙЛАР

* * *

Намусыңны калдырма һич малга карап,
Шөкереңне ташлый күрмә, барга карап.
Тәүбә-тәүфыйкның билгесе—канәгатьлек,
Гамәлеңне җуя күрмә малга карап!

* * *

Ир азмас, яманга иярмәс булса,
Гайбәт йөртеп, кеше гаебен тирмәс булса.
Сүз кадерен белер фәкать шундый ир-ат,
Үз акылы акылына тиңдәш булса!

* * *

Шыбырдап яуган яңгыр һич ташка кунмас,
Акылсызга сүз әйтсәң дә, башка кунмас.
Бәндәгә ниләр язган, шуны татыр,
Бер адәм дә тәкъдиреннән башка булмас.

* * *

Ак шоңкар, бәхете тайса, карга булыр,
Тугрыга күпме әйләнеп, зурга куныр.
Җанын-тәнен тәрбия кылган адәмнең дә
Үлеменнән хәбәр килсә, йөзе сулыр.

* * *

Кемнең зәвыгы юк, гыйрфаны да юктыр.
Кемнең гыйрфаны юк, вөҗданы да юктыр.
Кемнең вөҗданы юк, сөйгән яры юктыр,
Кемнең сөйгән яры юк, җаны да юктыр!

* * *

Бай булмас билен япак буган белән,
Тазармас асылы харамның юган белән.
Күпме надан күзен йомып, битен сыйпый,
Суфыйлык табылмый шул күз йомган белән.

* * *

Яхшының сүзе татлы балдан-майдан,
Сүзнең китерер мәгънәсен әллә кайдан.
Ут башында киерелүне киңәш итмим,
Төп билгесе ир-егетнең булсын—мәйдан!

* * *

Һәр җәүһәрнең асыллыгы—асыл ташы,
Ә берәүнең миллион сумлык кара башы!
Сөягегез сөягемнән ким димимен,
Затыгыз—тик затыбызның сәдакасы.

* * *

Егетләр! Надан дустан дошман артык,
Үлгәннән соң арысланнан тычкан артык.
Кулына бер шыр наданның гәүһәр төшсә,
Бәһасен кыла алмыйдыр мыстан артык.

* * *

Канады бер яхшы сүздән колак очы,
Татлы йокы, жылы түшәк—жан тынычы.
Йөгерек ат, яхшы хатын, төзек мылтык—
Чын егетнең шулар булыр юанычы!

* * *

Ат кызыкмас арпаның саламына,
Булма юлдаш адәмнең буш-яманына.
Юлдаш була калсаң адәм яманына,
Ташлап китәр дошманыңның табанына!

* * *

Һич ялынма яманга син «малы бар!»—дип,
Әйткәннәр бит: яманнарның күңеле тар, дип.
Борынгыдан заты нәжес булганнан соң,
Чучканы, әйт, кем сыйпый соң «жанвар» диеп?!

* * *

Яз яратып, кышны аңа игез кылды,
Үлемне дә барча жанга тигез кылды,
Ни кылса да, Ходаемның кодрәте киң,
Әмер кылса, коры жирдә диңгез кылды!

* * *

Дөнья бит ул—бер кысык юл боргаланган,
Багы тайса жиргә, дәүләт күрәлмаган.
«Юл авыр, авармын»—диеп туктап калма,
Өмет өзмә, яхшылык көт бер Алладан!

* * *

Жанга рәхәт, дус-яраннар бер хат язса,
Жан жәрәхәт, көпә-көндез ир-ат азса.
Яманнар гел үз башына үзе житәр,
Нахактан әгәр берәүгә баз казыса.

* * *

Кемнең зәвыгы булмаса, әлеме юк,
Кемнең белеме булмаса, гыйлеме юк.
Кемнең вөжданы булмаса—сөйгәне юк.
Кемнең сөйгәне булмаса—иманы юк!

* * *

Ага агасын сагына, алыш булса,
Ят та бик якын буладыр, таныш булса.
Дустың түгел, дошманың да көенәдер,
Гаебеңнән Тәңре биргән тажың булса!

* * *

Адәм булыр—адәмнәрнең нәкышыдыр,
Адәм булыр—хайван да аннан яхшыдыр.
Ташлар булыр—өстендә гел хайван йөрер,
Ташлар булыр—кыйммәтен бер Алла белер!

* * *

Җиһанда гел тугрылык белән хаклык
Һаман шулай изелерме, тапалырмы?
Ватылгач бер таш йөрәклек, аксөяклек,
Фәкыйрь халык та бер көлеп шатланырмы?!

* * *

Хәләлең хуш, яхшы булса, юк арманың,
Килгән чакта күтәп алса бер мәһанең.
Шәм каршында әйләнүче күбәләктәй,
Барган юлда корбан итсә татлы җанын.

* * *

Татлы телнең төбе ширбәт—мөлаем,
Тибрәлсен шул ширбәт телем һәр даим,
Бирдең телне, Тәңрем, безгә сөйлә дип.
Туры юлга телне шуңа әйдәем!

## Уяну

Булмаек дүрт аяклы мал шикелле,
Куырылган яфраксыз тал шикелле.
Бак сана бер: егет-адәм күркәмләнә,
Гыйлем белән сүз сөйләсә, бал шикелле!

Яз чыкты бакчаларга былбыл сайрап,
Атылып, чәчкәләрне гөл-гөл җайнап[1].
Салыекчы шул бакчага күзебезне,
Куйган юк бит караңгыга безне бәйләп!

Кар китте, сулар агып, бозлар эреп,
Бар дөньяны хозурлыкка китте төреп.
Киемсез, өйдә утырган ятим бала
Таралды урманнарга чәчкә тиереп[2]!

Йөгерде яшь балалар яланаяк,
Кушылдылар чыркырдашып тай-тулак.
Җан бармы хәрәкәтсез, карагызчы,
Бызырдап чыкканда язын яшел кыяк?!

Күз салып карагызчы һәр тарафка—
Дөньяда ачылгандай тимер капка!
Син дә инде һөнәргә омтыл, хәрәкәт кыл,
Талпынып һөнәр өчен мондый чакта!

---

[1] Гөл-гөл җайнап (казакча)—чәчкә атып
[2] Чәчкә тиереп—чәчәк җыеп

## Егетлек хасияте—мәгърифәттә

**Адәмгә авыр дәүләт буен бакмак,**
**Сүзләрнең дә мәгънәсе юк телең саклап.**
**Егетлек хасияте—мәгърифәттә,**
**Илдә үскән һөнәр түгел гафил[1] ятмак!**

**Күчмәле казакбыз бит күрке[2] астында,**
**Һөнәр юктыр, йоклагандай көрпә[3] астында.**
**Гамьсез булып ята бирсәң, хур булырсың,**
**Яу юк диеп уйламагыз бүрке астында!**

**Башка илне күрәбез: ул тауга чыккан,**
**Һичкайчак ил уңа алмас түбән баккан.**
**Мәгърифәт дәрьясы ул күпкә уртак,**
**Омтылып, хур калмыйдыр кулын тыккан!**

**Барыбыз да бертөрлебез табигатьтә,**
**Ялгыз аерма гына бар бер сыйфатта:**
**Гыйлем чәчкән адәмнәрне сыйламыйсыз,**
**Байкагыз[4], шушы холыкмы мәгърифәттә?**

**Тормышы башка илләрнең көн шикелле,**
**Тормышы да надан илнең төн шикелле.**
**Үзегез уйлап карагыз мигә салып:**
**Күренә бит шушы җире миң шикелле!**

**Булмыйдыр атлы белән җәяү бердәй,**
**Буламы алыс белән таяу[4] бердәй?**
**Байкасак[5], арасында аерма күп:**
**Буламы йокылы белән уяу бердәй?!**

**Булмайдыр сабан бердәй елгән[6] белән,**
**Буламы надан бердәй белгән белән?**
**Киң култык көпе[7] киеп, юан итек,**
**Файда юк күренгәнгә көлгән белән.**

**Файдасы юк буш сүзгә һәркем җетек[8],**
**Бу сүзгә талаш кылмас күңеле китек.**
**Таш, җебеп, балкымайдыр майлау белән,**
**Күнмәс ялгыз туң муен, юган итек.**

**Кымыз эчеп, һөнәр түгел ит астырган,**
**Берәрсе җәһаләткә тоташтырган.**
**Замана калай булса, бару шулай,**
**Чыгаекчы шул тарихтан адаштырган!**

---

[1] Гафил – ваемсыз
[2] күрке – куыш
[3] Көрпә – юрган, ябылдык
[4] Байкау – карау, күз ташлау, күзәтү
[5] Алыс белән таяу – ерак белән якын
[6] Байкасаң – карасак
[7] Елгән – гади эш коралы
[8] Көпе – аяк киеме
[1]Җетек – өлгер, җитез
[2] Җәһаләт – наданлык

Йөрисегез киң далада уйнап-көлеп,
Кызыктырган һөнәр түгел атка менеп,
Кукыраеп, муен сузып, түш киереп
Йөрүче уйламагыз һөнәр белеп.

Мактанмагыз кием белән атыгызга,
Шуны уйлагыз—ни лязем[1] бар затыгызга?
Як-якка карау кирәк баш күтәреп,
Әйләнә-алыстагы ятыгызга.

Ни лязем—шуны белмәк инсаният[2],
Һәр нәрсә үзгәрүдән булмайдыр ят.
Адәмгә лаеклы бер эшне белсәк,
Аерылыр шунда бездән хайваният!

Үтте гомер, ут өчен талашкан белән,
Булмыйдыр төзү бер адашкан белән.
Эзләсәң, табыладыр эзләгәнең,
Белем ал син белемгә дуслашкан белән!

Мал түгү—һөнәр түгел ул волостнойга,
Золымлык шуннан килеп кушылмаймы?
Сарыф кылып золымлыкка мал аямый,
Калырсыгыз ахырда сез тирән сайга.

Бәй, волостной! Һөнәр түгел пара[3] җыйган,
Начарга хөкем кылып, тикә[4] җыйган.
Эшеңне юньләрбез, дип, ияк кагып...
Хайван да моннан артык суын ейгән!

Карасаң байдан бире ауылнайга,
Карынын тутыра ит белән майга.
Халыктан җыеп алып, файдаланып,
Барадыр сәлам белән волостнойга.

Илереп талашадыр ауылнайлар,
Чыгымны бердәй салып ярлы-байга.
Ил сынашкан талаштан табыш табып,
Башка өлеш чыгара ул волостнойга!

Байлар йөри һөнәр күреп волостнойны,
Кызыгып, табыш күреп ит белән майны.
Байлыкта—камиллек дип, карынын сыйпап,
«Ученый дәрәҗә» дип ауылнайны!

Һәркайда хәлең харап, булсаң надан,
Йокыдан баш күтәрер зирәк адәм.
Башка йорт-гыйлем эзләп талпынуда,
Һич юктыр җир йөзендә бездән яман!

---

[1] Лязем—кирәкле, мөһим, зарур
[2] Инсаният—кешелек
[3] Пара—ришвәт, алым
[4] Тикә—бер кабым, сынык

Гыйлемлек дәрьясыннан каз алмаган,
Мәгърифәт тарихына күз салмаган,
Вәгазебез безнең кемгә тәэсир итәр,
Торган буш савытыбызга бал салмаган?!

Егетләр, хәбәрдар булыгыз заманадан,
Сыердан артык түгел бит надан адәм.
Нигә соң без хур булабыз башка йорттан,
Без дә бит туып үстек ата-анадан?!

Колак салырга торабыз юк киңәшкә,
Файдасыз, бушка олаккан ирегешкә[1].
—Улымын фәләннең!—дип, күкрәк кагып,
Кушабыз ата-ананы түбәләшкә[2].

Юнь күрер, якыныннан ише булса,
Буталган ул чама уйның «башы» булса,
Талпынып хәл кадәренчә карар идем,
Карарга хатын, бала, ашы булса!

Дәртем бар, дәрманым юк, мин—бүз бала[3],
Күргәнем дә гаептән юктыр данә[4].
Бер-бере бән[5] яулашалар ут башында—
Шушындый бахыр[6] казакъ кайгыларда.

Үз гаебеңне тикшерүне оят димәс,
Сыймыйдыр ак кәгазьгә хилаф киңәш.
Волость бәйнең юлын куй, һөнәр өйрән,
Дигәнемне тере җан нахак димәс!

Үземне төзек мин дип акламаем,
Күңелемдә булса уем, сакламаем.
Әйтегез, йә, бу сүземдә хата булса,
Үземне «хатам юк» диеп мактанмаймын!

Дәртем бар, телем сакау сөйләшүгә,
Мәйданда кулым чулак көрәшергә.
Юрткан белән көйсез ишәк узалмыйдыр,
Күчелер бераздан эш адымлауга!

Мин дә бит озак йоклап, гафил калдым,
Уйланып, инде менә исемә алдым.
«Юмартлык—кулда барга» дигән сымак,
Бар-булганны хәл кадәре акка салдым.

Сукыр куй, надан адәм нурны күрмәс,
Күзе югын башына да ул китермәс.
Һәркемгә үз кирәген эзләү кирәк—
Еламаган балага да имчәк тимәс!

---

[1] Ирегеш—йорттан йортка йөрүче, сорашучы
[2] Түбәләшкә—бәхәскә
[3] Бүз бала—үсмер егет
[4] Данә—өлеш
[5] Бән—белән
[6] Бахыр—мескен

## Карендәшлек

Яз яратып, кышны аңа игез кылды,
Үлемне бар-барлык жанга тигез кылды.
Һәр ни кылса, Ходаның кодрәте киң—
Әмер кылса, шул җирдә Ул диңгез кылды!

Егетләр! Дөнья үтәр башыгыздан,
Күңел куең әдәплеккә яшегездән.
Карендәшкә ихтирамлап карамасаң,
Каерылмый үтеп китәр каршыгыздан.

Хак зикерен[1] күбрәк әйтсәң, ак буларсың,
Сабырлык ахырында шат буларсың.
Хәзинә таптым, дип, кавемеңне[2] искә алмасаң,
Карендәш белән кавемгә ят буларсың.

Иртә намаз вакытында ята бирмә,
Харам нәмә алуга бата[3] бирмә.
Каршы ботак булмасаң, карендәш күп,
Карендәш белән татуның күңеле тук!

Карендәшкә сыймасаң, яман булып,
Кайда барсаң, төяләр күзеңә чүп.
Якыныңны кимсетмә алаш[4] өчен,
Хәрам эшкә керешмә талаш өчен!

Ялгызың ятыр җиреңне уеңа ал,
Утка төшмә берәүнең баласе өчен.
Җибәрмә әҗәл давын, чамаң килсә—
Кош канатын җәядер баласы өчен!

[1] Зикер – Алланың исемен искә алу, дога уку
[2] Кавемеңне, кавем – нәселеңне, кабилә
[3] Бата – рөхсәт
[4] Алаш – аласы

Рафаэль
Хәким

# ТАТАР РУХЫ

*"Өстә—күк Тәңре, аста—көрән җир яратылганда ике арада кеше углы барлыкка килде. Кеше угылларын борынгы бабаларыбыз Бумын каган, Истәми каган идарә иткән. Тәхеттә утырып төрки халкының илен һәм кануннарын саклаганнар, үстергәннәр.*

*Дүрт ягында дошман күп булган, сугышып, дүрт ягындагы халыкны буйсындырганнар: башлының—башын идергәннәр, тезлене—тезләндергәннәр. Элгәре, көнчыгышка, Кадыркан ешлыгына (Зур Хинган тауларына) кадәр, кире, көнбатышка, Тимер Капкага кадәр төрки халыкларны урнаштырганнар. Ике арадагы иясез Күк тврекләрне җитәкләп, алар тәхеткә утырдылар. Каганы белемле, зирәк икән, алып (көчле) каган икән, идарә итүчеләре шулай ук зирәк икән, батыр икән, бәкләре һәм халкы шулай ук төз (тугрылыклы) икән. Аның өчен илне шулай тотканнар, илне тотып, аның кануннарын үтәгәннәр".*

Күлтәгин истәлеге. Олы язма. 735 ел.

## "Мәңге Күк Тәңре"

IV гасырда Урал итәкләреннән көнбатышка юнәлгән һуннар халыкларның бөек күченешен китереп чыгарганнар. Алар тотрыклы балансны җимергәннәр һәм кабиләләр, халыклар, дәүләтләр күчүе башланып киткән. Һуннар белән Рим Папасы да, фарсылар да, Византия дә юмакайлана. Рим империясе, Аттила һөҗүменә чыдый алмыйча, ике өлешкә таркала. Һуннар мәйданнан китәргә дә өлгерми, шул ук тарихи вакыйгалар театрында төркиләр пәйда була һәм Аттила державасыннан зуррак һәм куәтлерәк яңа империя төзелә. Ашинә Каган ыруы исеме белән күп кенә төрки дәүләтләр барлыкка килә, Дунайдагы Икенче Болгар патшалыгы—Ашиннәр династиясе Дунай кыпчакларыннан (Ашиннәрдән) килеп чыккан. Аннары Бөек Дала Дәшти Кыпчакны дөньяга китерә. Һәм, ниһаять, Чыңгыз хан пәйда була һәм бөтен Евразияне тетрәтә.

Азиядә Ашиннәр ыруы урынына чыңгызлар өстенлек ала.

Аттиланы, бөек каганнарны, Чыңгыз ханны җиңүләрдән җиңүләргә нәрсә этәрә? Бөтен Азия аша Европага барып чыгу—безнең ата-бабаларыбызның нинди тарихи вазыйфасы ул? Нәрсә кирәк булган аларга?

Бу феноменны кемнеңдер теләк-омтылышларына яисә матди ихтыяҗларга, котылекләр һәм җирләр җитмәүгә, икътисадка һәм сәясәткә бәйләп кенә һичничек аңлатып булмый. Кеше өчен хыял булганнарның барысына да ирешкән саен, алар тагын да түргәрәк узганнар, көндәлек тормышның рәхәтеннән ваз

---

*Дәвамы. Башы журналыбызның 7-11 саннарында.*

кичеп, яу чапканнар һәм иксез-чиксез җирләрен тагын да киңрәк итү өчен гомерләрен дә аямаганнар. Чыңгыз хан Даос монахы Чан-чунга: "Бар минем бер күлмәгем, бер ашамлыгым бар, мин сыер һәм ат көтүчеләр кигәнне киям, алар ашаганны ашыйм",—ди. Нәрсә эзләгән соң ул?

Чыңгыз хан рухы гомер-гомергә кешелек дөньясы хәтерендә саклана, әмма монгол татарлары өчен ул галәм масштабындагы шәхескә әверелгән. Искәндәр Зөлкарнәен дә (Александр Македонский), Наполеон да чыңгызлар гамәлгә ашырган мәшһүр проектларга хәтта якыная да алмаган. Җир шарын үзгәртеп коруда Чыңгыз хан роле бөек диннәргә тиңдәш. Рәшидетдин сүзләренә карaганда, "Чыңгыз ханның Тәңренең яраткан бәндәсе булуына бөтен дөнья халкы» ышана. Бу аңа күк тарафыннан иңдерелгән миссия күк була. "Бар да дөньяны яулап ал!",—"Чыңгыз хан турында Ихлас Кыйсса"да аның яшәү максаты шул рәвешле билгеләнә..

Чыңгыз хан корал көче белән бөтен дөньяда тынычлык урнаштырырга омтылган. Үзен Ходай җитәкли, дөрес юлны күрсәтә, дип инанган ул. Моңа ышанырга да була, чөнки ул фантастик җиңүләргә ирешә. Яшь Тимучин таланты аркасында гына хан булган. Атасы бик яшьли үлә, аннан соң вассаллары терлек-туарларны, мал-мөлкәтне алып, кайсы кая качып китә. Ныгып җиткәч, яшүсмер үз тирәсенә нөгәр дусларын туплый, мал-мөлкәтне кире кайтара һәм төрле ырулар аңа елыша башлыйлар. Шулчак күрше-күлән борчуга кала. Торгутайның 30 мең җайдагы Тимучинның 13 мең җайдагына каршы чыга һәм бер тапкыр һөҗүм итеп аны тар-мар итәргә ниятли. Тимучин үз гаскәрләренең уң канатын—атлылар үтеп кермәслек урманга терәгән, сул канатын исә көймәле арбалардан һәм йөк арбаларыннан торган саклану системасы белән ныгыткан, бу арбаларга, дошманның игътибарын читкә юнәлтер өчен, хатын-кызлар һәм яшүсмерләр утыртылган. Торгутайга маневр өчен җай калмаган, бөтен гаскәре үзәктә урнашканга күрә, ул Тимучиннан көчлерәк була алмаган. Калганы Тимучинның гаскәри сәләтенә генә бәйле булган. Ул беренче мәртәбә җиңеп чыккан. Аннан инде башка җиңүләр тезелеп киткән һәм, ниһаять, 120 елда ул киездә күтәрелгән—хан дип игълан ителгән. 1227 елда вафат булган. Чыңгыз хан идарә иткән 21 ел дәвамында төрледән-төрле монгол һәм төрки кабиләләр чәчелеп яшәгән җирләр аның Евразия империясенә әверелгән. Ханлыгының башлангыч чорында Чыңгыз хан буйсынуында 13 мең арба булса, гомеренең азагында бөек ханга төрле телләрдә сөйләшкән һәм төрле диннәргә инанган 720 халык буйсынган."[1] Ул инде япа-ялан чүлләрне генә түгел, куәтле дәүләтләрне дә үзенә буйсындырган. Лев Гумилев билгеләп үткәнчә, "ул чакта монголлар 200 меңгә якын булган, ә калган ярты миллионы 1201-1210 елларда монголлар яулап алган кераитлардан, найманнардан, мәркитләрдән һәм татарлардан торган. Монголия тирәсенә урнашкан дәүләтләрдә халык гаять күп булган. Таңгут патшалыгында 2500 мең кеше яшәгән, шуларның 500 меңгә якыны гаскәриләр булган. Кытайда, Кинь (Цинь) чжурчжэнь династиясенә буйсынганнардан Төньякта һәм Көньякта—80 миллион, Хәрәзм солтанлыгында—20 миллионга якын, Көнчыгыш Европада—8 миллион чамасы кеше гомер иткән"[2]. Чыңгыз хан бу илләрне һәм үз халкыннан йөзләгән тапкырлар артыграк булган халыкларны буйсындырган. Моны берничди дә мантыйкка сыйдыру мөмкин түгел. Өстәвенә, Кытай һәм Азия белән чагыштырганда, икътисад та бик зәгыйфь булган. Мондый җиңүләрне гадәти мантыйки белән генә аңлату һич мөмкин түгел. Чыңгыз ханга Күк Үзе булышкан күрәсең.

Шундый ук вакыт эчендә—"үзгәртеп кору" заманында Россия үз территориясенең иң шәп яртысыннан мәхрүм калды, Каспий һәм Кара диңгезләрдә контролен югалтты, Балтыйк диңгезендә беренчелегеннән колак какты. Икътисадый һәм хәрби куәтен җуйды. Тарихта шәхесләрнең рольләре төрлечә була. Берәүләрнең миссиясе җирләр туплау булса, икенчеләренең—алдагы буыннар төзегәнне җимереп, җуеп бару.

---

[1] М.И.Иванин. О военном искусстве и завоеваниях монголо-татар и среднеазиатских народов при Чингисхане и Тамерлане. — М., Санкт-Петербург, 2003, с. 28.

[2] Лев Гумилев. Черная легенда... С. 288.

*Идел өстендә, корбанын эзләп, карчыга оча. Көчле җилгә күкрәген куеп, рәхәт чигә. Ул каршылык ярата. Җил көчәйгән саен, өскә омтыла. Шәфәкъ кызыллыгы урман-кырларны, судагы дулкыннарны яктырта. Кояш баюын күзәтеп, карчыга офык аръягына—Көнбатышка атыла. Аның шәүләсе, баеп баручы кояш белән бергә, зәңгәр күкләрдә эреп югала. Символлар безнең белән янәшә яши, алар—безнең тирә-юньдә.*

Чыңгыз ханның нәсел гербы—тырнакларына козгын эләктереп очкан шоңкар, ул үзе Мәңге Күк Тәңрегә табынган.

Тәңречелек—бөтен төркиләрнең традицион дине, ул шактый дәрәҗәдә абстракт һәм гади булган. Һуннар инде Тәңре ханга, Югары дөнья хуҗасына табынганнар, аларның символлары кояш, ай, биек агачлар, бигрәк тә яшен суккан агачлар булган инде. Аеруча Урта дөнья иясе "Изге Йир-Су" культы көчле саналган. Хәтта Җирне "чакыручы", ягъни Җиргә мәдхия укучы һун "сихерчеләре" дә булган. Һун пантеонының үзенчәлекле персонажы—"йол (юл) тәңре". Мәет күмгән чакта һуннар, иң әйбәт киемнәрен киеп, ат чабышлары, егетләр белән кызлар арасында уеннар оештырганнар, шуннан соң яшь-җилкенчәкләрнең ата-аналары балаларын өйләндерү турында сүз куешканнар. Борынгы төркиләрдә (көнчыгышта да, көнбатыш болгарларында да) дин һуннарның күзаллауларына тәңгәл булган.

*Тәңри өчүк бизке бол,*
*Идел йөрим а беңгү бол*[3].

Аларча Тәңре—дөньяны бар итүче, бөтен нәрсәнең чыганагы һәм сәбәбе. Ул җирләрне, күкләрне һәм шуннан аста бөтен нәрсәне яралткан. Ул кешеләрне яралткан, ул аларның яклаучысы, ул—бөек яклаучы көч. Аннан мәрхәмәт һәм рәхәтлек иңә. Тәңре «кеше» дип аталган акыллы җан иясен җирдә яшәсен өчен яралткан. Әмма кеше Аллага бурычлы икәнен оныткан, ул үзен аңа тиңли башлаган, аның белән ярышырга керешкән. Шул чак Тәңре бу кешене җир асты дөньясына—караңгылыкка ташлый һәм аңа "Эрклиг" дип исем бирә. Шуннан соң Тәңре тагын 9 кеше яралткан һәм хәзерге кешеләр шуннан үрчегән.

Тәңре каганнарга зирәк акыл һәм хакимият иңдергән, халыкка каганнар бүләк иткән, каганнарга каршы йөргәннәргә җәза җибәргән һәм каганнарга дәүләт эшләрен, хәрби эшләрне хәл кылганда ярдәм иткән.

Төрки тәңреләр арасында "ала атлы йол тәңре" һәм "кара атлы йол тәңре" дигәннәре дә искә алына. Алар, Тәңренең илчеләре буларак, кешеләргә "кот"—"тәңре рәхәте, рух—җан" җибәргәннәр һәм "тәңре ил" дәүләтен—«илаһи ил»не төзүгә этәргәннәр.

*"Мин—тәкъдирләр тәңресе! Көнен дә, төнен дә мин ала атта чабам!" Ул ике айлык кеше затына каршы чапкан. Алар очрашканнар. Кеше куркып калган. Тәңре әйткән: "Курыкма! Мин сиңа кенәзлек рәхәтен бирәм!" Шулай дигән ул!"*

"Фал китабы". X гасыр.

Күк Тәңре Чыңгыз ханның иманы була, бу иман башка инануларны да эченә ала, шуңа күрә Чыңгызхан бүтән диннәрне дә ихтирам иткән. Фарсы тарихчысы Җүвәйни язуынча: "Ул төрле юнәлештәге галимнәрне һәм дәрвишләрне ихтирам итә, аларны Ходай каршындагы арадашчылар дип саный, мөселманнарга да, христианнарга да хөрмәт белән карый, потларга табынучыларны да җәберләми. Аның балалары һәм оныклары арасыннан берничәсе үзләре теләгән динне сайлап алды: берәүләре Исламны үз итсәләр, икенчеләре христиан җәмәгатенә кушылалар, кайберләре потларга табыналар, кайсы-берсеrange исә ата-бабадан калган борынгы йолаларны үтиләр һәм бер якка да тайпылмыйлар, андыйлары бик аз була. Төрле диннәргә күчсәләр дә, алар юньсезлек, шәфкатьсезлектән читтә торалар, Чыңгыз ханның ясасыннан тай-

[3] Тоба (Енисей тармагы) елгасы буендагы икенче бер ядкяр.

пылмыйлар, ә хан ясасы буенча бөтен диннәр дә бер төрле дип санала һәм алар арасында аерма ясалмый".[4] Хәзерге заманда Европадагы корольләрнең берәр баласы Исламга күчсә яисә мөселман шәехенең баласы христиан яисә буддист булып китсә, бик гаҗәп тоелыр иде.

Коточкыч Варфоломей төнендә ("озын пычаклар төне") католиклар Парижда меңләгән гугенотны башка дин тотканнары өчен генә рәхимсез рәвештә суеп чыкканнар.

Чыңгыз ханның бөтен диннәргә дә тигез карашы соклануга һәм ихтирамга лаек, барлык мәгърифәтле кешелек дөньясы бүген шуңа омтыла. Чыңгыз ханның үткен акылына, алдан күрә белүенә таң каласың: ул бит урта гасырларда үзе яулап алган җирләрдәге барлык диннәргә карата тигез мөнәсәбәт урнаштыра алган.

Чыңгыз ханга мондый зирәклек кайдан килгәндер—әйтүе кыен: Кытай монахлары белән корган әңгәмәләренең файдасы тигәнме, яисә ул үз дәүләт диннәре булмаган төркиләр традицияләрен дәвам иткәнме. Мисал өчен, уйгырлар арасында буддизм, зороастризм, несторианлык һәм манихейлык таралган булган, һәм руханилар салымнан азат ителгәннәр. Бәлки, Чыңгыз ханга хас бу зирәклек Ходай рәхмәте булгандыр. Мөхәммәд пәйгамбәр белән Чыңгыз хан арасында ниндидер уртаклылыклар бар. Икесе дә укый-яза белмәгән, әмма гыйлемне бөтен нәрсәдән дә өстен куйган. Алар чыккан кабиләләр ярым кыргый булсалар да, алдан күрү, җәмгыятьне дөрес оештыру һәм югары әхлак нәтиҗәсендә ярты дөньяны яулаганнар. Әмма Мөхәммәд һәм аның тарафдарлары дөньяны ислам исеме белән үзләренә каратсалар, Чыңгыз хан диннәрнең тигезлеге өчен җан аткан. Ләкин шул гадәте аны империя төзүгә этәргән дип фаразлау дөрес булмас иде. Диннәргә тигез караш, билгеле инде, дәүләтне нығырга ярдәм иткән, әмма тарихтан билгеле булганча, еш кына империя дини әләм астында төзелә. Христиан Византиясен яисә Гарәп хәлифәтләрен искә төшерү дә җитә. Әмма Чыңгыз ханга хас "экуменизм"ның вакыты җитмәгән әле һәм соңрак аның үз халкы—монголлар ламаизм кабул иткәннәр, Алтын Урда исә Үзбәк хан дәверендә мөселман мәмләкәтенә әверелгән.

Бөтен җиңүләрдән соң да, кешелек дөньясы тарихындагы иң зур дәүләтнең чикләнмәгән хакиме булгач та, Чыңгыз хан күкләрдәге бөек көчкә тулысынча буйсынганын һәм үзен Ходай кулындагы корал икәнен сизгән һәм аңлаган. Алай гына да түгел, ул һәркем Аллага ышанырга тиеш дип санаган, шуңа күрә дингә аеруча әһәмият биргән. Үз бурычын җиренә җиткереп һәм куркусыз үтәр өчен кеше үз шәхси язмышының Ходай тәкъдирендә булуына җаны-тәне белән ышанырга тиеш. Шул рәвешле ул курку-өркүләрдән һәм дөньялык шаукымыннан арына. Шуңа күрә Чыңгыз хан барлык дини оешмаларны да салымнан азат иткән. "Татар-монгол изүе" чорында Православиене җәберләгәннәр дип язучы авторлар иң гади нәрсәләрне дә белмиләр. Бу хәл берничек мөмкин түгел. Болай дип уйлау чыңгызларның хакимлеге булмауны, ягъни "татар-монгол изүе" булмауны тануга тиң. 1312 елда Үзбәк ханның Алтын Урдада дәүләт дине итеп Исламны көчләп кертүе дә рус кенәзләренә кагылмый.[5] 1313 елда Үзбәк хан Русь митрополиты Петрга ярлык бирә, анда түбәндәге сүзләр язылган була: "Әгәр кем дә кем христиан динен хурлый икән, чиркәүләр, монастырьлар һәм часовнялар турында яман сүзләр әйтә икән, ул кешене үлем җәзасы көтә".[6] Бу җәһәттән Үзбәк хан хатыны Тайдула бигрәк тә аерылып тора, аны кеше арасында "христианнарны яклаучы" дип атап йөртәләр. Теләсә нинди дингә ихтирам чыңгызлар сәясәтенең нигез ташын тәшкил итә. Бу—бөтен казанышларга һәм идарә системасына хас була, шуңа күрә дә анда дини бәрелешләр булмый.

Диннәргә карата түземле мөнәсәбәт культура элементы буларак татар дөньясында озак еллар сакланып килгән. Казан ханлыгы чорында Казанда рус һәм әрмән бистәләре булган. Явыз Иван, Казанны яулап алып, мәчетләрне җимереп, алар урынында православие чиркәүләре салдыргач кына, ислам каршы тору идеологиясенә әверелә.

Җир йөзендә мессианлыкның төрле рәвешләре булган. Европа культурасының

---

[4] Г.В.Вернадский. О составе великой Ясы Чингиз Хана. — Брюссель. 1939, с.43.

[5] Үзбәк хан үз кызын Мәскәү кенәзенә кияүгә биргән һәм аңа православиегә күчәргә рөхсәт иткән.

[6] Ризаэтдин Фәхретдин. Алтын Урда ханнары. — Казан, 1996, 94 нче бит.

нигезендә "Рим рухы" миссиясе ята. Дөньяның бөек диннәре, иң беренче чиратта, иудаизм, христианлык һәм ислам җир шарында яңа дәвер башлануга этәргеч булган. Алар—башлангычларында ук мессиячел. Яһүдләр һәрвакыт үзләрен мессиячел халык дип санаган. Христианлык та төрле рәвешләрдә шундый ук дәгъвалар белән чыккан. Мөхәммәд пәйгамбәр чып-чын мессия булган. Немецләрдә фашист мессианлыгы коточкыч рәвешләр алган. Мессианлыкка гомер-гомергә уңай һәм тискәре күренешләр хас булган. Рим кануннары, корал көче кулланып булса да, Европа хокукиятенә нигез салганнар. Британлылар үзләренең казанышларын колонияләренә көчләп тагканнар, соңыннан бу казанышлар җирле культураның бер өлешенә әверелеп киткән. Испан культурасы, конкистадорларның коточкыч гамәлләренә карамастан, Латин Америкасының табигый өлешенә әверелгән. Монда билгеле бер дәрәҗәдә объективлык, котылгысызлык, зарурлык булган, югыйсә яулап алучылар киткәннән соң халык көчләп тагылган кыйммәтләрдән ваз кичәр иде.

Христианлык кешеләрне берләштерер өчен иңгән, исламның да миссиясе шундый ук. Бу диннәр бөек империяләр барлыкка китергәннәр, әмма кешелек дөньясын бербөтен итеп берләштерә алмаганнар. Чыңгыз хан да шул ук миссияне башкарырга керешкән һәм аның омтылышы да уңышсыз булып чыккан. XX гасырда кешелек дөньясы шушы мөһим чиккә килеп җитте. Бүгенге көндә АКШ халыкара мөнәсәбәтләрнең кысаларын билгеләүче бердәнбер держава миссиясен үз өстенә ала, әмма цивилизацияләр бәрелеше аркасында бу максат тагын тормышка ашмас, ахрысы.

Глобальләштерү авторлары, теләсәләр дә, теләмәсәләр дә, билгеле бер мессианчылыкка дәгъва кылалар. Алар Көнбатыш кыйммәтләрен, кайчакта дәлилләп, кайбер очракта җәмгыятьтәге процессларны үзләре аңлаганча мәҗбүриләп тагу юлы белән, бөтен дөньяга тарaталар. Демократия ара-тирә бөтенләй демократик булмаган ысуллар белән дә көчләп тагыла. Глобальләштерү идеясендә Чыңгыз ханның рухы—бөтен дөньяга хакимлек итү хыялы кабат-кабат чагылып китә.

Көч кулланып яисә дин, идеология, Интернет ярдәмендә урнаштырылган хакимлек арасында уртаклыклар бар. Мондый хакимлек бердәм закон яисә бердәм кыйммәтләр кертүгә, бер генә культура таратуга омтыла. Мондый күренеш исә гадәттә милли, территориаль, дини, этник, локаль культураны яклау рәвешендә җавап реакциясе кузгата. Бу ике мең ел элек тә, мең ел элек тә шулай булган. Дөнья бүген дә шундый ук.

Һуннар килеп нигезен дер селкеткәнче, Рим империясе дә мәңгелек сыман тоелган, Римның җимерелүен замандашлар Ходай каргышы сыман кабул иткәннәр. Баһдадны татарлар яулап алгач, Гарәп хәлифлеге халкы да шундый ук тетрәнү кичергән. Монгол империясе дә таркалган. Алтын Урда кыйпылчыклары өстендә яңа империя корганда, Мәскәү дә аны мәңгелеккә төзим дип ышанган булган.

Империяләр юкка чыкса да, аларның шәүләсе кала. Рим империясен—Көнбатышның Изге Рим империясендә һәм Көнчыгыш Рим империясендә—Византиядә торгызырга омтылып караганнар, габбаслылар Баһдад хәлифлеген, мәмлүкләр Каһирәдә һәм Оттоман империясендә үз империяләрен торгызмакчы булганнар, Монгол империясе Кытайда һәм Россиядә яңадан торгызылган да. Алар да янә таркалуга дучар булган. Әмма бөек яулаучыларның шәүләләре безнең арада йөри, безнең аңыбызга үтеп керә һәм бөек мөетләрне терелтү кебек тормышка ашмас хыялларга этәрә. Бердәм универсаль дәүләт төзү идеясенә күрсәтелгән каршылык кебек үк, Чыңгыз хан рухы да һаман җиңелми һәм бирешми әле.

*Таң тәңре келти,*
*Таң тәңре ози келти*
*...*
*Таң тәңре*

*Ядлы япарлы*
*Яруглы яшуглы*
*Таң тәңре*
*Таң тәңре...*

*Дәвамы киләсе санда.*

*Татар театрына 100 ел*

# АЧ ПӘРДӘҢНЕ, ГАЛИҖӘНАП ТЕАТР!..

ГАЛИӘСГАР КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ
ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ ДИРЕКТОРЫ
ШАМИЛ ЗАКИРОВ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ

*1906 елның 22 декабрендә Казанда татарча беренче ачык спектакль уйнала. Бу көн профессиональ татар театры туу көне итеп кабул ителә, чөнки күп санлы үзешчәннәрнең спектакльләре инде XIX гасыр ахырыннан ук даими куела килә. Чак кына соңрак оештыручы-педагог Ильяс Кудашев-Ашказарский кул астында татарның беренче театр коллективы "Сәйяр" труппасы эшли башлый, соңрак ул төркем Габдулла Кариев җитәкчелегенә күчә. Әлеге труппада татар театрын башлап җибәрүчеләрдән мөселман дөньясының беренче хатын-кыз артисткасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, артист, драматург һәм педагог Кәрим Тинчурин, режиссер Вәлиулла Мортазин-Иманский, актерлар Нури Сакаев, Гөлсем Болгарская һәм башкалар эшли.*

*Татар театрының традицияләрен дәвам иттерүчеләрдән драматурглар Гаяз Исхакый, Мирхәйдәр Фәйзи, Фәтхи Бурнаш, Нәкый Исәнбәт, артистлардан Зәйни Солтанов, Мөхтәр Мутин, Фатыйма Ильская, Хәлил Әбҗәлилов, режиссерлардан Гомәр Девишев, Сөләйман Вәлиев-Сульва, Гомәр Исмәгыйлев һәм башкаларның исемнәрен атарга була.*

*1926 елда театрга "Татар дәүләт академия театры" дигән мактаулы исем бирелә, 1939 елдан ул драматург Галиәсгар Камал исемен йөртә башлый.*



**—Татар театрына 90 яшь тулу көннәрендә мин сездән, Шамил әфәнде, театрның 100 еллык юбилеен ничегрәк күзаллыйсыз?—дип сораган идем. Бу чор илнең базар мөнәсәбәтләренә кереп баткан, һәм Россиядә күп кенә театрларның ябылган чоры иде. Ул чакта сез: "Татарстан дәүләтчелеге ныгыр дип ышанам. Милли мәктәпләребездә белем алган яшьләребезгә өмет баглыйм. Театрның киләчәген дә, кыйбласын да яшьләр аша күрәм,"—дигән идегез. Инде менә ун ел үтеп тә китте. Илдәге вазгыять белән бергә, әлеге фикерләрегез дә үзгәреш кичергәндер, билгеле.**

—Сез хаклы, күпчелек өметләрнең акланмавы, хыял гына булып калуы кызганыч, әлбәттә. Әйтик, татар теленең дәүләт теле дәрәҗәсенә ирешеп тә, гамәлдә үз вазыйфасын тулысынча үти алмавы, татар мәктәпләренең әкренләп ябыла баруы йөрәкне әрнетә, җанны рәнҗетә. Әмма безнең театрыбыз исән-сау, Аллага шөкер, инде менә 100 яшен тутырды.

**—Театрның ошбу олы юбилей елын, мөгаен, Театр елы итеп игълан итәргә дә мөмкин булыр иде. Җитмәсә театр сәнгатенә гомерләрен багышлаган бик күп**

**шәхесләрнең дә зур юбилейлары шушы елга туры килә. Бөтен бер гасырны яктырткан бу йолдызлар үзләре генә дә әнә күпме: Мөхтәр Мутин, Габдулла Кариев, Хәлил Әбҗәлилов, Мирхәйдәр Фәйзи, Галия Нигъмәтуллина, Гөлсем Камская, Габдрахман Камал II, Галия Булатова, Гөлсем Болгарская, Мәэмүн Сутюшев, Марзия Миңлебаева, Фатыйх Колбарисов, Ширияздан Сарымсаков, Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Наил Әюпов, Дания Нуруллина, Николай Юкачев...**

—Белгәнебезчә, Россия җирлегендә кешегә кешечә яшәү мөмкинлеген тудыру бик авырлык белән бара. Интеллигенция һаман иң рәнҗетелгән катлам хәлендә кала бирә. Дөрес, хөкүмәт соңгы бер-ике ел эчендә укытучылар һәм врачлар турында кайгырта башлады. Ә мәдәният өлкәсенә һаман күз йомып киленә. Мондый вазгыятьтә Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең 2006 елны Татарстанда әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан итүе, билгеле, бик күпләрне сөендерде. Киләчәккә өмет яңарды. Әйбәт эш-гамәлләрнең күбесенең башта Татарстанда тууына, соңыннан аның Россиякүләм закон көченә ия булуына күнегеп киләбез инде. Әдәбият һәм сәнгать елы да кешеләр күңелендә, тарих битләрендә матур эз калдырыр дип ышанасы килә. Сәнгатьнең бер төре булган Татар театрының 100 еллык юбилеенның әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителгән елга—бик күп, бик зур юбилейлар елына туры килүе, житмәсә аның туган көненең ел ахырында, ягъни 22 декабрьдә булуы, билгеле, юбилейлардан кешеләр арымады микән дигән шик тудырып, мине бераз борчып тора. Һәрвакыттагыча, бу юлы да безнең халыкның театрны яратуына, юбилейны үз бәйрәме итүенә өмет тотабыз.

Милли театрлар күпләп ябылган бермәлдә, безнең исән-сау яшәвебез, алай гына да түгел, татар театрларының һаман арта баруын—аларның саны бүген унга житте!—мин халкыбызның театрга булган олы мәхәббәте белән генә аңлата алам. Мәхәббәтнең шундые да була. Чөнки бүгенге көндә мондый күренеш башка бер милләттә дә юк.

**—Театрны халык яшәтә дигән гыйбарә бар. Моңа өстәп, театрны талантлар һәм шәхесләр яшәтә, ди белгечләр. Чыннан да, талантлы артистлар белән эшләү өчен режиссерның да талантлы булуы зарур. Бу очракта директор вазыйфасында да театрга меломаннарча гашыйк, һәр ике якның мәнфәгатен тигез кайгырта алучы шәхес булуы мөһим. Моны мин конкрет Баш театрны, сезнең эш ысулыгызны истә тотып әйтәм. Хезмәтегезнең без белмәгән якларын да бераз ачсагыз иде. Әйтик, галиҗәнап Марсель Сәлимҗанов белән эшләү дәвере эпизодларын. Тамашачы Театр дигән дәүләтнең эчке тормышын бөтенләй белми диярлек.**

—Ходайга шөкер, Камал исемен йөрткән Академия театры һәрвакыт талантлар белән гөжләп һәм гөрләп торды. Мин үземнең бөек Сәлимҗанов белән эшләү дәверемне иң бәхетле чор дип исәплим. Марсель Хәкимовичка хөрмәтем, ихтирамым чиксез булды; ана—димәк театрга!—хезмәт итүемне зур бәхеткә санадым. Без һәрвакыт бер-беребез белән килешеп эшләдек.

**—"Килешеп" диюегез белән ... менә бигүк килешәсе килми бит әле. Даһи Сәлимҗанов холкына үзсүзлелек, кырыс булу, кызып китү—кыскасы, диктатор гадәтләре дә ят булмавы сер түгел. Кайбер артистларга карата Марсель әфәнденең кискен алымнар кулланган чакларын, һәм андый очракларда сезнең әлеге артистны яклап, театрда саклап калуыгызны ишеткәнем бар. "Инсаният" труппасы төзеп, өлкән яшьтәге артистларны театрда саклавыгызны, алай гына да түгел, талантлы яшьләрне "Балачак" студиясенә туплап, театр гаиләсен ишәйтүегезне дә беләм.**

—Бәлки "килешеп" дию урынына, бер-беребезгә "юл куеп" эшләдек дию дөресрәк булыр. Эштә, бигрәк тә иҗат эшендә төрле хәлләр була, әмма гаиләнең әхлак кануннарында югары тәрбия алган Марсель Хәкимович һәрчак, һәр очракта үз дәрәҗәсен саклый белде. Хәтерлисездер, Чыңгыз Айтматов әсәре буенча сәхнәләштерелгән "Ахырзаман" спектакле үзенең куелышы белән үк театрда гына түгел, бөтен шәһәрдә вакыйга тудырган иде. Аны Сәлимҗановның үз укучысы, үз шәкерте, бик талантлы режиссер Дамир Сираҗиев куйды. Спектакльнең язмышы театрның иҗат советында кыл өстенә эләкте, әсәрне дә, режиссерны да гел бетереп



*Г. Камал театры коллективы. 2006 ел.*

ташладылар. Репетицияләр вакытында шаккатып, бераз көнләшеп тә утырган Марсель Хәкимович—эндәшми. Көтәм, һаман эндәшми утыра. Түзмәдем: "Мин мондый театрда эшли алмыйм. Китәм",—дидем. Шуннан соң гына Марсель Хәкимович сүз алды, спектакльнең сәхнәгә чыгуы хәл ителде. Әйе, Сәлимжановны яратырга мөмкин, яратмаска мөмкин, әмма аның бөеклеген күрмәү, олпатлыгына сокланмау, эшен, иҗатын хөрмәт итмәү мөмкин түгел... Мин аның театрга килеп керүен үк күзәтергә ярата идем. Ул иҗади планнар белән ашкынып, очарга теләгән кош кебек колач җәеп, җиргә тияр-тимәс адымнар белән килеп керә иде, һәм театр аның чиксез энергиясенә буйсынып, яшәп китә иде. Шул ук вакытта бик нечкә хисле, гаҗәеп нечкә күнелле шәхес иде ул. Салих Сәйдәшнең "Кандыр буе", "Хуш авылым"нарын Наил Әюпов җырлаганда мин Марсель Хәкимовичның бу җырларны күз яшьләре аша тыңлавына шаһит. Аның гарьләнүдән, рәнҗүдән саркыган күз яшьләрен күреп, тетрәнү кичерергә дә туры килде миңа.

**—Аңламадым: гарьләнүдән, рәнҗүдән дисезме?! Академия театрының баш режиссеры, СССРның халык артисты, тагын әллә күпме титул-дәрәҗәләргә төренгән Марсель Сәлимҗановмы?!**

—Әйе, ярты гасыр дәвамында Татарстанның рухи ягын кайгырткан, милләтнең рухи җанын, телен саклаган Кешенең пенсия кенәгәсе алган көн иде ул. Кенәгәне ачып, әллә 1600, әллә 1800 санына төртеп күрсәтте дә: "Мин бит гомеремне театрга багышлаган, театр өчен үземне аямаган кеше. Әйе, Кеше!—диде һәм күзләре яшьләнде. Ә соңгы елларда, бигрәк тә авырый башлагач, еш кына:—Хатынымны җәллим. Мин бит Гөлнарны бер тиенсез калдырам—ничекләр яшәр",—ди иде.

**—Гомерне театрга багышлау... Марсель әфәндenең эти-әнисе дә гомерләрен театрга багышлаган олпат шәхесләр. Татарстанның халык артистлары. Димәк тулы бер династия!.. Телевидениедә эшләгән чагымда, җитмешенче еллар башында Хәким аганы күргәнем, аның әдәбият, сәнгать, тарихны тирәнтен белүенә сокланганым хәтердә. Ул әле бер килүендә бездән, ягъни телевидениенең редакторлары, режиссерларыннан улы Марсельгә затлы, укымышлы татар кызлары арасыннан кәләш табуда булышуыбызны да үтенгән иде. Ә менә Галия апа Нигъмәтуллинаны якыннан белергә, сөйләшергә туры килмәде.**

—О-о, Галия апа! Галия апа... Театрның мәңгелек мәхәббәте инде ул. Әйтелмәгән мәхәббәте. Мин Марсельнең кунакчыллыгына, табында кунакларга үзе яраткан ризыкларның әле берсен, әле икенчесен тәкъдим итә-итә сыйлый белү осталыгына

шакката идем. Боларның барысы да ана әнисе Галия ападан көчкән икән. Улының таянырдай ышанычлы хезмәттәше булгангамы, Галия апа мине үз күрә, бик якын итә, иң яшерен серләрен дә сөйли иде. Миңа да ул үз әнием кебек якын булды. Җор сүзле, гел яхшы, кызыклы хәлләр турында гына сөйләргә яратучы якты күңелле, олы җанлы, искиткеч сабыр булуы өстенә, гаҗәеп дәрәҗәдә юмарт та ханым иде әле ул. Анын бу сыйфаты ярлы-ябагай артист халкы өчен бәяләп бетергесез бер хәзинә иде. Гастрольләр вакытында Галия ападан акча алып тормаган артист, ай-һай, булды микән?! Театрның җаны иде ул... Марсель беренче тапкыр Америкага апасы Әдилә янына киткәч, туган өй, туган ил өчен кызын югалткан, аны өзелепләр сагынган ана буларак, бу илгә улының баруында Галия апаның фаҗига күрүе, аны кире кайтмас дип борчылулары, мондый хәсрәт газабыннан авырый башлавы, һәм минем: "Сезсез, театрсыз, туган илсез яши алмый Марсель Хәкимович. Кайта ул, менә күрерсез!"—дип юатуларым бүген дә исемдә. Ходайга шөкер, Марселенең кайтуын көтеп ала алды Галия апа. Гаҗәп хәл: анын җеназасы да, үзе кебек, якты үтте. Җырләп кайткач, Актерлар йортына, искә алу йоласына җыелдык. Мондый чакта гадәттә күз яшьләре аша кызгану, үкенү, кайгы сүзләре сөйләнелә бит инде. Ә бу юлы Галия апа белән бәйле гел кызыклы хәлләрне генә сөйләп, ышанасызмы, гел көлешеп утырдык. Минем бүтән мондый искә алу кичәсен күргәнем булмады.

Галия апа театрда гаилә җылысын, олы бер туганлык рухын, туганлыкка охшаш дуслык рухын калдырып китте. Безнең бөтен бәйрәмнәребез бергә үтә. Шатлык-хәсрәтләребез дә уртак.

**—Режиссер Сәлимҗановның яраткан артистлары булуын беләм. Минем үземә, мәсәлән, бер сөйләшүебездә аның Шәүкәт Биктимеров, Ринат Таҗетдинов, Алсу Гайнуллина, Люция Хәмитова, Искәндәр Хәйруллиннарның талантына соклануын һәм бу артистларга чиксез ышануын әйткәне бар. Марсель әфәнде вафатыннан соң Алсу Гайнуллина сәхнәдә күренми башлады. Бу хәл Остазын югалту белән бәйлеме?**

—Марсель Хәкимовичның мәңгелеккә күчүе барыбыз өчен дә зур югалту булды. Бу югалтуны бигрәк тә анын шәкертләре авыр кичерде. Бермәлгә театр гел ятим калгандай тоелды. Әмма 100 яше якынлашкан театрга яшәргә кирәк иде. Һәм без әкренләп яшәп киттек. Баш режиссерыбыз да, Ходайга шөкер, Сәлимҗановның үзенең бик тә талантлы шәкерте, театрның үз улы—Фәрит Бикчәнтәев булды. Аны Президентыбыз Минтимер Шәрипович Шәймиев үзе билгеләп куйды. Ә Алсу... Алсу ханым, минем уемча, әле бүген дә Остазы Марсель Хәкимовичның юклыгы белән килешә алмый. Марсель һәр елны Алсу Гайнуллина өчен махсус бер спектакль куйды, гел героиняларны гына уйнатты. Һәм хәтта актрисаның капризларына да күз йомып, юл куеп килде. Билгеле, артык игътибардан адәм баласы бозыла бит ул. Алсу да мондый игътибарга күнекте булса кирәк. Бүген дә бик чибәр, һаман да япь-яшь актрисаның хәзерге халәте, остазы вафатында үзенең дә фаҗигасен күрүе аңлашыла да. Әмма мин ышанам: бик акыллы, талантлы, горур Алсуыбыз, зур шөһрәт казанган атаклы актриса Фатыйма Ильская хатасын кабатламас. Ул әле сәхнәдә яңадан-яңа образлары белән яңадән балкыячак! Чөнки ул үзен яратучы тамашачылар барлыгын белә. Театр дигән иҗат храмында анын әле шул ук Остаз Сәлимҗанов тәрбияләгән ике терәге, ике талантлы артист—ире Илдар һәм улы Искәндәр Хәйруллиннар эшли. Сез әйткәнчә, театр белән сихерләнгән династия инде бу!

**—Бу династия, ошбу гаилә туунын башында да шул ук Остаз торуын белмисездер әле, мөгаен. Бу турыда миңа Илдар әфәнде үзе болайрак сөйләде: "...Җитмеш өченче ел иде ул. Яшь артист буларак танылып кына килгән чор әле. Җилбәзәгрәк чак... Көннәрдән бер көнне Остазым Марсель Хәкимович Сәлимҗанов, бик чибәр, талантлы яңа студентка кыз барлыгын әйтеп, мине үзем тәмамлаган театр училищесына, имтихан вакытына чакырды. Бардым һәм ...Һәм пешкән алма кебек кып-кызыл битле, бик тә чибәр ул кызны күрдем... Исеме дә Алсу икән җитмәсә!.." Аларның өйләнешү тарихы менә шулай башлана... Хәер, театр дигән олы гаиләнең нигезен династияләр белән ныгытуда Сезнең дә катнашуыгызны ишеткәнем бар. Ә күренекле артист, талантлы**

**режиссер Рәфкать Бикчәнтәев һәм танылган артистка Наилә Гәрәеваларның улы Фәрит Бикчәнтәев белән Люция Хәмитовалар туенда баш кода булуыгызны да беләм. Инде менә династияне дәвам итүче унөч яшьтәге уллары Йосыфны да алты яшеннән бирле "Әлдермештән Әлмәндәр" спектаклендә—Илсур, "Әни килде" спектаклендә Рушан рольләрендә татарлар гына түгел, төрки дөнья тамашачылары да алкышлап килә. Театрны яшәтәчәк мондый күренешләргә сөенеп, Афәрин(!) дими, ни дисең!..**

—Хәтеремдә, 1999 елда Төркиядә "Әлдермештән Әлмәндәр" спектакле зур уныш казангач, Марсель Хәкимович: «Әнә Йосыфтан интервью алыгыз»,—дидем әле андагы журналистларга дип, бик озак горурланып йөрде. Ә династия дигәннән... Әле янарак кына яшь артистларыбыз Гүзәл Шакирова белән Руслан Низамовлар гаилә корды. Бу матур туйда да безгә, театрга диюем, кодалар да, яучылар да булырга туры килде. Әмма, ни кызганыч, театр гаиләләренең әхлакый нигезләре нык-лы булса да, матди яктан ныгытылмаган: хезмәт хаклары бик аз.



*Шамил Закиров һәм Марсель Сәлимҗанов Мәскәүдә, Татарстан республикасы көннәрендә. 1995 ел, июнь.*

**—Бая сез, "Фатыйма Ильская" хатасы, дидегез. Моны да ачыклап үтик әле. Сәхнәдә чагында улының сугыш кырында һәлак булуы турында хәбәр алып та спектакльне өзмәгән, ул кичтәге уены белән тамашачыларны гына түгел, пәрдә артындагы артистларны да тетрәндергән бу легендар ханым турында төрледән-төрле риваятьләр йөри. Берәүләр, шаккатмалы чибәр, артык горур, искиткеч талантлы, дисәләр, икенчеләр исә гел баш рольләрдә генә уйнап узынды, көйсез, үзсүзле, кире, усал иде, диләр. Үзе дә героиняларны уйнаучы Марзия апа Миңлебаеваның, мәсәлән, елый-көлә сөйләгәннәре хәтердә: "Ромео һәм Джульетта" спектаклендә Джульетта ролен без Фатыйма Ильская белән алмашлап уйнадык. Шушы роль белән Мәскәүдә иҗади яшьләр фестивалендә катнашу һәм мактаулы урын яулау бәхетенә ирештем. Ромео ролен ирем Фуат Халитов башкарды. Ул карап туймаслык чибәр иде, кара бәрхет костюмнан... Мин исә алсу крепдешин күлмәктән. Спектакльне караган Гадел Кутуй: "Марзия Миңлебаева белән Фуат Халитов диңгезгә чумдылар, чумдылар да йөзеп чыктылар" дип, безнең уенны диңгез кичү белән тиңләп, мактап зур мәкалә язды. Минем бу унышымны Фатыйма Ильская гомере буе кичерә алмады. Зыяны күп мәртәбәләр тиде... Менә сәхнәдә "Зәңгәр шәл" спектакле бара. Без—абыстайлар—ашка барырга әзерләнәбез. Сәхнәдән чыгар вакыт җитәрәк кенә абыстайларның берсе булып уйнаучы Фатыйма Ильская минем күлмәк итәгемә баса, һәм мин тамашачым алдында бик әздән генә егылмыйча, адәм хурына калмыйча калам. Тагын бер эпизод: "Сәхнәдә "Кыю кызлар" спектакленең премьерасы. Без—Фатыйма Ильская, Галия Булатова һәм мин—өч кыз ролендә "ишек катында" бер егетне сагалыйбыз. Фатыйма Ильская кулында сулы стакан. Егет килеп керү белән ул аның битенә су сибәргә тиеш. Менә егетебез күренә, һәм шул мизгелдә, теге стакандагы су йөземне каплый, күзләремә тула. Тушь белән сөрмәләнгән керфекләремнән битемдә буй-буй эз калдырып, буяулы су ага... Шушы хәлдә дә рольдә кала алуыма хәйраннар калам, Ильскаяның каһкаһәле йөзен шәйләү генә көч биргәндер дип уйлыйм..." Сез әйткән "хата" Марзия ханымның әлеге эпизодларында да чагылыш табамы?**

—Чыннан да, Марзия ханым сүзләре аша да Фатыйма Ильскаяга күпмедер дәрәҗәдә бәя биреп булыр иде. Режиссерларның аны гел баш рольләрдә, гел яшь

кызларны гына уйнатуы анын холкына да нык тәэсир иткән булса кирәк. Хатасымы, бәхетсезлегеме дигәндәй, өлкән яшьтәгеләр рольләрендә уйнарга теләми ул. 70 яше якынлашканда ана зур бүләк—мәшһүр драматург Шәриф Хөсәеновның "Әни килде" драмасындагы Ана ролен тәкъдим итәләр. Әмма Ильская: "Мин авыру карчыкларны уйнамыйм!"—диеп, бөек Ана роленнән баш тарта. Татар театры тарихында рольдән баш тарту кебек хәлнең бүтән булганы юк. Дөрес, гел героиняларны, яшь кызларны гына уйнаган бик чибәр актрисаларның өлкән ханымнар рольләренә күчә алмау, уйный алмау очраклары бар. Мәсәлән, Галия Булатова шундый фаҗига кичерде.

**—Шушындый ук язмышка безнең замандашларыбыздан Наилә ханым Гәрәева да дучар була язды түгелме? "Беренче мәхәббәт" спектаклендә—Рәхилә, "Зөбәйдә—адәм баласы" спектаклендә—Зөбәйдә, "Гүзәлем Әсәл" спектаклендә Әсәл образларын иҗат итеп, тамашачыларны хәйран калдырды да, берара сирәк күренә башлады, ничектер аның рольләре дә тоныклангандай булды. Шөкер, "Шәҗәрә"дә —Сәлимә, "Гаугалы гаилә"дә Меме образлары белән ул янәдән ачылды. Мәскәүдә Щепкин исемендәге Югары театр училищесын тәмамлап кайтучылар арасыннан да шушыңа охшашлы язмыш кичергән актрисалар бар...**

—Щепкинчыларга кагылышлы сүзләрегез белән бигүк килешмәс идем. Бу буын артистлары сәхнәдән төшеп тормады. Нәҗибә Ихсанова, Гөлсем Исәнгулова, Ринат Тажетдинов, Әзһәр Шакиров, Равил Шәрәфиевләр әле бүген дә сәхнә тота.

**—Бу очракта мин сәхнәдә «Миркәй белән Айсылу» спектаклендә -Айсылу, «Хуш, Назлыгөл»дә Назлыгөл, «Кол Гали»дә Энҗе образларында йолдыз булып балкыган Гөлсем Исәнгулова талантының театр тарафыннан тулысынча файдаланылмавын күздә тотып әйтәм.**

—Театр ел дәвамында күп дигәндә дә 3-4 кенә премьера чыгара ала. Һәр яңа спектакль зур чыгымнар сорый. Ә театрның мөмкинлеге чикләнгән. Труппа зур, талантлы артистларыбыз да, шөкер, житәрлек, һәм аларның һәрберсе роль көтеп яши. Билгеле ки, һәр талантны тулысынча файдалану жирлеге юк, һәм бу мөмкин дә түгел. Сезнең сүзгә өстәп, мин әле тагын берничә исемне атый алыр идем. Шуларның берсе—Ходай үзенә тавыш та, кыяфәт тә биргән, чиксез зур талантка ия—Зөлфирә Зарипова. «Отелло»да Дездемонаны, «Мәкер вә мәхәббәт» тә Луизаны, «Кол»да Клеяны, «Гүзәлем Әсәл»дә Хәдичә образларын иҗат итүче, хәзер инде мәрхүмә Шәхсәнәм Әсфәндиярова таланты да театр тарафыннан тулысынча файдаланылмады. Һай, аңардагы нәфислек, гүзәллек, мөлаемлылык, йомшаклык! Сәхнәбезнең кояшы иде инде ул... Минем беренче күргән һәм үземә театр дигән авыру йоктырган спектаклем дә Шәхсәнәм ханым Хәдичәне уйнаган «Гүзәлем Әсәл» булды. Чыңгыз Айтматовның бу әсәрен үзбәк режиссеры Ташхуҗа Ходжаев сәхнәләштергән иде. Ул спектакльдәге составны гына күзаллагыз әле: Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Ринат Тажетдинов, Наилә Гәрәева, Шәүкәт Биктимеров, Галимә Ибраһимовалар! Талантлар букеты!.. Театр дигән гомерлек авыру белән икенче тапкыр мин 1972-1976 елларда Ленинградта мәдәният институты каршындагы аспирантурада укыганда авырдым. Яхшы мәгънәдә, билгеле. Йокыдан уянганда көн саен башымда бер генә уй: бүген театрга барам!.. Анда яшәгән дүрт ел дәвамында дөнья театрлары арасында иң алдынгы саналган, иң абруйлы Товстоногов театры (БДТ) спектакльләренең берсен дә калдырмый карап бардым. Бөтендөнья театр сәнгате белән ныклап таныша башлавым да—шул елларга туры килә. Сахаров, Солженицыннарның тыелган язма әсәрләрен уку илдәге вазгыятьне тирәнтен аңлауга китерде. Мин Камал театрына 1985 елда, демократия җилләре белән бергә килдем, зур өметләр баглап килдем. Һәм мин Ходай тарафыннан бирелгән бу миссиямне—директор вазыйфасын үти башладым. Шөкер, бүгенгәчә үтәп киләм.

**—Хуш, театрның сезнең бу өметләрне аклардай көче бүген ни хәлдә? Труппа турында әйтүем.**

—Марсель Сәлимҗанов зур талантка ия артистлардан торган бай мирас калдырды. Анын шәкертләре: Наилә Гәрәева, Наил Әюпов, Ирек Баһманов, Рузия

Мотыйгуллина, Зөлфирә Зарипова, Фирая Әкбәрова, Әсхәт Хисмәтовлар. Алар ижатына Люция Хәмитова, Илсөя һәм Рамил Төхвәтуллиннар, Илдус Габдрахманов, Ләйсән Рәхимова, Илтөзәр Мөхәммәтгалиев, Радик Бариев, Искәндәр Хәйруллиннар кушылды. Болар да Сәлимжанов шәкертләре. Бу талантлар белән Фәрит Бикчәнтәев әле әллә ниләр эшләр, әллә нинди спектакльләр чыгарып, менә күрерсез!.. Бүген инде сәхнә түренә Фәрит Бикчәнтәевнең үзенекеләр—үз шәкертләре үрмәли. Арабыздан бик иртә киткән актриса, Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисткасы Фирдәвес Хәйруллинаның кызы, Казан мәдәният һәм сәнгать университетының III курс студенткасы Нәфисә, мәсәлән, Назыйм Хикмәтнең «Сыер» исемле шәп пьесасында героиняны уйный. Шушы көннәрдә премьера чыгачак. Әйткәнемчә, Фәрит—театр өчен—күктән төшкән яңа планета кебек. Фәритнең булуы—театрның бәхете инде ул. Бик зәвыклы, үтә тырыш, үтә җаваплы да... Казан мәдәният һәм сәнгать университетында театр факультетында актерлык осталыгы буенча дәресләр бирә, режиссерлар хәзерли. Аның бер кыз, биш егеттән торган режиссерлар группасы быел өченче курста укый... Репетицияләр, спектакльләр эчендә кайнап, Фәритнең төнге унберләрсез театрдан киткәне юк. Әле менә Театр юбилеена Нәкый Исәнбәтнең татарның беренче артистлары тормышына багышланган "Гөлҗамал" әсәре нигезендә, философик мәгънәгә ия, бөтенләй янача яңгыраштa спектакль әзерли. Болар өстенә, күпме фестивальләр, гастрольләр... Быел гына да Мәскәүдә, Алматыда, Уфада, Лондонда, Бакуда булдык.

**—Лондон дигәннән... Сез Марсель Сәлимҗанов турында, ярты гасыр дәвамында милләтнең рухи җанын, телен саклаган бөек кеше, дидегез. Чыннан да, Туфан Миңнуллин пьесалары һәм Марсель Сәлимҗанов куйган спектакльләр инде менә ярты гасыр дәвамында сәхнә тота, сез әйткән вазыйфаны үти. Шекспир иленә бу ике титаник шәхеснең бер спектаклен дә алып чыкмавыгыз гаҗәпкә калдыра.**

—Спектальләр бу гастрольләрне оештыручы Лондон продюсеры тарафыннан сайлап алынды. Ул Казанга килгәч, без аңа сигез спектакль күрсәткән идек. Алар арасында "Әлдермештән Әлмәндәр" дә, "Зәңгәр шәл" дә бар иде. Лондонга кассеталарда спектакльләрнең язмаларын да җибәрдек. Алар "Беренче театр", "Телсез күке", "Тимер борчак" спектакльләрен сайлаганнар. Туфан Миңнуллинның "Әлдермештән Әлмәндәр"е дә барса, бу—театр өчен бик абруйлы булыр иде.

**—Хәтерлим, ул көннәрдә Фәрит Бикчәнтәев: "Бөек Британия иленә бит бу! Җитмәсә, Рамазан аенда!"—дип сөенгән иде. Спектакльләр Лондон тамашачысы тарафыннан ничегрәк кабул ителде соң?**

—Зур сәнгать өчен тел белмәү—киртә була алмый икән. Безнең гастрольләребез бер пәрдәлек "Беренче театр" белән башланып китте. Икенче бүлектә исә бик зәвыклы концерт күрсәттек. Зөлфәт Хәким "Изге җир", "Газиз халкым" дигән үз әсәрләрен җырлаганда, күзәтәм, татарча берни аңламаучы инглиз тамашачылары елап утыра, зал шартлый. Үткен проблема, кайнар проблема күтәрелгән "Телсез күке"не дә бик җылы кабул иттеләр. Кара-каршы сугыш фронтларында катнашучы ике татарның кышкы урманда очрашу, аларның кочаклашып "Әсирләр" җырын җырлау эпизоды—тетрәндерде тамашачыны. Кыскасы, Лондонга бару—безнең театр өчен зур сынау иде. Без аны 100 еллыкка зур бүләк тә, аеруча зур хөрмәт тә итеп кабул иттек. Безнең Камал театры дөнья театрлары арасында да алдынгы икәненә инанып кайттык. Россия театрлары арасында да без иң көчлеләрдән. Фестивальләрдә гел югары урыннар гына яулавыбыз шуны күрсәтә.

**—Диннәребез уртак, телләребез, гореф-гадәтләребез охшаш Бакудан да бик сөенеп, Татарстан белән Әзербайҗан арасына рухи күпер салып кайтуыгызны ишеттем.**

—Татарның беренче театр коллективы—«Сәйяр» труппасы Бакуда 1909 елда үзенең спектакльләрен күрсәтә. Без бу баруыбыз белән егерменче гасыр башында ук башланган рухи бәйләнешләрне егерме беренче гасырда да яңартып, халыклар арасында илче, арадашчы булу миссиясен үтәп кайттык. Опера театрының мең

урынлы залы тамашачылар белән тулып торды. Спектакльләребездән соң да бертөркем тамашачы безне кунакханәбезгә хәтле озатып йөрде. Үзебез дә Театрның тәэсир итү көчен тоеп, аралашулардан хушланып, зур канәгатьләнү хисе кичердек.

Театр бит ул фанатлар гына эшли ала торган, бик түзем, әхлакый чиста кешеләрнең олы бер гаиләсе. Ул сүз, рәсем, җыр, музыка, бию кебек затлы сәнгатьләрнең синтезы.

Сезнең бер очеркыгызда әйтелгәнчә, театр ул тормыш кайтавазы: төнге аһәң, тавышсыз гына үксү һәм җан көлүе дә.

Театр ул үзе бер могҗиза, бер тылсым, җибәрми-ычкындырмый гына, магнит кебек гел үзенә тартып тора. Тамашачыларны да, безне дә!

**—Туксанынчы еллар уртасында Марсель Сәлимҗановка мин: «Сезне нәрсә дулкынландыра һәм нәрсә куркыта?»—дигәч, беләсезме, ул нәрсә дип җавап бирде: «Театр дулкынландыра. Директорымнан аерылудан куркам», диде. Маэстро шулай бәяләгән директорның үзенә дә шундыйрак сорау бирәсем килә: Сезне бүген нәрсәләр борчый?**

—Сөйләшү башында әйткәннәремне кабатлыйм: татар теленең бетүгә юл тотуы, татар мәктәпләренең ябыла торуы бик рәнҗетә, театрның тамашачысыз калу ихтималы нык куркыта. Тел—әхлакның нигезе. Телне саклау—милләтне саклау ул. Президент белән диалогында шагыйрь Равил Фәйзуллин: "Татарча укытуга астыртын саботаж ясаучы мәгариф әһелләре дә юк түгел дип беләм",—дигән иде. ("Казан утлары", быелгы 3 нче сан.) Уйланырлык нәрсәләр бар.

Дәүләт театрын тоту, Академия театрын яшәтү—бик авыр. Шулай да мине өмет яшәтә. Халык яшәсә—театрыбыз да яшәр, Иншалла!

**—Сез искә алган Президент һәм Шагыйрь диалогында Минтимер Шәймиев сүзен Тукай, Җәлил һәм Татар театры исемнәре белән башлый һәм Татар театры белән тәмамлый да. "...Буыннар сәхнә тота. Менә шуңа күрә 100 ел яши дә ул безнең театр, иманым камил, әле 200 ел да, алга таба да яшәр. Аларның киләчәге ышанычлы,"—ди Президентыбыз. Сөйләшүне шушы рухта тәмамлап, журнал һәм аның меңләгән укучылары исеменнән сезне котлыйм: Юбилей бәйрәмнәре мөбарәк булсын!**

—Театрга һәрчак игътибарлы булуыгызга рәхмәт, Рәйсә ханым! Гомумән, Татар театрының 100 еллык юбилей уңае белән барлык газета-журналлар да, радио-телевидение дә безгә ел дәвамында бик зур реклама ясады. Театрга, тамашачыларыбызга булышуыгыз өчен барыгызга да олы рәхмәт! Киләчәктә дә бергә-бергә булыйк!

**Рәйсә ЮСУПОВА** әңгәмәсе

Әзһәр
Шакиров

# ЯЗМЫШ ҺӘМ УЗМЫШ

(АРТИСТ ЯЗМАЛАРЫ)

Артист булгач, миңа кагылышлы бик күп мәзәк хәлләр, гыйбрәтле вакыйгалар булып торды. Шулардан берсен искә аласым килә. 1970 елны академия театры Мәскәүдә бик зур уңыш белән гастрольләрен уздырды. Шул уңай белән безне КПСС Үзәк Комитетының культура бүлегендә кабул иттеләр: театр директоры Рәшидә апа Җиһаншина, баш режиссер Марсель Сәлимҗанов, театрның аксакаллары Габдулла ага Шамуков, Фоат абый Халитов, Фатыйма ханым Ильская, Шәүкәт абый Биктимеров, Наил Дунаев һәм мин идем. Минем өчен моннан да зуррак вакыйганың булуы мөмкин түгел. Театрны 60 елга беренче мәртәбә шундый дәрәҗәле урында кабул итәләр бит. Бу хәл, өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Әхмәтҗанович Табеев янына керү генә түгел, анда да күп кеше үз гомерендә бер мәртәбә керә алмады. Хәзерге вакыт белән чагыштырганда, Президентның кабул итүе белән бер иде, артык булмаса. Керер алдыннан паспортларыбызны, партия билетларын тикшерделәр. Ишек төбендә сакчылар тора, офицер безне иркен бер бүлмәгә кертеп җибәрде. Менә безне кабул итүче ханым, очрашуны ачып: «Иптәшләр, нинди сорауларыгыз, теләкләрегез бар, әйдәгез уртага куеп, ачыктан-ачык сөйләшик»,— диде. Иң элек сүзне Рәшидә апага бирделәр. Ул театрга яңа бина кирәк икәнлеген бик дулкынланып, матур итеп сөйләде. Шуннан соң сүзне Марсельгә бирделәр: ул да мәгънәле итеп, төпле дәлилләр китереп, безнең театрыбыз шул дәрәҗәдә үсте, мөмкин булса, безне чит илләргә гастрольләргә чыгарсагыз иде, дип сүзен тәмамлады. Очрашуыбыз бик күтәренке рухта, күтәргән мәсьәләләребез дә бик зурлар—барыбыз да кайда утырганыбызны бик яхшы аңлыйбыз.



*Ә. Шакиров. 1962 ел.*

Аннары: «Менә хәзер яшь артистны тыңлап карыйк, бәлки аның да сораулары, теләкләре бардыр. Тартынып тормагыз»,—дип, миңа сүз бирделәр. Бераү булса, партия Үзәк Комитетына чакырган һәм яшьләргә шундый зур игътибар биргән өчен чын күңелдән горурланып рәхмәт әйтер иде. Ә мин торып бастым да җанымны газаплап килгән, борчыган сорауларымны сөйли башладым: мин әйтәм, менә инде ун елга якын театрда эшлим, йөз сум хезмәт хакы алам, өстемә кияргә җүнле киемем, гаиләмне ашатырлык акчам юк. Сез ничек оялмыйсыз, урамнан барганда бу кыяфәттә халыктан оялам, без бит партия идеяләрен халыкка җиткерүче театрда хезмәт итәбез. Безнең ничек яшәгәнебезне күрмисезмени? Җитмәсә театр журналында Англиядә яшәүче эшсез артистларны мыскыллап язасыз: янәсе, алар бер айга 480 фунт акча алып яталар. Мин әйтәм, безнең акча белән чагыштырганда, ул 1100 сумга якын туры килә, дим. Юк, тормыш болай бара алмый, үзгәрешләр булырга тиеш, партия идеяләрен халыкка җиткерүче артист ач-ялангач йөрергә тиеш түгел, дип җан ачысы белән сөйләвемнән көчкә тукталдым.

Шунда иптәшләремнең йөзенә карасам, ап-ак булып, бүртенеп, кызарып чыкканнар, берсе дә минем якка башын күтәреп карамый. Мәҗлесебездә бик авыр тынлык

*Дәвамы. Башы журналыбызның 11 нче санында.

урнашты. Житмәсә минем сөйләгәннәремне ике секретарь ханым язып бара икән. Кинәт сул күзем тартыша башлады, авызым әкрен генә кыйшая шикелле, иренем чатнап кипте, телем көрмәкләнә, күзалларым караңгыланып китте. Шунда ике ханым: «Тынычланыгыз, тынычлан»,—дип, алдыма лимонлы чәй, печенье китереп куйдылар. Кая миндә чәй кайгысы! Очрашу беткәч нишләтерләр икән дип, үз-үземә урын таба алмыйм.

Рәшидә апа чыккач:

—Син нәрсә, Шакиров! Партия Үзәк Комитетына килеп, шундый сүзләр сөйләмәсәң ярамый идемени? Син сөйләгәннән үзгәрешләр булыр дип уйлыйсыңмы?—диде.

Мин әйтәм, партия Үзәк Комитетында да сөйләмәгәч, кайда сөйләргә тиеш мин, дим. Марсель Хәкимович авыр сүзләр белән сүкте дә:

—Моннан соң мин сине беркая да алып бармыйм!—диде.

Культура министры белән өлкә комитеты кешесе нәрсә уйлаганнардыр, анысын кем белсен инде. Ярый әле, Аллага шөкер, театрдан куып чыгармадылар. Анысына да рәхмәт яусын. Әмма шушы очрашудан соң сул күзем шактый озак кына тартышып йөрде.

Мин бу вакыйганы ни өчен искә алып яздым соң әле? Чөнки хәзер дә минем жаным туктаусыз җәфалана, өзгәләнә. Кайчан без үзебезнең язмышыбызга аек күз белән карарбыз икән? Без бит бүген бик аз калып барабыз, башка милләтләр безне йотып бетерә бара. Бу дөньяда безгә үзебездән кала һичкем ярдәм итмәячәк, беркемнән дә рәхим-шәфкать көтмик. «Бу татарлардан котылсак, тормышыбыз яхшырачак»,—дип кенә уйлыйлар. Милләт буларак бетсәк, сөенәчәкләр генә. Күктән бәхет төшкәнен көтеп ятмыйк. Әгәр дә исән-сау милләт булып яшисебез килә икән, иң беренче нәүбәттә бер-беребезне хөрмәт итик, бер-беребезнең кадерен белик—җитәр бер-беребезне ашарга! Бердәм булыйк, бердәм булмаганга күрә безне ашап бетергәннәр дә инде. Милләт хакында сөйләгәндә тамактан өстен Рух бар—ата-бабаларыбыз рухы. Иманыбызны, дан-шөһрәтебезне сатмыйк, үзебезне башка милләтләрдән көлдермик!

Бәлки, миңа боларны язарга кирәк тә булмагандыр, әзрәк уңайсызрак килеп чыккан кебек. Әмма нишлисең: җаным түзмәгәч яздым инде.

Һәрхәлдә, артист дигән бөек исем минем өчен әллә кайда—күк йөзендәге мәңге сүнмәс-сүрелмәс йолдыз кебек балкып, нур сибеп тора ул! Бигрәк тә татар артисты. Ни кызганыч: халкы бар—дәүләте юк. Һаман да бер сүз: татар театрының урыс дәүләтендә урыны билгеләнмәгән. Татар театрының мөмкинлеге булса, әгәр аңа акча бирсәләр, аның бүген Мәскәүдә, иртәгә Санкт-Петербургта, берсекөнгә Уфада, Чиләбедә, Екатеринбургта, Самарада, Красноярскида, Новосибирскида... тагын әллә күпме кала, шәһәрләрдә айлар буена тулы залларда тамаша күрсәтергә мөмкинлеге бар лабаса! Урыс дәүләтендә татар театрына ирек бирмиләр. Ә бит татар халкы саны-исәбе белән Россиядә икенче урында. Татар бит эшен эшли, салымын түли, урыс дәүләтенә бөтен тәне, җаны белән хезмәт итә. Шулай булгач, аның үз телендә театр карарга гына да хакы юкмени?! Хәтта Советлар Союзы вакытында да татар театры, урыс театрлары кебек, үзенең тамашачысын канәгатьләндерергә тырыша иде. Ә хәзер нәрсә? Әгәр дә татар академия театры, Мәскәүнең иң зур театрлары кебек, «национальное достояние России» мәртәбәсен алмаса, аның киләчәге аяныч булачак.

Ә шундый дәрәҗә, мәртәбә алмаска безнең хакыбыз юк!

Татар театрына—100 ел. Без Россиядә—миллионнарча. Без моны ялынып сорарга тиешмени? Түгел! Әгәр безне кеше, милләт итеп санасалар, дәүләт, хөкүмәт үзләре бирергә тиешләр.

Мин Г. Камал исемендәге Татар академия театрыннан күптәннән бирле эшлим инде. Шуңа күрә үзебезнең театр турындагы кайбер фикерләремне әйтеп калдырасым килә. Әлбәттә, урыс артисты белән татар артистының аермасы хәтәр зур. Чөнки мөмкинлекләр бүтән. Урыс артисты тели икән бүген—Казанда, иртәгә Рязаньда, Костромада, Ярославльдә, бәхете булган шаттә, Мәскәүдә, Петербургта эшли ала—санап кына да бетерерлек түгел. Татар артистының бер академия театры бар, шундый югарылыктагы ике-өч театр булган шаттә, татар артистларына да кояш чыгар иде. Урысларның киносы белән телевидениесе турында әйткән дә юк инде. Татарның киносы белән телевидениесе дә юк!

Сез: «Безнең телевидение бар бит»,—дип әйтерсез. Ләкин ул чын татар

телевидениесе түгел. Безгә килгән кунакларга телевидение тапшыруларын күрсәтергә оят. Алар еш кына аптырап: «Нишләп сез үз телегездә телевидениедә сөйләшмисез?»— диләр. Җавабыбыз бар, әлбәттә: «Без түгел, безнең җитәкчеләребез шундый кешеләр булып чыктылар: үзләренең милләтеннән, теленнән оялалар».

Мин инде «Театр—ул милләтнең йөзен билгели» дип язып чыккан идем. Чөнки милләт бар икән, аның театры булырга тиеш, ансыз милләт юк. Урыслашып беткән шәһре Казанда татар халкы үзен милләт итеп, татар итеп театрда гына хис итә. Миллионлаган, таралып яткан милләттәшләребезне берләштерү, милли аңын уяту театрда күпкә җиңелрәк. Мин шуның өчен генә булса да татар театрларын саклап калыр идем. Телисезме, теләмисезме, татар халкының иң талантлы балалары татар театрына җыйналган, чөнки халкыбызның үзенә дә театр «җене» кагылган. Мин моны болай гына—сүз өчен генә әйтмим, мин моны үзем күрдем. Әгәр дә безнең әдәбиятыбыз, театрыбыз, моңыбыз булмаса, без төрки халыклар арасында мондый дәрәҗәгә ирешмәс идек. Татар театрына карап, төрки халыклар бүген дә үз-үзенә үрнәк ала.

1957 елның Мәскәүдәге вакыйгалары әле дә күз алдымда тора. Татар театры төрки халыклардан үзбәк, казакъ, кыргыз, әзәрбәйҗан, төрекмән театрларыннан бер дә ким түгел, бәлки өстен икәнлеген күрсәтте. Болар бит безгә караганда бер башка өстенрәк иделәр, чөнки үзләренә күрә дәүләтләре бар иде. Ягъни Союзный республикалар иделәр. Ә безнең халкыбыз бар—дәүләтебез юк, җиребез бар, ә илебез юк. Шушындый хәлдә дә безнең театрыбыз Мәскәүне шаулатты. Советлар Союзында татар театры барлыгын бөтен урыс халкына, хөкүмәтенә, җәмәгатьчелегенә, җитәкчеләренә күрсәтте. (Шул исәптән Минзәлә театры.) Хәтта Мәскәүдә безгә татар театры ачарга рөхсәт биргәннәр иде. Безнең җитәкчеләр генә (ачтырмадылар; янәсе, бөтен талантлы артистлар Мәскәүгә китеп бетәр, Казанда татар театрында уйнарга артист калмас, дип өректеләр, сурыктылар). Бүләкнең дә иң зурын, кадерлесен бирделәр: Ленин ордены. Мондый бүләк теләсә кемгә тәтемәде ул.

Минем күз алдымда—татар халкының бөек артисты Хәлил Әбҗәлилов. Шигърияттә Г. Тукай, музыкада С. Сәйдәшев булса, театрда мин күргән дан-шөһрәтле артистлардан Хәлил абый Әбҗәлилов иде. Аны дөньяда бөек артистлар белән тиңләргә мөмкин: грузин Хорава, осетин Тхапсаев, украин Бучма, урысның иң бөек артистлары... Менә ул шундыйлардан һич тә ким түгел иде. Менә кем ул—Хәлил Әбҗәлилев! Бүген «Хуҗа Насретдин»да—Хуҗа, иртәгә «Ташкыннар»да—Биктимер, берсекөнгә «Король Лир»да—Король Лир. Нинди камиллеккә ирешкән артист. Мондый иҗатны күпме генә теләсәң дә кабатлый алмыйсың инде ул. Комедиядә, драмада да, трагедиядә мондый бөеклеккә ирешеп уйнаган артистлар бөтен дөньяда бармак белән генә санарлык. Моны мин генә әйтмим, барча татар, рус тәнкыйтьчеләре язды. Аның театр сәнгатенә үз гомерен багышлаганлыгын шул заманның гакыллы шәхесләре шәрехләп әйтеп калдырган. Мондый артистларыбыз булганлыгына ничек горурланмыйсың ди инде!

Чыннан да, татар академия театры теләсә нинди урыс театры белән тиңләшерлек, тиң иде. Мәңге кабатланмас якты мизгелләр. Йөз ел буена татар дөньясыннан берәмтекләп җыйналган бәһа куеп бетермәслек талантлар. Менә хәзер—бүген генә мин аларның чын бәясен аңлыйм. Татар акылы—төштән соң.

Без Мәскәүдән кайтып эшли башлаганда театр шинеп калган гөлне хәтерләтә иде. Күп вакыт шулай була: театр бер күтәрелә, бер төшә. Алынасы дәрәҗәле исемнәр алынып беткән, талантлы өлкәннәребезнең бер өлешен пенсиягә җибәргәннәр, Мәскәүдән ГИТИСны бетереп кайткан кайбер артистларны «профнегодный» дип куып чыгарганнар, баш режиссер Ширияздан Сарымсаковны эшеннән алганнар. Труппада инндидер таркаулык сизелә, тамашага халык аз йөри. Өлкәнәеп беткән апалар—яшь кызлар булып, өлкән абзыйлар яшь егетләр булып уйныйлар.

Ә безнең торырга урыныбыз юк, хезмәт хакыбыз 70 сум. Шуның алты сумын «бездетность» дигәнгә алып калалар. Бар киләчәк өметсезлектән генә гыйбарәт.

Моңа карамастан, без театрны шул хәтле дә ярата идек ки, теләсә нинди авырлыкка түзәргә, чыдарга да риза-бәхил кебек идек. Әлбәттә, гадәти кеше моңа түзеп тора алмый, үзеннән-үзе каядыр китеп котылырга мәҗбүр була. Безгә: «Шундый хезмәт хакына кем эшләсен инде? Ташла бу эшеңне, җүнлерәген тап. Син бит аңгыра бәрән түгел»,—дип әйтә торганнар иде.

Чыннан да, минем белән бергә укыган иптәшләрем Хәмзә Арсланов, Миргалим Харисов, Роберт Батуллин, Туфан Миңнуллин, Әхтәм Зарипов театрдан китеп баргач, теләсә нинди эштә дә үзләрен талантлы иҗатчылар итеп күрсәттеләр. Батулла белән Туфан халкыбызның кадерле, хөрмәтле язучылары—драматурглары буларак танылдылар; Әхтәм Зарипов телевидениедә баш режиссер сыйфатында бик күп еллар буена чын мәгънәсендә иҗтиһад итте; Хәмзә Арсланов—дәүләт эшендә, Миргалим Харисов гәҗиттә эшләде. Уйлап кына кара: синең белән бергә укыган иптәшләрең әллә нинди дәрәҗәләргә ирешеп бетсеннәр әле. Биш еллык гомерләре Мәскәүдә укып бушка узмаган бит! Иң куанычлысы шул: театрдан киттек дип язмышлары фаҗигале тәмамланмады. Кызлардан Иркә Сакаева, Клара Газизова кебек кешелекле, миһербанлы, сабакташларына һәрчак хөрмәт белән караган якты телевидение «йолдыз»ларын сагынып ничек искә алмыйсың ди инде? Моны мин ни өчен әйтәм соң? Безнең курска әнә нинди талантлы татар балалар җыйналган булган икән бит!

Театрда эшләү үзенә күрә бер бәхетсезлектер дә әле ул. Чөнки һәр көнне тамашачы алдына чыгып сынау бирәсең. Безнең укытучыбыз Михаил Николаевич Гладков көлеп: «Театрда 30 ел эшләве генә авыр, аннан соң җиңеләя ул»,—дип әйтә иде.

Миңа калса, утыз елдан соң тагын да авыррак. Татар сәхнәсенә Дамир Хәйруллин (урыны оҗмахта булсын), Наил Дунаев, Ринат Таҗетдинов, Равил Шәрәфиев килеп керүен, хатын-кызлардан Флера Хәмитова, Мәсхүдә Хәйруллина, Фирдәвес Әхтәмова, Гөлсем Исәнгулова, Нәҗибә Ихсанованың сәхнәгә беренче аяк басуы театрыбызга ямь өстәде.

Шуның өстенә, театрга баш режиссер булып Марсель Сәлимҗановның килүе академия театрына саф җилләр иңдереп җибәрде.

Марсельнең яшь булуы, җаны-тәне белән татар театрының башка халыклар театрларыннан ким түгеллеген раслау, дәлилләү теләге, беренчелекне бервакытта да, беркемгә дә бирергә теләмәве безнең труппаны югары дәрәҗәдәге һөнәри рәвештә тотты. Кем генә килмәсен, нинди тәнкыйтьчеләр сүз әйтмәсен,—һәммәсе бер авыздан дигәндәй театрның талантлы артистларга ифрат бай икәнлеген, теләсә нинди урыс театрлары белән дә янәшә торырга хакы барлыгын билгеләп үтәләр иде. Мәскәүдә, Ленинградта, Уфада гастрольләр безгә һәрвакыт үзенә күрә бер имтихан булды. Һәрхәлдә, кайда гына уйнасак та, һәрбер спектаклебез татар тамашачысының күңелендә гомерлек истәлек булып калгандыр.



*М. Сәлимҗанов. 1965 ел.*

Миңа шундый сәләткә ия артистлар арасында үзеңә урын табуы әйтеп бетергесез авыр булганга күрә, сиңа үзеңнең нәкъ бу театрныкы икәнлегеңне исбатларга кирәк инде. Сүз дә юк, режиссерлар сине хөрмәт итәргә, сиңа ышанырга тиеш. Ә инде иҗатташларыңның сине талантлы актер сыйфатында кабул итүе үзе бер бәхеттер инде ул.

Режиссерлар һәрвакыт тыңлаучан, сабыр, үзенең кем икәнлеген күрсәтергә тырышмаган, буйсынган артистларны үз итүчән. Артист үзенең нәрсәгә сәләтле булуы белән режиссерның теңкәсенә тимәскә тиеш. Шуңа күрә акыллы артистлар бер нәрсә дә белмәгән, бер нәрсә дә күрмәгән, ишетмәгән, шундый да беркатлы, гади, режиссер ни кушса, шуны үтәүче, аның әйткәне берен һәрвакыт моны талант иясе әйтте дип кабул итүче ролен уйныйлар. Вакыты-вакыты белән тәмам аптырап каласың; чыннан да, бу артист ышанып, ихластан шулай эшлиме ул? Әллә юри шулай кылана гынамы? Театрда моның мисаллары бик күп. Менә шундый артистлар белән режиссер рәхәтләнеп эшли, үзенә тәм таба, ләззәт ала. Минем кебек, башта куеласы пьесаны сүгүче, аннан бирелгән рольдән канәгать булмаучы, режиссер белән юкка-барга бәхәсләшүче, фикере дә барлыгын белдерүче артист белән теге-бу режиссерның җәфаланып торасы килми.

Шуңа күрә эш башлаганда ук мине сүгеп ташлыйлар иде: янәсе, юк-бар белән

теңкәгә тимәсен, үз фикере үзендә калсын.

Мин дә режиссерларны тыңларга өйрәнгән идем инде. Ләкин соң булды, файдасы тимәде. Артист хезмәте—иң җайсыз хезмәт. Чөнки ул бөтенесенә буйсынырга тиеш. Шуңа күрә күп нәрсә синең иҗатыңнан, талантыңнан гына тормый, бу нәрсә синең холык-фигылеңнән, кешеләр белән бергә эшли белүеңнән, шушы коллективта үз урыныңны таба белүеңнән дә килә. Турысын әйткәндә, син өйрәтелгән эт кебек буйсына белергә тиешсең—театр эше шуңа корылган. Мин-минлегеңне, үз-үзеңне җиңә алмыйсың икән, сине бик күңелсез язмыш көтә. Театрга килү белән шушыны яхшы аңлаган кеше алга ыргыла. Аны бөтен кеше ярата, хөрмәт итә. Безнең эш кумәк хезмәт шул.

Син ялгызың гына бернишли алмыйсың. Бу режиссерга да, артистка да тигез кагыла. Үзең белән бергә эшләгән режиссер турында гадел фикер әйтү кыен, чөнки зур рольләр биргән режиссер синең иң кадерле кешең санала. Сиңа рольләр бирмәгәне, никадәр генә талантлы булса да,—сиңа беркем дә түгел. Әмма режиссерларны да аңларга кирәк: алар да иҗат кешеләре бит. Без артистлар тарафыннан аларның да җылы сүз ишетәсе килә. Бигрәк тә премьера көннәрендә. Артист кеше, режиссерга бәйле булганга күрә, күп вакыт аңа дөресен әйтә алмый, курка. Спектакль куелуның беренче көнендә син дөресен әйтеп кара: ошамады дисәң, гомергә яңа роль ала алмыйсың. Мин моны шактый сынаган кеше. Безнең эштә: «Син миңа дус, ләкин «Истина дороже»,—дип әйтеп булмый. Моңа җан, йөрәк, батырлык кирәк.

Ә вакыт уза торгач, дөреслек барыбер калкып чыга анысы.

Дөньяда үз эшен шулкадәр яраткан бүтән кешене мин күз алдыма китерә алмыйм. Бу нәрсә фәкать артистларга гына хастыр, мөгаен. Аңа берни кирәк түгел. Син аңа зур, көчле, тамашачыларны шаккатырырлык рольләр генә бир! Ул шуның хакына җанын, тормышын сатарга риза.

Шуңа күрә сез безне ничек бар, шулай кабул итегез: фәрештәне бөтен кеше ярата аны. Миңа: «Сабыр булырга кирәк»,—дип әйтәләр иде әйтүен, ләкин гомер кыска. Гомерең буена сабыр булып кына булмый шул, эшлисе килә.

Ә режиссерлар турында шуны гына әйтә алам: ул талантлы артистлар тәрбияли алганмы? Әгәр дә ул талантлы артистлар үстерә ала икән, артист өчен аннан да бөек режиссер юк.

Һичсүзсез, мин шәхсән эшләргә туры килгән режиссерларга үтә бурычлы, рәхмәтлемен.

Театрдагы беренче эшем Шамил абый Шаһгали пьесасы нигезендә куелган «Без аерылышабыз» спектаклендәге башкорт егете Котлыбай образы иде. Хәзер мена әлеге рольдә уйнаганымны искә төшергәндә аның фәкать башкорт егете икәнлеге генә исемдә калган инде. Үземчә, Котлыбайны Урал тауларында үсеп җитлеккән кеше итеп, күтәренкерәк рухта, ягъни татарлардан бераз аерылыбрак торсын диебрәк күрсәтергә тырышкан идем. Шарияздан абый Сарымсаков: «Син аны гап-гади итеп уйна»,—дип, мине бөтенләй икенче юнәлешкә этәреп җибәрде. Мин теләгән, үземчә аңлаган чын башкортны уйный алмыйча калдым. Бәлки, Шарияздан абый хаклы да булгандыр. Миңа исә үземне сәхнәдә тырышып-тырышып иркен, табигый тотарга өйрәнергә кирәк иде. Бу—артист өчен иң кирәкле беренче адымнарның берседер. Ансыз тиз генә үсүе, танылуы һич мөмкин түгел. Шушы эшне сикереп узып, үземчә җәһәт кенә талантлы артистлар рәтенә керәсем килде, ләкин һәр эштә, һәр нәрсәдә эзлеклелек дигән нәрсә бар бит. Син шуларга өйрәнмичә торып, киләчәктә рольне ничек итеп эшләргә кирәк икәнен белә алмыйсың. Сәхнәдә беренче мәртәбә Вәкил абый Закиров, Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Шәүкәт абый Биктимеров, Ибраһим абый Гафуровның ничек уйнаганнарын күреп, үземә шактый сабак алдым. Миңа иң кызыгы Шарияздан абый Сарымсаков булды. Ул рольләрне артистларга үзе уйнап күрсәтә: шуннан тәм таба, ләззәт ала, рәхәтләнеп көлә, җитмәсә, рольнең иң тәэсирле, йә иң кызык җирен уйнап күрсәтә. Моннан соң артистка уйнарга бернәрсә дә калмый шикелле.

Мин шундый күренешне күргәч, шаккаттып, аптырап карап тора идем, артистлар миңа килеп: «Ул күрсәткәнчә уйный күрмә тагын, харап буласың»,—дип кисәтеп китәләр иде.

Хәзер инде мин: Шарияздан абый гомере буена үзен бөек артист дип санаган,

шуны исбат итәр өчен уйнап күрсәтә торган булган, дип уйлыйм.

Ул мине ошатты, ахрысы: миңа бер-бер артлы зур-зур рольләр бирде, рәхмәт яусын инде аңа.

Шулай бервакытны Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» трагедиясе буенча куелган спектакльдә үзе белән бергә ул миңа Дәрвиш ролен бирде. Әлбәттә, ул үзен трагик актер итеп күрсәтергә теләде, үзеннән башка әлеге образны гәүдәләндерерлек артист юк дип исбатларга тырышты. Күрегез: нинди кабатланмас артист бит ул Шириаздан Сарымсаков! Сез аны белми идегез, хәзер менә күрегез инде!

Нишләптер артистлар да, тәнкыйтьчеләр дә аның Дәрвишен үзе күткән дәрәҗәдә кабул итеп җиткермәде. Гәрчә бу спектакль искиткеч көчле, матур, зәвык белән эшләнгән иде, тамаша заллары һәрвакыт тулы булды.

Берзаманны мин Шириаздан абыйга:

—Син бу рольдә уйнама инде, Шириаздан абый, миңа гына калдыр,—дидем.—Җитмәсә минем киемнәремне дә киясең икән.

Шириаздан абыйның миңа карап көлеп торганы әле дә исемдә. Беләм, ул: «Мин шушы малайга роль бирдем, ә хәзер ул мине уйнатырга теләми!»—дип уйлады инде. Хәерчегә якты чырай күрсәтсәң, ямаулык сорый, диләр ич. Мин дә менә шундыйрак бер оятсыз булдым да куйдым. Үзем егерме биш яшьлек, эшли башлавыма нибарысы тулар-тулмас өч кенә ел. Инде менә үз остазымның ролен тартып алырга маташам. Чөнки артистлар килеп, минем уйнавымны бик мактыйлар иде шул.

Фәкать соңыннан гына аңлап алдым: Шириаздан абыйга үч итеп, юри генә котыртып әйткәннәр икән. Режиссер булып күрсәтү бер эш, ә сәхнәдә спектакльнең башыннан ахырына кадәр уйнап чыгуның бөтенләй бүтән нәрсә икәнлеген мин шунда аңладым.

Сүз дә юк, Шириаздан абый Сарымсаков театрыбызның иң кадерле режиссерларыннан берсе иде ул. Бик кызганыч, иң талантлы, остаз булып өлгергәч, ул 1966 елны театрдан китәргә мәҗбүр булды, шуңа дучар ителде. Әгәр ул театрда эшләсә, минем язмышым бөтенләй икенче төрле булыр иде. Минем шуны аңларлык та башым булмаган шул. Әгәренки без бердәм булып, аны яклап чыксак, бәлки ул театрдан китмәс тә иде. Аны спектакльләр куярга соңыннан да чакырып алырга була иде, вә ләкин киң күңеллелек җитмәгән шул—чып-чын татарлар булып калдык.



*Ә. Шакиров «Дәрвиш» ролендә. 1965 ел.*

Ул исә гомере буена театр белән кызыксынды, вафат булганына кадәр гел безнең белән аралашып торды. Театрга, артистларга үпкә-сапкасын һич белдермәде, чөнки холык-табигате җәһәтеннән горур кеше иде. Театрыбыз, артистларыбыз турында телевидениедән, радиодан искиткеч кызыклы, акыллы, мәгънәви яктан хәтергә сеңеп калырдай истәлекләрен, хатирәләрен сөйләп, яздырып калдырды. Салих абый Сәйдәшев турында беренче кинофильмны ул эшләде. Татар театр сәнгатендәге беренче профессор нәкъ менә ул булды да.

Тормышы нихәтле генә фаҗигале булмасын, Шириаздан абый һичкайчан югалып, сынып кала торган кешеләр затыннан түгел иде. Үзенең укучылары Наил Әюповны, Хәлим Җәләйне иң якын балаларыдай күреп, һәрвакыт тормышлары, иҗатлары белән ихлас кызыксынып, белешеп торды. Мондый бөек кешене ничек хөрмәт белән сагынып искә алмыйсың?

Режиссер Марсель Сәлимҗанов белән 40 елга якын бергә эшләгәнгә арабызда төрле хәлләр килеп чыккалый иде. Гаиләдә бергә-бергә яшәгәндә һаман ал да гөл булып тормый бит, «бер болганмый—су да тонмый, болганмый булмый-булмый». Беренче эшем Хәй абый Вахитның «Соңгы хат» пьесасы буенча куелган спектакльдә Зөфәр роле иде. Ул минем өчен бик зур яңалык иде дип әйтә алмыйм, ләкин Марсельнең баш режиссер вазифасында театрда куйган беренче спектакле шул иде. Ул үзенең эшли белә алуын шундый зур югарылыкта күрсәтте ки, барыбызның да аның белән яңадан эшләргә язсын иде дигән теләкләребез минем күңелемдә тирәнтен сеңеп калган. Барча артистлар «режиссер икән, шундый булсын, үз эшенә Марсель

кебек әзерләнеп килсен» дип аны бик мактадылар. Без бит әйтәбез: «Менә ул чын профессиональ режиссер, артистлар белән эшли белә».

Эш дәверендә ул минем белән якынаеп китте, без дуслар дәрәҗәсендә идек. Ул миңа бер-бер артлы рольләр бирә башлады. Бервакытны ул миңа:

—Мин Празат белән бергәләп Нәкый Исәнбәтнең «Спартагын» куярга уйлыйм. Әзерлән, Спартакны син уйнарсың,—диде.

Шатлыгымнан нишләргә дә белмим, нинди рәхмәт сүзләре әйтсәм дә, аңлатып бирә алмам шикелле иде. Ике «ярты»ны кесәмә тыгып, янына кердем.

—Иртәгә үк әзерләнә башлыйм. Шакировның Спартакны нинди итеп уйнаганын күрерсең,—дидем.

Шуннан соң көне-төне дигәндәй шул хакта гына хыялланып, үз «өстемдә» эшләргә керештем. Ягъни физик күнегүләр ясыйм, әйткәнемне сәхнәдән тамашачыга ап-ачык «күренерлек» хәлгә җиткерергә тырышам. Менә карагыз, күрегез: гладиатор нинди була, янәмәсе. Кайвакыт төнлә кайбер җөмләләрне, гыйбарәләрне дә кычкырып-кычкырып куйгалыйм, ятлыйм. Мине белгән артистлар минем ничек роль өстендә эшләгәнемне беләләр.



*Ш. Сарымсаков. 1966 ел.*

Менә бер ай үтте, ике ай, куярга яңа пьесалар алдылар,—ә «Спартак» юк та юк! Түзмәдем:

—Марсель Хәкимович, «Спартак»ны киләсе сезонда куясызмыни?—дидем.

—Юк, мин аннан баш тарттым. Празат белән килешә алмадык.

—Нәрсәгә монда Празат? Син бит миңа сүз бирдең: куям дип!

Ул минем хәлемне аңлады бугай, һичбер сүз әйтмичә, кулын селкеп китеп барды. Мин ап-ак булып катып калдым. Шуннан соң ни булганлыгын күз алдыгызга китерәсездер. Нишләп йөргәнемне, театрга, Марсельгә булган мөнәсәбәтемне әйтеп, язып тору кирәкмидер. Күңелемдәге, йөрәгемдәге бөтен өметләрем чәлпәрәмә килде.

Байтак гомер өметсезлеккә бирелеп йөрдем. Мин бит Спартакны уйнап, үземнең нинди артист икәнемне күрсәтермен дип уйлаган идем. Юк шул, язмагач, берни эшләп тә булмый. Тормышта син бертөрле уйлыйсың да, ә киресе килеп чыга.

Мин моны ни өчен язам соң әле? Эшләнгән шактый эшләр онытылдылар инде, ә менә эшли алмаганы шулай күңелемдә тора да тора бирә. Мин театрның күп эшләрен кабул итеп бетерми идем. Без чит кешенең хезмәтенә бик зур таләп, дәгъва белдерәбез. Үзебезнең эшебезгә генә, начар килеп чыккан шәттә, «пьеса начар иде» яки «рольне эшләргә режиссер ярдәм итмәде» дип, үзебезне һәрвакыт юатабыз. Ә чынлыкта исә һәммәсе барыбер артистка гына кайтып кала. Бер сүз белән әйткәндә, әтәч бик яхшы кычкыра, ә менә йомырканы барыбер тавык сала. Уильям Шекспирның «Ричард III» трагедиясен театрыбызда куялар икән, шуның өчен Уфадагы башкорт театрыннан Илшат Йомаголовны чакыралар икән дигән хәбәр таралгач, Марсельгә хәйран үпкәләп йөргән идем. Ул килүен-килде, ләкин Марсель «Ричард III» не куймады. Ул гына да түгел, татар театрында Илшат агайның язмышы бик күңелсез бетә язды.

Мин нишләп әлеге «Спартак»ны, «Ричард»ны искә төшердем соң? Театрда мондый пьесаларны уйнарлык артист бармы? Шекспирны, Гогольне, Чеховны куярлык режиссер бармы театрда? Әллә бу драматурглар әсәрләрен хәзер телевизордан үз телләрендә карау да җитәме? Нинди «күзлектән» карыйсың бит! Әгәр шул әсәрләрдәге рольләрне уйнарлык артист, сәхнәгә куярлык режиссер булса? Нигә академия театрының данын күтәрмәскә. Классик пьесаларда уйнау артистларга зур бер мәктәп ләбаса. Бар бит сәнгатьтә шундый биек, якты маяклар: алар синең бөтен гомереңне яктыртып тора.

Әлбәттә, милли театрда, аеруча татар театрында татар халкы язмышы, дөньясы, музыкасы, теле—бар рухы яңгырап торырга тиеш! Шушы нәрсә юк икән, татар театрының киләге дә шул хәтле генә.

*Ахыры бар*

# ТАТАР КИТАБЫНЫҢ АЛТЫН САНДЫГЫ

Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителгән ел буларак, 2006 ел олуг юбилейларга бай булды. Татар әдәбиятының алтын сандыгы—Китап палатасы оештырылуга да быел 80 ел тулды.

Китап палатасы дигән оешма барын мин 1971 елда ишеттем. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаган көннәрем иде. Казан каласында татар мәктәпләрен бармак белән генә санарлык булганга, эшкә урнашу мөмкинлеге юк дәрәҗәсендә. Укытучым Фуат абый Ганиев Китап палатасына барып карарга киңәш бирде. Җәйге челләдә Татарстан дәүләт музее ишегалдында зур, якты бина эзләп, шактый кангырып йөрдем. Мин эзләгән бина музейның бер почмагында урнашкан булуын күз алдына да китермәгән идем. Музейны саклаучы этләр өрүеннән сагаеп, коридордагы ишекне әкрен генә шакыдым. Ачык йөз, тәмле сүз белән Китап палатасының ул вакыттагы директоры Әнисә апа Хисамова каршы алды.

Палатадагы хезмәткәрләр «Матбугат елъязмасы»н эшләү белән мәшгуль иде. Алар яшь белгечне, ягъни мине, бик шатланып үз араларына кабул иттеләр, бер гаилә әгъзалары кебек тату һәм бердәм эшли башладык.

Ул көннәргә инде 35 ел үтеп тә киткән. Бүгенгедәй хәтеремдә—мине эшкә өйрәтүчеләр Әнисә апа Хисамова, Фәтхия апа Сабитова, библиограф Мәрьям апа Искәндәрова, Китап палатасының җыештыручысы (аны алай дип әйтергә тел дә әйләнми, чөнки ул безгә әнкәбез кебек иде) Сафия апа Ильясова. Китап палатасында күп еллар тырышып хезмәт куйган библиографлар Асия Гомәрова, Анастасия Мәхмүтова, Фәрдия Җиһаншина, Сәвия Касыймова, архив мөдире Раушания Сафина, яшьрәк буын вәкилләреннән Ләйсән Переведенцева, Резедә Гамбәрова исемнәрен әйтеп үтмичә мөмкин түгел. Безнең хәлне белергә элекке директорыбыз Әхмәт ага Булатов, Мәскәүдә аспирантурада укучы Татьяна Дунаева килә иде, күңел иркен булгач, җыйнак кына бүлмәгә барыбыз да сыйдык.

Остазыбыз, киңәшчебез, татар китабы тарихын өйрәнүгә бөтен гомерен багышлаган олуг галим, Китап палатасының якын дусты, академик Әбрар ага Кәримуллин белән булган кызыклы һәм гыйбрәтле әңгәмәләр сагынып сөйләргә генә калды.

Газета-журнал төпләмәләренең еллар үтү белән саргайган битләреннән материаллар эзләүче аспирантлар, студентлар, фән кандидатлары да безнең белән бер бүлмәдә утырып эшләде.

Язылачак әсәрләренә кирәсе теге яки бу мәгълүматны тәгаенләү өчен әдипләребез Мирсәй ага Әмир, Хәсән Сарьян, Локман Бадыйкшан, матбугат тарихын өйрәнүче Альберт Айнетдинов, тарихчы Хәтмулла Заһитов, Абдулла Алиш иҗатын тирәнтен өйрәнүче, аның туганы—мөгаллимә Илсөяр апа Сәнкишева, шагыйрьләр Роберт Әхмәтҗанов, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Фаил Шәфигуллин—барысы да Китап палатасы фондындагы материаллардан файдаланган шәхесләр. Ул чорда елына 300-400 укучы (эзләнүче) кабул итә идек. Аннан тыш Татарстан Өлкә Комитетына, Мәдәният министрлыгына, Татарстан Язучылар берлегенә күпсанлы язма белешмәләр үтәү дисеңме... Саный китсәң, күп иде алар.

Музей бинасында өч ел утырганнан соң, директорыбыз Әнисә апа Хисамова безнең оешманың әһәмиятен, аның күпкырлы эшчәнлеген айлар, еллар буе йөреп түрәләргә исбатлавы нәтиҗәсез калмады. 1974 елның сентябрендә, Китап палатасына Бауман урамындагы, барлык каләм әһелләренең туган өе кебек, тарихи Матбугат йортына күчү насыйп булды. Ул чактагы шатлануыбызны күрсәгез... Ишек алдында бер почмактан шәһәр үзәгендәге тарихи бинага күчү безнең өчен әкияти

хыялыбызның тормышка ашуы булды, ләкин архивыбызның яртысы яңа бинага сыймады, музей эчендә калды һәм бүгенге көндә дә шунда «саклана».

Казан каласында Китап палатасы дигән оешма барлыгын һәм аның эшчәнлеге нидән гыйбарәт икәнен белмәүчеләр бүгенге көндә дә аз түгел. Безгә теге яки бу китапны сатып алырга теләүчеләр мөрәҗәгать итә, чөнки безне китап кибете дип уйлыйлар, андыйларга безнең сәүдә оешмасы түгеллегебезне түземлек белән аңлатырга туры килә. Кайберәүләр исә: «Нәрсә, сез анда палатада «авыру» китапларны дәвалыйсызмы әллә?»—дип шаярталар. «Китап келәте» дип атаучылар да очраштыра. Китап палатасы—халкыбызның аңын һәм белемен, хәтерен, мәдәни байлыгын туплаган кыйммәтле хәзинә сарае икәнлеген зыялылар, галимнәр һәм әдипләр, укымышлы кешеләр, шулай ук бу оешмага йомышы төшкәннәр генә аңлый.

Татарстан Республикасы Халык Комиссарлары Советының 1926 елның 21 декабрь карары белән Татарстан АССРда, Идел буе автономияле республикалары арасында беренче булып, Китап палатасы оештырыла. Соңрак андый палаталар Башкортстанда һәм Чувашиядә дә ачыла. Китап палатасы төзү фикерен Татарстан Мәгариф халык комиссариаты коллегиясе секретаре, доцент Рифкать Таһиров күтәреп чыга. Язучы Галимҗан Ибраһимов житәкчелегендәге Академүзәк моны хуплый. Китап палатасы иң башта нәкъ менә шул гыйльми тикшеренү үзәге каршындагы фәнни китапханә составына кергән. Республика Халык Комиссарлары Советының икенче бер карары нигезендә Татарстан территориясендәге барлык типографияләр үзләрендә басылган һәр төр продукциядән Китап палатасына бушлай мәҗбүри нөсхәләр җибәрә башлыйлар. Шулай ук СССРдагы башка төрки һәм шәрык телләрендәге әдәбиятны туплау да йөкләнә. Моннан тыш палата Татарстаннан читтә татар телендә чыккан басмаларны да алмашу тәртибендә яки РСФСР Үзәк китап палатасы аша алып тора. 1929 елда Мулланур Вахитов исемендәге үзәк Көнчыгыш китапханә-музее кушылу нәтиҗәсендә, палатаның фонды үткән еллардагы басмаларга да байый.

Китап палатасы оешкач та аның беренче директоры итеп 1930 нчы елларда мәдәният өлкәсенә зур өлеш керткән, зыялы шәхес Гакыйль Ашмасов билгеләнә. Палата, оештырылуының беренче көннәреннән башлап, республикада чыга торган китаплар турында библиография төзү эшенә дә керешә. 1929 елда Суфия Таһирова тарафыннан төзелгән «Гыйльми библиография. 1925 елда басылып чыккан китаплар» күрсәткече дөнья күрә, ә 1930 елдан башлап квартал саен «Матбугат елъязмасы» чыга башлый. Бу күрсәткечкә Татарстанда басылып чыккан барлык китап, газета, журналлар теркәлә. Ләкин елъязманың өч кенә саны чыгып кала, чөнки ул вакытта төрле ведомстволарга буйсынган китапханә, библиография оешмаларын берләштерү башлана. Китап палатасы үзенең мөстәкыйльлеген югалта һәм Казан дәүләт университеты китапханәсенең бер бүлеге булып кына кала. Палата архивында булган, 1929 елга кадәр нәшер ителгән гарәп язулы китаплар, газета һәм журналлар фәнни китапханәнең гомуми фондына күчерелә.

1938 елда Китап палатасы янадан мөстәкыйль оешма булып эшли башлый, елъязмалар чыгару жайга салына. Ул вакытта директор вазыйфаларын Шәмсеруй Минеева башкара.

Бөек Ватан сугышы елларында, искиткеч авыр шартларда да, Китап палатасы туктамыйча эшләвен дәвам итә. Анарчы Мәскәүдә Дәүләт тарих музееның нумизматика бүлегендә фәнни хезмәткәр булып эшләгән Әхмәт ага Булатов палатага директор итеп билгеләнә һәм әлеге хезмәткә 25 ел гомерен бирә. Өлкән библиограф вазифасын бу чорда тирән белемле, үз эшенең остасы, «тере энциклопедия» Мәсгудә апа Бурнашева башкара.

Бөек Җиңүдән соң Китап палатасының эше җайга салына, библиографик күрсәткечләр чыгару да тәртипкә китерелә. 1930 елга кадәр «Китап елъязмасы» гына чыгып килгән булса, сугыштан соң «Вакытлы матбугат елъязмасы», 1949 елдан «Нота әсәрләре елъязмасы», 1953 елдан «Рецензияләр елъязмасы», 1955 елдан «Журналларда һәм газеталарда басылган мәкаләләр елъязмасы», 1961 елдан Татарстан Республикасы Милли китапханәсе белән берлектә «Татарстан

Республикасы башка республикалар матбугатында» исемле библиографик күрсәткечләр әзерләп чыгарыла башлый. Шул ук 1961 елда аерым чыккан «елъязмалар» берләштерелеп, «Матбугат елъязмасы» исеме белән дөнья күрә.

Эш колачының киңәюе нәтиҗәсендә алтмышынчы елларда Китап палатасының штатлары арттырыла, фондлары зурая. Палатага 40 елдан артык гомерен биргән Әнисә Хисамова шушы чорда биредә эшли башлый. 1965 елда Әхмәт ага Булатов лаеклы ялга киткәч, җитәкче итеп Татьяна Дунаева (соңгы елларда Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институты проректоры вазифаларын башкарды, педагогика фәннәре кандидаты) билгеләнә. Китап палатасында эшне фәнни нигездә оештырган яшь белгеч тиздән Мәскәүгә аспирантурага укырга киткәч аның урынына Әнисә Хисамова кала. Библиография эшенең бөтен нечкәлекләрен белгән Әнисә ханым, үзенә генә хас тырышлык һәм тыйнаклык белән, 17 ел дәвамында директорлык эшен башкара. Ул эшләгән чорда Китап палатасы «Татарстан китаплары» исемле библиографик күрсәткечнең I һәм II томнарын (Казан, 1979, 1986) бастырып чыгара, яңа китапларны пропагандалауга зур әһәмият бирә, архив бинасын киңәйтүгә һәм хезмәткәрләрнең эш урыннарын яхшыртуга ирешә. Хөкүмәтебез тарафыннан Әнисә Хисамованың хезмәтләре лаеклы бәяләнеп, аңа Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре исемнәре бирелде.

Әнисә ханым лаеклы ялга киткәч, озак еллар палатаның баш библиографы булып эшләгән, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Рауза Ханнанова директор итеп билгеләнә. Бу чорда Татарстан Милли китапханәсе белән берлектә китапханәләр һәм нәшрият хезмәткәрләре өчен бик әһәмиятле «Каталог һәм елъязмаларда, библиографик күрсәткечләрдә татар телендәге сүзләрне кыскарту» дип исемләнгән методик күрсәткечнең яңа басмасы эшләнә, «Китапханәләр, нәшриятлар һәм мәгълүмат оешмалары хезмәткәрләре өчен русча-татарча сүзлек» дөнья күрә, каталоглар системасын редакцияләү эше дәвам иттерелә, кулдан язылган һәр карточка машинкада бастырыла, унарлы универсаль төркемләү системасына күчерелә, компьютерлар системасы үзләштерелә.

Китап палатасын 1998 елдан Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Харис Әшрәфҗанов җитәкли. Китап җанлы кеше буларак, ул палата алдына куелган бурычларны аңлый, хатын-кызлардан гына торган коллективның шатлыгын да, кайгысын да уртаклашып яши.

Матди кыенлыкларга карамастан, «Татарстан Республикасы матбугат елъязмасы» хәзерге көндә дә чыгуын дәвам итә.

Китап палатасының соңгы еллардагы эшчәнлеген күз алдына китерү өчен кайбер саннарга игътибар итик. Палатага 2005 елда татар һәм рус телләрендә мең ярымга якын китап, 60 исемдә журналлар һәм фәнни хезмәтләр, 24 исемдә республика газеталары, 84 исемдә шәһәр һәм район газеталары, 143 исемдә төрле оешмалар, житештерү берләшмәләре, югары уку йортлары газеталары һәм башка төр басмалар—сынлы сәнгать әсәрләре, ноталар, афишалар керде. Алар елына 21-22 мең данәне тәшкил итә. Хәзерге вакытта фондыбызда 1 миллион 600 меңгә якын берәмлек басма продукция саклана.

Китап палатасы фондына керә торган бөтен басмаларны теркәү, исәпкә алып вакытында эшкәртү һәм квартал саен «Матбугат елъязмасы» төзеп нәшриятка тапшыру эшен 14 кешелек хезмәт коллективы башкара. Рухи мирасыбызны киләчәк буыннарга җиткерү өчен Китап палатасы хезмәткәрләре тырышып эшли. Хезмәт ветераны Назилә Борһанова, баш библиограф Сөгъдә Хәбибуллина, архив мөдире Әнисә Хәсәнова, әйдәп баручы библиографлар Люция Нәҗметдинова, Ләйсән Ярхәмова, Лилия Сабирҗанова үтә четерекле хезмәтне күңелләрен биреп башкаралар. Әле күптән түгел эшли башлауларына карамастан, библиографлар Алия һәм Лилия Җиһаншиналар, Ләйсән Касыймова, хисапчы Роза Әхмәтова үзләрен тырыш, унган хезмәткәрләр итеп таныттылар.

Эшебезнең төп—беренче максаты барлык төр басма продукцияне исәпкә алу (теркәү) һәм мәңгелеккә саклау булганлыктан, Китап палатасы хезмәткәрләре һәр басманы үзебездә булдыру, аның килми калуына юл куймауны үзләренең бурычлары итеп саныйлар. Моның өчен командировкаларга йөриләр,

типографияләр белән элемтәгә керәләр, шулай ук чит төбәкләрдә татар телендә нәшер ителүче һәр басманы алдыру юлларын эзлиләр.

Икенче юнәлеш—палатага кергән һәр хезмәтне эшкәртеп, «Матбугат елъязмасы»н төзеп, бастырып чыгару вакытын, китапханәләргә, галимнәргә мәгълүматның барып җитүен тизләтү. Элек «Елъязма»ны тарату китапханәләр коллекторына тапшырылган иде, ә хәзер бу эшне дә үзебез эшләргә мәҗбүрбез. Татарстан Республикасы Милли китапханәсе «Елъязма»ны таратуда зур булышлык күрсәтүен әйтеп узарга кирәк.

Өченче юнәлеш—Татарстанда басылып чыккан татар китапларының репертуарын төзүне дәвам итү. Аның I томы—1979, II томы—1986, III томы—1995, IV томы—1996, V томы—2004 елда басылып чыкты, хәзер VI томга материаллар туплау дәвам итә.

Соңгы вакытта иң мөһим эшләребезнең берсе—каталогларны компьютерлар системасына җайлаштыру.

Бу көннәрдә Китап палатасы мәш килеп 80 еллык юбилеена әзерләнеп йөридер дип уйласагыз, бик нык ялгышырсыз. Чөнки барлык хезмәткәрләр 14 нче август аеннан бирле Китап палатасының сиксән еллык фондын күчерү, тәртипкә салу, ягъни төяү-бушату эшләре белән мәшгуль. Әгәр татар халкының «Ике күчеү—бер януга тиң» дигән мәкален дә искә төшерсәк (элекке күченүләрнең санын әйтә алмыйм, мин белгән 35 елда алар өчәү булды)—мәсьәләнең мәшәкате аңлашылса кирәк.

Сиксән еллык унаеннан шәһәр үзәгендәге иң затлы, берәр яңа бинага күчерәләр дип уйласагыз да ялгышырсыз. Быел Татарстан Китап палатасы Республика Милли архивының 8 март урамындагы бинасына күчерелде, урын бүлеп бирелеп, шунда сыендык.

«Тарих кабатлана» дип акыл ияләре юкка гына әйтмәгәннәр шул. 1930 елда югалткан мөстәкыйльлеген 1938 елда кабат кире кайтарган Китап палатасы—халкыбызның рухи хәзинәсен саклаучы, халык аңы, халык хәтере булган китапларны киләчәк буыннарга илтергә, җиткерергә бурычлы оешма—2007 нче елдан мөстәкыйльлеген янә югалту алдында тора. Китап палатасы директоры Харис Әшрәфҗанов өстәлендә ята торган рәсми хатта: «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 нче елның 19 декабрендә кабул иткән «Татарстан Республикасының массакүләм мәгълүмат чаралары турында»гы 611 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт Китап палатасын Баш архив идарәсенә кушарга»—дип, акка кара белән язылган. Бу хатка карата ни дә булса өстәп шәрехләү артыктыр дип уйлыйм.

Татарстан Республикасында Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителгән 2006 елда халкыбызның рухи байлыгын саклаучы оешманың мөстәкыйльлеген югалтуын алга таба атлау дип әйтеп булмый, әлбәттә.

Алай да ничә гасырлардан бирле якты көннәр киләсенә өмет баглап яшәгән татар халкы, шул исәптән Татарстан Китап палатасы коллективы да киләчәккә ышанычын өзми. Әдәбият һәм китап әһелләре дә кайгыртучанлык күрсәтерләр дип өметләнәбез. Рухи хәзинәбезнең күгәрмәс алтын сандыгын тиешенчә бәяләп, кыйммәтенә күрә кадерен белергә иде.

**Миләүшә ШАКИРОВА,**
*Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре,*
*матбугат отличнигы.*

## Редакциядән

Татар халкының белем хәзинәләреннән берсе — Татарстан Республикасы Китап палатасының мөшкел хәле турында матбугатта да, югары даирәләрдә дә борчулы фикерләр булды. Республикабыз Президенты Минтимер Шәймиев белән «Казан утлары» журналының баш редакторы шагыйрь Равил Фәйзуллин әңгәмәсендә

Китап палатасы турында аерым сүз булып, Илбашыбыз бу оешманың киләчәге уңай хәл ителәчәге турында әйткән иде.

Тик әлегә Китап палатасының язмышы куанычлы якка үзгәреп җитмәве күренә. Бигрәк тә, Бауман урамындагы Матбугат йортыннан кузгалып иң беренче чыгып киткән оешма — Китап палатасы булуы, аның артыннан башка милли матбугат оешмалары да чыгачагы нindидер авыр фал кебек.

Аң-белемгә, китап сүзенең көченә җитди әһәмият биреп, ил өчен катлаулы чорда оештырылган, дәһшәтле Бөек Ватан сугышы елларында да эшчәнлеген туктатмаган Китап палатасының менә хәзерге мөмкинлекле—мул дәверебездә мөстәкыйль оешма буларак хокуклары чикләнеп, архив карамагына тапшырылуын алга китеш дип бәяләп булмый. Мондый хәл ятим Тукайны асрамага биргәнне хәтерләтә яисә михнәттән җәфа чигеп, чарасызлыктан мәҗбүри өйдәш булуга охшый.

Ихтимал, бу бер хаталану гынадыр, матди байлык артыннан кугандагы кабаланудан ялгыш ясалган җайсыз адымдыр. Берүк, шулай гына була күрсә иде. Югыйсә, рухи байлыкның урыны һәрвакыт иң түрдә булырга тиешлеге меңнәрчә кат расланган хакыйкать бит. Рухи терәк булган диннән сиксән еллап аерылып тору нәрсәгә китереп җиткергән иде. Хата адым ясалганлыгы еллар узгач кына аңлашылды. Алга таба китап һәм матбугат кебек мәгънәви мирасыбыз да җәберләнсә, безне шундый ук нәтиҗә — денсезлек һәм имансызлык көтә.

Һәрхәлдә, күп гасырлык гаҗәеп бай мәдәнияты һәм әдәбияты булган татар халкына мондый гамәл килешми. Әдәбият һәм сәнгать елында бигрәк тә. Киләчәктәге варисларыбыз «Булдыргансыз икән...» дип рәнҗемәсеннәр иде.

Әйе. Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителгән елның ахыры килеп җитте. Ләкин ул татар әдәбияты һәм сәнгате белән хушлашуга тәңгәлләштерелмәсен. Киләсе яңа елларга аяк басканда ныклы ышаныч, тотрыклы рух, какшамас иман белән керсәк иде.

---

## КИТАП ПАЛАТАСЫ

*Мәдәният йортындагы Китап палатасы анын эшендә зур урын тота. Ул СССРда чыга торган барлык татарча әсәрләрне үзендә туплауны максат итеп ала. Анын өстенә башка телләрне, бигрәк тә Шәрык телләрендәге әсәрләрне булдыруны да күздә тота. Моның өчен Китап палатасы төрле җөмһүриятләр белән мөнәсәбәт тотып, алар белән әсәрләр алмаша, шул юл белән үзендә төрле телләрдән әсәрләрне җыя. 1927-28 нче елларда Китап палатасына барлыгы 17666 әсәр кергән. Болардан 2827 китаплар булып, калганы гәзит-журналлар шикелле вакытлы матбугат. Телләр мәсьәләсенә килгәндә монда хәзер барлыгы 32 телдә әсәрләр бар. Алар түбәндәгечә: алагай, авар, айрат, урыс, әрмәни, үзбәк, уйгур, инглиз, башкорт, татар, төрек (дагыстан, кырым, азәри, аҗар, госманлы), төрекмән, чәчән, чиркәс, даргин, гарәп, фарсы, таҗик, француз, карачай-балкар, каракалпак, казакъ-кыргыз, керәшен, кумык, куми, лак, лезгин, мордва, мари, нугай, немес, якут һәм яврей телләре. Китап палатасы быел Германиядә Кёльн шәһәрендә ачылган матбугат күргәзмәсенә 26-27 нче елларда татар телендә чыккан бөтен әсәрләрнең гыйльми индексын җибәрде. Шушы елда ун тапкыр әдәбият күргәзмәсе ясады. Шушы күргәзмәләр һәм экскурсияләр вакытында төрле әсәрләр, әдипләр, аларның хезмәтләре турында утыз тапкыр докладлар ясалды.*

*1925 нче елда матбугатка чыккан татарча әсәрләргә гыйльми библиография төзелеп бастыру өчен типографиягә бирелде. Татар дөньясында беренче мәртәбә мәйданга килгән бу әсәр тиз көндә басылып чыгачак.*

*Китап палатасы үзенә килгән әсәрләрдән аерып Мәдәният йортында булган гыйльми оешмаларга аларның сызыгы буенча бирәр данә бирә килә. Мәдәният йорты идарәсенең соңгы карары буенча Китап палатасында һәр әсәр өч данә сакланырга тиеш. Моның бер данәсе төпләнү шикелле үзгәртүгә очратмыйча, матбагадан ничек чыккан, шул көенчә саклана. Болардан башка Үзәк Шәрык көтепханәсенә, Үзбәкстанга, Азәрбәйҗанга һәм Башкортстанга бирәр данә җибәрелә. Китап палатасы иске әсәрләрне җыю эшен дә алып бара. Шушы вакыт эчендә бер мең данә иске әсәр җыелган.*

*Китап палатасы янында уку залы булып, анда татарча, урысча чыга торган барлык вакытлы матбугат булган кебек, башка Шәрык вакытлы матбугатын да табарга мөмкин. Шулай ук быел Гарептә булган чит телләрдән дә журналлар булачак. Бер ел эчендә Китап палатасы буенча вакытлы һәм даими матбугат буенча төрле телләрдә барлыгы 287000 әсәр керәчәк. Бу һәр көнгә 115 әсәр туры килә. Монда фәкать идейный содержаниядә булган әсәрләр генә керә. Афиша, игълан шикелле әсәрләр керми. Алар яңадан 6000 чамасы булырга тиеш. Бу кергән әсәрләргә регистрация ясау, каталог төзү, фәннәргә аеру һәм библиография төзү эшләре планга кертелгән һәм эшләнә. Бу ел эчендә 26-27 нче елларда чыккан татар әсәрләренә гыйльми библия (библиография) төзелеп бастырылырга уйлана.*

**Зәки МӨХСИНЕВ**

*(«Татар мәдәнияте йорты» исемле мәкаләдән. — Яңалиф. — 1928. — № 21-22).*

---

*Алхәбәр*

# «КАЗАН УТЛАРЫ»—2007

## Альберт Фәтхи турында истәлекләр

Фәнебезгә тугрылыклы хезмәт иткән китапчы галим, археограф, милләтебезнең сирәк шәхесләреннән булган Альберт Фәтхинең (1937—1992) тууына 70 ел. Аның тормышы, гыйльми эшчәнлеге һәм фәнни мирасы тиешле дәрәҗәдә объектив итеп хәзергәчә өйрәнелмәгән һәм серлерәк булып кала бирә.

Альберт Фәтхинең шәхес буларак бөеклеге дә, фаҗигасе дә хакыйкатьне сөюдә, гадел һәм туры сүзле, фидаи җанлы, үтә таләпчән галим булуында, милли фәнгә эчкерсез хезмәт итүдә, халкыбыз өчен янып-көеп яшәүдә.

Ул стандарт галим түгел, калып-кысалар, катыргы исем-дәрәҗәләргә исе китмәгән, хәтта кемнәрдер өчен «җайсыз» шәхес тә иде. Менә шул сыйфатлары өчен хөкүмәт органнары да дөмбәсләде, хезмәттәшләре дә читләшергә тырышты, чордаш фән әһелләренең кайберләре аны түбәнсетеп маташты, кемнәрдер күрмәмешкә салышты... Тик аның җаны да, рухы да дөньяның мондый ваклыкларыннан өстенрәк, олуграк иде. Альберт Фәтхиләрне кысрыклаган әшәке заманнарда да ихластан хөрмәт итүчеләр, искиткеч белемен олылаган кешеләр (өлкәннәр дә, яшьләр дә) аңа тартылдылар, киңәштеләр һәм аралаштылар. Аңа ияределәр һәм аңа ошарга тырыштылар, сокландылар.

Альберт Фәтхи дигән исемнең хикмәте нәрсәдә, ул кем булган соң? Аның белән аралашкан галимнәр, хезмәттәшләре һәм шәкертләре нәрсә диләр, аны ничек бәялиләр? Журнал сәхифаләрендә замандашларының истәлекләре тәкъдим ителәчәк.

# ҮЗ НӘШРИЯТЫБЫЗ

Наширлек эшчәнлеге—китапханәләр эшендәге мөһим юнәлешләрнең берсе. Эре федераль һәм күп кенә милли, республика, өлкә китапханәләрендә әлеге эшчәнлек бик актив һәм күпкырлы рәвештә алып барыла. Алар гыйльми хезмәтләр җыентыклары, монографияләр, фәнни әдәбият нәшер итә, кайберләре үз һөнәри газеталарын яки журналларын, башка төр периодик басмаларын чыгара. Әлеге җәһәттән Татарстан Милли китапханәсе—Россиядә алдынгылар сафында.



Татарстан Милли китапханәсе—1865 елда оешкан Казан шәһәре җәмәгать китапханәсенең турыдан-туры варисы. Оешу заманнарында да, Үзәк Губерна, Үзәк Шәрык китапханәсе дип аталган инкыйлаб еллары чорында да, сонрак В. И. Ленин исемендәге өлкә китапханәсе булып яшәгән, 1960 еллардан Республика фәнни китапханәсенә әйләнгән вакытларында да нәшрият эшчәнлеге китапханә өчен ят шөгыль булмаган. Китап фондларын чагылдырган каталоглар, китапханәнең аерым бер вакыт аралыгындагы эшчәнлеген тасвирлаган хисаплар, методик ярдәмлекләр, библиографик күрсәткечләр әледән-әле дөнья күреп торган. Ләкин 1980 нче еллар ахырында—1990 нчы еллар башында җәмгыятьтә туган яна вәзгыять китапханәләрдә нәшрият эшчәнлеген дә башкача кору, ягъни билгеле бер тәртипкә салу һәм активлаштыру зарурлыгын китереп чыгарды.

Китапханәләрнең нәшрият эшчәнлеге белән шөгыльләнүе берничә максатны күздә тота, болар—китап фондлары, кабатланмас язма һәм басма мирас ядкәрләре белән кинкүләм укучылар катлавын таныштыру, биредә эшләүче хезмәткәрләрнең фәнни хезмәтләрен һәм эш тәҗрибәсен башка китапханәчеләргә һәм кызыксынучыларга житкерү, шул рәвешчә аларга методик ярдәм дә күрсәтү, китапханә хезмәтләреннән файдаланырга килүчеләрнең библиографик һәм башка төр мәгълүматлар эзләү эшен җиңеләйтү.

Татарстан Республикасының Милли китапханәсенә унбиш елга якын (1986—2000) җитәкчелек иткән, аны ил һәм дөнья күләмендә югары дәрәҗәгә күтәргән, эшчәнлегенә яна сулыш биргән язучы һәм халык депутаты Разил Исмәгыйль улы Вәлиев инициативасы белән Милли китапханә моннан ун ел элек, 1996 елда «Милли китап» дип аталган үз нәшриятын оештырды. Хәзерге көнгә кадәр, ягъни ун ел дәвамында, «Милли китап» нәшрияты татар һәм рус телләрендә түбәндәге төр басмалар нәшер итү белән шөгыльләнә: китапханәчелек эшенә һәм библиографиягә, китап һәм мәгълүмат гыйлемнәренә караган белешмә басмалар; «Китапханә хәбәрләре» исемле фәнни-гамәли, һөнәри журнал; республикабыз мәдәниятенең төрле юнәлешләрен, үз фондларындагы бинихая зур рухи, милли байлыкны чагылдырган библиографик һәм әдәбият күрсәткечләре; төбәгебездәге китапханәләрнең тарихына караган фәнни басмалар; Татарстандагы барлык китапханәләрнең, республикабыздан читтәге татар китапханәләренең гаммәви һәм мәгълүмати эшчәнлегенә ярдәм итә торган методик материаллар; республикабыз халыклары тарихының һәм мәдәниятенең әһәмиятле сәхифәләрен яктыртучы фәнни һәм фәнни-

популяр хезмәтләр; буклетлар, календарьлар, каталоглар, белешмә битләр, чакыру кәгазьләре һ. б.

Нәшрият эшчәнлеге китапханәнең еллык эш планы нигезендә гамәлгә ашырыла. Әлеге вазыйфа һәм бу юнәлештәге төп җаваплылык, нигездә, китапханәнең редакция-нәшрият бүлегенә йөкләнгән. Фәнни-методик, татар әдәбияты һәм туган якны өйрәнү, сирәк китаплар һәм кульязмалар, мәгълүмат-библиография бүлекләре, күргәзмәләр залы хезмәткәрләре нәшер итү, бастырып чыгару һәм тарату өчен материаллар әзерлиләр, башка бүлек белгечләре дә бу эштә катнаша. Аларның һәм читтән җәлеп ителгән авторларның иҗади эшенә бераз каләм хакы түләү максатында, сирәк булса да, заказ белән дә китаплар нәшер ителә.

Китапханәнең иң бай тарихлы басмасы—«Татарстан Республикасының истәлекле һәм онытылмас даталар календаре»—1950 нче еллар ахырыннан бирле чыгарыла. Ул Татарстанның иҗтимагый, сәяси, мәдәни тормышындагы төп вакыйгаларны һәм фактларны, шулай ук күренекле шәхесләрнең—язучыларның, фән, мәгариф, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренең—юбилейларын чагылдыра. Еллар уза барган саен укучы ихтыяҗларына яраклаштырып ана үзгәрешләр, өстәмәләр кертелә; китапханәләрдә, музейларда эшләүчеләр, мәдәният, мәгариф, матбугат һәм радио-телевидение хезмәткәрләре, туган якны өйрәнүчеләр арасында «...Календарь»дан файдаланучылар саны арта бара. Гомумән, туган якны, аның тарихын өйрәнүгә багышланган басмаларны күпләп нәшер итү—Татарстан Милли китапханәсен башка милли республикалар китапханәләре рәтендә аерып торган үзенчәлек. Мисалга Татарстанның тарихи һәм мәдәни һәйкәлләренә, Саба районына багышланган библиографик күрсәткечләрне, Татарстандагы Ташлык, Шәңгәлче, Мәмәшир, Башкортстандагы Камышлытамак авыллары тарихларына караган Т. Кәримов, Г. Исламов, Н. Шәрифуллин китапларын китерергә була. Татарстан һәм татар китапханәләре тарихын өйрәнү—Милли китапханәдәге төп фәнни юнәлешләрнең берсе. Аның нәтиҗәләре дә аерым җыентыклар рәвешендә татар һәм рус телләрендә берничә тапкыр «Милли китап» нәшриятында дөнья күрде.

Нәшриятның аякка басып килү елларында ук махсус төзелгән коллектив тарафыннан әзерләнгән һәм «Мәгариф» нәшрияты белән берлектә бастырып чыгарылган «Китапханәләр, мәгълүмат оешмалары һәм нәшрият хезмәткәрләре өчен русча-татарча сүзлек»не (1998) аерым телгә алмыйча булмый. Чөнки нәкъ менә шушы басма китапханә эше өлкәсендә татар теленең кулланылышын арттыру, урынын ныгыту җәһәтеннән житди бер адым дип бәяләнде һәм Россиядә мондый төр сүзлекләрнең беренчесе булды.

XX йөз башында чыккан татар газета-журналларына багышланган гомуми һәм кайберләренең эчтәлеген ачкан аерым библиографик күрсәткечләр төзеп нәшер итү вакытлы матбугатыбыз тарихын өйрәнүгә саллы өлеш кертә. «Милли китап» нәшриятында мондый басмалардан «XX йөз башы татар тәгълим-тәрбия журналларының («Тәрбияи әтфаль», «Тәрбия», «Мәктәп», «Мөгаллим») библиографик күрсәткече (1997), М. Госманов белән Р. Мәрдановның «Шура» журналының библиографик күрсәткече» (2000), Р. Гайнанов, Р. Мәрданов, Ф. Шәкүровларның «XX йөз башы татар вакытлы матбугаты: 1905—1924» күрсәткече (2000), А. Заһидуллинның «Әд-дин вәл-әдәб» журналының библиографик күрсәткече» (2003) нәшер ителде.




Мәшһүр татар галиме Шиһабетдин Мәрҗани шәхси китапханәсенең катлаулы язмышын чагылдырган, галим Р.Мәрданов төзегән «Мәрҗани китапханәсе» фәнни-библиографик җыентыгы—бу юнәлештә нәшер ителгән беренче һәм бердәнбер басма. Ул Татарстан Милли китапханәсендә саклана торган уникаль кульязма документны фәнни әйләнешкә кертүе белән дә әһәмиятле.

«Милли китап» нәшриятының тагын бер горурланырлык хезмәте—«Татар әдипләре» сериясендә нәшер ителүче биобиблиографик күрсәткечләр. Әлеге эшнең максаты—күренекле әдипләребезнең библиографик тасвирлау рәвешендә иҗади һәм фәнни хезмәтләре чагылдырылган тулы белешмәләр булдыру. Хәзерге көнгә кадәр

«Нурихан Фәттах» (1998), «Айдар Хәлим» (2001), «Һади Такташ» (2003), «Самат Шакир» (2003), «Ризаэтдин Фәхретдин» (2003), «Кыям Минлебаев» (2004), «Миркасыйм Госманов» (2004) биобиблиографияләре укучылар кулына барып иреште, төзелеп беткән яки нәшриятка әзерлек эше тәмамланып килүче «Рабит Батулла», «Туфан Миннуллин», «Разил Вәлиев», «Гомәр Гали», «Равил Үтәбай-Кәрими» басмалары үз чиратларын көтә.

Санап үтү рәвешендә генә булса да, А. Габделхакованың «XX йөз башы татар балалар китабы: 1901—1917» библиографик күрсәткечен (1999), М. Вәлиевнең «Китапчылык тарихы (кыскача курс)» (2005), «Китап редакторы: Иҗат һәм оештыру эшчәнлеге» (2006), Ш.Бикеевнең «Основы информатизации библиотек» (1999) дигән, югары уку йортлары студентларына адресланган уку ярдәмлекләрен, Ә. Кәримуллинның «Без тарихта эзлебез» исемле фәнни һәм публицистик мәкаләләре җыентыгын (2000), Н. Дәүләтнең төрекчәдән Р. Батулла тәрҗемәсендә дөнья күргән «Русия төркиләренең милли көрәш тарихы: 1905—1917 еллар» хезмәтен (1998), Н. Сәмигуллинның «Ил язмышы—ир язмышы» дип аталган хатирәләр, очерклар, публицистик язмалар китабын (2005), Г.Вәлиеваның «Тылсым», М. Шәйхинең «Ак буран», М. Шәйбәкованың «Бәхет кошы», Р. Имаевның «Гомер агышлары», Р. Шагаевның «Яшәү һәм өмет», И. Хаҗиевның «Узелки макраме», «Иң яхшы бүләк: Түбән Кама шәһәре һәм районы балалары иҗаты» кебек шигырь җыентыкларын «Милли китап»ның күркәм басмалары рәтендә күрсәтик.

Нәшрият басмаларының зур өлешен фәнни-методик бүлек нәшер иткән, күләмнәре буенча зур булмаган, әмма китапханәләр эшендә әһәмиятләрен бәяләп бетергесез күптөрле методик ярдәмлекләр тәшкил итә. Алар Татарстанның һәм башка республика, өлкә, илләрнең китапханәләрендәге эш тәҗрибәсен дә чагылдыра; китапханә хезмәте, китап укучылар белән эшләү, китап фондларын туплау һәм саклау, китапханәләрдә түләүле хезмәтләр булдыру серләренә дә төшендерә; күренекле шәхесләребезнең юбилейларын үткәрү өчен кинәшләр, сценарийлар да тәкъдим итә; китапханәчеләрнең яңа икътисади шартларга җайлашуына да булыша, аларның һөнәри осталыгын арттыра; төрле китапханәләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне дә көйли.

Гыйльми һәм социологик тикшеренүләрнең, фәнни-гамәли конференцияләрнең нәтиҗәләрен бергә туплаган җыентыклар да, китапханәнең күргәзмәләр залына куелган китап күргәзмәләренең каталоглары да укучылар тарафыннан теләп файдаланыла.

Татарстан Милли китапханәсе тарафыннан 1996 елдан башлап елга ике тапкыр татар һәм рус телләрендә «Китапханә хәбәрләре—Библиотечный вестник» дип аталган фәнни-гамәли журнал нәшер ителүне шушы ук «Милли китап» нәшрияты эшчәнлегенең бер тармагы икәнлеген алдарак әйткән идек. Әлеге һөнәри басма республикабыздагы китапханәләрнең эш тәҗрибәсен, торышын һәм проблемаларын чагылдыру белән беррәттән, Россия, якын һәм ерак чит илләр китапханәләрендәге үсеш тенденцияләрен яктыртуга да зур игътибар бирә, үз сәхифәләрендә тарихи, публицистик һәм әдәби язмалар, мәдәният өлкәсенә караган рәсми материаллар да урнаштыра. Журналның эчтәлеге дә, бизәлеше дә, полиграфик сыйфаты да елдан-ел камилләшә бара.

Китапханәнең нәшрият эшчәнлеге аның болай да зур булмаган бюджетыннан финанслана.

«Милли китап» нәшрияты, ул нәшер иткән басмаларның күбесе республикадагы шәһәр, район, авыл китапханәләренә, шул исәптән читтәге татар китапханәләренә дә җибәреп барыла. Кайбер басмалар исә дөнья күрү белән үк популярлык казанып, тиз арада таралып та бетә. Димәк, «Милли китап»ның файдалы эшчәнлеген киләчәктә дә дәвам итү өчен җирлек бар дигән сүз.

**Ирек ҺАДИЕВ,**

*Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең директор урынбасары.*

# ҖӘМГЫЯТЬ ҺӘМ МӘКТӘП

Мәктәп нинди генә сикәлтәле юллар, зур сынаулар узмады. Менә хәзер дә мәгариф системасында зур үзгәрешләр бара: профильле укыту, авыл мәктәбен үзгәртеп кору, бердәм дәүләт имтиханнары, яңа технологияләр куллану... Тик шунысы хак: мәктәп тормышына нинди генә үзгәрешләр кертергә тырышсалар да, аны табигать, җәмгыятьнең язылмаган законнары билгеле бер туры юлдан алып бара.

Мәгариф тарихы мәктәп һәм җәмгыятьнең үзара мөнәсәбәте һәрчак катлаулы булуын раслый. Мәктәп яшәеш ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тырыша. Әмма тормыш һәрвакыт үзгәреп тора, андагы кискен мәсьәләләр бергә туплана бара. Шулай итеп, кайбер очракта иҗтимагый канәгатьсезлек хисе, иң беренче чиратта, мәктәптә барлыкка килә. Ләкин, җәмәгатьчелекнең канәгатьсезлек белдерүе сәбәпле, урта мәктәп күп очракта аз-маз гына үзгәртелергә мөмкин, чөнки мәгарифне тирәнтен үзгәртеп кору җәмгыятьнең үзен дә тамырдан үзгәртүне таләп итә. Бары тик шул вакытта гына яңа тарихи чынбарлык нигезендә мәктәп тә үзгәреш кичерә ала.

90 нчы елларда җәмгыятьтә тирән үзгәрешләр барлыкка килгәч, мәгариф учреждениеләренә дә яңалыклар дулкыны «бәреп керде». Шунысы әһәмиятле: бу үзгәрешләр мәктәпнең үзеннән башланды. Укытучылар коллективы, югарыдан күрсәтмәләр көтеп тормыйча, яңа эш формаларын, укытуның яңа технологияләрен эзли башлады. Башкача булу мөмкин дә түгел. Укытучы халкы шундый тынгысыз, үҗәт җанлы инде ул. Мөмкинлек, шартлар булмаса да, таулар күчерергә әзер. Мөгаллимнәрнең күңеле дә саф, самими, тормышта очрый торган төрле тискәре күренешләргә алар чын күңелдән көенә, шуларны булдырмау юлларын эзли башлый.

Хәзерге чорда укыту-тәрбиягә үзгәрешләр кертүдә иң беренче каршылык булып мәгариф эшләренә тиешле күләмдә акча бүлеп бирмәү тора. Ә акча бигрәк тә мәктәпкә кирәк. Укытучы, аптырагач, йөдәгәч, класс бүлмәләрен ремонтлау, яңа әсбаплар сатып алу өчен ата-аналардан акча җыярга мәҗбүр. Бу—килешә торган эш түгел, билгеле. Нишлисең, башка чара юк. Мондый хәлне газета-журналлар, радио, телевидение бик нык тәнкыйтьли. Мондый очракта мөгаллимнәргә сүз әйтү урынсыз, минемчә. Аны җәмгыять шуңа этәрә. Элеккеге зур завод, предприятиеләрне акционерлаштырып, аларның хуҗалары булып калган һәм, законсызлыктан файдаланып, үзләре теләгәнчә хезмәт хакы алучылар, бер шәһәрдә генә дә 4—5 фатир тотучы, чит илләрдә виллалар салдыручы, акчаларын Төркия, Швейцария, АКШ банкларында саклаучы абзыйлар, дәдәйләр типтереп яшәгәндә, мәгариф, мәдәниятне үстерүгә, сәламәтлекне саклауга акча бик аз кала шул. Билгеле, «Мәгариф» дәүләт проекты кысаларында иң яхшы мәктәпләргә—1 миллион, иң яхшы укытучыларга 100 мең сум күләмендә акча бирелде. Ләкин азкомплектлы авыл мәктәпләре бу бүләкләрне, бик теләсәләр дә, ала алмый. Чөнки аларда тиешле шартлар юк. Бу әлеге мәсьәләне тамырыннан хәл итү дигән сүз түгел. Ә бит икътисадый үсеш ягыннан алга киткән илләрдә, гомумән, мәгарифне үстерүгә нык игътибар ителә. Аларда илнең нык үсешен тәэмин итүче көч булып кеше, шәхес торуын бик ачык аңлыйлар. Мәсәлән, Японияне алыйк. Анда табигый байлыклар юк диярлек. Ә мәгарифне, мәдәниятне үстерүгә зур әһәмият бирелүе, бу өлкәдә дөрес сәясәт алып барылу белемле, квалификацияле, кешеләргә беренче дәрәҗәдә кирәк булган әхлакый сыйфатлы кадрлар, үз илләренең патриотларын тәрбияләргә ярдәм итә.

Мөгаллимнәребез, бик аз хезмәт хакына, җиде кат тирен түгеп, эшли дә эшли. Белемле, яхшы, намуслы, милли җанлы кешеләр тәрбияләргә тырыша. Тирә-юньдәге кырыс тормыш, җиңел юл белән табыла торган акчаны үзара бүлешә алмыйча бер-берсен үтерүчеләр, наркоманнар, эчкече, сукбайлар саны ел саен меңәрләп арта барган бу җәмгыятьтәге тормыш ул эшне бер «селтәнүдә» юкка чыгара.

Укытучы бу күренешләргә тирәнтен сыкрый, борчыла. Шундый күре-

нешләргә генә түгел, үзе өчен дә, балалар өчен дә, аларның киләчәге өчен дә.

Гомумән, безнең илдәге һәр җәмгыять кеше тормышына, язмышына шактый тискәре йогынты ясый. Әле күптән түгел генә мин улыма мәктәптә математика укыткан һәм аларның класс җитәкчесе булган мөгаллимәне очраттым. Хәзер пенсиядә инде ул. Ләлә ханым Троицкида туып-үскән. Шунда рус милләтеннән булган кешегә кияүгә чыккан. Бу гаилә ике малай тәрбияләп үстергән. Соңыннан алар Казанга күчеп кайткан. Баштарак мин һәм башкалар Ләлә ханымны Ольга Ивановна дип белә идек. Төсе, кыяфәте белән гел рус кешесе кебек ул. Тик шулай да аның мөлаем карашында, йомшак сөйләшүендә татар милләте сыйфатлары чагылып киткән кебек була иде. Мәсьәләгә очраклылык ачыклык кертте. Көннәрдән беркөнне укытучылар конференциясенә багышлап төзелгән стендта Ольга Ивановна фотосурәте күзгә чалынды. Рәсем астындагы язуны җентекләп карасам, ни күрим: Ләлә Ибраһимовна Геполова дип язылган иде анда. Ә инде шуннан соңгы очрашуда мин аңар Ләлә Ибраһимовна дип эндәштем. Ул йомшак кына итеп күз сирпеп алды да: «Миңа үз исемем белән эндәшүче юк иде әле. Яшьлегемә, милләтемә кире кайткандай булдым»,—диде. Шулай еллар уза торды. Минем улым да мәктәпне, югары уку йортын тәмамлады. Математикадан төпле белемле булуы белән аерылып торды ул. Ләлә Ибраһимовна очрашуларның берсендә болай диде: «Хәзер мин ялда. Еш кына үткән гомеремне искә төшерәм. Үземнең туган телемне белмәвемә бик үкенәм. Җәй көннәрендә татар карчыклары, үзләренең кершәндәй ак яулыкларын бәйләп, ишек алдына чыгып утыра. Рус карчыклары да, аерым бер төркемгә берләшеп, гәп сата. Ирексездән үз-үземә сорау бирәм: мин—кем? Татармы, русмы? Мин бер төркемгә дә кушыла, алар белән чын күңелдән аралаша, сөйләшә алмыйм. Алар да мине кабул итми кебек. Менә шушы уйларны уйлап кайчак төн йокыларым кача...»

Әйе, мөгаллимә Ләлә Ибраһимовнада татар каны ага, заманында телебезгә, гореф-гадәтләребезгә бик үк әһәмият бирмәве өчен аның йөрәге газаплана, җәберсенә. Бары тик укытучы йөрәге генә әнә шулай сызлана ала. Советлар чорында бер милләт кенә калдыру идеясен гамәлгә ашырыга керешкән идеологлар «эшчәнлегенең» ачы җимеше бу.

Ләлә Ибраһимовнаның шундый хәлгә калуында безнең чынбарлыгыбызның, җәмгыятьнең зур гаебе бар, билгеле. Бу турыда күп сөйләргә булыр иде. Мәгариф тормышында да мөгаллимне сыкрандыра торган хәлләр еш булып тора. Республика, район күләмендә үткәрелә торган конкурс, смотрларда татар теле һәм әдәбияты укытучыларының класстан тыш үткәргән чараларга бәя бирүче комиссия составында татар әдәбиятын, телен, мәдәниятен, тарихын тирәнтен белгән кеше булмавына да бик борчыла ул. Үзен мыскыллау дип тә, санга сукмаулары дип тә аңлый. Әмма күңелен төшерми. Эшли дә эшли. Балаларга белем һәм тәрбия бирә.

Мәгариф системасында тәрбия үзәк урынны алып тора.

Тәрбия—укучы шәхесенең үсеш процессы белән максатчан идарә итү ул. Бала мәктәптә, мәктәптән тыш учреждениедә генә түгел, ә бәлки тирә-юньдуслар, кайбер өлкәннәр тәэсире белән дә формалаша. Укучы үзенең вакытының күп өлешен мәктәптә үткәрә. Анда таныш-белү эшчәнлеге белән шөгыльләнеп, кешеләр белән аралашып, ул үзенә төрлечә тәэсир итүне сизә. Мәктәптә исә аларның барысын да шәхесне үстерүдә төп рольне уйнарга ярдәм итә торган бердәм системага берләштерү мөмкинлеге бар.

Демократик җәмгыятькә туры килә торган тәрбия системасының һәр шәхес үсешенә юнәлтелгән булуы зарури.

Балалар тирә-юнь турында төрле чыганаклардан: ата-аналардан, балалар бакчалары тәрбиячеләреннән, дәресләрдә, урамда, радио-телевидение тапшыруларыннан, кинофильм, китаплардан белә. Кагыйдә буларак, аларда дөнья төрлечә чагылдырыла. Шуңа күрә мәктәпнең бурычы—дөньяның бербөтен һәм катлаулы икәнлеген бөтен тулылыгы белән күзалларга һәм аны хисси кабул итәргә мөмкинлек тудыру. Укыту процессын, класстан тыш эшне һәм балаларның мәктәптән тыш эшчәнлеген үз эченә алган тәрбия системасы барыннан да бигрәк менә шушы бурычны гамәлгә ашыруга юнәлтелгән булырга тиеш. Аның икенче функциясе—рухи, мәдәни үсеш процессында укучыларны әхлакый кыйммәтләрне аңлый белергә төшендерү; өченчесе—һәр укучыда граж-

данлык узаңы булдыру; дүртенчесе—баланы үзен танып белергә, үзүсешенә, үзенең мөмкинлекләрен тормышта сынап карарга ярдәм итү. Бүген мөгаллим әнә шуларны гамәлгә ашыру белән мәшгуль.

Тәрбия турында сөйләгәндә тагын бер мөһим мәсьәләгә тукталып үтмичә булмый. Матбугат битләрендә, радио, телевидение тапшыруларында Россиядән тәрбиягә алган ятим балаларны Америка гражданнарының кыйнап үтерүе турында әледән-әле хәбәрләр яңгырый. Россия Федерациясе Президенты каршындагы Гражданлык җәмгыяте һәм кеше хокуклары институтларын үстерү советы рәисе Элла Панфилова чыгышында («Комсомольская правда» газетасы, № 112, 2005) әйтелгәнчә, соңгы 30 елда чит ил гражданнары Россиядә туган 42 мең баланы уллыкка яисә кызлыкка алган. Шуларның 13 е үтерелгән. Моннан тыш, Россиядә 2000 нән артык сабый үз гаиләләрендә кыйнап үтерелә.

Без: «Россия—бөек держава, бай ил»,—дип әйтергә яратабыз. Менә шушы бөек державада 700 меңнән артык ятим бала бар. 2 миллионлап малай һәм кыз сукбайлыкта йөри. Ни өчен гаиләләр, балалар шундый хәлдә яши? Ни өчен гаилә тәрбиясе бөя куя алмаслык дәрәҗәдә түбән. Ни өчен безнең балаларны чит илләр асрамага ала? Монда сорау бик күп. Аларны бер көндә генә дә хәл итеп булмый. Җәмгыятьнең аек акыллы кешеләр тәрбияләве, нык гаиләләр булдыруы өчен зур тырышлык куясы бар. Моны балаларны, гаиләләрне яклау фонды, наркоманлыкка каршы көрәш конторалары ачып кына хәл итеп булмый. Җәмгыятебездәге бу ямьсез күренешләр тамырларын бик тирән җибәрде. Аларны булдырмау өчен кешегә игътибарны арттырырга, хокук тәртибен бозучыларга каршы катгый чаралар күрергә, һәр оешманың яшь кеше формалаштыруга үзенең ныклы өлеш кертүенә ирешергә кирәк. Юкса, җәмгыятьтә һаман тискәре күренешләр арта гына тора.

Элла Панфилова әйтүенчә, балаларны саклау проблемасы—милли куркынычсызлык проблемасы. Балаларга, гаиләләргә тиешле мөнәсәбәт булмау нәтиҗәсендә, Россиядә соңгы елларда балалар саны кими бара. 1997 елда бу сан—35 миллион, 2003 елда 30 миллион тәшкил иткән. Балаларның хокук тәртибен бозуын булдырмау, сукбай балалар санын киметү буенча да күп эшләр эшлисе бар.

Россиядә балалар мөнфәгатен яклый торган 570 оешма эшли. Аларга бик күп чыгым тотыла. Алар эшчәнлегенең нәтиҗәсе генә аз.

Мәктәптә тәрбия системасының иң мөһиме һәм иң беренче юнәлеше—балалар сәламәтлеген саклау. Безнең ил кыен чорны кичерә: ул—чирле. Чирле җәмгыятьтә чирле балалар туа һәм үсә.

Бүгенге җәмгыятьтә балалар тормышын тулырак күз алдына китерү өчен саннарга мөрәҗәгать итик. Яңа туган балаларның 20 проценттан артыгы акыл ягыннан зәгыйфь, Россиядә—7 млн., Татарстанда 7 меңгә якын наркоман теркәлгән (ә теркәлмәгәннәре күпме?) Россиядә 35 млн. эчкече бар. Революциягә кадәр Россия җан башына исерткеч эчемлекләр куллану буенча дөньяда 11 нче урында торган. Бүген илдә һәр кеше елына уртача 27 л исерткеч эчемлек кулланa. Ә бу сан дөнья күләмендә 5 л тәшкил итә. Шуны да ассызыклап үтик: җан башына 8 л исерткеч эчемлек кулланганда милләт бетүгә йөз тота башлый. 2005 елның 6 аенда Россия халкы 362 мең кешегә кимегән. Хәзер Россия Федерациясендә 141 миллион кеше яши. Бу саннар эчкечеләрнең, наркоманнарның һ.б. авыруларның һаман арта баруы, аларның бу якты дөньядан вакытыннан алда китүе турында сөйли.

Хәзер балалар һәм яшүсмерләрнең 15 проценты гына сәламәт. Яшь буынның 75 процентына психиатрия ярдәме һәм тиешле дәва кирәк.

Безнең Татарстанда да балалар сәламәтлеге шәптән түгел. Укучыларның 50 процентка якыны азканлылыктан интегә, гәүдә авырлыгы—буйларына, ә буйлары яшьләренә туры килми. 20 меңнән артык кеше сабый чактан ук гарип. Билгеле, авыру балаларны дәвалау һәм тәрбияләү өчен хөкүмәтебез бернәрсә дә эшләми дип әйтеп булмый. Бу максат өчен берникадәр акча тотыла. Әмма ул җитәрлек түгел.

Шәһәр читендә урнашкан җәйге сәламәтләндерү лагерьларының саны да елдан-ел кими. Элеккерәк елларда үсмерләр клубларында төрле түгәрәк, секцияләр эшләде. Бүген аларның барысы да ябыла, спорт корылмаларына балалар түгел, эшмәкәрләр хуҗа. Ә ябылган ишек алды клубларына коммерсантлар кереп оялаган.

Бары тик сәламәт балаларга гына тиешле белем һәм тәрбия бирергә мөмкин. Әгәр дә сабыйның тамагы—тук, өсте—бөтен, сәламәтлеге булмаса, аңа гыйлем туплау өчен шартлар тудырылмаса, мөгаллимнәр нинди тәрбия системасы гына уйлап тапсалар да, аның бернинди нәтиҗәсе булмаячак.

Әйе, үзгәртеп корулар чорында кешеләр тормышы начарайганнан начарая бара. Ә бит бөек фикер ияләре билгеләп үткәнчә, икътисадны үзгәртеп кору белән кешене «үзгәртеп кору» тыгыз бәйләнештә алып барылырга тиеш. Үзгәртеп коручыларның менә шуны аңламаулары нәтиҗәсендә халык күп кыенлыкларга дучар булды.

Билгеле, илне торгынлыктан чыгару өчен дәүләт властеның тотрыклы булуы, ил җитәкчелегенең үз эшчәнлеген икътисадый яктан акыллы итеп оештыруы кирәк. Бу эшләрдә дә тәрбия зур әһәмияткә ия. Узган гасырда ук барлык каршылыклар, колачлы мәсьәләләр тәрбия аша хәл ителүе, аның озын, әмма дөрес юл булуы билгеләп үтелгән.

Бүген бары тик мәктәп, мөгаллим генә рухи яктан бай иҗади кешене тәрбияли ала, ул халкыбызны рухи яңарту үзәге булырга тиеш. Шуны истә тотып, республикабыз мөгаллимнәре укучыларның сәламәтлеген саклауга зур әһәмият бирәләр. Чөнки бу мәсьәлә—тәрбия системасының мөһим бер юнәлеше.

Аксубай районы Иске Илдерәк мәктәбе укытучылары физик культура чаралары белән сәламәт тормыш рәвеше принципларын формалаштыра.

Мондый эшчәнлек балалар тәрбияләүгә комплекслы якын килү зарурлыгы, организмның физик үсеше белән шәхес үсеше арасындагы үзара тыгыз бәйләнешне файдалану нигезендә билгеләнә. Мәктәптә бу юнәлештә нәрсәләр эшләнә соң?

Бирегә укучыларны сәламәтләндерү эше махсус программа нигезендә алып барыла, һәр укучының «Безнең сәламәтлек» дигән диагностик картасы бар. Класс җитәкчеләре бу картага кайсы баланың кайчан, нинди авыру белән авыруы, ничек дәвалануы, хәзерге вакытта сәламәтлеге торышы, медицина тикшерүе нәтиҗәләре турында язалар.

Һәр уку елы башында классларда анкета сорауларына җавап яздырыла. Анкета мәгълүматлары балаларның кайсы фәнне тырышып үзләштерүен, физкультура дәресләренә мөнәсәбәтен, нинди спорт секцияләрендә шөгыльләнүен белергә ярдәм итә. Мәктәптә физкультура дәресләрен класстан тыш спорт чараларын тиешле дәрәҗәдә үткәрү өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Һәр укучы бер спорт секциясенә йөри. Спорт бәйрәмнәре үткәрү традициягә кергән. Көз һәм яз көннәрендә «йөгерешчеләр көне» уздырыла. Анда барлык укытучылар, укучылар, ата-аналар катнаша.

Мәктәптә I класстан ук сәламәтлек кеше өчен иң кыйммәтле, иң әһәмиятле нәрсә икәнлеге төшендерелә. Шуңа күрә укучылар да, ата-аналар да моңа нык игътибар итә. Моның нәтиҗәләре дә бар. Соңгы мәртәбә үткәрелгән медицина тикшеренүләре күрсәткәнчә, балалар салкын тию авырулары белән авырмый, ябык һәм кирәгеннән артык симез, шулай ук тәмәке тартучылар, исерткеч эчемлекләр кулланучылар юк.

Укучыларның сәламәтлеген ныгыту мәсьәләсе мөгаллимнәрнең игътибар үзәгендә булуы тагын бер мисалдан бик ачык күренә.

Аксубай якларында суда йод җитешми икән. Бу исә калкансыман биз авыруы китереп чыгара. Шуңа күрә укытучылар, балаларда бу чирне булдырмау өчен, составында йод булган антиструмин даруын үз акчаларына сатып алалар һәм аны шәфкать туташлары бушлай өләшәләр. Билгеле, бу эш табиб җитәкчелегендә эшләнә.

Сөйләгәннәрдән күренгәнчә, Аксубай районының Иске Илдерәк мәктәбе тәрбия системасында укучыларның сәламәтлеген ныгыту төп юнәлеш булып тора.

Кеше дөньяга 3 алшарт белән туа. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: хәрәкәткә, вертикальлеккә, пространствога омтылу. Җәмгыять еш кына бу омтылышны сүндерә. Укучылар аз хәрәкәтләнә, тирә-юньдә пычрак һава, без куллана торган ризык экологик яктан чиста түгел, мәктәпләр кысан.

Бала 3—4 яшьтә көненә—9—10 мең, 5—6 яшьтә—13 мең, 7 дә—15—30 мең адым атларга тиеш. Шуңа күрә һәр дәрестә физкультминутлар үткәрү зарури. Аз

хәрәкәтләнүчеләрнең тормышы кыска булуын мисаллар белән дәлилләргә була. Мәсәлән, йорт куяны (кролик)—3—4 ел, ә кыр куяны 15 ел яши. Чөнки аның гомере чабып уза. Моны истә тотып, мәктәпләрдә тәнәфесләрне озынрак итәләр, ул вакытта балаларны саф һавага алып чыгалар. Һәр көнне экология дәресе үткәрелә. Күз, кул, аяк, бармаклар өчен махсус күнегүләр, һәр дәрестә 15 минуттан һәм 30 минуттан соң физкультминуткалар уздырыла.

Мәктәптә югары белемле физиологлар һәм психологлар эшли. Табиблар белемен күтәрү академиясенең балалар авырулары кафедрасы белән килешү дә төзелгән, табиблар әледән-әле укучылар сәламәтлеген тикшереп тора. Тикшерү мәгълүматлары медицина картасына теркәлә һәм алга таба сәламәтләндерү чаралары күрелә.

Әйе, укучылар сәламәтлеген саклау һәм ныгыту—тәрбия системасының мөһим юнәлешләренең берсе.

Хәзерге чорда безнең илдә бара торган яшәү өчен көрәш, шәхси эшмәкәрлекне хуплау, җәмгыятьтә үз-үзеңне генә ихтирам итү хисенең көчәя, коллективларның таркаулана баруы, яшьләр арасына базар мөнәсәбәтләренең кыргый законнары үтеп керүе, безгә бөтенләй ят булган мөнәсәбәтләр формалашу яшь кешенең якты омтылышларын сүндерә, үзенә тиешле тормыш юнәлеше сайларга комачаулый. Аңа еш кына гаилә дә ярдәм итә алмый. Ул да базар «чире» белән авырый. Бу шартларда яшь буынга мәктәпнең гуманлы тәрбия системасы гына ярдәм итә ала. Бары тик мәктәп, укытучы гына яшь буынны фаҗигадән коткарып калырга мөмкин. Билгеле, мөгаллимнәргә дәүләтнең зур ярдәме кирәк.

Тормыш мәктәп алдына тәрбия эшен яңача оештыру бурычын куя. Мәсәлән, хәзерге вакытта яшьләр (гомумән, җәмгыять) акча туплауга зур әһәмият бирә. Элегрәк тә әлеге мәсьәлә игътибардан читтә түгел иде, ләкин базар мөнәсәбәтләре бу хисләрне тагын да көчәйтеп җибәрде. Педагогика фәне мондый хәлгә нинди карашта торырга тиеш? Мәгълүм ки, «акча артыннан куу»ны, акча туплау өчен төрле җинаятьләр эшләргә әзер торуны тәнкыйтьләп кенә тормышка үзгәреш кертеп булмый. Хәзер чоры башка. Шунысын да танырга кирәк: яшүсмернең кооперативта эшләп, яки шәхси эшмәкәрлек белән шөгыльләнеп, яисә шәхси автомашиналарның пыяласын юып акча тупларга тырышуы—гадәти күренеш. Ләкин яшүсмерләргә бу мәсьәләдә уңай тәэсир итүдән баш тарту хата булыр иде. Шулай итеп, акча туплау белән табигый мавыгу ныклы әхлакый нормаларга туры килүенә, көч куеп эшләп алган акчаны җыначел яки башка төрле юл белән табылганыннан аера белү күнекмәсе тәрбияләүгә нык игътибар итәргә кирәк. Бу—хәзерге чорда барлыкка килгән педагогик мәсьәлә. Эшләп алган акчаны ничек тоту, кирәкле әйбер сатып алу, хуҗаларча эш итү күнекмәсе тәрбияләү дә гади генә бурыч түгел. Аларны гамәлгә ашыру тәҗрибәсе әле тупланмаган. Шунысы ачык: базар һәм мәктәп бер-берсеннән «йөз чөерергә» тиеш түгел, ә бәлки алар шәхесне заман таләбенә җавап бирерлек итеп тәрбияләүдә кулга-кул тотынып эшләргә тиеш.

Хәзерге мәктәп алдында «Базар икътисады алга киткән җәмгыять»кә хас булган тәрбия эшен гомумкешелек кыйммәтләренә туры килерлек итеп ничек оештырырга?» дигән сорау тора. Бу искә алынган тәрбия юнәлешенең зур гомуми мәсьәләсенең бер өлеше генә. Элеккеге тәрбия системасы һәм традицияләре таркалу сәбәпле, яңаларын эзләү һәм табу шактый кыен. Мондый мәсьәләләр байтак. Без мәкаләдә аларның кайберләрен санап кына үтәбез. Иң мөһим бурычларның берсе—үзенең иҗади шәхес булуын исбат итәргә сәләтле шәхес тәрбияләү. Бу исә тәрбия эшенә яңача якын килүне таләп итә. Дөньяны иреккә, демократик танып белергә өйрәтү, фикер төрлелеге булдыру—урта мәктәпнең төп бурычы.

**Мәҗит ВӘЛИУЛЛИН,**
*Россия Федерациясенең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре,*
*«Мәгариф» журналының баш мөхәррир урынбасары.*

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ТӘФТИШ*** *г.* — Тикшерү, эзләү (мәс., юриспруденциядә) *//Хосусый мәктәпләрне ача алмый: ... 3)Җинаятьләр белән гаепләнеп, тәфтиш һәм хөкем астында булучы кешеләр* (Г.Гыйсмәти. Хосусый мәктәпләр, класслар, курслар хакында яңа законнар. Петроград, 1915); ревизия; тентү; ил чиген узганда тамгаханә тикшерүе. *Тәфтиш һәйәте* — ревизия комиссиясе. *Тәфтиш кылу.*

***ТӘХӘЛЛУС*** *г.* — Псевдоним (мәс., *Казани, Кырыми* кебек). Атаклы шәхесләрнең каберташларында еш кына *Болгари, Сувари* тәхәллусләренә тап булабыз. М.Әхмәтҗанов татар кульязмаларында очрый торган тәхәллусләрнең этнонимны түгел, бәлки авторның кайсы җирле географик-административ төбәккә нисбәтле икәнен күрсәтә дип яза. Мәс., Муса Бигиев Мисырда басылган әсәрләрендә үзен Муса бине Җарулла әр-Руси, әт-Татари, әр-Растуфдуни дип таныта. Шагыйрь Мифтахетдин Акмулланың да әл-Башкорди тәхәллусе милләтне түгел, бәлки "ул яшәгән урынның башкорт җирләре белән бәйле икәнлеген" белдерә.

Псевдоним мәгънәсендә *мөстәгар* сүзе дә кулланылган.

***ТӘҺАРӘТ, ТАҺӘРӘТ*** *г.* — Пакьлек, сафлык; чистарыну. Исламда кешенең чистарыну йоласы. *Эчке тәһарәт* (гөнаһлы булганнан соң яки ярамаган эш кылганнан соң җаныңны пакьләү) һәм *тышкы тәһарәт* (тәнеңне, кием-салымыңны, көнкүреш кирәк-яракларын, торагыңны һ.б.ны чистарту) була. Эчке тәһарәт өчен *тәүбә итү, кәффарәт* һәм *тәкъва тормыш* алып бару шарт. Акмулла әйтә: "Иң әүвәл пакьләү кирәк эчнең керен", — ди.

Тышкы тәһарәтнең түбәндәге төрләре бар: 1.*Госел* — тулы тәһарәт, бөтен тәнне юу йоласы, *тәһарәт кәбирә*. Каты авырудан соң, кыен сәфәрдән яки ябылудан кайткач, ир белән хатынның җенси мөнәсәбәтеннән соң, мәеткә кагылудан соң, дуңгыз вә эткә орынгач, мәчеттә җомга намазына барыр алдыннан, уразага керер алдыннан, никах алдыннан һәм башка әһәмиятле эшләр алдыннан госел коеналар. Госел һәм, гомумән, тәһарәт өчен *пакь су* булуы зарур. Коенган вакытта уң җилкәдән башлау һәм баш очыннан коену дөрес хисаплана. 2.*Возуэ* — тулы булмаган юыну, кече тәһарәт, тәһарәт сәгыйрь. Намаз алдыннан эшләнә: битне, терсәккә чаклы кулларны һәм аякларны юу тиеш. 3.*Тәяммем (тәйәммүм, тәяммом)* — якын-тирәдә пакь су булмаганда яки башка аерым очракларда (су ике чакрым чамасы ерак булса, су белән тәһарәт алып шөгыльләнү аркасында җеназа яисә гаед намазларына өлгерә алмый калырлык булса һ.б. шундый мөһим сәбәпләр булганда) ком (җир заты) белән тәһарәт алу рөхсәт ителә. 4.Очы юешләп чукланган махсус агач таякчык — *мисвәк* белән тешләрне чистарту (*тасвик*). 5.*Истинҗа кылу* — олы һәм кече хаҗәтләрне үтәгәннән соң гаурәт җирләрне юу. 6.*Мәсех* — өс-баш һәм аяк киемнәрен юу һәм чистарту.

Тәһарәтханәгә кергәндә сул аяк белән атлап керергә, чыкканда исә уң аяк белән атлап чыгарга кирәк дигән кагыйдә бар.

Торакны җыештыру һәм җилләтү, савыт-сабаны чистарту, нәҗесләнгән урыннарны су агызып юдырту, шулай ук мәетне юу да тәһарәт гамәлләренә керә.

---

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче санынннан басылып килә.*

Тәһарәтнең зарурлыгы һәм аның гамәлләрен ничек кылу турында төрле мәзһәбләр арасында фикер төрлелеге (*ихтиляф*) яшәп килә.

"Ий мөэминнәр! Әгәр намазга басарга теләсәгез, башта тәһарәт алыгыз, ике кулыгызны терсәкләре белән һәм битегезне юыгыз, кулыгызны юешләп башыгызны сыйпагыз һәм дә аякларыгызны тубыклары белән юыгыз. Әгәр җөнүб булсагыз, юынып пакьләнегез! Вә әгәр сырхау яки сәфәрдә булсагыз, йә берегез даладан килсә, йә хатыныгызга якынлык кылсагыз, шушы хәлләрдә юынып пакьләнергә су тапмасагыз, пакь җиргә ике кулыгызны сугыгыз, шул кулларыгыз белән битегезне сыйпагыз, икенче мәртәбә җиргә сугып ике кулыгызны сыйпагыз! Аллаһ сезгә тарлыкны теләми, бәлки сезнең пакь булуыгызны тели һәм нигъмәтләрен сезгә тутырып бирергә тели, шаять биргән нигъмәтләренә шөкер итегез!" ("Маидә" сүрәсе, 5:6, "Коръән тәфсире" буенча). Коръәннең үзендә тәһарәт кагыйдәләре бу кадәр тәфсилләп аңлатылмаган. Әүвәлге мөселманнар бу мәсьәләдә Пәйгамбәрнең ничек тәһарәт алуына ияргәннәр һәм Аның гамәлләре Сөннәгә кагыйдә сыйфатында кертелгән.

Тәһарәт алганда укыла торган дога: *Аллаһүммә таһһир кальби вә җәнабәти вәл-кәраһәти*-Аллаһым! Кальбемне һәм тәнемне шакшы-пычраклардан арула.

//*Тәһарәт бозылу (сыну). Тәһарәт төзү. Тәһарәт яңарту.* Кайчагында сөйләм телендә *тәрәт* дип кенә әйтелә, ләкин *тәрәт* сүзе татар телендә башлыча кеше тизәге, олы йомыш мәгънәсендә йөри.

***ТӘШӘББЕС*** *г.* – **1**.Инициатива, бер эшкә тәвәккәлләп тотыну; башлам. //*Шушы ук даирә, Англиянең сәүдә һәм санагать вәзарәтенә мөрәҗәгать итеп, аннан Русия белән сәүдә мөнәсәбәтен башлауны Англия хөкүмәте үз тәшәббесе белән эшлиме, әллә бу эшне хосусый кешеләр кулына бирәме? — дип сораган.* Ф.Әмирхан. **2**.Тапкырлык. //*Мәрхүм Шакир әфәнденең шаян дикъкать сыйфатларыннан берсе дә андагы фикер тәшәббесенең вәсгатедер.* Р.Фәхреддин.

***ТӘШӘББЕСАТЫ МИЛЛИЯ*** *г.* – Милли башлангыч, милли инициатива. //*Соңгы елларда Русия мөселманнары мәркәзләренең һәрберендә тәшәббесаты миллия ясалып торган вакытта, Казан боларның һичберсенә юньләп иштирәк итмәде.* Ф.Әмирхан.

***ТӘЭМИН АКЧАСЫ*** *гт.* – Залог итеп бирелә торган сума. Мәс., элекке "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенә кабул иткәндә шәкертләрдән "ун сум *дәхүлия* һәм өч сум *тәэмин акчасы*" алынган. Мәдрәсә нәрсәсенә зыян итмәгән шәкертнең тәэмин акчасы яз көне үзенә кайтарылган.

***ТӘЯММЕМ*** *г.* – "Ул төзәтте" мәгънәсендәге "*амма*" сүзеннән. Чистарыну (мәс., госелләнергә су табылмаса, ком, чиста тузан белән тәһарәт алу — пакь җиргә ике кул белән сугып, йөзне һәм кулларны сыйпау). Бу турыда "Ниса" сүрәсенең 43 нче аятендә әйтелә. Хәдискә караганда, ком белән тәһарәт алуны рөхсәт иткән аять Пәйгамбәргә яу сәфәре вакытында назил булган. Бер хәдистә Аммар бин Йәсирнең яу сәфәре вакытында, тулы тәһарәтне имитацияләп, комда аунавы турында ишеткәч, Мөхәммәд Пәйгамбәрнең: "Хактыр ки, сиңа шушылай эшләсәң дә җиткән булыр иде", — дип, учларын җиргә тидерүе һәм, аларга өреп, аннары битен һәм кулларын сыпыруы турында әйтелә.

*Тәяннум кылу* — пакь җир белән тәһарәт алу. Тәһарәт алуның беренче төре — *вөзүэ*.

Хәзерге матбугатта *тәяммүм* һәм *тәяммөм* язылышлары да очрый. Иң кулае *тәйәммүм* дип язу булыр иде.

***ТЕЛМӘРЧЕ*** – "Борынгы төрки ханның хезмәт штатында ишек агасы, сакчы, ярлыкчы, бетекче, казначы, боерчы белән беррәттән тылмарчы яки телмәрче дә булган. Ул борынгы дастаннарны сөйләп, үгет-нәсихәт биреп, сугышчыларны рухландыру белән бергә тылмачлык итү белән дә шөгыльләнгән" (Р.Әхмәтьянов). Татар теле диалектында "телмәр" — *телчән*, башкорт телендә "телмәр" — *нотык*. Ихтимал, тылмач сүзе шуннан килеп чыккандыр.

***ТЕРНӘК*** *бор.төр.* – "Древнетюркский словарь"да ике мәгънәсе күрсәтелә:

"1.Союз, җәмәгать, өммәт. 2.Җыелыш, шура (совет)." "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә исә түбәндәге мәгънәләре теркәлгән: "1.Таган аягы. 2.Ярдәмче, дус, иптәш." Бу мәгънәләрне "таяныч" сүзе берләштерә шикелле. Ә "тернәкләнү" фигыленә килгәндә, аның туры мәгънәсе "өммәт-җәмәгать арасына керү, үзләшү"гә тарта. "Аякка басу", "рәткә килү" мәгънәләре икенчел булса кирәк.

***ТЕШ КАРАЛТУ*** – Электә өлкән яшьтәге татар хатын-кызлары махсус хәзерләнгән онта белән тешләрен каралта торган булганнар. Бу онта фисташка (пестә) агачында була торган "шешек" яки гөмбәне төеп һәм тимер яныгы белән катнаштырып ясалган. Н.И.Воробьев аны *"таш-калы"* дип атый һәм бу гадәтнең безнең якларга ислам белән Төркестаннан кергәнлеген искәртә. Ярлырак хатыннар тешләрен чикләвек төнәтмәсе белән каралта торган булганнар. Кыз-кыркын тешен каралтмаган.

***ТИГЕН*** *бор.* – Келәймә. Электә арзанлы металлардан ялган акча ясауны булдырмас өчен, көмеш акча кисәкләренә тиген сукканнар.

Тагын кара: ***ТИЕН; ТӘҢКӘ; АКЧА.***

***ТИЕН*** – Вак акча берәмлеге, бер сумның йөздән бер өлеше. Тарихи күзлектән карaганда, бу термин электә товар алмашу берәмлеге булып "тиен" тиресе йөргәнлегенә ишарәли. Безгә күрше халыкларда да "тиен" сүзе бер үк вакытта җәнлекне һәм акча берәмлеген белдерә (мәс., марича – *"игур"*, мордвача – *"ур"* сүзләре). Русларда да тиен (*белка*) тиресе акча берәмлеге хезмәтен үтәгән. Татарда "Эшләгәнгә койрыклы тиен, эшләмәгәнгә койрыксыз тиен" дигән мәкаль дә йөргән. Гарәп сәяхәтчесе Ибн-Рустә X гасыр башларына нисбәтле хәбәрендә: "... аларның [болгарларның] иң төп байлыгы – сусар тиресе. Аларның суккан акчалары юк. Чылтыр акчаны аларда шул сусар тиресе алмаштыра. Һәр тире ике ярым дирһәмгә бәрабәр. Ак эре дирһәмнәр аларга товар алмашу хисабына мөселман илләреннән килә." Билгеле булганча, русларда да *кун* (*куница*-сусар) акча берәмлеге булып йөргән. Чыганаклардан болгарларның кара төлке тиресен Төньяк Африкада 100 динарга сатулары билгеле. Кызыл динар арзанрак булган, ихтимал, ул кызыл бакырдан коелгандыр.

Тарихчы Әзһәр Мөхәммәдиев икенче бер гипотеза тәкъдим итә: "Затлы металларга арзанлы металлар кушып ялган акча ясауга комачау итү өчен, дәүләт власте металл акчаларга келәймә суга башлый. Борынгы төрки телдә келәймә *тиген* дип аталган. Без хәзерге тиен сүзе җәнлек тиресеннән түгел, ә шул тиген сүзеннән килеп чыккан дигән фикердә торабыз," – дип яза ул. Бу гипотеза җитәрлек нигезле дә була ала.

Тагын кара: ***АКЧА; ТИГЕН; ТӘҢКӘ.***

***ТИМЕРКАРА*** – "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә бу сүз "Легендар ат, төн символы" дип аңлатыла һәм иллюстрация итеп "Тимеркараны акбүзат куа, акбүзатны күкбүзат куа" һәм "Тимерказыкка тимеркара бәйләнгән" дигән ике табышмак китерелә. (Җаваплары – төн, көн, кич һәм төн.) Билгеле булганча, *Акбүзат* белән *Күкбүзат*, шулай ук *Тимерказык* – реаль йолдызлар (барысы да Кече Җидегән "чүмеченең" сабында урнашканнар). Чыннан да, Тимеркараны реаль йолдыз белән тәңгәлләштереп булмый, ул тулаем төнге күкне сурәтли шикелле.

***ТИМЕРКӘН*** *бор.төр.* – Ук очы, ук башагы, сөмәк. "Древнетюркский словарь"га "темүркән" рәвешендә теркәлгән.

***ТИРӘН КАЗЫП ТҮБӘ КҮМҮ*** *тар.* – Төрки-монгол эпосында еш очрый торган гыйбарә. Гүрне тирән казып, курганны биек өеп, хөрмәтләп күмү йоласы.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# СИМВОЛЛАР СЕРЕ

Илсөяр Иксанова—үз шигырьләрендә образлы фикерләү ярдәмендә катлаулы сурәт тудыруы белән билгеле шагыйрә. Анын шигърияте эчке мәгънәне ачуга юл күрсәтүче символик образларга гаять бай.

Күнел лирикасы—кешегә хас булган ин хисле, эмоциональ кичерешләр гаммасын үзенә туплаган шигърият. Илсөяр Иксанованың 1991 елда дөнья күргән "Ышанасы килә" дигән китабы яшьлекнен әнә шундый ин ихлас шигырьләрен үз эченә алган иде. Шагыйрәнен тәүге шигырьләре тормышта үз юлынны эзләү, максатларны билгеләү кебек кабул ителә. "Кешеләргә ышанасы килә", "Гомер", "Сискәнү", "Кеше булса...", " ...Әллә ничек кенә үтә гомер" һ. б. шигырьләрендә лирик героиня традицион анланышта якты өмет символы булган йолдыз образын яратып куллана.

Ә ел фасыллары хисләр үзгәрешен билгеләп кенә калмый, шул хисләрне баерак, тулырак итеп күрсәтү өчен дә кулланыла. Җәй образы "Минем җәем", "Җәй сагышы", "...Мин җәйләрдә", " ...Бу—җәйнен беренче янгыры" һ. б. шигырьләрендә хисләрнен ин көчле, ялкынлы чорын гәүдәләндереп килүче символ булып торса, аерым шигырьләрдә традицион мәгънәсен үзгәртеп, сөйгән ярларны аерган фасыл, чор буларак анлашыла ("Юл арасы гына..."), җәйдән көзгә күчеш исә лирик герой күнелендәге сагыш хисләренен көчәюен символлаштыра.

Көз образы—И. Иксанованың бөтен иҗатын инләп алган, гел кабатланып килгән, шигъриятендә сагыш-хәсрәт агымын көчәйтүче символ. Анын башлангыч иҗатына караган "Көздә калдыр", "Көзге сагыш", "Хуш, яфрак", "Әбиләр чуагы", "Курыкмагыз", "Сонгы очрашу", һ. б. шигырьләрдә сагыш тойгысы ташый, тәлгәш-тәлгәш миләш детале дә "дөрләп янган сагышны" көчәйтү өчен кулланыла. М. Цветаевага багышланган "...Синен жанын мина күчкән мәллә" шигырендә соры көз шагыйрә гомеренен монсу, төссез, "жан өзелеп калган" халәтен белдерүче символ.

Шагыйрә көз вакытын тасвирлап, еш кына шигырьгә фәлсәфи эчтәлек алып керә. "Көзге фәлсәфә" шигырендә лирик герой исеменнән шагыйрә яшәешнен туу-үлем белән бәйле хисләрен тәкъдим итә. Автор кеше тормышында алышынып торган өмет-өметсезлек чиген күрсәтә, үлүне—көз, тууны яз белән символлаштырып, кешенен бу җиргә мәнгелеккә килүе искәртелә. "Гомер" шигырендә исә көз яшьлекнен үтүенә ишарә булып тора.

Мәгънә төсмере ягыннан көзгә якынайган кыш образы "Сагыш", "Җаным—буран", "...Телисенме, хисләремне", "Ак энҗе хисләрем" һ. б. шигырьләрдә хисләрнен төрле дәрәҗәсен, төрле төсмерләрен белдерә. Шагыйрәнен күнел лирикасына караган беренче шигырьләреннән "Кышкы янгыр" исемле шигырендә лирик геройнын сөюен онытырга теләп газаплануы ята. Беренче строфада буран көткән — мәхәббәтен югалтканга күрә хәсрәт тулы авыр тормыштан башканы өмет итмәгән—гашыйкнын янгырга, хисләрне искә төшерүче, янартучы күренешкә гаҗәпләнүе әйтелә. Аннары авыр үткәннән сон ("сине миннән алып киткән" чордан) юл бүгенгегә ("синен эзне, йөзне чагылдыручы үтә күренмәле пыяла") тоташа. Үз чиратында бу борылыш лирик герой күнелендәге хәсрәтне көчәйтә.

"Ак мон" шигырендә кыш һәм аккош образлары каршы куелып, "көзләрдән өреккән"—өметсезлеккә бирелгән—гашыйкларнын аерылуы, бергә була алмавы, хыялларынын чынга аша алмавы бәян ителә. Ә "...Телисенме, хисләремне..." дип

башланган шигырьдә лирик геройның яратуы, шул ук вакытта үз мәхәббәтеннән качуы кебек билгеләнгән каршылыклы хиснең сафлыгы кыш аклыгы белән янәшә куела. "Буран" шигырендә исә салкын кыш, ак буран детальләре аша лирик геройның — ялгыз җанның—җавапсыз хискә борчылуы яши. Лирик герой сөйгәненең аңа киләчәктә хис белән җавап бирәчәген көтеп юана, буранның салкынлыгын үзенә күчерергә өметләнә. Ә "Китмә миннән!" шигырендә лирик герой тормышның асыл мәгънәсен "ярыбызны эзләп якты дөньяга килү" дип билгели. Шигырьдә кыш символы шулай ук ап-ак кар, ап-ак сагыш, ак буран детальләре белән тулыланып, гашыйкның үзен сөйгән ярга җавап хисен белдерүе, әрнүле эндәшүе кебек аңлана, мәхәббәтен саклап калу өчен соңгы өмет кебек укыла.

"Өзмә өметемне" шигырендә лирик геройның сөйгәнен табуга ышанычын югалтуы ел фасылларының алышынуына бәйләнә. Көз—сонару, хыялның чынга ашмавы, югалуы символы. Кыш, яз, җәй вакытлары исә көтү чоры кебек аңлана. Лирик герой матур, татлы хыялларын—ак төс, өметенең кими башлавын исә зәңгәр төс белән аңлата. Ул җәйләрдә, шушы матур вакытта, үзендә дә үзгәрешләр көтә.

Димәк, И. Иксанованың башлангыч чор шигырьләрендә ел фасыллары белән бәйле күренешләр алар—лирик геройның сагыш хисен төрле төсмерләрдә ачучы символлар. Яшәешнең һәр мәлендә үзгә бер төсе табылган моң: "сары урманнарга сарылып исүче, яфрак шавы булып көйләүче, язда чук-бөре булып шытучы, ак моң булып карлар кебек очып йөрүче, ромашкалар булып аланнарда үсүче" ...Әнә шундый сагыш лирик геройның даими халәтен билгеләүче хис булып тора.

И. Иксанова алма, күбәләк детальләрен дә яратып куллана. Алма символы традицион аңланышта мәхәббәт бөтенлеген белдереп тә ("Алмагач"), мәхәббәт тудырган игелек, илаһи дәрәҗәдәге җылылык, изгелек өлгесе мәгънәсендә дә ("Алтын алма" шигырендә ул апасын алтын алма белән чагыштыра) кулланылып, рухи яктан бер-берсенә якын, туган җаннарның бербөтен булуын билгели. Лирик-фәлсәфи характердагы "Көзге алмагач" шигырендә алма, көзнең символик эчтәлеге белән кушылып, шул җылылыкның бетүе, юкка чыгуы турындагы мәгънәгә дә ишарәле. Ә менә күңел лирикасы белән фәлсәфи лирика чигендә торган "Хатын-кыз" шигырендә автор хатын-кызны алма белән чагыштыра. Биредә Сөйгән яр һәм Дөньяга мөрәҗәгать итү аша хатын-кыз мәхәббәт һәм тормыш бүләк итүче мәңгелек зат буларак идеаллаша.

"Күбәләк" шигырендә апасына—күбәләкнең эчке халәтенә—каршы чынбарлык, гасабилы яшәеш куела. «Кара төн» дип дөньядагы әшәкелек атала, ә кара төндә очкан ап-ак күбәләк исә матурлык сакчысы һәм изгелек үлчәме, дип бәяләнә. "Үзем белән хушлашу" шигырендә дә лирик герой яшьлеген, мәхәббәтен күбәләккә тиңли. Күбәләк биредә илаһи дәрәҗәдәге күңел сафлыгын, иң якты хыялларны, аларның тормышка ашуына берсүзсез ышануларны белдерүче сабыйлык символы.

"Могҗиза"—шагыйрәнең беренче чор иҗатында туган әсәр. Анда героиня сөйгәне белән матур тормыш кору, бала үстерү турында хыяллана. Ләкин бу шигырь аның тормышында һәм иҗатында яна дәвергә күчүе кебек тә аңлана ала. Лирик героиняның үзен бәхетле иткән күкләргә рәхмәте киләчәк тормышының да шулай ук барачагына өмет авазы белән кушыла. Мәхәббәтнең барлыгын, янәшә булуын тою шатлыгы яшәү мәгънәсе төсендә Илсөяр Иксанованың ире Илдар белән бәхетле гомер дәверендә кат-кат кабатлана ("Мин—ярына кайткан елга...", "Әллә соңлап, әллә нәкъ вакытында..." һ. б.). Бу әсәрләрдә матур хисләр гайбәтне ияртми, мәхәббәт аңа каршы тора ала, матурлыкны тойган бәхетлеләр тик изгелек кенә йөртәләр, аларга барлык эшләрендә күзгә күренмәгән нәни, ләкин игелекле фәрештә ярдәм итә, саклый, ди автор. Фәрештә — кешенең матурлыкны аңлау, кабул итү, кадерләү дәрәҗәсе ул. Әлеге кичерешләрне дәвам итеп "Бала көткәндә" шигыре хатын-кызны билгеләгән төп гамәл — ана булырга әзерләнү чорында туган хисләрне яктырта. "Тормыш мәгънәсе" шигыре исә хатын-кызның яшәеш мәгънәсен "карынымда синең җаның—мәхәббәт тупылдавы" дип раслый.

"Туу" шигырендә хатын-кызның бала тапкандагы хисләре алына. Шигырьдә

хисләр үсеше бала тапкандагы хисләрне гомумиләштереп бирү кебек. Шигырь строфаларында тезмә саннары кабатланмау (биш, ике, ике, өч)—могжизага тиң күренеш дәвамында газап катыш иң олы шатлык кичергән хатын-кыз хисләрен көчәйтү алымы. Ике тезмәле строфалар баланың дөньяга килү мизгелендә ана кичерешләрен бөтен тулылыгында тасвир итә. Кырыгынчы кылы өзелергә җитеп газапланган ана әле яна туган сабые авазын ишетүгә бар газабын оныттырырлык шатлык кичерә.

И. Иксанованың бердәнбер кызы Айсылуга багышлап язылган шигырьләреннән "Кызым" исемлесе эчтәлекнең үзгә формага салынуы ягыннан игътибарга лаек. Янында кызы булудан чиксез бәхетле ана үз хисләрен бишек җыры көенә төреп сөйли. Беренче строфада сабыен "җанымнан өзелгән аклыгым", икенче строфада "бәгъремнән өзелгән җимешем" дип иркәли, соңгысында "йөрәгемнән өзелгән гомеремдер" дип көчәйтә һәм һәрбер строфада хисне үстергәннән үстерә бара. Ярым көйләп, ярым такмаклап, шигырь ритмына салынып укылуыннан чыгып һәм басымлы иҗекне салмаграк итеп уку соралып торуына, борынгы язма төрки шигырьдәгечә 11 — 11 үлчәменә корылган булуына нигезләнеп бу шигырьне гаруз формасына якыная, дип күрсәтергә мөмкин. "Кызыма бишек җыры", "Яз", "Мин әни булдым, әни" шигырьләрендә дә ананың балага булган хисләре кабатлана, алар яна төсмерләр белән баетыла.

Сөекле ирен югалтканнан соң Илсөяр Иксанова иҗатында аерым бер дәвер булып сагыш темасына караган шигырьләр языла башлый. "...Минем җанда инде мәңге үзгәрмәс бер хис бар. Ул — Ялгызлык",— дигән вакытта даими сагышка күнгән Шагыйрәнең моңлы күзләре, сабыр елмаюы сокландыра да, гаҗәпләндерә дә. "Фаҗига", "...Синдә бармы сагынулар", "Сусау", "Хушлашу", "Рәнҗү", "Мәңгелек моң", "...Синнән башка мин бәхетле булмам", "Бәхилләшү", "Илдарыма", "...Синсез язлар яз мени соң", "Өмет сорыйм", "...Үрти-үрти үрсәләнгән җанны", "Бүген", " ...Әйттемме авыр сүз", "...Синсез яши алмам кебек...", "... Синең кебек башка беркем булмас", "Китәсең...", "Ачы учак", "Таулар" һ.б. шигырьләрендә дә без авторның үзен, аның хисләрен таныйбыз.

Әйе, И. Иксанованың ирен тауларга озаткач язылган шигырьләре аерылу сагышы һәм аның кайтуын сагынып та, куркып та көтү авазы лейтмотив булып бара. Фаҗигале 1998 ел августыннан башлап бүгенге көнгәчә шагыйрә иҗатында төп образ булып мәхәббәт фаҗигасенә дучар булган ялгыз хатын, төп тема булып "Бөек Ялгызлык" тора. Фаҗига урынын билгеләгән тау образының бу чор лирикасында аерым урын алып торуы да табигый. Лирик герой өчен таулар—мәхәббәтнең иң биек ноктасы да ("Китәсең..."), һәркем омтылырга, җитәргә тиешле рухи үр, югарылык та, мәхәббәттән өстенрәк була алган, сөйгән ярларны аерган тинсез көч тә ("Таулар"). 1998 елның әрнү-сызланулы 11 августында язылган "Китәсең..." шигырендә тау—"язмышның без менәсе" биеклеге, түбәсе, мәхәббәт югарылыгы кебек аңлана. Ә соңгы строфада "ишелеп төште лә гомергә" дип тау образы аша белдерелгән әрнү чарасызлык, өметсезлек, сызлану ноктасына җиткерелә.

"Таулар" (2000) шигырендә исә тау гашыйклар ашкынган рухи үр һәм аларны аерган кыргый көч мәгънәсендә килеп, шигырьне ике өлешкә бүлә. Шагыйрә башта сөйгәненең ашкындырганы өчен тауларга үпкә белдерүен әрнеп әйтә. Өченче строфада лирик геройның бүгенге халәтен: ярты җаны сөйгәне белән күкләргә ашканга күрә, "үзенә дә сәер" психологик кома хәлендә калуы күрсәтелә.

Ә менә поэтик фикерне иркен агышка корып һәм иреклe формада язылган "Фаҗига" шигырендә лирик геройның хәсрәте ут, су кебек табигать стихияләре аша көчәйтелә. Бәхетле гомернең соңы—мәхәббәтнең тоткында калуы кебек бирелгән сулар януы, упкынга салынган утлар образлары ярдәмендә ачыла. Шагыйрә төн һәм таң, ут һәм су образларының каршылыгы аша фаҗигане романтик эстетика традицияләрендә көчәйтә. Шигырьнең һәр строфасында кабатланган метафора—төнге суларның януы—лирик герой хисенең чарасызлык ноктасына җитүен билгели. Ә киләчәкнең билгесез, шомлы булуын, кадерлесен җуйган хатын-кызда өмет югалуын шагыйрә сүнәчәк утлар, болганачак сулар рәвешендә бирә.

1998 елдан башлап иҗат ителгән "Соңгы сагыну", "Ачы учак", "...Син мине бәхетнең...", "...Таптым... яраттым...югаттым...", "...Ярый әле төшләремә кердең", "Язмыш" һ. б. шигырьләрендә әрнүле җанга дәва, күңелгә юану эзләү сизелә. "Ачы учак" шигырендә лирик геройның сагышын ачы учак эпитетына салынган ялгызлык халәте билгели. Табигатьтәге үзгәрешләргә дә, тормыш-яшәештә барган бар хәлләргә да битарафлыгы исә ("яңгыры бер миңа, кары бер") лирик геройның күңелендәге югалту ачысының дәрәҗәсен күрсәтә. Юану чарасы шул: тагын бер генә мәртәбә үзенең сөйгәнен—тормыш иптәшен—күрәсе, аның күзләренә карап сөенәсе килә. Лирик герой әсәрдә нурсыз тормышын көзге урман белән чагыштыра, ә үзен сары учакка тиңли. Традицион аңланыштагы ялгызлык сагышы символы булган сары төснең шигырьдә учакны ачыклап килүе—лирик геройның җанына урын таба алмавы кебек аңлана. Икенче строфада көзге урман инде көзге миләш белән алышына. Көзге миләш ачысы алсу учак белән янәшә килеп, хыялның ачы хәсрәт белән алышынганлыгын искәртә. Аннары лирик герой үзенең сагынуын кабатлап, көчәйтеп, урман һәм миләш символын балан дип үзгәртә, учакны билгеләүче ачы эпитеты исә мәхәббәтен югалткан ялгыз кеше хәсрәтенең даими булуын раслый. Мәхәббәт фаҗигасе шагыйрә иҗатында шулай ук язмыш белән килешү, аны кабул итү төсендә дә бирелә. Аларда сабырлык фәлсәфәсе өскә чыга: "Язмыш", "...Таптым... яраттым... югалттым" һ. б.

Илсөяр Иксанова иҗатында гражданлык лирикасы аерым урын алып тора. "Бәхет таны", "Азатлык елы" шигырьләре 90-еллардагы милли күтәрелеш, иҗтимагый аң үсешен чагылдыра. Аларда лирик герой—милли үзаны, омтылышы белән башкалардан аерылып торган милләтпәрвәр шәхес. Канатлы ат, акбүз ат, елан, эт, маймыл кебек мифологик образларны автор хис көчәйтү вазифасын үтәп килгән композицион каршылык алымы белән тоташтыра. Лирик геройның борчулы уйлары—оча торган ат символы аша, ә хөрлек, ирек турында хыялланып яшәүче халыкның авыр язмышка дучар ителүе—эш атына әверелдерелүе—өметләрнең киселүе дигән сүз. И. Иксанова романтик шәхес уйлары аша киләчәккә бәйле теләкләрнең җырда гына кала алуы турында да хәбәр итә ("...Их, Такташым.."), ерак үткәннәрдән бүгенгегә күчкән ап-ак бабай образы аша үз халкының матур киләчәгенә өмет җуелмавын да әйтә ("Исәнбәт белән очрашу"). Шагыйрә туган халкы күңелендә үз урынын да эзли. М. Әгъләмовка багышланган "Шагыйрь" шигырендә ул "хис ташкынын акыл тыялмау, артык гади, сәер булу" кебек сыйфатларны үзендә дә таба, күңел лирикасына караган "Матурлык", "Апатия" шигырьләрендә исә "җиргә нигә килү" кебек сорауларга җавап эзли.

И. Иксанова үз иҗаты белән тормышны символлар аша аңларга ярдәм итә. Ул яшәешнең барлык якларын да күрсәтергә омтыла, шигырьләре белән төрле темаларга туктала, аларда сагыш, моң, мәхәббәт кебек мәңгелек хисләр урын ала. Киләчәктә без әле шагыйрә И. Иксанованың янадан-яна шигырьләрен укып уйланырбыз, моңланырбыз, тирә-юньгә игътибар белән карарга—бәхет, мәхәббәт, яшәүнең кадерен белергә—өйрәнербез.

**Ләйсән ИШМИЕВА**

# «ТУГАН ҖИРЕМ ДӘ, ТУГАН КӨНЕМ ДӘ—ИКӘҮ...»

Кем ул Кадим Җәмит? 1999 елда Лондонда нәшер ителгән «Татар энциклопедик сүзлеге»ндә аның турында: «Җәмитов Кадим Җәлил улы (1946 елда туган), сынчы: «Су анасы» (1990), «Тукай» (1985), «Замандаш»—татар мәдәнияте эшлеклеләреннең портретлар сериясе (1992), Казандагы «Хөррият» скульптурасы (1996) авторы, 1973 елдан бирле Мәскәүдә яши», диелгән. Әйе, 2001 елда дөнья күргән «Кто есть кто в татарской общине Москвы» белешмә-китабындагы ике йөздән артык милләттәшебез арасында Кадим Җәмит тә бар. Аның иҗатына бу басмада бер бит урын бирелгән, фотосурәте дә урнаштырылган.



*Рәссам Кадим Җәмитов үз Тукае янәшәсендә.*

Аның тормышы, бигрәк тә балачагы бер дә гади узмаган. Сез мона, алга табарак укыгач, тулысынча ышанырсыз...

Мин аны кырык елга якын беләм дип курыкмыйча әйтә алам. Моны раслый торган дәлилем дә бар: шәхси альбомымда 1968 елның 9 Маенда—Җиңү бәйрәмендә җырчы Эльбрус Сибгатуллин, рәссам-баянчы Вил Гарипов, нәфис сүз остасы Хәйдәр Һадиев (өчесе дә вафат инде, бу язмам аларга дога булып барып ирешсен) һәм Кадим Җәмитов бергәләп Шәмәрдәндә төшкән фоторәсем саклана.

Дөрестән дә, Кадим гомере буе Вил Зариф улын үзенең остазы итеп саный, аны хөрмәт итә. Җырда әйтелгәнчә, юкка түгел, юкка түгелдер. Бик иртә рәсем сәнгате белән мавыга башлаган Кадим, Иске Икшермәдә чагында ук, Шәмәрдәндә балаларга рәсем дәресе бирүче, шул бистәдәге промкомбинат клубын да җитәкләүче, Саба-Шәмәрдән урамнарын Ленин сурәте һәм урак-чүкеч төшерелгән плакат-әндәмәләр белән бизәүче рәссам турында ишетә һәм ярты юлын җәяү, калганын машина белән аның янына килә. Ижаудагы Удмурт педагогия институтында белем алган кин күнелле Вил абыйсы аны җылы кабул итә һәм бик теләп гамәли дәресләр бирә башлый. Тора-бара Кадим остазы укыган институтның графика сәнгате бүлегенә керә.

Ә инде 1969 елда, яшем җитеп, мин хәрби хезмәткә алынгач, безнең юллар аерылды...

1996 ел. Мине, инде унбиш ел район газетасын җитәкләүче мөхәррирне, ул

вакыттагы хакимият башлыгыбыз Фәрит Гыйльмиев үзенең бүлмәсенә чакырып шалтыратты.

—Мәскәүдән Икшермә мәктәбендә бергә укыган сабакташым кайткан. Кинәшләшәсе мәсьәлә бар иде,—диде ул.

Киллем, башлык бүлмәсенә кердем. Бу мизгелдә район хуҗасы үзе телефоннан сөйләшә иде...

Һәм.. Чирек гасырдан соң булса да, Кадим белән бер-беребезне бик тиз танып алдык. Җылы итеп исәнләштек. Бу минутларда Фәрит Гыйльмиевич та бермәлгә аптырап калды һәм:

—Сез ничек танышлар әле?—дип сорады.

...Олы сәнгатькә юл ярганчы Кадимгә шактый сикәлтәләрне узарга, дөньяның ачысын-төчесен татырга туры килә. Ижау педагогия институтында төп белгечлек буенча дәресләрнең тирәнлеге, масштабы аны канәгатьләндерми башлый. Өч курсны бетергәч, ул Мәскәүгә китә һәм Югары сәнгать техникумына укырга керергә омтыла. Аннары армия сафларына алына, анда да рәссам-сынчы «айт-два»га йөрми. 1973 елда янадан Мәскәүгә кайта. Башта СССР Рәссамнар берлеге каршындагы иҗат яшьләре берләшмәсенә йөри. Аннары биш ел буе Владимир Табах остаханәсендә сәнгатьнең нечкәлекләренә төшенә. Якташыбыз шунда профессионал булып китә. Гипс, таш, агач, бронза, шамот (эреп, пыялаланганчы яндырылган аерым төр үзле балчык) кебек материаллардан күп кенә сыннар ясый. 1983 елда ул Россия рәссамнар берлеге әгъзасы итеп кабул ителә. Иҗади әсәрләре дә күргәзмәләрдә еш күренә башлый. «Курайчы» дип исемләнгән сыны тәүге мәртәбә 1971 елда автономияле республикаларның Бөтенсоюз күргәзмәсендә урын ала. Якташыбызга 1985 елда Германиядә уздырылган «Сын-сурәт һәм мохит» дигән тематик күргәзмә яна уңышлар китерә. Аның бакырдан чокып эшләнгән «Шатлык» исемле әсәре табигый зурлыгында хатын-кыз сыны була. Ана бик олы бәя бирелә һәм Мәскәүдәге атаклы Третьяков галереясенә сатып алына. Хәзер инде Кадимнең үндүрт әсәре әлеге галереяда урын алып тора. Бу язмада К. Җәмитнең барлык иҗат җимешләрен дә санап чыгу мөмкин түгел, әлбәттә. Аның талантының үзенчәлеге шунда: ул милләтебезнең рухына, хис-тойгыларына, әхлакый-эстетик көченә, нечкәлекләренә тирән үтеп керә. Мәсәлән, Санкт-Петербургта «Татар-91» күргәзмәсендә аның «Мөселман карты» аеруча зур уңыш казана.

Гомумән, мөхтәрәм якташыбыз иҗатында татар милләте вәкилләре зур урын алып тора, хосусан үзебезнең милли сынлы сәнгатебезне үстерүне максат итеп куя ул. Ә инде Австриядә булып үткән күргәзмәдән аның «Савыгу» әсәрен Венадагы Милли нәфис музей сатып ала. Хәзер ул андагы бер мәйданны бизи.

Кадим Җәмитов иҗатында Тукай һәм аның замандашлары Галиәсгар Камал, Сәгыйть Сүнчәләй, Камил Мотыйгый, Фатих Әмирхан, Сәгыйть Рәмиев һәм башкалар образлары киң урын алып тора. Аның бигрәк тә Г. Тукай әсәрләренә, татар халык иҗатына ихтирамлы булуы күзгә ташлана. Бу темаларга сынчының 1990 елда Мәскәүдә беренче шәхси күргәзмәсендә булучылар аеруча игътибар итә. Монда аның төрле жанрдагы утыз дүрт әсәре куелган була. Ул 1991елда Казанда татар сәнгате күргәзмәсендә катнаша. Анда Мәскәү, Санкт-Петербург, Уфа, Алма-Атада яшәүче иҗатчыларның хезмәтләре күрсәтелә. К. Җәмитовның үнике әсәре аеруча югары бәяләнә. Ә инде 1994 елда аның шәхси күргәзмәсе «Казан» милли мәдәни үзәгендә ай буе эшләде. Аны ачу тантанасында районыбыз делегациясе дә катнашты.

«Исеме дә, эш-хезмәтләре дә болгар-татар халкының бәгырь үзәгенә җуелмас рәвештә язып калынган Бакый Урманче, аннары Васил Маликов, соңында Кадим Җәмит иң мәртәбәле бер сынчыбыз сыйфатында хөрмәтләнергә, кадерләнергә лаек булган шәхесләребездән берседер»,—дип язды үзенең «Оста дөньясы» дип аталган бәяләмәсендә танылган прозаик Әхәт Гаффар.

...Кадим Казанга Австрия, Чехо-Словакия, Германия, Франция, Бөекбритания, Япония, Америка, Корея, Канада кебек илләрдәге күргәзмәләрдә катнашканнан соң Мәскәү аркылы кайтып төште. Шулай итеп, сынчының язмышы башта СССР башкаласында сыналды. Ә бит байтак шәхесләр, киресенчә, Казаннан Мәскәүгә китәләр. Хәзер Кадим Җәмитов башкалабызда, районыбызда еш була. Сабалыларга билгеле булганча, ул 1995 елда Татарстан милли музееның районндагы филиалына бер дистә иҗади эшен бүләк итте. Алар арасында дөнья күләмендәге танылган икенче якташыбыз—академик, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Әбрар Кәримуллин бюсты да бар иде. Әлеге тантанада атаклы китап галиме Әбрар ага үзе дә катнашты. (Биредә Кадим Җәмитнең Ә. Кәримуллин кебек танылган утызлап татар шәхесләренең бюст-портретларын эшләвен дәвам итүен дә искәртү кирәктер). Бу изге гамәле белән Кадим әфәнде үзен талантлы гына түгел, киң һәм юмарт күңелле, туган ягына тугрылыклы изге җан икәнен дә күрсәтте.

2005 елга аяк басканда ул үскән төбәге булган Икшермә авылындагы «Тургай» балалар йортына—Тукай бюстын бүләк итте. Бөек шагыйребезнең тууына 120 ел тулу уңаеннан, аның бюстларын тагын биш-алты мәктәпкә тапшырды.

Еллар үткән саен Кадим Җәмит иҗат иткән «җанлы сыннар» саны арта тора. Җәлилнең Оренбург шәһәрендәге һәйкәле дә аныкы. Татарстан Республикасының Президенты Минтимер Шәймиев, Россиянең һәм Татарстанның атказанган урманчысы Нургали Миннеханов бюстларын да Кадим Җәмит ясады. Нурлатның үзәк мәйданына куелган шәһәр символы Нурлы Атның авторы да безнең якташыбыз.



*Академик Әбрар Кәримуллин үзенең бюсты янында. (Саба).*

Атаклы артист Владимир Дуров нигез салган «Җәнлекләр театры» бар Мәскәүдә. Шуның 75 еллыгы уңаеннан үзе ясаган җәнлекләр-кошлар күргәзмәсе белән Кадимне дә чакыралар. Биредә сынчы иҗаты белән юбилейга килгән КПССның Мәскәү шәһәре комитеты беренче секретаре Виктор Гришин (1914—1992) таныша һәм соныннан К. Җәмит аның әмере белән башкаланың дәрәҗәле районыннан өч бүлмәле фатир ала.

Гаилә хәленә килгәндә, җәмәгате—үзебезнең Иске Икшермә авылы тумасы Нурзия белән матур тормыш корып, бер кыз һәм бер малай тәрбияләп үстерделәр. Хәзер Рәзидә Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында белем ала. Гали (борынгы шагыйребез Кол Гали күздә тотылып кушылган) әле мәктәптә укый. Гаилә башлыгы, танылган сынчы булу өстенә, әдәби иҗат белән дә мавыга. Аның хикәя-эсселары республика газета-журналларында еледән-әле басылып тора. Кадим Җәмит үзенең гыйбрәтле балачагы, яшүсмер чоры, армия хезмәте еллары, гомумән, шәхси тормышы турындагы күләмле автобиографик повестен тәгаләп килә.

Менә шушы урында бу язманың авторына, бәлки, нокта куярга да кирәк булгандыр...

Әммә... минә шул «әммә»лар җанны телгәли шул. Әлеге очеркны әзерләгәндә миңа шактый чыганаклар—энциклопедияләр, китап-белешмәләр актарырга,

героемның тәрҗемәи хәле турындагы мәкалә-бәяләмәләр белән танышырга туры килде. Аларның барысында да: «Кадим Җәлил улы Җәмитов Саба районының Олы Арташ авылында 1946 елның 15 январенда туган»,—дип язылган. Юк! К. Җәмитов әби-бабаларының кендек каны тамган газиз җирендә тумаган шул! Дөньяга аваз салган көне дә унбише түгел. Елын әйткән дә юк. Кадим Җәмитнең 60 яшен тутыру форсатыннан файдаланып, хәзер дә чын хакыйкатьне каплап торган чуар пәрдәне бераз гына ачып, талант иясенең кайчан да булса дөнья күрәчәк автобиографик повестеннан өзек китерик әле.

«...Әсирлектә булган анам белән ерак Германия җиреннән кайтып төшкәнмен мин. Алты айлык чагымда. Мине яшереп тотарга тиеш булганнар. Барлыгымны белдермәс өчен. Югыйсә «нимес көчеге» дип теткәләп ташларлар иде. Шулай итеп, өч яшькә кадәр якты дөнья, чит кешеләр күрмәдем мин Сталин илендә...»

Әйе, Кадимнең барлыгын башта өч кенә кеше—әбисе, энисе һәм туган тиешле абыйсы гына белә. Аларга күрше-тирә дә сугылмый. Бик тә ярлы булалар чөнки. Әбисе биләмгә үзе генә чыккалый, эт-баш, сыер-аяк, эшкә чыксан—бер таяк заманы булса да, энисе фермадан кайтып керми. Тәпи йөри башлаганнан бирле сабый өчен коты очканы «кеше...» була. Әбисе ана һәрдаим: «Тәрәзә янына киләсе булма, кеше алып китәр, өйалды ишеге төбендә аждаһа көтеп утыра, кабып йотар!»—дип тукый.

Мунча кебек кечкенә, эчтән-тыштан тирәүле өйдә Кадимнең яши торган җире өч «биләмә»дән тора. Чолан, түбәнөй, кыш көне—мич башы. Ул шунда ашый да, йоклый да, уйный да. Уен диганнән, аның «иптәшләре» дә, уенчыклары да кара таракан, кондыз, олы чебен, күбәләк, өй бакасы... соңрак—тычкан, мәче, эт кебек җан ияләре була. Җитмәсә, имидән иртә аерырга теләптер инде, энисе сабыена үз телен үзе суырырга өйрәтә. Тора-бара, гел хәрәкәттә булгач, теле зураеп китә, ияге дә алга чыгып, соныннан, үзе әйтмешли, берничә бүлемтекле «өнендә» яши торган җәнлеккә охшый башлый ул...

Кыскасы, тышкы дөньяның нәрсә икәнен белми шул. Әмма әбисеннән «кояш чыкты», «кояш кыздыра», «кояш сүрелде», «кояш баеган вакыт» дип сөйләгәненнән аның барлыгын, куктә «йөзеп йөргәнен» чамалый бала. Тыштан терәтелгән ишекне ачып чыгып, куктә янып торган түп-түгәрәк нәрсәгә карап торгач, күзләреннән яшь ага башлый... Шуннан соң, бәбәкләре шешеп, берни белмичә озак кына авырып ята.

«Бүгенге көндә Казан калабызның тамгасы булып балкып торучы Хөррият һәйкәле «кошын» шул сабый чакта саташып ятканда төшемдә күрдем. Кояш кебек күк йөзендә янып тора иде ул... Кырык җиде елдан соң исемә төште шул Һомай кошы...—дип искә ала рәссам.

Савыккач, тагын ишегалдына тартыла. Башта этәч, тавыклар, аннары кәҗә белән «таныша». Көннәрдән беркөнне боларга әбисенең ерак туганнары–ирлехатынлы кешеләр бер кичкә килеп китәләр. Шулардан соң авылда: «Тегеләр гарип, бөкре балаларын калдырып киткәннәр»,—дигән сүз тарала. Барлык каршылыкларны җиңеп, Кадим урамга ыргыла. Бу вакытта инде гаепсез сабыйның Германия җиреннән кайтканы да ачыклана. Олылар карап торып балалар көрәшә торган урында булган вакыйганы Кадим болайрак итеп искә ала.

Анда беренче мәртәбә килеп чыкканда тышкы дөнья белән таныша башлаган гына чак. Минем барлыгымны, килмешәк булып Германия җиреннән кайтуымны бөтен авыл белә иде инде. Ул көнне башта мине сырып алдылар. Аннары сүзсез генә карап тордылар, араларыннан берсе әйтеп куйды:

—Шушымыни инде ул туганнары калдырып киткән гарип малай?

—Нишләп инде... Җилдән туган үз баласы бит ул аның...

—Беләсез икән пычагымны! Герман җиреннән алып кайткан килмешәк бит ул...

—Маймыл баласыдыр ул—әнә бит, ияге чыккан, телен асылындырган, үзе

бөкре...

Менә шулай дәвам иткән әңгәмәдән соң, бер егет:

—Йәгез, малайлар, шушы нимес көчеген сала аласызмы, көрәшеп карагыз әле,—дип команда бирә.

Шуны гына көтеп торган, Кадимнән хәйран гына олы малайлар моны дөмбәсләргә тотыналар.

Канга батып кайта өенә канатсыз кош баласы. «Үзен сугышкансыңдыр әле»,—дип каршы ала аны әбисе һәм чолганына бикләп куя.

Тере була Кадим. Әмма «токмачлар» гел куерып тора. Кызамык авыруыннан да, колхоз фермасыннан качкан үгезнең мөгезенә эләгә-эләгә, котыра-котыра «туп итеп» уйнавыннан да исән кала...

Үзен-үзе белә башлаганнан бирле күңеле сурәткә тартыла баланың. Дөрләп янган учакка карап торырга ярата ул. Аның ялкынында әллә нинди сихри көч, тере сурәтләр күрә.

Баскыч төпләренә әбисенең бабасы чорыннан ук калган зур-зур ташлар салынган була аларның. Шуның чәрдәкләнгән бер кисәген алып, баскычка сызгалый Кадим. Тора-бара әллә нинди сурәтләр килеп чыга, баскычны тутыргач, капка белән койманы бизәкләргә тотына.

Мич башында ятканда түшәмдәге ботакларны, алар тирәсендәге сызык-эзләрне дә могҗизалы «шайтаннар», «җанварлар» итеп күрә булачак сынчы. Аннары әбисе ипи йә көлчә пешергәндә камырдан вак-төяк фигуралар ясап, шуларны кызган кирпечкә тезәп пешереп, ашарга ярата...

«Рәсем җене» бик иртә кагыла шул Кадимгә. Әнисе мәктәптә җыештыручы булып эшли башлагач, ярдәмгә малаен да алып бара. Бер класста парталар арасыннан карандаш кыйпылчыгы таба ул. Өйләренә кайткач, шуны бармак арасына кыстырып, ак моржага сызгаларга керешә. Алар рәсем кыяфәте ала. Кадимнең күңелендә уелып калган тагын бер хатирә бар. Төсле карандашлар белән бәйле вакыйга монысы. Ул заманда мунча һәр хуҗалыкта булмый. Беркөнне аның әбисе юынырга дәшәләр. Кадимне дә ияртә ул. Мунчага бара торган кешеләргә юл авылдагы бердәнбер кибет аша уза. Андый чакта бала шунда сугылмый түзәме соң?! Керәләр, әбисе, озак тормыйча куып җитәрсең, дип китеп бара. Ә Кадим пыяла астындагы нәни-җыйнак кына, яртылаш ачылган кечкенә генә тартмадан ялтырап күренеп торган алты төрле төстәге түгәрәк таякчыкларны күреп, тораташтай катып кала. Кибетчедән сорап алып, тотып карый, аннары сихерләнгән кебек була, авырлык белән булса да кечкенә тартманы кире кайтарып, әби белән мунчасын берьюлы онытып, өенә йөгерә һәм матчага кыстырылган кәгазь төргәктә икегә бөкләнгән өч кәгазь акча барлыгын исенә төшерә.

Шуларны эләктереп, кибеткә мышнап килеп керә ул. Сатучы Хурҗиһан апасы сабыйның рәсемгә хирыслыгын белә, шулай да: «Йә, әйт әле, кайдан алдың бу акчаларны?»—дип сорый.

«Әби бирде»,—ди бала. Кибетче ышанып бетмәсә дә, кызганыптыр инде, карандашларны балага тоттыра һәм: «Калган акчаны әниенә бирермен»,- ди югалтуыннан куркып.

Үзләре төсле уттай янып торган, исләре үк тәмле булган карандашларны эләктерү белән куанып-шатланып өенә кайтып керә һәм, кеше юклыктан файдаланып, аларны очларга керешә. Шул мизгелдә әбисе кайтып керә дә: «Денсез! Тукта, шайтан малае! Калганнарын очлама—әниең кайтыр да илтеп бирер!»—дип кычкыра. Аннары акча төргәген барлап килә һәм елый башлый.

Сабый бу хәлгә аптырап кала, чөнки аның әбисен беркайчан елатканы булмый.

—Әби, җаным, мин ул акчаларны эшләп түләрмен, менә күрерсең!

Дөрестән дә, алты елдан соң, авылдашларының резин итекләрен ямап-

ябыштырып кайтара ул әлеге акчаны.

Әнисе кайткач, давыл яңадан бер «котырып» ала. Һәрбер тиен хисапта була шул ул заманда. Әни белән әби тагын бер тапкыр «дуэт» ясап елашып алалар. Кире илтеп кенә бирерләр иде, очланганнар бит. Шулай итеп, карандашлар үзенә кала гөнаһсыз сабыйның. Ә инде очраклы килеп чыккан кәгазь кисәгенә тәүге төсле сызыклар төшергәндә ниләр кичергәнен бүген дә онытмый Кадим. Чөнки бу аның күптөсле дөньяга беренче адымы, Бөек Матурлык патшалыгына керүе була...

Хөрмәтле укучым! Мин К. Җәмитовның «Истә калганнары»ннан берничә генә мисал китердем. Әнә шундый күңелләрне тетрәндерә, йөрәкләрне телгәли торган эпизодлар бик күп була сынчының тормыш юлында. Алары турында инде чыгачак китабыннан укырсыз. Авторның үз дөньясы гына түгел, авыл халкының авыр тормышы да сурәтләнә ул хәтер-хатирәләрдә.

—Исемсез кеше булмый,—дип искә ала Кадим.—Ул адәм баласына тугач та бирелә. Дүрт яшьләр тирәсендә генә барлыкка килде ул минем. Ягъни тышкы дөнья белән аралаша башлагач. Таныклык алганда булгандыр инде ул. Җитмеш җиде көнгә сонрак туган итеп теркәгәннәр мине. Шулай итеп, минем туган җирем дә, туган көнем дә икәү... Миңа исемем белән юньле-башлы эндәшүче булмады. Укый башлагач кына яңгырый башлады ул. Таныклыгымда фамилиям Җәмитов булса да, жиденчене бетергәнчегә кадәр әбием фамилиясе белән—Миннеханов булып йөрдем. Ә «әтием» Җәлил Җәмит улы дип теркәлгән иде. Анамның кыз вакытта Донбасста танышкан егетенең исеме булырга тиеш ул.

...Нәкъ җитмеш җиде көн алдан котладым мин Кадимне 60 яшьлек юбилее белән. Телеграмманы алгач, аптырап калган ул. Чираттагы шаярту, дип уйлаган. Телефоннан аңлаштык аннары.

—Ул көнне үз гомеремдә бер кешенең дә котлаганы булмагач, башыма да килмәде,—диде.

Ярар, бу язманы табигатемә хас шаярту тонында төгәлләп куйыйк инде.

Икенче туган көне белән дә котладым аны районташлар исеменнән. Шуннан соң сүзебез иҗат мәсьәләләренә барып тоташты һәм аның сирәк кешедә була торган сынчылык талантының кан аша бирелүенә ишарә ясадым.

—Монысын әле расларга кирәктер. Мәнә син каләм тибрәтүеңне каннан килә дип уйлыйсыңмы?

—Әлбәттә,—дидем мин катгый итеп.—Минем бабай ягыннан туганнар арасында классик язучылар, шагыйрьләр бар бит...

—Кемнәр алар?—дип сорады Кадим Җәмит.

—Берсе—Кави Нәҗми, икенчесе—Нажар Нәҗми,—дидем.—Һәм... Тәлгат Нәҗми...

Ул ихлас күңелдән, эчкерсез итеп көлде.

Мәнә шулай гел елмаеп, озак яшә, Кадим! Арыма, талчыкма, алҗыма, вак-төяк хөсетлелекләргә, каршылыкларга бирешмә! Үзебез, кайчан да булса, барыбер бу фани дөньядан бакыйлыкка күчәрбез, дустым. Әмма иҗатың үлемсез һәм мәңгелек Синең!

**Тәлгат НӘҖМИЕВ,**
*Татарстанның атказанган*
*мәдәният хезмәткәре.*

Миркасыйм
Госманов

# СИРАТ КҮПЕРЕНДӘГЕ УЙЛАР

*Аны мин беренче мәртәбә күтмәгән, уйламаган жирдә курдем, шунда ук лекциясен дә тыңладым. Казанга килгәч тыңлаган беренче лекциям иде ул.*

Университетта имтиханнар башланудан берәр ай элегрәк килгәнгә, вакытым шактый иркен иде. Шуна күрә һәркөнне диярлек шәһәрнең төрле почмаклары белән танышып йөрдем. Татар бистәсен әллә ничә катлар гиздем, зиратка да каткат бардым, паркта да булгаладым. Шәһәр паркы монда да, күп жирләрдәге кебек, Горький исемендә икән. Ул шактый ошады үземә. Шуна күрә анда көндезләрен дә, кичләрен дә булгаладым. Кызыклы очрашуларга да тап булдым.

Бер көнне төштән соң ашыкмыйча гына үзәк аллея буйлап атлый идем. Каршыдан, татарча сөйләшә-сөйләшә, олы яшьләрдәге ике кеше якынлашты. Берсенең төс-кыяфәте, бөтен килеш-килбәте шундук игътибарымны җәлеп итте. Зур гәүдәле, таза, төп-төз буй-сынлы, элеккеләр әйтмешли, сүзнең чын мәгънәсендә солтанатлы кыяфәттәге ир-ат иде ул. Йөзчырае да үзгәчә матур. Кыска итеп кыркылган ияк очындагы чал сакалы белән мыегы да гаҗәп килешеп тора үзенә. Өстендә, җәй көне булуга карамастан, шул елларга хас модадагы зәңгәрсу-соргылт төстәге кыйммәтле габардин макентош, елкылдап торган ачык галстук, фетр эшләпә, кулында затлы таяк...



Гомумән, аның бөтен килеш-килбәте элекке чорлардан калган фотосурәтләрдән генә мәгълүм аксөяк зыялыларны, мәшһүр әдип-галимнәрне хәтерләтә иде. «Затлы татар интеллигентлары сакланып калган икән бу Казанда», дигән фикер узды баштан. «Бәлки, үземә дәрес бирәчәк олы профессорларның берседер бу? Илаһи, шулай булсын иде»,—дип тә теләп куйдым. Соклануданүзем дә сизмичә, татарчалап уң кулымны түшемә куеп: «Әссәламгаләйкүм!»—дип кычкырып сәлам бирдем.

Элек бездә тулаем хөкем сөргән, хәзер исә бары Урта Азия якларында гына бераз сакланган, минем аңыма бала чактан ук сеңеп калган гадәт буенча шулай сәламләдем. Безнең халыкны сабый чактан ук хөрмәтле олы кешеләргә шулай кычкырып сәлам бирергә һәм олы кешенең көр тавыш белән «Вәгаләйкүмәссәлам!» дигән хуплаулы җавабын ишетергә өйрәткәннәр иде...

Ләкин солтанатлы картым сәламемне алмады. Иреннәрен кыймылдатып та җавап бирмәде, ичмасам, башын гына булса да изәп куймады. «Бу нинди дивана нәрсә тагын!» дигән төсле, бераз гаҗәпләнгән, хәтта сәерсенгән салкын караш белән төксәйгән килеш күз сирпеп алды да, таяк очын югарыга бер чөеп, юлдашына таба борылды.

Узып та киттеләр. Нык-нык басып. «Киттеләр» дип күплек санында әйтсәм дә,

аларның икенчесе кем һәм нинди булуын бер дә хәтерләмим хәзер. Дөресрәге, шунда ук онытттым да шикелле мин аны. Әмма таяклы картның әлеге мәгърур килеш-килбәте бүгенгә кадәр күз алдында...

Шунысы кызык, бу мәһабәт кыяфәтле кешене беренче кат күргән мәлдә уйлаган уйларым, кылган фаразларым акланды да, бер үк вакытта акланмады да.

Әлеге очрашудан соң унбиш-егерме еллар чамасы узгач, аның белән шәхсән танышырга, хәтта бераз сөйләшеп утырырга да туры килгән иде. Аның теләге буенча булды бу очрашу. Габделхак Кудашев дигән кеше икән. Башкортстан якларында туып үскән, элекке белемен авыл мәдрәсәсендә алган, совет чорында исә төрле уку йортларында математика укыткан. Күптән пенсиядә. Элекке татар мәдрәсәсе, андагы тәртипләр, шәкертләр арасындагы гореф-гадәтләр турында истәлеккә тартымрак бер мәкалә язган икән. Менә шул хезмәтен басмага тәкъдим итәр өчен фикер сорап, Мөхәммәт Мәһдиев белән икебезгә язмасын күндергән иде. Икебез дә аны кызыклы, басарга һичшиксез лаеклы дип таптык (мәкалә соңрак «Казан утлары»нда басылып та чыкты).

Текстны кайтарыр, кайбер фикерләремне үзенә генә әйтер өчен кульязмада күрсәтелгән адрес буенча өенә бардым. «Восстание» урамы тирәләрендәге инкубатор чебиләре сыман үзара охшаш «хрущевка»ларның берсендә яши икән. Карт гадәти өй киемендә генә, инде бераз картая төшкән булса да, кыяфәте буенча ул һаман олпат, солтанатлы, матур да иде. Әңгәмәсе дә, элекке зыялыларыбыз әйткәнчә, хушсөхбәт, ягъни ягымлы вә күңелле. Әлеге парктагы кебек тәкәбберләрчә төксәюенең эзе дә юк. Сүзләренә караганда, ул һәр елны ай саен пенсия акчасыннан өлеш чыгарып, үз авылындагы мәктәпкә татарча китаплар җибәргәләп тора икән. «Башкортстандагы татар мәктәпләре үги бала хәлендә бит»,—дип көрсенеп куйды ул. (Укытучы пенсиясенең күпме икәнлеге мәгълүм инде. Ярый әле, ул елларда китаплар бик очсыз иде. Ә татар-башкорт мөнәсәбәтләренең беркадәре үзенчәлекле икәнлеге хакында беренче мәртәбә мин аннан элек тә, дөресрәге шул 1958 елда ук ишеткән идем.)

Шулай, Казанның Максим Горький исемендәге паркында фараз кылганымча, Габделхак Кудашев чыннан да зыялы табигатьле һәм ихлас хәйриячел рухтагы кеше булып чыкты. Тик әлеге фараз-теләгемнең икенче өлеше, ягъни үземне укытачак профессорларның берсе булуы хакындагы өметем бөтенләй акланмады. Белгечлеге буенча да, кәсеп-һөнәр дәрәҗәсе ягыннан да.

Ләкин шулай да, аның белән беренче кат очрашкан көнне үк, «аягы җиңел булгандыр» күрәсең, чыннан да, остаз дип әйтерлек олы затларның берсен күрү, хәтта аның дәресендә дә утырып кайту бәхете насыйп булган иде миңа.

Биргән сәламемне шулай таптап кына китүче кешеләргә гаҗәпләнгән, моның сәбәпләрен әле җүнләп аңламаган, формаль «европалашу», дөресрәге, тулаем урыслашу белән вульгар атеизмның традицион гореф-гадәтләр тамырына ни дәрәҗәдә балта чабуларын рәтләп белмәгән хәлдә алга таба атлавымны дәвам иттем мин. Бара торгач элекке көннәрдә үземә таныш булмаган, ягъни әле күрмәгән урыннарга да килеп чыктым.

Казансу буена таба борын-борын булып, «шуып» кына төшә торган сөзәк тау битләре гаҗәеп матур икән. Тау битләрен каплаган ямь-яшел хәтфә болыннарда утрау-утрау агач төркемнәре. Яки ачыклык белән бүлгәләнгән урман эчләрендә утрау-утрау ямь-яшел аланнар... Тау битләре буенча кыеклап сузылган сукмакларда берән-сәрән кешеләр күренә. Парлашып баручы яшьләр—егетләр белән кызлар. Берәүләре түбән төшсәләр, икенчеләре үргә таба меналәр. Җәйрәп яткан Казансу көзгесендә баеп бара торган кояшның алтын шәүләсе дөрләп кабынган. Суны да кабызган төсле...

* * *

Төп аллеядан кайтып барганда, ерак түгел ачык эстрадада бер ханым башкаруында татар җыры яңгыравын ишеттем. Зәңгәр төскә буялган эскәмияләрнең берсенә барып утырдым. Буй-сынына сыланып тора торган озын итәкле кара күлмәк кигән, ярыйсы гына таза, бер үк вакытта күркәм фигуралы җырчы ханым Җәвәһирә Сәләхова икән. Аның ике-өч җырыннан соң сәхнәгә

кечерәк кенә гәүдәле, шулай ук матур тавышлы Нажия Теркулованы чакырдылар. Монысының җырлары да баягы «очрашудан» кырылган кәефне юатырга, дәваларга тырышкан төсле ягымлы иде.

Конферансьеның яна белдерүе сагаерга мәҗбүр итте: «Сәхнәгә күренекле әдәбият белгече профессор Мөхәммәт абый Гайнуллинны чакырабыз! Ул сезнең сорауларга да җавап бирер».

Мине ин элек профессор дигән дәрәҗә сагайтты, әлбәттә. Күз алдына университетның ак баганалары килде...

Сәхнәгә ыспай гына кәчтүм-чалбар кигән, әмма галстуксыз, күлмәк якалары ачык, уртача гына буйлы «гап-гади» бер агай килеп чыкты. Профессор дигәч, мин башкачарак көткән идем. (Дөрес, ул чакта М. Гайнуллин әле профессор дәрәҗәсен алмаган, конферансье ханым исә «аванс белән» шулай олылаган икән.) Әлеге олпат карт янында бу... Житмәсә сакал-мыеклары гына түгел, чәчләре дә бөтенләй кырылган. Шоп-шома башлы кеше иде ул. Хәтта кашлары да, кырып ташлаган төсле, ачык кына күренми. Башыма килгән иң беренче уй: «Фантомас!» булды. Әгәр баш-күзен, бит-чыраен чак кына яшькелт төскә буяп та куйсаң!..

Профессор дигәнебез авыз ачып бер-ике җөмлә әйтүгә игътибар белән тыңларга тотындым. Сүзне ул ерактан башлады. Уналтынчы, унҗиденче, хәтта унсигезенче гасырларда да, колониаль изүгә дучар ителү нәтиҗәсендә, татар халкы бик авыр шартларда яшәгән, культурасын, әдәбиятын үстерүгә бернинди мөмкинлекләре, кирәкле шартлары булмаган икән. Бары унтугызынчы гасырның ахырларында гына, капиталистик мөнәсәбәтләр урнаша башлагач, аның иҗтимагый тормышында җанлану барлыкка килә. «Татар тормышының чын-чынлап янаруында бөек мәгърифәтче, энциклопедист галим Каюм Насыйриның роле бик зур» дигән сүзләрне ишеткәч, Алматы китапханәләренең берсендә бу кешенең кайбер мәкаләләрен укыган булуымны искә төшердем. Ул мәкаләләр миңа бик тә ошаган иде. Шуңа күрә бая башыма килгән шаян, хәтта беркадәре әдәпсезрәк уйларым өчен уңайсызланып та куйдым...

1905 елдан соң татар әдәбиятының гөрләп үсүен, бу процесста бөек шагыйрь Габдулла Тукай тоткан урынны лектор шактый тәфсилләп тасвирлады. Аның Пушкин, Лермонтов иҗатларын гаҗәп олылавын билгеләде. Аннары Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд иҗатларын да искә алды. Әмма татар әдәбиятының чын-чынлап чәчәк атуы 1917 елдан соң совет чорына туры килә икән. Һади Такташ, Шәриф Камал, Гадел Кутуй, Кави Нәҗми, Габдрахман Әпсәләмов, ниһаять, Сталин, ягъни Дәүләт премиясенә лаеклы «Намус» романын язган Гомәр Бәширов һәм башка бик күпләр...

Лекция шулай гомум сүзләр белән тәмамланугa, бер-ике сорау да бирелде. Бер ханым кайберәүләрнең русча сүзләрне күп куллануларын, бутап сөйләүләрен әйтеп, моңа карата «хөрмәтле профессорның» мөнәсәбәтен белергә теләде. Икенчесе, егет кеше иде бугай, татарларның рус кызларына өйләнүе хакында сорады. Беренче сорауга ниндирәк җавап бирелгәнен хәтерләмим хәзер, мәгәр икенчесенә җавап ачык булды: әгәр бер-берсен чыннан да яратып, хөрмәтләшеп яшәсәләр— «пажалысты, үз ихтыярлары; тик еш кына, бигрәк тә олыгая төшкәч, андый гаиләләрнең тынычлыклары бетүчән була; мондый очракта аклап булмый андый никахларны»...

Бер планда махсус максат белән оештырылган лекциядән соң бөтенләй башка рухтагы сорауларның бирелүе мине уйландырды. Димәк, тыңлаучыларны әдәбият хакындагы тарихи, теоретик мәсьәләләр кызыксындырмый, аларны гадәти тормышның кайбер күренешләре күбрәк борчый икән. Мине исә укылган лекциянең нигездә гомум сүзләрдән генә торуы, анда әллә ни яңалык булмавы сәерсендерде. Дөресрәге, ошамады ул лекция. Гәрчә лекция үзе төзек булып, бик шома яңгыраса да. Андагы фактларның һәммәсе диярлек дәреслекләр буенча да билгеле иде. Кыскасы, булачак укытучыларымның шундыйрак лекторлардан тору ихтималы мине әллә ни сөендермәде...

Ләкин мондый ашыгыч һәм кырыс хөкемемнең үзе дә сайрак фикерләүдән, хәтта проблемаларны җыйнап белмәүдән килеп чыкканлыгын бераз соңрак кына аңладым мин. Шулай ук хакимият ияләре кушуы буенча киң катлам халык алдында

сөйләнәчәк сүзләрнең дә формаль яктан шулай рәсми, эчтәлек җәһәтеннән чамалы гына булырга тиешлеген дә белми идем әле. Андый лекцияләрнең «популяр» дип аталуларының сәбәпләре дә миңа соңрак кына мәгълүм булды. Мондый популяр чыгышларның шулай махсус рәвештә сай булуы тыңлый торган аудиториянең дәрәҗәсенә дә бәйле икән. Ниһаять, парктагы ачык эстрадада бушлай җыр тыңларга җыелган чуар җәмәгатьчелек арасында университетка керер өчен махсус әзерләнеп килгән, зурдан дәгъва итүче кеше дә берәү генә булгандыр ул көнне...

Кыскасы, әлеге лекция ясаган тәэсирләр чамалы булган шикелле, аның хакта ашыгыч рәвештә чыгарылган хөкем дә бик сай, «тубыктан гына» икән. Әдәбият белгече Мөхәммәт Гайнуллинның чын-чынлап кем булуын, татар филологиясе белемендә аның тоткан урынын азмы-күпме дәрәҗәдә төгәлрәк аңлау мөмкинлеге университетка кергәннән соңгы ике-өч ел дәвамында гына барлыкка килде. Әлбәттә, башка лекторларны да тыңлау, филология буенча төрле әдәбият, җөмләдән галимнең үз хезмәтләре белән дә якыннан танышу нәтиҗәсендә.

* * *

Мөхәммәт ага Гайнуллинның үзе белән танышып аралаша башлаганчы, аның шәхесе, кайбер гадәтләре хакында өстәмә мәгълүматларга да ия булу мөмкинлеге туган иде. Университет китапханәсенең сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә мин, беренче курста укыган чакта ук, «Аң», «Шура» кебек революциягә кадәр чыккан журналларны укыштыргалый башлаган идем. Бер көнне анда олы гына яшьтәге, мәгәр гаҗәеп сөйкемле, хәтта үз яшенә нисбәттән матур, чибәр дип әйтергә лаек бер ханым да күренде. Ул да элекке гәзит-журналларны караштыргалый икән. Аның кем икәнлеге хакында бүлек мөдире Мостафа абый Ногмановтан сорадым. Филология фәннәре докторы Мөхәммәт Гайнуллинның хәләл җефете, доцент Җамал ханым Вәзиева, диде. Бу исем-фамилияне элек тә очратканым бар иде: М. Гайнуллин һәм Җ. Вәзиева авторлыгында чыккан әдәбият буенча дәреслекләрне әллә ничә мәртәбәләр актарганым бар.



*М. Гайнуллин шагыйрә Зәйнәп Сәгыйдә белән «Азат хатын» редакциясендә. 1978 ел.*

Җамал апаның үзе белән шәхсән танышу да кызыграк килеп чыкты. Бер көнне, кичкенә генә уку бүлмәсендә бүлек мөдире һәм без ике укучы гына утырган чакта, ул:

—Сез Уфадан килдегезме әллә?—дип сорады.

Үземнең университет студенты булуымны, беренче курста укуымны әйткәч, ул гаҗәпләнүен белдерде:

—Иске язуны шулай җинел укуыгызга, яшегезгә дә карап, мин сезне читтән килгән берәр аспирант яки яшь галимдер дип уйлаган идем! Кайда өйрәндегез соң бу язуга?

Сүзгә, рәхмәт төшкере, Мостафа абый кушылды, һәм ул минем кем булуымны, кайчан, кайлардан килүемне кыскача әйтеп бирде. Шул рәвешчә, ул мине соңгы вакытларда үзем тарафыннан еш тәкрарланып тәмам туйдырып бетергән сүзләрне тагын бер кат кабатлаудан коткарды.

Җамал апа исә тиз аралашучан, сөйләшергә дә яратучан кеше булып чыкты. Сүз җае туры килгән саен, «Мөхәммәт агагыз болай дип әйтә, тегеләй уйлый», дип кыстыргалаудан тыш, кайсы мәсьәләне аның ничегрәк хәл кылуы, яктыртуы, кемнәр

белән ничек бәхәсләшүе, хәзер нәрсәләр эшләве турында да әйткәли иде. Өзек-өзек рәвештә бирелгән шундый хәбәр кисәкләреннән дә җигелеп эшләүче «фән корбаны»нын кешелек кыяфәтен дә, гыйльми кыюлыгын да, иҗтимагый йөзен дә күз алдына китерүе артык кыен түгел иде.

Боларга беренче ике-өч ел дәвамындагы һәм аннан сонгы чорлардагы күзәтүләрне дә кушып фикер йөртергә мөмкин. Шулай иткәндә, әдәбият белгече Мөхәммәт Гайнуллиннын XX гасырнын 40-70нче еллары дәвамында татар филологиясе белемендә тоткан урыны, үз чоры һәм даирәсе өчен никадәре зур әһәмияткә ия булуы ачыграк күренә. Шуна күрә мин бу урында, галәти истәлек кысаларыннан чыгып, икенчерәк алым-стильгә күчәргә телим.

* * *

Профессор Гайнуллиннын гыйльми эшчәнлегендә төп ике юнәлеш аерата нәтиҗәле иде. Аларнын беренчесен мин ин әлек татар филологиясе белеме буенча кадрлар әзерләүгә, аларны «аякка бастыруга» керткән өлеше дип билгеләр идем. Шул ук вакытта анын мин укыган елларда университетта дәресләр алып бармавын да әйтергә тиешмен (ялгышмасам, ул педагогия институтында беркадәре укыткан бугай). Сонгы елларда ул нигездә гыйльми җитәкче сыйфатында аспирантлар белән җитәкчелек итүдә һәм башкалар җитәкчелегендә әзерләнгән диссертацияләргә рәсми бәя бирүдә, ягъни оппонент булуда зур активлык күрсәткән галим иде. Һәрхәлдә, 1960—1970 елларда Казан университетынын тарих-филология факультетында өзлексез рәвештә эшләп килгән һәм бөтен Татарстан өчен бердәнбер булган гыйльми советында татар филологиясе буенча якланган һәр икенче-өченче диярлек диссертациянен «беренче оппоненты филология фәннәре докторы Мөхәммәт Хәйруллович Гайнуллин» була иде.

Галимнен болай еш оппонентлык итүеннән чыгып, аны «кизү», ягъни дежур оппонент дип бәяләүчеләр дә, бәлкем, табылгандыр. Чынлыкта, минемчә, болай килеп чыгунын ике объектив сәбәбе бар иде. Аларнын беренчесе ул елларда Казанда татар филологиясе белеме буенча фән докторларынын гомумән аз булуыннан килә иде. Мәсәлән, бөтен Татарстанда филология буенча ике фән докторы гына бар иде. Берсе олы яшьтәге, сәламәтлеге дә бик чамалы булган телче галим профессор Латыйф Җәләй, икенчесе әдәбият белгече Мөхәммәт Гайнуллин иде.

Сәбәпләрнен икенчесе исә сонгысынын ул елларда сәламәтрәк тә, хәрәкәтчәнрәк тә булуы өстенә яшьләргә карата ихлас теләктәшлеге белән дә бәйле иде, минемчә. Аспирант җитәкчеләре дә, җитәкләнүчеләрнен үзләре дә беренче оппонент сыйфатында күбрәк М. Гайнуллинны чакырырга тырышалар иде. Шуна күрә күпкә кадәр әдәбият тарихына, хәзерге әдәби процесс мәсьәләләренә, тел белеменә, хәтта фольклорга багышланган диссертацияләр хакында да төп рәсми хөкемне Мөхәммәт ага Гайнуллин чыгарып килде. Ә ул һәрвакыт диярлек яклана торган диссертацияне чамалы гына тәнкыйтьләп, эшлекле тәкъдимнәр дә ясап һәм, ин мөһиме, әйбәт кенә мактап, «бу хезмәтнен авторы дәгъва итеп торган гыйльми дәрәҗәгә һичшиксез лаек», дип йомгаклап куя иде.

* * *

Диссертация яклаулар, билгеле, рус телендә генә бара, ә Мөхәммәт аганын русчасы—сүзләрнен, җөмләләрнен мәгънәләре дөрес булса да—янгыраш ягыннан бик чамалы, татарча көчле акцент белән әйтелә иде. Мәсәлән, «приходит к правильному заключению» кебегрәк гыйбарәсе «прихудит к пырауилному заклучени» булып ишетелә иде. Шуна күрә Мөхәммәт ага сөйли башлау белән кайберәүләр авыз ерып елмаерга, пырх-пырх көләргә дә тотыналар. Башта үземә дә көлкеле булып тоела иде. Сонрак игътибар иткәнем бар: анын акцентыннан көлүчеләр арасында, аны яхшылап белмәгән тәкәббер холыклы руслардан тыш, үзләре дә русча әллә кая китмәгән татарлар күбрәк була иде. Мондый чакларда Тургеневнын бер чәчмә «шигырендәге» фикере: үзеннен кимчелегенне яшерергә теләсән, андый сыйфатны башкалардан да табарга тырыш, шуны бүтәннәргә дә әйт, дигәнрәк хикмәтле сүзләре искә төшә иде.

Гомумән, ул елларда русча әйбәт белү, чатнатып нәкъ русларча сөйли белү хакында сүз куертулар модада иде. Мона, ихтимал, республика лидерларыннан Фикрәт Табиевнын шул хакта кат-кат әйтүе, барлык уңышларның нигезен иң элек русчаны яхшы белү дип раслаулары да тәэсир иткәндер. Ә инде татар зыялыларыннан ул елларда күп сөйләүче һәм русчаны шулай татарча матур акцент белән яңгыратучының берсе ул телгә зурайгач кына өйрәнгән Мөхәммәт ага Гайнуллин булса, икенчесе, һичшиксез, Гариф Ахунов иде.

Мөхәммәт аганың русчасы хакында йөремсәк мәзәкләр дә бар иде. Мәсәлән, әгәр риваять дөрес булса, директорның хуҗалык эшләре буенча урынбасары булып эшләгән чагында ул, бер җыештыручы әбине теге дөньяга озаткан вакытта, матәм нотыгы сөйли. Мәрхүмә бик тырыш, эш сөючән әйбәт кеше иде дип озак кына мактагач, болайрак нәтиҗә ясый, имеш: «Вут ана умирла. Всим нам нады с ния пример взят». Җыелган халык көчкә генә көлүдән тыелып кала. Урынбасар исә өстәп тә куя: «На этым панихида кончился. Тепер йава прадулжим в магиле»...

Әмма ләкин, ничек кенә булмасын, рус сүзләрен рус колагы өчен ничек кенә сәер итеп яңгыратмасын, Мөхәммәт ага Гайнуллин фатихасы белән элек кандидат, аннары фәннәр докторы булган кешеләр аз түгел иде әлеге 60-70 нче елларда. Үз нәүбәтендә алар да фәнебезгә яңа көчләр килүгә үзләреннән өлеш керттеләр. Әгәр бүген күп тармаклы татар филологиясе белемендә йөзгә якын фән кандидаты, дистәдән артык доктор вәкаләтлек итә икән, мондый көчләрнең барлыкка килүенә Мөхәммәт ага Гайнуллин керткән өлеш тә зур булды дип әйтергә тиешбез.

* * *

Галим эшчәнлегенең икенче төп юнәлеше һәм зур нәтиҗәлесе сыйфатында мин аның тарафыннан югары уку йортлары өчен төзелгән дәреслек һәм хрестоматияләрне күрсәтер идем. Төгәлрәк әйткәндә, монда мин татар әдәбияты тарихы буенча әзерләнгән, күп еллар уку әсбабы буларак хезмәт иткән китапларны күз уңында тотам. Университет һәм башка институтларның татар бүлекләрендә тыңлаган лекцияләрдәге материалларның никадәр тулы булу-булмауларын, аерым иҗатларга бирелгән бәяләмәләрнең ни дәрәҗәдә гадел яки нахак икәнлеген беркадәре сынап карау өчен дә зарур иде алардагы материаллар. Һәрхәлдә, минем үзем өчен шулайрак булды.

Әлеге дәреслек кулланмаларында XIX йөз һәм XX гасыр башы авторларыннан Һибәтулла Салихов, Габделҗәббар Кандалый, Мифтахетдин Акмулла, Каюм Насыйри, Закир Һади, Заһир Бигиев, Муса Акъегет, Шакир Мөхәммәдев, Фатыйх Кәрими, Риза Фәхреддин иҗатлары да текстлар белән мул тәэмин ителүе яңа заман әдәбиятыбыз тарихын чагыштырмача киңрәк яктыртуга хезмәт итә иде. Чоры биргән мөмкинлекләргә муафикъ рәвештә, әлбәттә. Иҗатлары киңрәк яктыртылу «өстәгеләр» тарафыннан әллә ни хупланмаган, киресенчә, «кызыл авызлар» тарафыннан гел тәнкыйть ителүе, кире кагылуы кагыйдәгә әверелгән кайбер әдипләрнең мираслары буенча да әлеге кулланмалардан шактый бай мәгълүмат алып була иде. Чоры, даирәсе өчен аларда характерлы, котылгысыз дип әйтерлек чикләнгәнлекләр, кимчелек-ялгышлар да очрауга карамастан бу шулай.

Кырык-илле ел дәвамында иҗатының әһәмияте әзлекле рәвештә кимсетелгән, хәтта бөтенләй диярлек кире кагылган, наширлек, хәйриячелек эшләре дә инкяр ителгән шагыйребез Закир Рәмиев—Дәрдмәнд булды. Аның мирасы бөтенләй онытылмауга, дөресрәге, әкренләп әдәби фикер хәрәкәтенә кайтарыла баруына да әлеге кулланмалар керткән өлеш аз булмады дип әйтер идем. Һәм, гомумән, бу олы шагыйрьнең мирасы тулысынча кайтарылуга да галим тарафыннан 1959 елда, шагыйрьнең 100 еллыгы уңае белән ясаган махсус докладе һәм аның редакциясендә чыгарылган шигырьләр җыентыгы алга таба зур бер адым хезмәтен үтәгән иде. Моңарчы бер мәкаләмдә тәфсилләбрәк язганымча («Бертуган Рәмиевләр» китабында), әлеге йөзъеллыкның уздырылуы, тарихи дөреслеккә таба борыла башлау буларак, җәмәгатьчелектә милли бәйрәм хисен дә тудырган иде.

Шулай итеп, XIX йөз—XX гасыр башы иҗтимагый, мәдәни тормышыбызда, бигрәктә әдәби фикеребез тәрәккыятендә билгеле урын биләгән, моңарчы

мираслары тигез дәрәҗәдә өйрәнелмәгән әдипләребезнең мирасларын барлау, алар белән киңрәк җәмәгатьчелекне таныштыру галим хезмәтләренең төп өлешен тәшкил итә.

Хатын-кыз әдипләребездән Газизә Сәмитова, Мәһруй Мозаффария, Гыйффәт туташ, Мәхүбҗәмал Акчурина иҗатларын, эшчәнлекләрен өйрәнүен дә мин махсус билгеләп үтүне кирәк табам. Шунысы да билгеле булсын: бездәге хатын-кызларның иҗтимагый активлыгы бер татар дөньясында гына түгел, бәлки Русиядәге, Көнбатыш Кытайдагы башка мөселман төркиләр өчен дә гыйбрәтле, шунысы белән тарихи зур әһәмияткә ия хәрәкәт, хәтта төгәл бер күренеш иде.

Кыскасы, җыеп әйткәндә, сугыштан соңгы авыр елларда, шәхес культының сөреме әле бетеп җитмәгән, большевизмның догматик, тынчу атмосферасы да тулаем хөкем сөреп торган, төрле чикләүләр, эзәрлекләүләр, «башка сугулар» һаман гамәлдә булган шартларда яшьләрнең җитлегүенә даими рәвештә юмарт теләктәшлек күрсәткән олы рухлы, шунысы белән үзенчә гүзәл кеше иде Мөхәммәт ага Гайнуллин.

Мәдәният вә әдәбият тарихы буенча ул башкарган эзләнүләр, ул чыгарган китаплар да, чорына хас, димәк, тарихилыгы белән аңлаешлы кайбер үзенчәлекләренә, җитешсезлекләренә карамастан, һәрьяклап ихтирамга, хөрмәт итүгә лаек байлыгыбыздыр. Минемчә, профессор Мөхәммәт Гайнуллин безнең филология белемендә узылуы котылгысыз рәвештә зарур булган, шунысы белән үз миссиясен үтәргә тиеш һәм үтәгән билгеле тарихи чорның (бәлки аның мөһим бер этабының) күренекле, киң күңеллелеге белән затлы вәкиледер.

* * *

Галимнең хезмәтләре арасында эчтәлегенең максатчанлыгы һәм байлыгы җәһәтеннән, минемчә, иң әһәмиятлесе «Татарская литература и публицистика начала XX века» дип исемләнеп рус телендә чыккан күләмле монографияседер (Казан, 1966). Ул тарихыбыздагы иң якты сәхифәләрнең берсен тәшкил иткән мәсьәләгә—вакытлы татар матбугаты туу, үсүгә, аның гомум эшчәнлеге тарихына багышланган олы хезмәт. Анда әдәби фикер һәм язма культурабыз яңару күренеше татар телендәге төрле газит-журналларның барлыкка килү, нинди юнәлештә эшләү процессы белән берлектә күзәтелә, билгеләнә. Шуның белән бергә әлеге газит-журналларны барлыкка китергән, яшәткән, үстергән әдипләрнең, журналистларның хезмәтләренә дә төрле яклап анализ ясала, бәя бирелә.

Китап, укучыга шактый мул белем бирүдән тыш, аны төрле мәсьәләләр буенча уйланырга, фикер йөртергә, эзләнергә этәрүе белән дә бәхәссез әһәмияткә ия иде. Аны укып уйлану, узган тарихыбызның шул бай, катлаулы күренешен әтрафлырак, тагын да төгәлрәк, тирәнрәк аңларга омтылу теләге безне, Мөхәммәт Мәһдиев белән икебезне, әлеге китапка таянып дигәндәй, «XX йөз башы татар әдәбияты һәм матбугат тарихының кайбер мәсьәләләре» дип исемләнгән мәкалә белән чыгыш ясауга китергән иде (Казан утлары, 1967, №7).

Мәкаләдә без М. Гайнуллин китабының гомум әһәмиятен, кыйммәтен махсус билгеләп үттек, әлбәттә. Шулай ук анда әле хәл ителеп бетмәгән, бәхәслерәк яктыртылган мәсьәләләргә дә тукталган, кайбер фактларны, күренешләрне ничегрәк өйрәнү, яктырту мөмкинлекләренә дә тукталган идек. Сүз бигрәк тә Ризаэддин Фәхреддин, Фатыйх Кәрими ише зур, катлаулы әдипләребез эшчәнлеген яктыртудагы монарчы хөкем сөреп килгән берьяклылык хакында да барды.

Матбугат органнарына бәя бирүдә редакторларны наширлардан, конкрет авторларны исә редакторлардан аерып карау фикерен дә алга сөреп карарга тырышкан идек. Янәсе, элекке газит-журналларга тулаем гына бәя бирергә, барысын бер таяк белән сөреп, гаепләүче тамгалар сугуның хаксызлыгын да расларга омтылып караган идек.

Әмма, монарчы бер әйткәнемчә, безнең нәкъ соңгы мәсьәләләр буенча әйтергә теләгән фикерләребез шул чорда хөкем сөргән рәсми караш тарафдарларыннан Хәсән Хәйри, Камил Фәсиев ише «авыр тупларның», ягъни партия оешмалары тарафыннан танылган авторитетларның көчле генә тәнкыйтьләренә очраган иде.

Минем аңлавымча, әлеге мәкаләбездә Г. Тукайның «Китмибез!» шигыренә карата ул елларда гел хөкем сөреп торган советча бозык (янәсе, Тукай татар милләтчеләренә шулай «җавап биргән» иште) аңлатманы дәлилле рәвештә кире кагуыбыз, ягъни нәфрәтнең рус шовинистларына адресланган булуын раславыбыз тәнкыйтчеләргә ошамаган иде; бигрәк тә үзен гел идеолог итеп сизүче К. Фәсиевнең ачуын кабарткан булса кирәк. Бер сүз белән әйткәндә, безне «бербөтен буржуаз агым» идеясенә теләктәшлектә, ягъни, тагын да ачыграк әйтсәк, буржуаз милләтчелектә гаепләгәннәр иде (бу хакта аерым сүз дә булыр, бәлкем).

Ләкин безнең өчен көнелсез, хәтта хәвефле булган әлеге кампаниядән соң Мөхәммәт ага Гайнуллин белән минем арада үзара якынаюга таба хәрәкәт барлыкка килеп, дустанә дип әйтерлек мөнәсәбәт тә урнаша башлаган иде.

Дөрес, әлеге мәкаләбез хакында сүз, хәтта аны искә алу омтылышы да булмады. Очрашкан саен кул биреп күрештек, хәл-әхвәл сораштык. Ул минем нәрсәләр эшләвем белән һаман кызыксынып торды. Башта мин бераз сагаеп, шүрләп тә йөргән идем: берәр җаен китереп, саллырак җавап белән «тондыруы да» ихтимал дип. Тик бер нәрсә дә булмады. Бары татар әдипләренә багышланган җыентыгына караган гадәти рецензиям чыккач кына, рәхмәтләр әйтеп кулымны кысты. Димәк, әлеге тешләгрәк рухлы мәкаләбездәге хаклы тәнкыйтьне, авыррак булса да, иргетләрчә «йотып җибәргән», ягъни объективлыкка омтылуның кирәклеген, зарурлыгын таныган икән. Бу сыйфат галимдә гаделлеккә омтылу хисенең көчлерәк булуын күрсәтсә кирәк.

* * *

Шул рәвешчә әкрен генә якынлашкач, төрле мәсьәләләр буенча фикер алышырга, кайбер очракларда җинелчә бәхәсләшеп тә алырга туры килгәли иде. Гомумән, аның белән сөйләшүе, фикер алышуы җинел дә, күнелле дә иде. Ул бер дә үзен өстен тотмас, елмаеп-көлеп кенә сөйләшер. Шул ук вакытта үзенең дәрәҗәсен дә саклар иде. Бу аның сиңа карата кулланган ягымлы эндәш сүзләреннән сизелеп тора. Минемчә, ул, яшьрәк кешеләр белән сөйләшкәндә, «акыллым» дигән эндәш сүзен еш куллана иде. Аннары аның бер гадәте—авыз эчендә тел очын ары-бире йөрткәләп, битләрен бөлтәйткәләп куя торган кызыклы гадәте дә бар иде. Һәрхәлдә, аның белән рәсмилеккә бирелмичә генә сөйләшергә мөмкин иде.

Бер көнне җаен китереп, Каюм Насыйрига багышланган китабында Шиһабеддин Мәрҗани эшчәнлеге кирәгенчә яктыртылмавын, хәтта аның әһәмиятен бөтенләй инкяр итүгә юл калдырылуын әйткән идем. Аның җавабы мин көткәннән башкачарак килеп чыкты:

—Гомумән дөрес әйтәсең,—диде ул елмаеп һәм битләрен бөлтәйткәләп алды.— Тик бер нәрсәне генә онытма. Ул китапны язган чакта шартлар бөтенләй башка иде. 1944 елгы махсус карарның әле суынып җитмәгән чагы. Берәр элекке чор галиме хакында сүз кузгатсаң, «Алтын Урда хакында ул нәрсә язган? Казан ханлыгын ничек яктырткан, этногенез мәсьәләсендә нинди позициядә торган?»—дип төпчена башлыйлар иде. Әгәр мәсьәләне шомартыбрак яктыртырга теләсәң, донос язарга да әзер торучылар җитәрлек иде. Каюм Насыйрида, үзең белгәнчә, әлеге сораулар хакында әллә нәрсәләр юк. Безгә, гомумән, шундыйрак алым белән эшләргә туры килде: кайсы ат белән кызурак, тизрәк чабасың, максатка җитә аласың, шуны иярләргә, шуңа атланырга тырыша идек.

Сүзләреннән, образлырак итеп әйтүеннән Мөхәммәт ага үзе дә канәгать иде, күрәсең, ялтырап торган башын бер чөеп алды да, хәйләкәр генә елмаеп өстәп куйды:

—Каюм Насыйриның гадирәк, димәк, демократрак булуын да истә тоттык, урыслар турында да начар фикерләре юк аның. Мәрҗани белән аның араларында каршылык булуы да бәхәссез бит... Менә, заманалар бераз үзгәрүгә, Мәрҗани турында үзеннең мәкаләң дә чыкты. Фәннең, гыйлемнең үсүе шулайрак бара шул, акыллым. Килер вакыт, сезнең буыннан да кимчелекләр, хаталар таба башлаячаклар...

Соңгы фаразга миндә җавап юк иде, әлбәттә. Киләчәк буыннар гына түгел,

үзебез дә бүген үк үзебезнең кичә эшләнгән эшләребездән кимчелекләр табабыз. Ә киләчәк буын вәкилләренә килгәндә, Аллага, Алла биргән инсафка, иманга тапшырырга кала. Совет чоры авторларының элекке чор галимнәрен ничек тапалаулары, хурлаулары күз алдында...

Ләкин мин, авызымның шулай тиз генә томалануы белән килешергә теләмичә, һөҗүмне икенче планга күчерергә тырыштым. Каюм Насыйрине «энциклопедист» дип атаулары белән килешмәвемне әйттем. Чөнки энциклопедизм дигән күренешнең бары Урта гасырлар өчен генә хас тәрәкъкыят икәнлеген искәрттем. Аннары белем дәрәҗәсе ягыннан гади мәктәп-мәдрәсә укучылары өчен грамматика, арифметика буенча популяр дәреслекләр язучыны чын энциклопедист Леонардо да Винчи белән янәшә куеп булмый бит! Хәтта колагыннан тарта-тарта энциклопедист дип олыланган Ломоносов белән дә...

—Моның шулай икәнлеген мин дә беләм,—диде Мөхәммәт ага һәм авыз эчендә тел очларын бер-ике мәртәбә уйнаклатып алгач, елмаеп куйды,—Ломоносовны үзен дә дөрес искә төшерден, энциклопедист сүзе исә безгә Мәскәүдән килгән иде. Ломоносовны күккә чөю урыс милләтенең аның тәрбияләү өчен кирәк булган. Без дә бит Каюм бабаны олылау юлы белән татарның абруен күтәрергә тырыштык. Революциягә кадәр язуы да, хәтта үз әдәби теле дә булмаган дип тасвирлана торган «кыргый илбасар» татарның «энциклопедисты» хакында шул елларда сүз кузгатуның әһәмиятен онытма, акыллым! Ул хәзер генә сезгә кирәкми энциклопедистлар!..

«Димәк, бу илдә фән дигән нәрсә белем генә түгел, сәясәт тә икән,—дип уйлап утырдым мин.—Сәясәттә исә, аның бер тармагы булган дипломатиядә дә, әхлак нормалары чамалырак була шул.» Моннан соң да мина гуманитар фәннәрдән тарих белеменең табигате, аның бурычлары хакында күп уйланырга, ул фәнме, фән булмаса, нәрсә соң ул тарих?—дип күп мәртәбәләр баш ватарга туры килде...

Сәясәт дигәч, шуны да истә тотарга кирәк: ул гуманитар фәннәр өлкәсендә эшләүчеләр өстендә һәрвакыт нечкә җепкә эленеп торган үткен кылычны, яки хәтәр балтаны хәтерләтә. Аның бик куркыныч, хәтта мәгънәсез дип әйтерлек очраклары да була. Мөхәммәт ага Гайнуллин язмышында да андый хәлләр күп булганга охшый.

Репрессиягә эләккән элекке галимнәребез, әдипләребезнең фикерләре, хезмәтләре онытылу, юкка чыгу хакында сүз чыккач, мондыйрак җавап ишеттем:

—Алай ук бөтенләй юкка чыкмадылар шул алар,—диде Мөхәммәт ага уйчан гына.—Без бит шулардан укыган кешеләр. Аларның язганнарын хәзер дә укыйбыз. Дөрес, яшереп кенә укып файдаланабыз. Тик исемнәрен атарга куркабыз. Үзебезнең язганнарны да чыгармаслар, гаепләрләр дип курыктык. Шуңа күрә дә сер булып кала инде алар...

«Сер» дигәннән, соңрак Альберт Яхиннан шуны да ишетергә туры килде:

—Бер көнне, М. Гайнуллин белән очрашкач, сүздән сүз чыгып, ул болайрак әйткән иде: «Мин үз китапларымны утызынчы елларда репрессияләнгән галимнәребезнең хезмәтләреннән файдаланып, хәтта алардан күчереп яздым. Тагын сәяси гарасатлар чыгып, аларның калган әйберләрен дә җыеп яндырсалар, бөтенләй югалу ихтималыннан куркып, ичмасам, фикерләре минем китапларда сакланыр дип уйладым. Тик билгеле сәбәпләр аркасында исемнәрен генә атый алмадым. Әйтче, зинһар, болай эшләп мин дөрес иттемме, әллә җинаять кылдыммы?» Мин ул мәлдә Мөхәммәт агага өздереп кенә җавап бирә алмадым, әлбәттә,—диде Альберт сүзен йомгаклап.

Әйе, Русия һәм СССР шартларында М. Гайнуллин кебек эшләре әйбәт кенә, хәтта «ал да гол генә» рәвештә барган кешеләрнең дә язмышлары мәҗбүри каршылыклар белән тулы булган.

• • •

Тагын бер очрашуда Мөхәммәт ага:

—Йә, яна сорауларың юкмы соң тагын?—дип сорады һәм кеткелдәп көлеп куйды.

—Бар!—дидем мин кыюлана төшеп.—Кичә генә сезнең Акмулла хакындагы кайбер язганнарыгызны карап утырган идем, бер нәрсәгә игътибар иттем әле.

Шагыйрьнең «бәндәне ризык дигән кыймылдатыр» дигән сүзләренә карата сез шикләнү белдерәсез шикелле. Реалистларча уйлаучы кеше буларак, Акмулла, минемчә, мәсьәләнең тамырына карап фикер йөрткән. Кешеләр генә түгел, барлык җан ияләре дә ризык эзләп кыймылдыйлар, хәрәкәтләнәләр бит!

Бу юлы да Мөхәммәт ага җавап эзләп кесәсендә күп актарынмады:

—Шулай икәнлеген мин дә беләм, элек тә белә идем.—диде җәһәт кенә.—Ләкин яшьләргә, студентларга адресланган китапта: «Сез дә шулай ипи артыннан гына чабыгыз!»—дип яза алмыйм бит инде! Ни өчен идеалны кеше гел туенудан гына эзләргә тиеш?!

Шулай дип, мәсьәләне чак кына икенче якка таба борып җибәрде дә, гадәтенчә тел очлары белән битләрен бөлтәйткәләп алгач, такыр башын сыйпап куйды.

—Сина, казакъ теле белән якыннан таныш кешегә, Акмулла иҗатын яхшылабрак өйрәнергә кирәк булыр, күрәсең. Мин аның, дөресен әйткәндә, кайбер сүзләрен, гыйбарәләрен кыенлык белән аңлыйм. Тоям ни турында сүз барганын, ләкин нечкәлекләренә кадәр төгәл аңлап бетермим. Акмулла иҗатын безнең чын-чынлап өйрәнгәнебез, бәяләгәнебез, үзләштергәнебез юк әле. Ә ул бик зур шагыйрь, чын шагыйрьләрнең берсе!

М. Гайнуллинның һәр ситуациядән бәхәстән җиңел генә диярлек чыга алуына карап, мин элегрәк аны гомумән җиңелчә генә фикер йөртүче, үзенә тәнкыйть күзлеге аша карамый торган, үз эшләреннән гел канәгать кешедер дип тә уйлап куйгалый идем. Мондый уйларым белән ялгышкан булуымны сонрак кына аңладым.

1981 елның яз айларында мине Татарстан китап нәшриятының директоры Гарәф ага Шәрәфетдинов чакыртып алды. Шушы елда Мифтахеддин Акмулланың 150 еллыгына багышлап, аның әсәрләрен чыгарырга кирәк икән. Бу эшне миңа тапшыруын һәм эшне тиз башкарырга кирәклеген белдерде ул. Минем искә кылт итеп Мөхәммәт аганың сүзләре төште. Һәм алындым әлеге эшкә. Көне-төне дигәндәй эшләп (мин, гадәттә, төннәрен озак-озак утырырга күнеккән), җыентыкны ерып чыктым диярлек. Өлгерә алмый аптыраган чакларымда М. Гайнуллинны «каргар» кебек булсам да, китап чыгып житкәч, аңа үз рәхмәтләремне кычкырып әйтергә дә әзер идем. Тик шуны гына белмәдем: нәшрият директоры бу эшкә мине чакыру фикеренә үзе килгәнме, әллә берәр кеше тәкъдим иткәнме? Хәер, ачыклап йөрүнең кирәген дә тапмадым ул вакытта...

* * *

Мөхәммәт аганың башкаларга, бигрәктә яшьләргә карата теләктәш, ярдәмчел кеше икәнлеген миңа башка юнәлештә дә сынап, татып карарга туры килгән иде. Шуларның берсе хакында.

1969 елның җәендә, тормышыбызның матди яктан бераз катлауланыбрак торган, кем әйтмешли, «яшь совет галименең» хәерчелеге сизелебрәк торган көннәрендә, Алматыдан телеграмма килеп төште. Әтиебезнең вафатын хәбәр итеп. Тиз генә очып барырга, кирәкле чыгымнарның бер өлешен булса да күтәрергә тиеш идем мин. Хезмәт хакын бирүгә дүрт-биш көн калган, ә тиешле бер гонорар кисәген тагын озаграк көтәргә туры киләчәк. Ә мәсьәләне тиз генә, бүген үк хәл кылырга кирәк. Уйлана торгач, бурычны Мөхәммәт агадан сорап карауны кулайрак таптым. Телефоннан шылтыратып, бер ашыгыч эш килеп чыгуын әйтеп, Щапов урамындагы өйләренә юнәлдем (анда элек тә бер кат булганым бар иде).

Ишекне һәрвакыттагыча матур елмайган сөйкемле Җамал апа ачты. Алгы бүлмәгә өйдәгечә гади киенгән Мөхәммәт ага да чыкты, үзенең кабинетына чакырды. Килүемнең сәбәбен ишетүгә үк ул пижам чалбарын сала башлады. Аннары каушаганрак кыяфәт белән:

—Хәерле булсын инде, иманлы булсын дип телик,—диде һәм тиз-тиз киенергә тотынды.—Өйдә әллә ни акча юк иде, хәзер кассадан алып бирәм. Төшке ашка ябылганчы барып өлгерик...

Акчаны мин сораганнан артыграк итеп бирде ул:

—Соңгы бурычың бит, иркенләп тот. Тартынма. Кайтарыр өчен дә ашыкмассың. Өлешләп бирсәң дә ярый,—ниһаять, шунда гына сорап куйды.—Ничә яшь иде сон әтиенә?

* * *

Шуны да әйтергә кирәк, Мөхәммәт ага, минемчә, бик матур картайган кеше иде бугай. Күпкә кадәр төс-кыяфәте бер килеш торды аның, әлләни үзгәрмәде. Һаман шул ук ялтырап тора торган такыр баш, чип-чиста көләч йөз, бөлтәеп-бөлтәеп ала торган күр яначлар.

1983 елда сиксән яшен тутырганда да ул элеккечә диярлек үк хәрәкәтчән булды. Юбилей бәйрәменә багышланган зыяфәт мәҗлесенә мине дә чакырды: «Кара аны, килми калма, юкса үпкәләрмен!»—дип өстәп куйган иде. Бауман урамындагы элекке (Юныс Әхмәтҗанов чорындагы) татар ашлары йортының зур залында оештырылган кичке мәҗлес юбилярның үз авторитетына лаек рәвештә халык белән шыгрым тулы, мул һәм ихласлыгы белән аерылып торган иде. Кичәдә катнашкан артистлардан Вафирә Гыйззәтуллинаның аерата илһамланып, бии-бии җырлавы да истә калган. Бигрәк тә юбилярның ана яратып, сокланып каравы күз алдыннан китми...

* * *

Соңгы мәртәбә аның белән иркенләп сөйләшүебез хастаханә шартларына туры килде.

Кинәт кенә әллә нидән эч авыртып, касык тирәләре дә катып җафалана башлагач, кинәш сорап, профессор Марс Михайловка шалтыраткан идем. Ул исә, ай-ваема карамыйча, мине Вишневский исемендәге урология хастаханәсенә илтеп салды. Тик бер көн узуга сәбәбен табиплар да билгели алмаган әлеге чирем, пычак белән кырып алган шикелле, ничек башланган булса, шулай ук кинәт юкка да чыкты. Берәр нәрсәдән агуланган булуың ихтимал, диделәр. Шундый нәтиҗә турында хәбәр иткән табип күрше корпуста профессор Гайнуллин ятуын, операцияне уңышлы кичерүен, хәзер инде «йөгереп йөрүен дә» әйтте. Шул ук көнне кичен хәлен дә белим, җае килсә, чак кына әңгәмәләшеп тә утырыйм дигән ният белән эзләп киттем үзен.

Бер зур палатада үзе генә ята икән. Шатланып каршылады. «Һай, шәп булды бу! Эчем пошып ята идем, ялгыз ятуның начар ягы да бар икән,»—диде кулларын уып.

Бераз ябыга төшкән булса да, кәефе, күренеп тора, әйбәт кенә иде. Көлә-көлә операциянең ничек ясалуын, наркоз шул урында гына булгач, хирургларның кайда ничек кисүләрен, үзара ничек сөйләшүләрен ишетеп яткан икән.

Минем ничек «яп-яшь килеш» монда эләгүемне сорашкач, чиремнең үз-үзеннән бетүен ишеткәч: «Була андый очраклар, нирвыдан да булуы ихтимал»,—диде дә сүзне икенче якка борды. Тарих фәне өлкәсендә, бигрәк тә Мәскәү тарихчыларының соңгы хезмәтләрендәге яңалыклар белән кызыксынды.

—Соңгы вакытларда, сәламәтлегем артык борчыгач, яңа әдәбият белән җүнләп таныша алмадым шул. Ярар, чурт эсним. Хәзер начар түгел. Карале, Алтын Урда буенча яңа мәгълүматлар тапмадыңмы тагын? Онытканчы шуны да әйтим әле, Алтын Урда белән артык мавыгып, Болгарны да онытмагыз инде!

Беркадәре вакыт шул тирәләрдә юангач, сүз үзеннән-үзе дигәндәй татар-башкорт мөнәсәбәтләренә, татар әдәби мирасын йолкып тарткалау тирәсенә күчте.

—Бу көннәрдә шуның хакта күп уйланып яттым әле,—диде ул һәм беркадәре вакыт тел очын боргалап утырды.—Сез яшьләрнең безнең буынны гаепләве хакында да... Дөрес, мирас өчен талаш асылда Мәҗит Гафурины ике халыкның да уртак шагыйре ясаудан башланды. Монда безнең өлеш бар барын. Башта без иҗатын татар милләтчесе буларак башлаган Мәҗит Гафурины башкорт шагыйре дә дип әйтүдән әлләни югалтмабыз дип уйлаган идек. Башкортлар белән бер инештән су эчеп, бер табактан аш ашаган халык бит без. Мин үзем аларга карата ихлас дус та, рәхимле кардәш тә булудан бернинди хилафлык күрмәдем. Күрмим дә. Ин якыннан аралашып, хәтта туганлашып беткән халыклар бит без! Никадәрле чын татарларның җир алу өчен башкорт булып язылуларын да онытмыйк. Шуңа күрә кайбер әдипләрнең чыннан да уртак булулары табигый бит! Тик соңгы елларда алар чама хисен бөтенләй югалттылар шул. Татар теле булмаган, төрки тел генә булган дип

әйтүләре дөреслеккә һич тә туры килми, бигрәк тә әдәпкә сыеп бетми. Бу бит төгәл бер халыкны тарихтан бөтенләй сызып ташларга омтылу дигән сүз бит! Теге ни, урыслар әйтмешли, «свинья за стул—нуги на стул» дигән шикелле килеп чыкты шул.

Үзенен кискен хөкеменнән үзе дә сискәнгән кебек кинәт туктап калды ул, бераз сүзсез утырды. Аннары өстәп куйды:

—Әгәр фәлән вакытка кадәр башкортлар татар теленнән, татар әдәбиятыннан файдаланган, үз өлешләрен шул процесска керткән дип әйтсәләр, моңа кем каршы чыккан булыр иде? Мондый юлдан баш тартып, авторларны, әсәрләрне тупас рәвештә башкортлаштыру, үзләштерү юлын сайладылар... шул рәвешчә бетмәс-төкәнмәс конфликт барлыкка килде...

—Башкортстанда яшәүче кайбер татарларның үзләре дә моңа шактый өлеш керттеләр шикелле,—дидем мин, сүзгә кушылырга теләп.—Шундый татарлар мәсьәләне күбрәк болгаттылар бугай. Аннары Казан галимнәре белән язучылары да кунак-кунак уйнарга, Уфага барып сыйланып кайтырга да яраттылар шикелле.

—Анысы да булмады түгел, булды! Тик татарның болай артык уступчивый булуында башка сәбәпләрнең, зуррак сәбәпләрнең барлыгын да онытмыйк...

—Акланыр өчен һәрвакытта...—дип башлаган идем, Мөхәммәт ага кулы белән ишарәләп туктатты:

—Гафу ит, акыллым, әйтеп бетерим инде сүземне бер башлагач... Синең, егетем, утызынчы елларның гарасатларын үз җилкәңдә татып караганың бармы? Шул-шул!.. Үзбаш фикер йөртергә сәләтле зур әдипләребез, чын белемле галимнәребез төркем-төркеме белән төрмәләргә утыртылгач, юк ителгәч, милләт мәнфәгатен якларга кемнәр калды соң? Бер төркем котлары алынган, кечкенә «җилдән дә» яфрак кебек калтырап тора торган куркаклар һәм бармак белән ясалган ярты надан «галим» кисәкләре! Аларның барлык горурлыгы, хокукка «правалары» ата-бабаларының ярлылыгы, хәерчелеге белән мактану иде. Ярлы кеше баласы булсан—әйбәт, бай кеше, мулла кеше нәселе булсаң—начар, имеш... Андыйлар халык, милләт мәнфәгатен анларга сәләтле иделәрме соң?!. Бер сүз белән әйткәндә, утызынчы еллар гарасатыннан соң без башсыз диярлек калган идек. Әйе, башсыз калып, бик вакланып калган идек. Вак кешеләрнең интереслары да вак була шул...

Мине Мөхәммәт аганың үзенә, үз буыны вәкилләренә карата бу дәрәҗәдә кырыс, хәтта рәхимсез рәвештә хөкем чыгаруы гаҗәпләндерде, әлбәттә. Шуңа күрә, сүзгә кушылырга җай таба алмыйча, тын гына утырдым. Бераз сөйләүдән тукталып торган Мөхәммәт ага тынычрак тон белән тагын сүзләрен дәвам итте:

—Кырым татарларын, кайбер Кавказ халыкларын үз илләреннән сөрүләр... 1944 елгы мөһим карар да, тез артына гына түгел, муен тамырына да суккан иде безнең. Татарны татар булудан биздерә башлады ул карар. Башкортстандагы кардәшләребездән бер өлешенең башкорт булып язылуларының сәбәбе менә шуннан килә, минемчә. Бер сәбәбе генә, билгеле. Шул карардан соң халыклар арасындагы дуслык турында сүзләр куерганнан куерды. Тик бер үк вакытта бер халыкны икенчесенә өстерү дә барлыкка килгән иде. Мәктәп дәресләкләрендә татар исеме сүгенү сүзенә әверелә язды. Димәк, сәбәпләрнең елга башын башка яклардан, башка мәнфәгатьләрдән дә эзләргә кирәк... Болай дип әйтү белән мин үземне, үз буыным вәкилләрен акларга җыенмыйм. Юк! Бездә дә гаепләр бар, хәтта күп. Әйткәнемчә, бик вакланган идек без. Күп очракта көндәлек ризык, кечкенә торак өчен генә бил бөгеп эшләргә риза булдык. Ни кушсалар, шуны эшләдек. Бер-беребезне сатуга кадәр барып җиттек. Бер телем ипи, бер калҗа ит, бер җылы сүз өчен... Бу көннәрдә, бульнис шартларында менә шулар хакында күп уйланып яттым әле мин... Уйдан вакыт-вакыт башым шартлардай булды!...

Бераз утыргач өстәп куйды:

—Апирацияне җинел узды дисәләр дә, яшь тә килеп тәрләгән бит. Алла кайчан ни буласын бер кем дә белми. Кыскасы, сират күперен узып барыш хәзер. Аны барыбер бер узасы...

Әңгәмәнең бәхәскә әверелүен, кискенләшүен, мәсьәләнең болай артык тирәнгә кереп китүен, хәтта драматик төс тә алуын көтмәгән идем, әлбәттә. Хәзер уйлап карасам, хәтәр чиргә дучар булган, ясалачак операциянең әллә нинди нәтиҗә бирү

ихтималын да анлаган картыбыз шулай төрле яклап уйланырга, үзенә карата да кырыс хөкем чыгарырга мәҗбүр ителгән икән. Аның сүзләрендә акланырга теләүдән бигрәк үз-үзен анларга омтылу көчлерәк иде шикелле.

Минемчә, бу мәсьәләләр хакында Мөхәммәт ага элек тә уйлаган булганга охшый. Аерым-аерым, өзек-өзек рәвештә дигәндәй. Әмма хастаханә шартларында, бигрәк тә хәтәр операция көтелгән вәзгыятьтә барлык борчылулары бергә кушылып, бүселеп чыкканга охшый. Бүген ул шулай еллар буена эчендә җыелып килгән борчылуларын берьюлы бушаткандыр мөгаен...

Китерелгән дәлилләре бер селтәнүдә кире кагарлык түгел.

Хәер, аларның буыны гына түгел, без дә күп очракта, төптәнрәк уйлап карасаң, өстән-өстән генә фикер йөртеп, берьяклырак хөкем чыгарырга ашыгабыз түгелме соң?..

* * *

Фикер алышуның кискенлеген бераз йомшартыр өчен әңгәмәгә шаянрак юнәлеш бирергә тырыштым:

—Ничек уйлыйсыз әле, Мөхәммәт ага: татар әдәби мирасын шулай мул итеп үзләштерү нәтиҗәсендә башкорт культурасының чын милли сыйфатлары юылып, ахыр чиктә саф башкортларның үзләре дә татарлашып бетмәсләр микән?

—Кызык фикер, булуы ихтимал,—диде ул уйлана төшеп.—Ләкин тарихта моның киресе, дин һәм язу культурасының үзгәрүе аркасында бер милләтнең икегә аерылу, үзара дошманлашу фактлары күбрәк бит. Мәсәлән, Ливан гарәпләре, Ольстердагы хәлләр. Серблар белән хорватларны да шулайрак диләр. Керәшеннәр дә уйландыра...

—Ләкин безнең арада бүген дин ягыннан да, динсезлек җәһәтеннән дә артык аерма юк бит...

Мөхәммәт ага тагын уйланып калды:

—Алай гына җинел уйлама син. Диннән тыш идеология белән сәясәт тә бар әле... Ярар, чурт эсним! Ничек әле, иртәгесе көн өчен ишәк кайгырсын, диләрме? Тамак кипте, бер чәй эчеп җибәрик әле,—дип термоска таба үрелде, үзенә—чынаякка, миңа стаканга чәй салды.

Кайнар чәйдән бер-ике йоткач:

—Чурт эсним,—дип кабатлады.—Минемчә, тарихи дөреслек барыбер өстен чыгачак әле! Дөреслек бит ул капчыктагы без шикелле, барыбер тишеп чыга. Сак кыланмасаң, үзенә дә кадала... Әйдә, оптимист булыйк, яхшыдан өмет итик!

Бу сүзләрдән соң ул гадәти, шат табигатьле, көләч йөзле Мөхәммәт агага әйләнгән иде. Ләкин бу кыяфәте вакытлы күренеш, тышкы кабык кына булып тоелды миңа. Эчке серне, авыр чирне яшергән кабык булып...

Паркта беренче мәртәбә күргән «әдәбият белгече профессор Мөхәммәт абый Гайнуллин» искә төште. Ул көн белән бүгенге көн арасында нинди зур аерма!..

Әйе, кешеләр хакында күп очракта бик ашыгыч рәвештә берьяклы фикер йөртәбез икән шул...

Ишектә шәфкать туташы күренде. Кулында шприц иде. Кул сәгатенә карап, китәргә вакыт диган сыман, миңа ишарәләп куйды.

—Иртәгә дә кер, сөйләшәсе сүзләр күп әле безнең!—диде Мөхәммәт ага, үзе уколга әзерләнә башлады.

Тик иртәгесен кереп булмады аның янына—иртәгесен мине хастаханәдән чыгарып җибәрделәр.

Шулай итеп, бу безнең соңгы мәртәбә иркенләп сөйләшүебез, гыйбрәтле аңлашуыбыз булган икән.

*15-22. 09. 2005*
*Наратлы*

# «ИНДЕ ҮЛСӘМ ДӘ БУЛА...»

## МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ. КӨНДӘЛЕК СӘХИФӘЛӘРЕ

**1943 ел.**

Ач вакытта гадәт буенча озын тәнәфестә өйгә йөгереп кайттым. 2 класста укыйм, әти төрмәдә, әни 4-5 баланы туйдырырга тиеш. Беркем эшләми. Фашистик алым белән безне изәләр. Әни әҗәткә он эзләп чыгып киткән икән дә, кайтып керде. Мин ишек янында сөялеп торам. Әни берни дә тапмаган. Шунда әни мине кочаклап җылады: и бала, сиңа нәрсә ашатыйм инде мин, дип. Мин дә җыладым да, мәктәпкә кереп киттем. Башка көнне озын тәнәфестә өйгә кайтмадым. Проклятие Сталину! Кабахәт, иблис.

И күңелле көннәр бар иде! Матур кыш, мин яшь—24тә, флоттан кайткан, кыш көне лыжада йөрим, ял көне, беләм—әни мичкә яккан, нәрсәдер пешерә. Кызарып-пешеп өйгә кайтам, барысы да матур, барысы да әйбәт, минем бу дөньяда бер дошманым юк, мин дә бик әйбәт, кешеләр дә бик әйбәт. Ул кышкы матур көннәр, ул моржадан чыккан тәмле исләр, ул авылның кышкы тын көннәре!

Чеховның "Белолобый" хикәясен авыл малае укый: Билал абый... Шуннан ары аның фантазиясе юк, теге сүзнең мәгънәсен аңламый.

Әдәби деталь:
**70 еллар** егетләре-кызлары карточка артына язалар:

*Ялгыз каен ялгыз җирдә үскән,*
*Ә мин ялгыз җирдә үсмәдем.*
*Ямьсез икән диеп карамагыз—*
*Матурлыкка диеп төшмәдем.*

Көймә комга терәлде дигән әйтем татар халкында бар. Димәк, борынгы бабалар балыкчы, елгачы булганнар: Иделдә, Камада һ. б.

Мине бүген патша итсәләр иң беренче нәрсә эшләр идем?

Без яшь вакыттагы вальслар, танголар, фокстротлар, җырларны, музыканы җыйдырыр идем дә көн саен кич шуларны тыңлар идем.

Тальян гармуннар, русский гармуннарда уйнаучыларны радиокомитетка чакыртып яздыртыр идем.

Авыл турында язганда искә алырга: ...Зөлфия—как тип. Аның бөтен тормышын, булганлыгын, әдип-фольклорчы, табигать баласы икәнлеген, чыршы башыннан карга күкәе, җиләк җыю, кыр үрдәге тоту, әрекмән белән киенү... һ. б., һ. б. Трагический финал.

**9. II. 79**

**1970 елда** ел башыннан мине бик каты кыйный башладылар. Бер мәкаләм өчен. Шуннан мин неблагонадежныйлар исемлегенә кердем. (Хәзер ул мәкаләне рәхәтләнеп цитировать итәләр). Шул елны әни бик каты авырый башлады. Саташа башлады... Шул чорда мин "Фронтовиклар" дигән роман яздым. Хәзер шуның икенче изданиесен әзерләп утырам—шаккатырлык! Ничек яздым икән? Әгәр мине тормыш шулай кыйнамаган булса мин аны яза алыр идемме икән?..

---

*Дәвамы. Башы журналыбызның 11 санында.*

Әгәр дә кешеләр мина күпме әдәби материал биргәннәрен белсәләр иде, минем белән елмаеп кына, хәл-әхвәл сөйләшеп кенә яшәрләр иде. "Ах, кызганыч бәндәләр, кызганыч бәндәләр" (Г. Коләхметов).

"Ахмак (начар) кешеләрне исән чагында таяк белән шунын өчен кыйнарга кирәк, чөнки үлгәчтен янә тагы бер кат хурлап, мыскыл белән тамгалап, җәзалап булмый. Алар үлгәннән сон үзләре турында һичбер исем калдырмыйлар". Г. Гейне.

Сонгы заман җырларында конкрет фикер әйтергә куркалар.

"Башны башка терәп сина әйтер сүзем барсыман..." Нишләп барсыман? Бу—алиментлы карт бер бабник сүзе. Конкрет әйтүдән курка.

Тагын: "Сине уйлап йөрәкләрем әллә нишләде..."

Ә нишләде сон? Йөрәк усаллана, бозыла, рәхәт чигә һ. б., һ. б. Ә монык нишләгән? Автор өстенә алмый.

Тагын: "Тик берәү, тик берәү анлар күк миндәге ярсулы хәлләрне..." Нинди ярсу? Кеше үтерергәме? Ут төртергәме? Тик "кем" генә ул "берәү"? Автор әйтергә курка.

**2. III. 79**

"В рабочий полдень", концерт. "Костры горят далекие"—Нечаев.

"Сормовская лирическая"—Отс Георг.

(Мин шуларны тынлаганда яшьлегемә кайттым да еладым. "Сорм. лир." җырын 1952 елда отпускка кайтканда матрослар, солдатлар белән Волга күперен чыкканда җырлаган идек).

Безнен Казаклар тегермәне янында тугайда бер карт каен бар. 1939 елнын җәендә (ул көннәрдә матбугатта яна алфавит турында шаулыйлар иде, шуна күрә елы хәтердә калган) без абый белән шунда тегермән чиратына төшкәч шул каен янына чыккан идек. Печән вакыты идеме икән? Мин, арада ин артык кеше, бер читкә барып утырдым, каен күләгәсенә ике-өч авылнын кызлары, егетләре җыелган иде. Кара янган битле, кара-чутыр беләкле, юан-таза бәдәнле кызлар чирәмгә капланып ятканнар да, сабыр гына егетләр белән сөйләшәләр, сабыр гына уен-көлке әйтешәләр иде. Мин алардагы тазалыкка шаккатып карап утырдым. Ана гына түгел: һәрберсе үзенчә горур, үзенчә шәп, "шәхес" иде.

Бичаралар... Анда алар белән сөйләшеп яткан егетләрнен барысы да диярлек сугышта беттеләр. Ул кызлар сугыш вакытында кадерсезгә калдылар. Аларнын бәяләре төште. Аларны сугыштан сон тегеләй иттеләр, болай иттеләр. Целая психологическая революция. Хатын-кызнын ин кадерле әйберсенен бәясе сукыр бер тиен булып калды.

Ул каен әле дә торамы? Карарга кирәк.

**79 ел, 3 IV.** Яза-яза ун кулыма паралич була ахры инде. Каләм сабы тотуы көннән-көн авырая. Ике бармагым бик сызлый. Яз, яз кигә. Урамда әтәч кычкыра. Шәһәрдә! Молодец!

Искә төште: ике-өч ел элек май аенда янгырлы бер көнне Бөгелмә аэропортында утырган идек. Безне—М. Хәбибуллин, М. Әгъләмов, мине Миргазиян Юнысов апасы Кәшифә белән бергә озата килгән иде. Миргазиян зур дөньяга ашыкты. Мәскәү—телефон, театры, встречи, ЦДЛ, дуслар...

Бер ачыш: Тукай Уфага баргач, М. Гафурины сорашмаган, бармаган, бер китапханәгә кереп ящик өстендә ял итеп яткан. Тукайны кунакка чакырырга Гафури үзе йөгереп килгән, әмма Тукай ана бармаган.

**1979 ел, 3 августта** Пицундага килдем. Юлга чыгарга ике көн кала нервларга әллә нәрсә булып бик авыр сәгатьләр кичердем.

Әле дә рәтләнеп бетми, нәрсәгәдер бик каты эч поша. Дингез дә, коньяк һавасы да шатландырмый. Менә өч көн инде үземә монда да урын таба алмыйм. Авыр.

"Грозна, страшна грядущая впереди старость, и ничего не отдает назад и обратно!

Могила милосерднее ее, на могиле напишется: “здесь погребен человек”, но ничего не прочитаешь в хладных, бесчувственных чертах бесчеловечной старости”. Н. В. Гоголь (где?). Пицунда **1979, 11. VIII**

**22 август.** Иртәгә өйгә кайтасы. Әллә нигә эч поша. Хәерле булсын. Самолетка авария булыр кебек. Мин кайтышка өйдә бер бәхетсезлек булыр кебек. Аллага тапшырдык.

**4 сентябрь, 79 ел.** Искәндәрне укыткан ике укытучы авиакатастрофада һәлак булганнар. Мәктәптә бүген уку юк, траур. Әмма бөтен бала шат: укучылар өчен разведчиклар турында фильм (бушлай) күрсәтелә. Ишек алдында иртәдән бирле шатлыклы авазлар яңгырап торды.

Бу дөнья—шулай...

Пушкин—Н. А. Дуровой

“Издать книгу нельзя в одну неделю; на то требуется по крайней мере месяца два”. Ха-ха!



*Авылда. 1974 ел, июнь.*

Бүген искиткеч матур кояшлы көн (6. IX. 79). Пионерскаяга бардым да, кибетләрдә йөрдем. Кайтып китәр алдыннан гына борынга аш исе килеп керде, башым әйләнде, кире борылып эшчеләр ашханәсенә кердем. Мин анда 55-56 елларны кергәли идем. 23 елдан соң шунда кереп, талон алмыйча, чиратсыз бер тәлинкә щи алдым. 20 тиен биреп. Мин бик бәхетле идем. Исәпләдем: 1947 елда, реформага кадәр, Арча ресторанында шуннан начаррак щи 17 сум тора иде. 1947—17 сум = 1 с. 70 тиен калды. 1960 елгы реформа—1 с. 70 =17 тиен.

Эшчеләр арасында, студентлар, узучылар арасында ашадым. Рәхәт, ләззәтле булды...

Авыл егете шәһәргә килгәч үзенең заводка киткән кызы белән очраша да, икесе дә сөйләшеп йөри торгач, колхоз базарына баралар. Тегесен-монысын сатып алалар, күзгә байлык, рәхәтләнеп йөриләр. Кино да, музей да кирәк түгел, кан тарта—базарда ни әйтсәң дә үз халкың. Авыл рухы.

* * *

Авыл егете шәһәрдәге кызы белән кинодан чыккач тәмәке кабыза да: «Ну, ошадымы соң?»—ди. Гел шулай гына була ала.

* * *

Пычрак, юеш октябрь көне, шыксыз шәһәр, шыксыз, туңган кешеләр. И шул көнне авылдан культпоходка килиең дә, колхоз базарына кереп тозлы кыяр ашап, иптәшләр белән шәпләп эчиең дә пригородный вагонга кереп караңгы кырлар буйлап авыз киереп җырлап кайтыең...

**1979 ел.** 39 ел узгач... октябрьнең 25е. Кемдер “Бьется в тесной печурке огонь...” дигәнне уйный. Безнең йортта. Елыйсы килә. Шул изге көйне хәтерләүчеләр бар әле. Жить... жить... Гаҗәп...

**1950 ел.** Октябрь. Юк, сентябрь ахыры. Коры, жылы жилле төн. Яфраклар оча, бик жылы. Ай—сап-сары, бик зур. Агачлар шаулый. Жил, жил...

Мин повестка көтеп йөрим. Барысын да ташлап, бөтен бурычларны, йөкләмәләрне ташлап, барысын өзеп китәм. Барысын да өзеп, бер дә кайтмаска китәсе килә. Шунда мин З. дигән бер кыз белән урамда торам. Төн, сары ай, агачлар инри, сыгыла. Ул кыз—финансист, район үзәгенә (Яна Чуриле) эшкә килгән. Бик нәфис, матур күзле. Мине үбә дә үбә. Бер сүз әйтми. Минем китәсен белә. Туйганчы үпте дә, муенга асылынып яннаклардан сыйпады да, квартирасына кереп китте. Ә мин жилле сары төндә ялгыз басып калдым. Ахырдан ул кыз мина бик акыллы, ләкин авыр хат язды: мина больше язма, язышуны дәвам итүне кирәк дип тапмыйм, диде. Ә мин аны гел сагынып яши идем. Шуннан онытылды.



*Арча, сабантуйда. 1981 ел, июнь.*

Тик күк йөзендә сары ай күренгән көзге кичләрдә генә шул кыз, анын бантиклы суконный эшләпәсе, чәчләреннән килгән ислемай исе гел хәтергә төшә икән. Мин аны әле нәрсәгә хәтергә төшкәнен белеп яшәми идем, ә бүген көзге айны күрдем дә (инде кыш) шул матур, борчулы әлләнинди бер кичне искә алдым. Картайдым—факт.

Нәкъ 1979. 7. XII 42 ел элек—19 XII 1937—минем әтине алып чыгып киттеләр. Мин мона Лев Толстойча гына сорау бирә алам. Анын шундый әсәре бар: "За что?"

Хөкемдардарга каршы килү—үз каныңны үзең агызу кебек.

Мин авылда ике малайның егетлеккә күчкәнен күрдем: кесәләреннән тиккә генә түгәрәк көзге чыгарып үзләрен карап алдылар. 1936 елда Хөрмәт (сугышта үлде). 1939 елда—Мансур. 9 яшьтә кесәсендә көзге бар иде. Миндә ул хаҗәт 1945 елның язында "Үрнәк"тә укыганда туды.

Бүген төш күрдем: дүрт топольнең берсен кистем, аудардым. Урамнан әни кайтып килә. Каршына чыктым, ул үлгән иде, шуннан кайта. Кочакладым да елыйм. Тезләнеп еладым. Урамдагы бөтен күршеләр карап тора. Рәхәтләнеп елап уяндым, иртәнге сәгать 4 иде. Аннан йоклый алмадым. Авыр булды.

**1980, август.** Нукус—Каракалпакстанда йөрибез. Шамуков Габдулла белән бер машинада. Шамуков тәгәри-тәгәри көлә. "Әйдә барыйк, кызлар карыйк" дигән язмада "Бетховен һәм Казиле Зариф" дигән бүлек бар. Шамуков тәгәри:—Разница бик зур бит, каһәр,—ди.

*Ахыры киләсе санда*

Миргазиян
Юныс

# КУНАКХАНӘ МАҖАРАСЫ
# ЯКИ РӘШӘТКӘЛЕ КУПЕ

*Шагыйрь белән шагыйрь дуслаша алмый.*
*Дуслашса да бары тыштан гына—*
*Түрә белән бары куштан гына...*

Гамил Афзал

## 1

Бәлки бу тинтәклегемне дә кәгазьгә теркәп калдырырга кирәктер?

Әдәбиятка атлап кереп кенә килгән чагым. Тәнемә бармак калынлыгы тоз сеңгәнче дингезләрдә йөреп кайтканнан соң татарларның тарихи һәм рухи Мәккәсе Казаныма юл тоттым. Килеп төштем, чемоданымны күтәреп ул чакта Бауман урамындагы Язучылар берлегенә юнәлдем. Коридорда дистәгә якын каләм остасы дөньяның катлаулы проблемаларын чишә иде. Мин күп өстәлле кысан бер бүлмәгә килеп эләктем. Бер почмакта мине әдәбиятка житәкләп алып кергән кеше—Илдар Юзеев утыра. Хәл-әхвәл сорашканнан соң ул кунакханәгә урнашу мәсьәләсен Гариф Ахуновның урынбасары—минем якташым янына кереп хәл итәргә киңәш бирде.

Кердем. Кабинет иркен. Өстәлдә ул чакта райком секретарьлары гына куллана торган телефон, акча кәгазенә басылган календарь, кул куярга кертқән кәгазьләр, затлы папкалар.

Якты йөз белән каршы алды Якташым, урын күрсәтте, гозеремне сорады.

—Миңа кунакханә кирәк иде. Биш-алты көнгә, аерым номер.

—Эшлибез аны, яшьти. Кунакханә мәсьәләсе чиктән тыш катлаулы булса да.

«Яшьти» сүзен беренче тапкыр ишетүем. Бездә гадәттә «яшьтәш» дип яисә урысчалап «годок» дип дәшәләр бер елда туган егетләргә.

—Мин «Казан» кунакханәсен яратам, анда бик тә шәп люкс бар. Шуларның берсен эләктерәсе иде.

—Ярый, яшьти. Әйттем бит, кунакханә мәсьәләсе проблема, дип. Көт, оештырырбыз.

Гадәттә житәкчеләр тел озайтып утырганны яратмыйлар, чөнки аларның һәр минутлары алтын бәрабәренә. Мин көтәргә вәгъдә биреп кабинеттан чыктым да, янә Илдар Юзеев янына кереп утырып, башланган сүзне дәвам иттем.

Бераз вакыт үткәч, «яшьтием» янына тагын кердем. Ул тагын шул «көтәргә кирәк»не кабатлады.

—Ярый, мәсьәлә ачыклангач чакырырсыз. Мин Илдар Юзеев янында булырмын.—Шушы сүзләрдән соң тагын чыгып киттем.

Тагын бер-ике мәртәбә керергә туры килде. Урынбасар һаман шул ук сүзләрне тәкрарлады. Соңгы керүемдә мин Рәис Даутовларга барачагымны һәм шуннан туры Якташым заказ биргән «Казан» кунакханәсенә кереп урнашачагымны әйттем дә:

—Кабат очрашуга кадәр,—дип, яшьтиемнең кулын кысып чыгып киттем.

Рәис дустым һәм Галиәсгар Камалның нәбирәсе (оныгы) Диләрә мине татарга гына хас кайнар кунакчыллык белән каршы алдылар. Татлы сый, тәмле сүз вакыт

агымын тизәйттеме, әллә дуслык хисләре изрәтеп җибәрдеме, беренче тапкыр сәгатемә караганда төн уртасы якынлашып килә иде инде. Мин ашыгып җыена башладым.

—Төнгә каршы бимазаланып йөрмә инде, кунып кына кит,—диде Диләрә ханым.—Кунакханәнә иртәгә дә өлгерерсең әле.

—Көнендә урнашып калмасаң, сөйләшүнең юкка чыгуы бар. Якташым минә кунакханә мәсьәләсе бик катлаулы диде.

Таксида барганда «Казан» кунакханәсендәге люкс турында уйладым. Йокы бүлмәсе аерым, кунак каршылый торган алгы бүлмә иркен. Җиһазларның кайберләре Тукай заманыннан бирле сакланып калган. «Шератон»нар, «Һилтон»нарың бер якта торсын!

Администратор янына килдем. Паспортымны күрсәттем. Бронь юк иде. «Димәк, Якташым «Татарстан» белән сөйләшкән. Анда да начар түгел бит. Дөрес, бер урынлы бүлмәне эләктерү катлаулырак. Ике урынлысында да яшәргә була...

Монда да минем турыда беркемнең дә кайгыртмаганлыгы ачыкланды. Күнелемә шундый уй килде: «Янында сөйләшеп утырмавыма хәтере калган булса кирәк. Шуны белгертер өчен мине юри начаррак җиргә урнаштыра».

Мин Казан каласында булган барлык кунакханәләргә сугылып чыктым. Хәтта кандалага батып беткән «Колхозчылар йорты»на да кереп карадым. Анда да заявка да, урын да юк иде. Ә бит беренче керүдә Якташым:

—Эшлибез аны, яшьти,—дип, күнелемә ышанычлы өмет салган иде. Урынбасар янына кереп йөргәндә әһәмият бирмәгәнмен икән, әле генә бу хәлгә гаҗәпләнеп куйдым: кергән саен җитәкченең вәгъдәсе сүлпәнәя барды. Мин бит моны аңларга тиеш булганмын... Төп башына утыртты бит бу мине!

Иртәгә мин алып килгән чит ил эчемлекләрен авыз итәргә әшнәләрем җыела башлаячак. Тукта әле, Якташым мондый дегустацияләргә бер генә тапкыр да катнашмады бит. Бәлки аны да чакырырга кирәк булгандыр? Гамьсезрәк йөрүемнең бер сәбәбе шул: диңгез буена урнашкан портлы шәһәрләрдә кунакханәдә эшләүчеләр диңгезчеләргә чиктән тыш мәрхәмәтле, әйтеп бетермәслек дәрәҗәдә кайгыртучан иде. Ничә еллар корабтан төшеп калганнан соң Одессага кайтыр алдыннан самолет яисә поезд көткәндә бер генә тапкыр да урамда кунганым булмады минем...

Бәлки, унайсызлыкка кул селтәп, Рәис Даутовларга барыргадыр? Юк, бер тапкыр баш тартканнан соң кире кайту һич тә егетлек түгел инде... Ә Мөхәммәт Мәһдиевнең ишегән шакып карасам? Юк, кысанлыктан котылыр өчен ничәмә еллар ялыктыргыч көрәш алып бара ул. Тукта әле, минем бит иркен квартирда яшәүче дустым бар. Җае чыккан саен ул мине мактарга тырыша, әсәрләремә эчке рецензияне күкләргә чөеп яза. Урам автоматыннан шул дустыма шалтыраттым. Башта бик озак трубканы алмый тордылар. Ниһаять:

—Кем шалтырата?

Сорау чиктән тыш рәнҗүле иде. Табигый хәл, кешене төн уртасында уяту, бигрәк тә үзен кызганмыйча көне-төне диярлек Прометей аяусызлыгы белән эшләүче кешене. Шушы турыда уйлау белән тавышым шиңде. Көч-хәл белән әйттем исемемне.

Сүгенү буенча кораб боцманнары белән кем ярыша ала икән? Күп ишеттем мин алар авызыннан чыккан, урысның горурлыгы саналган данлыклы газиз аналарны тегеләй-болай итүне... Минем колак пәрдәмә килеп бәрелгән мат боцманнарныкыннан күпкә аяусызрак иде. Бу—кимсетелү, таптау шартларында туган паханнар маты иде. Шушы ике сүз хәл итте тәкъдиремнең алдагы беренче адымын. Алып килгән чит ил эчемлекләрен йотып утырганда җырланган арзанлы мәдхиягә башым әйләнгән мин идиотның. Алар бит искиткеч авыр шартларда эшләп табарга тиешләр ипекәйләрен. Газета-журнал редакторлары, нәшриятныкылар, баш редакторлар. Шуларга өстәп, Язучылар берлегендә утыручылар. Ниһаять, әдәбиятның кашка тәкәләре дәрәҗәсенә ирешкән, өлкә комитеты белән даими элемтәдә торган язучылар. Шуларның берсе генә булса да сиңа дошманлык күрсәтә икән, син ипекәйсез калдың дигән сүз. Ә мин ипиемне башка юл белән табып яшим...

Казанга килгәндә җинел генә тоелган чемодан Казан урамынын салкын ташларына басып вокзалга барганда шул кадәр авыр тоела иде. Өстәвенә баш акылы минем Казаннан кайтып китүемә каршы. «Син чираттагы дуамаллыгыңны эшлисен,—ди ул мина.—Ну, китәрсен Казаннан... Нәшриятларда эшлисе эшләрен эшләнмичә калыр. Дусларын рәнҗер. Ә сине төп башына утырткан Якташын синен бу дуамаллыгыңны үз файдасына кулланачак. Ул бит акыллы кеше. Синен юләрлегенне раслар өчен йөз төрле дәлил таба алачак. Китмә Казаннан. Вокзалда төннен калган өлешен үткәреп җибәр дә иртәгә кунакханәне башка кеше аша оештыр. Монда энен белән Әфганстанда эшләгән житәкченен үз карамагындагы кунакханәсе бар. Туган-тумачан бар бу калада, авылдашларын бар». Йөрәк акылы бу дәлилләрне пыр туздырып ташлады: «Шушы мәсхәрәдән сон да баш иеп үзеннән көлгән бәндәләр каршына барсан... Кая сон синен горурлыгын? Егетлеген кая?»

Күпме иза чиктем мин шушы компромиссыз йөрәк акылынын аяусызлыгы аркасында... Күпме авырлыклар, күпме югалтулар кичердем. Бәлки, йөрәк акылы шул тәкъдир дигән нәрсәнен үзедер? Яисә ул язмышымны алдан белеп, шуна таянып эш итәдер? Анын нигә җинеп чыгуларын башкача анлатып та булмый бит... Шушы уйлар белән мин Казан вокзалына килеп кердем.

## 2

Шундый шыксыз иде вокзал эче. Сине гаиләдән, туганнардан, дус-ишләрдән аера торган урын бит. Бәлки, шуна тимер юл вокзаллары шулай каһәрле тоела торгандыр? Гаилә җылысыннан, туган туфрагыннан аерып армиягә озата тимер юл вокзалы. Һәм поездга утырырга билет бирмичә җаныңны ала. Газиз балаларын сугышка озатып калган аналарнын, хәләл җефетләрнен, сөйгән ярларнын күз яше белән юылган аяусыз урын бу...

Габделхай Сабитовка тартым, әмма сонгы чиккә житеп таушалган, чиктән тыш ябык бәндә швабра белән вокзалнын пычрак идәнен юып йөри. Төнге кассада йокымсырап бер карт маржа утыра. Янына килеп, Мәскәү поездына билет сорадым. Чираттагы поездга билет юк иде. Сонрак үтәселәренә билетны поезд килергә ике сәгать кала сатачаклар. Маржанын кулын майларга әзер булуымны да сиздердем юкса—ярдәме тимәде.

Идән юучы янына килдем, туган телдә хәл-әхвәл сораштым. Идән юунын авыр, санга сугылмый торган эш булуын әйтеп, хәленә кердем. Сүзләремне кабул итте Габделхайга охшашлы бәндә. Шуннан сон чемоданыма күрсәтеп, әйттем:

—Анда өч бик тә әйбәт шешә бар. Чит илнекеләр. Чираттагы поездга билет оештыра алсан, шул шешәләрнен берсе синеке.

Идән юучы кипкән иреннәрен ялап куйды. Аракынын әҗәл даруы дәрәҗәсендәге чагы бит. Бу бәндәнен кыяфәтендә шешә белән дуслык ачыктан-ачык сурәтләнгән иде.

Аллага шөкер, мөрәҗәгатем җавапсыз калмады. Бер сүз дә әйтмичә, швабрасын стенага илтеп сөяде дә кассир янына керде бу. Алар бик кайнар сөйләштеләр. Боткалары пешмәде булса кирәк, Габделхайны хәтерләткән кеше икенче катка менеп төште, вокзалдан чыгып китеп, шактый озак югалып торды да минем кулыма билет китереп тоттырды. Билет ике сәгатьтән Казан аша узасы Омск поездына иде. Купе. Аскы урын. Түбәм күккә тиде. Юкка төшенкелеккә биреләм икән, бу дөньяда күпчелек әйбәт кешеләр!

Башта билет хакын түләдем. Идән юучы артыгыннан баш тартты. Чемоданымны ачып, дуслар белән эчәргә алып килгән, Эрнест Хемингуэй яраткан испан коньягы «Фундадор»ны сөйрәп чыгардым. Яна танышым туалетлар янындагы чиләкләр, швабралар саклана торган урыннан зур бер телем ипи һәм дәфтәр кәгазенә төргән йөз грамм чамасы хамса алып килде. Затлы коньякны Россиядә лимон белән эчәләр. Моны Наполеонны жингәннән сон оешкан «Изге союз» кинәшмәләрендә эчкәндә Александр Беренче патша уйлап тапкан. Коньякнын классик закускасы—бастырма. Гурманнар аны персик («шафталы» сүзен өнәмим) белән эчәләр. Әмма шушы яшькә житеп затлы коньяк өчен каклаган каздан да затлы, аннан да тәмлерәк закусканы

очратканым юк минем. Коньякны хамса белән эчмиләр дип әйтмәдем инде мина игелек күрсәткән кешегә.

Ул мине вокзалга янәшә урнашкан бинаның аулак бер бүлмәсенә алып керде. Монда ремонт бара иде. Стеналарга штукатурканы көндез генә сылаганнар булса кирәк. Әчкелтем цемент исе. Тузан. Аяк астында кантарлы кирпеч ватыклары. Бүлмәчекнең уртасында түшәмне эшкәртер өчен әмәлләнгән дүрт аяклы җайланма— «козлы». Җиңе белән цемент валчыкларын сыпырып төшереп, яна танышым закусканы шунда куйды. Мин «Фундадор»ны утырттым.

Ипи һәм хамса белән сырлы итеп эшләнгән калын «урыс стаканы»н да алып килгән икән. Коньякны шуна тутырып салып, коткаручыма суздым.

—Башта үзең эч инде,—диде ул. Эчүнең йоласы шундый бит.

—Мин юл кешесе. Исерек баштан килсәм, вагонга кертмәүләре бар. Син, дустым, гафу ит инде,—дип, чөмереп алгач, затлы коньякны йотып җибәрмичә бер тын авызымда тоттым. Кан тамырлары буенча тәнгә талгын гына рәхәт җылылык таралды. Шул җылылык испан ярларын юып шаулаучы ак яллы дулкыннарны, Әндәлүс хәлифәлеге чорыннан сакланып калган кайнар ярсуны, дәртле «Фламинго» биюләрен җанландырып, хәтеремне уятып җибәрде. Йоткан өлешне өстәп, мөлдерәмә тулы стаканны идән юучыга суздым. Ул башта тирән итеп сулыш алды, өч-дүрт йотуда стаканны бушатты да койрыгыннан тотып хамса капты.

—Ошыймы испан коньягы?

Яңа танышым шактый гына уйга калып, шешәгә карап торды.

—Дару тәме килә. Мин балачактан даруны өнәмим.

Эрнест Хемингуэй инде каберда иде. Шуңа карамастан, бу сүзләрне ишетсә, ул барыбер ыңгырашып алыр иде.

—Бу—Хемингуэйның яраткан коньягы. Аны әз-әз генә кабып, тәмләп эчәргә кирәк. Аннан соң бу эчемлеккә хамса да килешеп бетми. Шулай да бу—чын ир-егетләр эчемлеге.

Габделхайга охшашлы кеше авызындагы кара икмәк белән хамсаны чәйнәп йотты да бер тын мина карап торды.

—Хумингэй дигәне обком тирәсендә чуала торган кешедер инде. Алар төрле ят эчемлекләр белән масаерга яраталар. Менә мин чит илләрдә чыга торган журнал тышлыкларындагы «теге» урыннарын гына каплап төшкән шәрә кәнтәйләргә карап йөрим. Әй мактыйлар шуларны, имеш, хур кызларын бер якта торсын. Мин үзем алар белән бер түшәккә ятмас идем. Кай җирләреннән тотарга, ничек күңелләрен күрергә белмичә интегеп бетәрсең. Хатыным маржа минем. Кочарга да рәхәт, канына тоз салганда рәхәтләнеп кыйнап ташларга да була. Ул әле тукмаганнан соң тагын да якынрак тоела башлый. Бу коньяк та теге кәнтәйләр кебек. Юк инде, барыбер аракыга җитми. Күңегелгән.

Шешәне бушатып бетергәнче коткаручым янынnan китмәдем. Җиде йөз илле граммлы шешәнең соңгы тамчысы идән юучының карнына кереп яткач, арткарак чигенеп карадым. Юк, егылмый. Аякларын киңәйтебрәк баскан. Тора. «Менә бит безнең татар... Испанның ир-егетләрен горурландыра торган коньягы җиңә алмады. Кан көчле бездә, токым...» Габделхайны хәтерләткән танышым иелеп чемоданымны күтәрде:

—Киттек. Синең поездыңның тавышы да ишетелә шикелле.

Без перронга чыгуга чыннан да поезд килеп туктады. Уникенче вагонны эзләп таптык. Танышым чемоданымны үрелеп эчкә тыкты, проводницаның колагына пышылдап кына нәрсәдер әйтте. Кочаклашып саубуллаштык. Аумаска тырышып вокзалга таба атлап баручының коньяк парлары белән баһадирларча көрәшүе күңелдә соклану катыш горурлык уята иде.

### 3

Поезд кузгалып китте. Көпчәкләрнең рельс җөйләре белән чәкелдәп бәхәсләшеп баруы күңелне дәвалый иде. Бу тавыш дулкын гөрселдәвеннән котылып коры җиргә эләккән саен инде менә күп еллар туктаусыз кабатланып тора. Башлы-күзле

булганнан соң дингез ярында, кайчандыр минем ерак бабаларым яшәгән Хачби авылы урынында яшәү җилгә очты. Һәр ялым нәкъ менә шушылай идән астыннан ишетелгән тәгәрмәчләр тавышы белән башланып китә.

Җаным тынычлана башлады. Дөрес, нәшрияттагы эшләремне эшләп, ялыктыргыч озын айлар буе көткән дусларым белән серләшеп ялгызлык тойгысының һөҗүменнән котылу насыйп булмады. Иншалла, теге мине кочак җәеп каршы алган бәндәгә барып тез чүгүдән котылдым...

Чемоданымны ятак астындагы тартмага тыктым. Юлдашларыма күз салып алдым. Аста хатын-кыз, өстә ир кеше, минеке өстендәге ятакта яшь кенә егет. Израэп йоклыйлар. Проводница янына барып чиста җәймә, мендәр тышы, сөлге алып килдем. Поезд бригадасы Омскиныкы булса да проводница татар хатынына охшаган. Төсмерләүдән тыш кан тануы да бар бит әле. Рәхәт булып китте. Мәскәүгә барып җиткәнче мин милләттәшем җылысын тоеп торачакмын...

Урын җәйдем. Чишенеп яттым. Күзләр йомыла башлаганда борыныма аракы белән сыекланган тозлы кәбестә исе килеп бәрелде. Бер исерек, капшанып, стенага беркетелгән урын номерларын эзләп азаплана иде. Ниһаять, туктап, мин яткан җиргә күрсәтте:

—Это мое место.

—Гафу итегез, урын минеке,—дидем мин тыныч кына.—Билет проводницада. Ышанмасагыз барып карагыз.

—Нет, место мне принадлежит,—диде сәрхуш акырып.—Убирайся, гад!

Купедашлар уянды. Өске ятактагы ир шелтәле тавыш белән әйтте:

—Нельзя ли потише? Совсем обнаглели!

Тавышка проводница үзе килде.

—Бер урынга ике билет сатылу була торган хәл. Сез, иптәш пассажир, бригадирга мөрәҗәгать итегез. Ул алтынчы вагонда.

Бәлки проводница татар хатыны да түгелдер. Аның милләттәшемә охшаш булуы гына да аркамнан сыйпап назлап куйды. Эчемнән генә аңа рәхмәт әйттем. Әледән-әле ялгышсаң да язмышыңны татар хәл иткәндә син аның сиңа карата мәрхәмәтле булуына алдан ышанып, өметләнеп торасың. Ә андый куанычлы ышанулар елдан-ел сүлпәнәя, сирәгәя бара. Ышаныч кими барганлыкны да беләсең, барыбер ниндидер сукыр үҗәтлек белән Аллаһы Тәгаләдән язмышыңны хәл итәргә милләттәшеңне җибәрүен һаман ялварып сорый бирәсең...

Алар кергәндә мин инде йокыга китеп беткән идем. Тагын теге сасы ис борыныма, хәтта бәгыремә килеп бәрелде. Бригадирны ияртеп теге минем урыныма дәгъва кылучы килгән икән. Дәгъвачы лаякыл. Бригадир кызмача. «Бергәколкынганнар булса кирәк?»—дигән шомлы тоемлау күңелемә китереп тондырды. Ут яндырдылар. Бригадир билетымны борыныма тигезә язып болгап алды:

—Вы, гражданин, фальшивобилетчик! Немедленно освободите место!

Купедашлар, уянып, шаулаша башладылар. Минем җыенганны да көтеп тормыйча, дәгъвачы өстемдәге җәймә белән одеалны йолкып идәнгә ыргытты. Икенче мизгелдә чемоданым коридорга очты. Утыз җиденче еллардагы репрессияләр вакытында гавамның «халык дошманнарына үлем!»—дип ерткычларча үкергән чакларында миңа ун гына яшь иде. Шулай да хәтерлим. Муллаларны, зыялыларны, кулак тамгасы сугып авылның иң тырыш, иң эшчән игенчеләрен сөргенгә озатканда халык нәкъ мине купедан куганда карап торган күршеләремдәй карап торды.

—Мин билетның кайсы көннеке икәнен тикшермәгәнмен. Зинһар, гафу итегез. Үзегез сатмасагыз, яна билетны беренче тукталышта ук алып керәм. Төшермәгез поездан, зинһар өчен!

Алга таба барырга ымлап күрсәткәч кенә аңладым, янда торган милиционер мине кулга алырга килгән икән.

Үзара бәрелешеп аякны өзәргә торган тамбур идәненә баса-баса, бер вагоннан икенчесенә атлыйбыз. Мин чемоданымны сөйрәп—алдан, милиционер арттан. Һәр поездда милиционер йөргәнлеге миңа мәгълүм иде. Милиционер утырып йөрүче кетәккә янәшә зимагурлар телендә «каталажка» дип аталган хибес булуын шуның эченә кертеп бикләгәннән соң гына аңладым. «Кунакханә»гә урнаштык, ниһаять!..

Милиционерлар кулындагы ачкыч йозак тишегенә керер алдыннан минем бәгъремне айкап узды. Чемоданымны идәнгә куеп, поезд төрмәсенең эчен тикшерә башладым. Түшәмдәге тычкан уты кадәр генә яктылык сирпүче лампочканы тимер челтәр эченә яшергәннәр. Тәрәзә рәшәткәләнгән. Бәлки бу проводниклар өчен әмәлләнгән ике урынлы кысан купе булгандыр? Өстәлне, өске ятакны алып ташлаганнар. Шыксыз кысанлык—без инде андый нәрсәләргә күнеккән. Безне совет чорының казарма тәртипләре, чәнечкеле тимерчыбык белән уратылып алынган ил шартлары тәрбияләде. Йөрәкне әрнетеп, сине тоткын дәрәҗәсенә төшереп мәсхәрәләве—ишекне тышкы яктан шартлатып бикләп куюлары иде. Бу ил чынбарлыгы тудырган, гасырдан гасырга күчеп тә янау көчен җуймаган мәкаль искә килеп төште: «От сумы и тюрьмы не зарекайся». Нинди генә гадел, даими законга буйсынып яшәвенә карамастан, бу илдә синең бер сәбәпсез, җинел генә хәерчегә әверелеп китүең дә, бер гөнаһсыз төрмәгә юлыгуың да бар. Минем монда килеп эләгүем шуна гап-гади бер мисал...

Армия хезмәтендә гауптвахталарда утыргалаганым булды анысы. Анда да кагыйдәләр аяусыз һәм каһәрле. Әмма гауптвахтада утырганда син Рәсәй армиясенең кешене колга гына түгел, бөҗәккә әверелдерә торган кагыйдәләренә каршы баш күтәрүең белән горурлана аласың. Ә монда? Җинаятьче түгеллегенне белгертер өчен кемгә мөрәҗәгать итәргә?.. Закон яклар дип ышанырга мин бөтенләй үк томана түгел идем. Россиядә «закон что дышло».—Закон тәртәсен теләсә кайсы якка каерып була. Мәскәүдән кузгалып киткәндә нинди матур уйлар, татлы хыяллар эчендә йөзә идем... Шулай да, печтик кенә булса да бер куаныч калган икән әле. Ашыкканга күрәме, паспортымны алырга онытканнар. Чыннан да, алар ашыга иделәр, чөнки мине урынымнан кудырткан пассажир бригадир белән бергә китте. Димәк, мәҗлесләре дәвам итә. Бәлки, Мәскәүгә барып җиткәнче һаман чөмерә торырлар да минем турыда бөтенләй онытырлар?

## 4

Поезд баруын әкренәйтә башлады. Тормозлар ыңгырашып алдылар. Көпчәкләрнең шакылдавы тынды. Шушы мизгелдә йозак тишегенә ачкыч тыккан тавыш ишетелде. Төрмә тоткыннарына таныш хистер бу. Ачкыч, нәкъ бикләгәндәге шикелле, ишеккә кергәндә минем бәгъремне айкап узды.

Ишекнең як-ягында ике милиционер минем чыкканны көтеп тора иде. Муенына автомат асканы—җәлпәк борынлы бәләкәй генә сержант. Пистолетлысы—таза буйлы, төскә шактый матур өлкән лейтенант. Поезд милиционеры, лаякыл ук булмаса да шактый исереп өлгергән карсак кына җирән старшина, өлкән лейтенантка минем билетны сузды.

—Җинаятен раслый торган купюралары кайда?—диде старлей.

—Кулына тоттырдым бит. Әллә син сукырмы?

—Бу бит поезд билеты гына.

—Ә сина тагын нәрсә кирәк?

—Җинаятьче ясаган ялган акча купюралары. Кая соң алар?

—Билет—кулында. Җинаятьче каршында басып тора. Шул җитмимени?

—Сез бит, иптәш старшина, радиотелефоннан фальшивомонетчик тоттык дип хәбәр иттегез. Без шуны көттек.

—Каян алыйм мин сина ялган акча ясаучыны?—урынынннан кузгалган поезд ишегеннән башын тыгып торучы милиционер әшәке сүзләр белән сүгенеп, кабат кычкырды.—Фальшивомонетчикны мин сезгә «шулай итеп» ясап бирииммени?

Мине каршылаган милиционерларның кәефләре кырылуы күзгә күренеп тора иде. Чыннан да, аларның хәлләре юлбарыска куйган капкынга куян эләктерүгә тин иде.

Перронга төшү белән вокзал түбәсенең читендәге язуга күз салдым. Анда эре хәрефләр белән «Канаш» дип язып куелган иде. «Шатлан, Миргазиян дус, Жир шарын әйләнеп йөри торгач, ниһаять, син Канашка да килеп җиттен...»—эчемнән генә үз-үземнән мыскыллап көлеп куйдым.

—Ә бит бу гражданинның билеты да фальшивый түгел,—диде өлкән лейтенант сержантка. Әчемә җылы йөгерде. Өлкән лейтенант мөстәкыйль фикер йөртүчеләр токымыннан иде.

Вокзал бинасын сул яктан урап, бер төркем пионерлар сафка тезелеп каядыр баралар. Озын торыклы пионервожатый, бармагы белән миңа таба төртеп күрсәтеп, үсмерләргә нәрсәдер аңлатып алды. «Әнә, җинаятьчене төрмәгә алып баралар. Сез, Ленин васыятьләрен тормышка ашыручылар, менә бу адәм актыгы кебек җинаятьчеләр белән тәмам тамырларын корытканчы көрәшергә тиешсез»,—шулайрак дип әйтте булса кирәк.

Вокзалга янәшә урнашкан милиция идарәсенә кердек.

—Сержант Андриянов,—диде өлкән лейтенант, минем җинаятьчел кикрикне шиндерер өчен автомат тотып килгән милиционерга.—Бу эшне мин инде берүзем дә ерып чыга алам. Син теге саклау камерасында эшләүчене, кыйнап хатынын имгәткән адәмне алып кил. Кисәтеп куям, сак бул, бик тә холыксыз, дуамал кеше диләр.

Сержант чыгып киткәч, өлкән лейтенант тәмәке кабызды. Тарткан арада ашыкмыйча гына мине баштан-аяк күзе белән капшап чыкты.

—Паспортыгызны бирегез,—диде ул һәм кулын сузарга курыктымы, әллә инструкция шулай куша идеме—паспортыма өстәлдән урын күрсәтте.

Загранпаспортымны кесәмнән чыгарып милиционер каршысына өстәлгә салдым. Милиционерның бүгенге көндә юкка чыгып барган тагын бер күркәм сыйфаты ачыкланды: шакката, хәйран кала белү.

—Гафу итегез, мондый паспортны минем беренче тапкыр күрүем. Шуңа күрә шикләнебрәк карыйм,—диде миңа беркетмә төзергә җыенучы.

—Аны чит илләргә йөрүче корабларда эшләгән диңгезчеләргә бирәләр. Арттагырак битләрендә минем нинди портларда булуым теркәлгән.

—Дускай,—диде милиционер, уңайсызлана төшеп.—Чит илләрдә йөргән кешедә билетка гына түләрлек акча булырга тиештердер бит инде? Сез соң срогы чыккан билет белән поездга утырып нигә вакланштыгыз?

Мондый милиционерны гомеремдә беренче тапкыр очратуым иде. Мин нишләптер маңгайлары ике илледән артмаган «дядя Степа»ларга юлыгам. Аларның күпчелеге шундыйлармы, әллә миендә ике генә сыр булган милиционерга юлыгу минем тәкъдиремә язылганмы? Менә бит, Алланың рәхмәте, бөтенләй төрмәгә утырып беткән чакта минем дуамаллыкларымны күзәтеп торучы фәрештә ярдәмгә нинди кешене җибәргән!.. Язмыш җиле уңай якка борылудан файдаланып, үземнен шушы идиотлыкка юлыгуымны төкми-чәчми өлкән лейтенантка сөйләп бирдем. Казанга чыннан да нәшрият эшләре белән килүемне дәлилләр өчен өстәлгә үземнен Язучылар берлеге билетын чыгарып салдым. Минем бәхетемә каршыдыр инде, билет Казанда түгел, Мәскәүнен үзендә бирелгән иде. Чөнки үз республикасында яшәмәгән кешене Казан кабул итә алмый иде. Сибгат абый Хәким, Гомәр абый Бәширов дәфтәр калынлыгы ике китап авторын, көчләрен, вакытларын кызганмыйча артыннан йөреп, Мәскәү оешмасыннан кабул иттерделәр.

Билетны күргәч, милиционерның шаккатуы тагын да көчәйде. Кызыл чын күн тышлыкның өске ягында Ленин ордены сурәте. Аскарак алтын хәрефләр белән «Союз писателей СССР» дип язылган. Өлкән лейтенант билетны ачты. Сул якта минем фоторәсемем. Фотога төшәргә, билгеле, төнне өтермәндә үткәреп бармаган идем мин. Билеттан милиционерга карап торган кеше шактый зыялы, ышанычлы күренә. Өлкән лейтенант билет номерын, союзга кайчан керүемне дикъкать белән укыды, минем ялган акча ясаучы буларак кулга алынуымны истә тотып, һәр билгене, язуны, сурәтне жентекләп тикшереп чыкты. Ниһаять, шиге калмаганын белгертепме, әллә язучы белән кара-каршы утырыга шатланыпмы, дустанә елмайды.

—Бу имза Георгий Марковның үзенекеме?

—Соң?..

—Тере Евтушенконы да үз күзегез белән күргәнегез бармы?

Татар теленда «Тере Евтушенконы күргәнегез бармы?»—дип әйтеп булмый. Туган телебез шул дәрәҗәдә камил ки, үлгән кешене кабергә күмәләр бит, күргәч, тере

булмый нинди булсын, дип, ул ана болай сөйләргә юл куймый, карыша. Урысча исә «Перед вами живой писатель», «живой классик», «живой фәлән»—дип әледән-әле тамашачыларга мөрәҗәгать итәләр. Бу инде Россия тарихында репрессия-үтереш-опричниналарның тукталып тормаганлыгын раслый. Әле иртән генә исән танылган шәхеснең төштән соң Лубянка базында мангаена тугыз грамм кургаш алуы мөмкин. Шунлыктан, аны «тере!» дип сөенеп (гаҗәпләнеп?) кешеләргә күрсәтүне аңлап була, әлбәттә.

—Евтушенко белән әшнәләрбез дисәм, ялган булыр иде,—дип аңлаттым өлкән лейтенантка.—Берничә мәртәбә аның башка язучылар белән сөйләшеп утырганын күргәнем булды. Бер тапкыр—Белла Ахмадуллина, Булат Окуджава, Андрей Вознесенский белән. Аннан соң—Юрий Казаков белән, Чыңгыз Айтматов белән һәм тагын берничә язучы белән. Бер тапкыр чит илдән кайтып төшкән чагы иде булса кирәк. Өстендә шәмәхә бәрхет пинҗәк, күлмәгендә аллы-гөлле чәчкәләр сурәте. Андый күлмәкне хатын-кызның да күбесе киярга оялыр иде. Утырган жиреннән аягын алга таба сузып җибәргән, үзенең Парижда сатып алган оекбашы турында сөйли. Кырык минут тирәсе сөйләгәндер. Ярты сәгатьтән Язучыларның Үзәк йортына килгән барлык каләм осталары ул оекбашның аяк тирен сеңдерә торган махсус катламы булуын, бәясе уртача бер костюм хакы торуын беләләр иде инде.

Өлкән лейтенант беркетмә язарга әзерләп куйган кәгазьне мыштым гына шуыштырып, өстәл тартмасына яшереп куйды.

—Безнең Геннадий Айгины да күргәнегез бардыр алайса?

—Хәтта айнык чагын да күргәнем булды[1],—дидем дә, мөмкинлектән файдаланып мактанып та алдым.—Дөньякүләм танылган, этнопедагогика белгече академик Геннадий Никандрович Волков белән кунакка йөрешәбез. Моннан ике ел элек чуаш хатыны вафат булгач, аны Чабаксарга кайтарып җирләде. Яшь хатыныннан малае бар.

Чуашлар үзләренең күренекле милләттәшләре белән горурлана беләләр. Минем академик Волков белән таныш булуым абруемны тагын бер ниргәгә күтәреп куйды шикелле. Һәм—туктарга вакыт иде. Яналарын өсти башласам, чама белмәү, хлестаковлану булачак.

Өлкән лейтенант телефон номерын җыйды:

—Чираттагы Мәскәү поезды кайчан килеп җитә? Ничә минутка туктый?—Ана нәрсәдер әйттеләр. Ул дәвам итте.—Шул кырык минуттан киләчәк Новосибирск поездына «СВ»дан бер билет әзерләп торыгыз. Хөкүмәт заказы бу. Заказны линейный УВД начальнигы өлкән лейтенант Митряшкин[2] бирде.

Бу сүзләр йөрәгемнән йокысыз, тоткынлыкта үткән төннең агулы юшкынын юып төшерде. Сулыш алуларым ук җиңеләеп киткәндәй булды.

Бер тын мина сокланып карап, елмаеп торганнан соң өлкән лейтенант өстәл тартмасыннан кызыл тышлы папка тартып чыгарды. Ачты. Папкадан берничә бит машинкада суктырылган язма алды.

—Тыңлагыз әле.

«Б» авазын әйтүеннән өлкән лейтенантның чуаш халкы улы икәнлеген сиземләп алган идем. Шигырьләре урысча язылган булып чыкты. Кешенең иҗатын бәяләгәндә Парижлагы саклана торган эталоннар төгәллеген кем генә саклый ала икән? Бигрәк тә, җанымны пычракка таптап, кешелегемне изәрлек тикшеренүләрдән аралап калган затның әсәрләренә бәя биргәндә. Аның шигырьләре, Шарль Бодлерныкы биеклегенә күтәрелә алмасалар да, Николай Рубцов, Александр Кушнер һәм тагын шул дәрәҗәдәге шагыйрьләрнекеннән бер чеметемгә дә ким түгел шикелле тоелды мина. Шагыйрь сәгатенә карап алды да укудан туктады:

—Сез, язучы әфәнде, нәрсә эчәргә телисез: коньякмы, виномы, аракымы? Әллә Чуаштан ясый башлаган, кырык үлән тамыры төнәтмәсеннән торган бәлзәмне ачыймы?

---

[1] Узган ел Айгиның эчүен ташлаганын ишеткәч, сабыйларча куандым.

[2] Милиционерның фамилиясе үзгәртелеп бирелә.

—Без, шагыйрь дустым, минә нәрсә эчәбез,—дидем дә, чемоданымны ачып, өстәлгә итальяннарның горурлыгын, этикеткасына тузган чәчле Бахус сурәте төшкән «Веккья романья бутон»ны утырттым.

Поезд килгәнче без никадәр тырышсак та шешәнең яртысын гына үзләштерә алдык, чөнки әңгәмәбез коньяктан да татлырак иде безнең.

—Мин инде бу шешәне иң кадерле истәлек итеп сервантымда гына тотармын,—диде өлкән лейтенант.

Чуаш милиционеры Максим Егорович Митряшкин алып биргән «СВ» вагонында барганда аңа Чуаш Язучылар берлегенә керергә рекомендация бирергә онытуыма эчем ачытып куйды...

—Син, дингез бүресе, нигә Якташыңны рәнҗеттең?—минем мажараларымнан соң шактый вакыт үтеп Мәскәүгә килгәч, Мөхәммәт Мәһдиев сүзен әнә шулай дип башлады.—Татар язучылары йөз процентка аны яклыйлар. Ярамый яхшы кешегә начарлык эшләргә. Бизәми тәкәбберлек ир-егетне.

«Тәкәббер» сүзен Мөхәммәт дини тәгълиматта иң зур гөнаһ саналган «гордыня»га тәңгәл итеп әйтте.

—Ул кунакханәгә урнаштырырга вәгъдә бирде. Мин, ахмак, аңа ышандым. Ул биргән сүзендә тормады. Бу очракта мин рәнҗергә тиеш түгелме икән?

—Әйттем бит, татар язучылары йөз процентка аның ягында, дип. Якташың каршына кунакханә сорарга килгәнсең, ә үзең гел Илдар Юзеев янында утыргансың. Сүз дә юк, Илдар чын шагыйрь. Әмма ул ипи алырга чыгып кибет таба алмыйча кайта торган кеше. Якташың исә, әгәр син аңа якты йөз, бары тик якты йөз генә күрсәтсәң дә, ул сиңа кирәгеңне җиде кат җир астыннан табып бирә.

—Әйе, табып бирә. Әнә, кунакханә броненең кулыма китереп тоттырды. Люкска. Әмма ул люкс нигәдер поезд каталажкасында булып чыкты.

—Син бит аны санга сукмагансың, кимсеткәнсең. Үзең аның янына кунакханә сорап килгәнсең, үзең гел Илдар Юзеев янында мәлҗерәп утыргансың.—Мөхәммәт минем нинди җинаять эшләвемне кабатлады.—Аннан соң Рәис Даутовларга киткәнсең. Заявка бирер өчен синең паспортың кирәк булган. Ул сине төн урталарына кадәр диярлек эшендә көтеп утырган.

—Аның сүзен кабатлап, күземә төтен җибәрмә әле. Кунакханәгә заявка бирер өчен бернинди паспорт та кирәкми. Тем более кирәгеңне җиде кат җир астыннан табып бирә ала торган кешегә.

—Син, мариман дустым, фәлсәфә куертма. Бу чиктән тыш җитди мәсьәлә. Син үзеңне генә түгел, сине җитәкләп әдәбиятка алып кергән Бәшировларны, Сибгат абыйларны, Хәсән Туфанны да уңайсыз хәлгә куйгансың.

Менә шулай төгәлләнде минем «Кунакханә мажарасы».

*2003, декабрь.*

# В

**ВӘЛИУЛЛИН** Рәзим Нәгыйм улы (3.1.1942, Зәй р-ны Кәдек а.), шагыйрь, композитор, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1967). 1967-93 елларда Лениногорск шәһәре музыка-сәнгать пед. училище укытучысы. 1993 тән ТР Язучылар берлегенең Әлмәт бүлеге җаваплы сәркатибе, бер үк вакытта 1997 дән ТР Композиторлар берлегенең Әлмәт бүлеге рәисе. Шигырьләре «Беренче карлыгачлар» (1970) исемле күмәк җыентыкта, «Үз ягым» (1994), «Зирекле елга» (1994), «Уч төбендә кояш» (1995), «Ак тулпарда» (1996) исемле шигырь китапларында дөнья күрә. В. шигъриятенә нечкә лиризм б-н сугарылган публицистик пафос хас. Ул татар халкының үзенчәлекле мәдәни мирасын саклап калу мәсьәләләрен күтәрә. С.Есенин, А.Блок, А.Ахматова шигырьләрен татар теленә тәрҗемә итә. Музыка өлкәсендә В. татар җыр сәнгате традицияләренә таянып иҗат итә. Ул 150 дән артык җыр һәм романс (ш. и.үзе шигырьләренә), 30 лап хор әсәре, симфоник сюиталар (1981; 1998), кыллы квартет, скрипка һәм фортепиано өчен пьесалар, балалар өчен җырлар авторы.

Әд.: Хәлим А. Үз тавышым үземә ошамый... // Аргамак. 1997. N1; Юныс М. Кечкенә утрауның комлы ярында // Идел. 1998. N8.

**ВӘЛИТЕВА** Наилә Минһаҗ кызы (15.3.1946, Кукмара штп) тәрҗемәче. Алабуга пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1968), Әгерҗе р-ны Иж-Бубый авылында урта мәктәптә укыта. 1971-2001 елларда Казанда Татарстан китап нәшриятында эшли. Татар теленә Э.Н.Успенскийның «Крокодил Гена һәм аның дуслары» (1976 «Крокодил Гена и его друзья»), В.Г.Распутинның «Онытма гомергә» (1983 «Живи помни») повестьларын, Н.Думбадзеның «Мәңгелек канун» (1986 «Закон вечности») романын, А.Милнның «Винни-Пух маҗаралары» (1991 «Винни-Пух и все-все-все) әкият-повестен тәрҗемә итә.

**ВЕРЁВКИН** Михаил Иванович (1732, Мәскәү губ. Клин өязе -21.3.1795, Мәскәү губ., Дмитров өязе Михалёво а.), драматург, тәрҗемәче, Фән һәм сәнгать академиясенең мохбир әгъзасы (1785). 1755-57 елларда Мәскәү ун-тында. 1758-61 дә Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе директоры. Аны губерниянең аң-белем тарату үзәгенә әверелдерә, укучылардан һәвәскәрләр театр труппасы оештыра (укучылар арасында Г.Р.Державин да була). 1760 та Казан губернатор иптәше (урынбасары) итеп билгеләнә. 1761 дән Казан губерна канцеляриясендә хезмәт итә. 1763 тә үзенең нәселдән килгән утарына – Покровское авылына кайта. «Шулай тиеш» («Так и должно», 1773), «Исем бәйрәмен үткәрүчеләр» («Именинники», 1774), «Төп-төгәл» («Точь-в-точь», 1774-85) комедияләре авторы. Аларда Дидронын мещан драмаларындагы үзенчәлекләр рус классицизмының сатирик комедияләре традицияләре б-н үрелеп бара. «Шулай тиеш» һәм «Төп-төгәл» комедияләрендә уңай герой ришвәтче, комсыз, куркак һәм надан кешеләр арасында яшәргә мәҗбүр. «Туган көнендә»дә, Бомарше комедияләрендәгечә, хуҗаларга мәхәббәт интригаларында аларның тапкыр хезмәтчеләре ярдәм итә. Екатерина IIгә панегирик рәвешендә язылган «Безнең урамнарда бәйрәм» («На наших улицах праздник» һәм «Астрея» (икесе дә 1776) пьесалары, «Уйдырма» («Небылица», 1778) повесте авторы. Француз теленнән (Андре Рюэр де ла Гард Малезер тәрҗемәсеннән) Коръәнне рус теленә тәрҗемә итә (1-2 кисәк, 1790).

Әд.: Тупиков Н.М. М.И.Верёвкин: Историко-литературный очерк. СПб., 1895.

*Ж.Ф.Хәкимева.*

**ВЕРГАЗОВ** Азат Фатыйх улы (8.3.1932, Пенза өлкәсе, хәзерге Неверки-

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 саныннан басылып килә.*

но р-ны Карновар а.), язучы. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1958). 1958-64 елларда Яшел Үзән р-нындагы Олы Җәке авылы мәктәбе директоры, 1964-70 тә Карагуҗа авылы мәктәбендә укытучы һәм соңыннан укыту бүлеге мөдире булып эшли. 1974-85 тә «Татарстан» дәүләт телерадиотапшырулар комитетының әдәби-драматик тапшырулар редакциясендә өлкән мөхәррир. 1991-98 дә «Аҗаган» ж-лын оештыручы һәм аның баш мөхәррире, бер үк вакытта «Аҗаган» нәшрияты директоры (1992 дән). Әсәрләре 1960 еллар урталарыннан басыла башлый. В. нигездә яшүсмерләр, аларның әти-әниләре һәм укытучылары арасындагы мөнәсәбәтләр турында яза: «Дулкыннар ни сөйли» (1978), «Уяну» (1984), «Без — сезнең балалар» (1996), «Йөрәк җыр сорый» (1998) повестьлары шундыйлардан. «Ташу» (1979) повестында колхозлашу елларының катлаулы вакыйгалары сурәтләнә. «Кайту» (1992) романы асылыбызга кайту, милли традицияләрне яңарту мәсьәләсенә багышланган. 1993 тә «Кода, май кап!» дигән сатирик повестьлар һәм хикәяләр җыентыгы, «Язгы сөйләшү» дип аталган шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. В. әсәрләренә лиризм һәм тел байлыгын нечкә тою хас.

Әсәр.: Йөрәк җыр сорый. Сайланма әсәрләр. К., 1998. Т.1.

Әд.: Сверигин Р. Ташу // Социалистик Татарстан. 1981. 8 февр.; Фәйзи З. Олы иҗат юлында // Шәһри Казан . 1994. 25 нояб.; Салихҗан И. Тугрылык үрнәге // Шәһри Казан. 1998.6 нояб.

*Г.М.Габделхакова.*

**ВИЛЬЯМС** (Wiliams) Гарольд (1876-1928), инглиз журналисты. 1904-18 елларда Петроградта инглиз газеталары хәбәрчесе булып эшли. Г.Тукайның «Пар ат» шигырен инглиз теленә тәрҗемә итеп, аның кыскача тәрҗемәи хәле һәм 20 йөз башы татар әдәбияты хакындагы мәкалә б-н бергә «Russian Review» («Россия хәбәрләре») ж-лында (1914) бастыра.

**ВИНЕЦКИЙ** Ян Борисович (10.3.1912, хәзерге Украина, Запорожье ш. — 1.8.1987, Казан), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1967). 1932 елда Ленинград очучылар мәктәбен тәмамлый, 1936-37 дә Испания респ-касының хәрби-һава көчләре сафында сугыша. 1941 дән Казан пр-тиеләрендә хәрби вәкил булып эшли. 1943 тә Волхов фронтында самолётларны сынауда катнаша. 1948 дә Казан Юридик мәктәбен экстерн рәвешендә тәмамлап, 1956 га кадәр ТАССР Прокуратурасында эшли. 1956-72 дә «Советская Татария» г-тасы редакциясендә. Әсәрләре 1939 дан басыла башлый. «Сандугач» («Соловей», 1953) повесте, «Мадрид повесте» («Мадридская повесть», 1956) испан халкының фашистларга каршы алып барган сугышын, интернациональ бригадалар сугышчылары көрәшен тасвирлый. Производство темасы «Тугрылык» («Верность», 1948) повестенда, «Үрләр яулый кеше» («Человек идёт в гору», 1954), «Ышанучы» («Тот, кто верит», 1963) романнарында чагылыш таба. В. — күпсанлы хикәяләр, очерклар һәм театраль рецензияләр авторы. Рус теленә И.Газинең «Онытылмас еллар»ын («Незабываемые годы», 1950), «Гади кешеләр»ен («За городом, за Казанью», 1957), А.Шамов, Г.Әпсәләмов, Ф.Хөсни, М.Хәсәен, Г.Минский һ.б. әсәрләрен тәрҗемә итә. Өч Кызыл Байрак, «Почёт Билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана. Биобиблиографич. справ. К., 1970; Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиографик белешмә. К., 1986.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Әхәт
Сафиуллин

# «БҮГЕН НИЧӘСЕ?»

ШАЯН ХИКӘЯ

Мин үзем Яна елнын бишенче көнендә үк өнемә килдем: тамак ачкангамы, эчәсе килгәнгәме уянып киттем. Хәер, хатын сүзе дөрес булса, анарчы да һәр көн өнемдә булганмын. Яна ел чыршысын да карап кайтканбыз, Казаннын төрле ягында яшәүче туганнарыбызда да булганбыз. Тик хәтерләмим генә.

Өнгә килдем дә хатыннан:

—Бүген ничәсе? Иртәгә эшкә түгеллдер?—дип сорадым.

Ял дип эшне дә онытырга ярамый!

—Һи-и, бүген бишесе генә әле! Эшкә унберендә генә бит!—диде ул һәм, мине күреп, корт чаккандай, кычкырып җибәрде:—Абау, Салихҗан, синме бу?!

—Мин булмый, кем булсын!—дидем.

—Кара әле үзенә көзгедән!

Торып басыйм дисәм, аяк тотмый, куллар калтырый, салам сындырырлык та көч юк. Алай да стенага ябыша-ябыша көзге янына килеп җиттем. Ана күз салсам, йөрәгем жу итеп китте: мина бөтен жирен йон баскан ниндидер җанвар карап тора! Куркудан, өнсез калып, идәнгә егылганмын. Үземне хатын кырындырып-юындырып кеше рәтенә кертксч кенә таныдым. Таныдым да, кеше итеп сизә башладым. Житәр, мин әйтәм, дөньяга чыгып саф һава сулап керергә кирәк.

Өйдән чыксам, ишегаллында—ап-ак кар! Тездән. Карале, мин әйтәм, төш житеп килә, ә дворник әле карны да күрәмәгән! Шунда гына исемә төште: Яна ел ункөнлеге бара лабаса!

Ишегалды карын ничек кирәк алай ерып урамга чыктым. Анда да чип-чиста кар! Шәһәр урамы димәссен! Әйтерсен, туган якнын кышкы кыры уртасында басып торам! Рәхәт булып китте. Арырак күз салсам, унлап машина кар көртләрендә батып калган! Карале, мин әйтәм, нишләп чистартмаганнар бу юлларны?! Шунда кылт итеп исемә төште: ил-жиребездә Яна ел бәйрәме ләбаса! Кем чистартсын аны?! Үзләре гаепле: Яна ел ункөнлегендә ни пычагыма машина белән чыгарга?! Бәйрәм узгач та өлгерерләр иде әле!

Кинәт алдымдагы кар өеме астыннан кеше башы күренде. Куркып киттем.

—Карале, мужик, бүген ничәсе?—дип сорады миннән баш.

—Бишенче гыйнвар,—дидем мин.

—Чынлап әйтәсенме? Чыннан да, унбере түгелме?—диде ул, «Пан или пропал»да миллион откандай балкып.

—Анарчы тагын биш көн ята аласын әле!—дип сөендердем мин аны.

—Рәхмәт сина, мужик!—Ул, авызын колагына чаклы ерып, тагын бөгәрләнеп ятты.

—Катып үләсен. Өенә кайтып йокла!—мин әйтәм.

—Өйгә кайтып барышым бит инде,—диде ул һәм гырлап та җибәрде.

Берничә адым атларга өлгермәдем, чыр-чу килеп таудан шуучы балаларга юлыктым. Кызарышып беткәннәр, мәш киләләр шуып. Туктале, мин әйтәм, кайдан килгән сон бу тау?! Карасам, жыелган чүп-чар тавы өстеннән шуалар икән. Өстенә кар явып киткән дә, рәхәтләнә бала-чага! Кызыгып куйдым. Тик чүплектән тау ясау килешмн, мин әйтәм, нишләп түкмиләр икән аны? Шунда кылт итеп исемә төште: Яна ел бәйрәме ләбаса! Рәхәтләнеп калсын бала-чага!

Алар бәхетеннән көнләшеп ерак китмәдем, берәү машина капоты өстенә бер яртыны чыгарып куйган да баш төзәтеп утыра. Мине күрүе булды, йөгереп килеп тә житте.

—Карале, брат, бүген ничәсе?
—Гыйнварның бишесе,—дидем.
—Димәк, әле иртәгә эшкә түгел?
—Ниткән эш?! Эшкә хәтле күзең күгәрер әле!
—Рәхмәт сина, брат!—диде ул, сөенеченнән мине кочаклап.—Белмисеңме, Челябинская Тракторная урамы кайда икән? Береннән бирле эзлим, берсе дә әйтә алмый шуны...
—Гафу итәсең, Казанда күпме яшәп, андый урам турында ишеткәнем юк,—дидем.
—Ничек Казанда?!—дип күзләрен түгәрәкләндерде ул.
—Шулай, хәзерге вакытта син Казанның Ершов урамында басып торасың.
—Туктале, брат, тукта!—диде ул, маңгаен уып.—Ни сөйләвең?! Ниткән Казан булсын бу?!
—Гафу итәсең, дускай, дөресен әйтәм: син Казан урамында басып торасың.
—Ә ничек килеп эләктем соң мин монда?!
—Анысын син белергә тиеш. Үзең кайдан соң?
—Чиләбедән.
—Чиләбедә-ә-н?!
—Әйе, Чиләбедән,—диде ул.
—Ә монда ничек килеп эләктең?!
—Кем белгән аны!? Яңа елны каршылаганнан соң бер дустымнан өйгә кайтып барышым...

Танышу хөрмәтенә берәрне күтәрдек тә шәһәрдән ничек чыгасын аңлатып бирдем. Икәүләшеп этә-төртә торгач, машинасын да чыгардык. Китеп барды. Бөтенләй кире якка...

И, мескен адәм баласы, салмыш баштан ничә көн каңгырап йөри, ник бер гаишник туктатып кешенең хәлен белешсен! Шунда исемә төште: Яңа ел ункөнлеге бара лабаса! Кеше ялгыш Чиләбедән Казанга тикле килеп чыккан икән, монда гаишникларның ни гаебе бар?! Үзе гаепле: мөгаен, өендә сирәк була торгандыр...

Карале, монысы нинди карачкы тагын?! Як-ягына куллары белән селтәнә-селтәнә бер ир заты килә. Әйе, адәми зат бугай. Кимендә ярты ай кырынмагандыр! Бер аягында галош, икенчесендә күнитек. Әллә кайдандыр качкан, әллә качып барышы...
—Бүген ничәсе?—диде ул, килеп житмәс борын.
—Бишенче гыйнвар,—мин әйтәм.
—Чынлапмы? Димәк, иртәгә эшкә түгел?
—Тагын биш көн ял бар әле!—дип шатландырдым мин аны.
—Рәхмәт сиңа, изге кеше!—диде ул, мине үпмәкче булып.—Карале, алар сине дә үтермәкчеме?
—Кемнәр?
—Менә болар... мөгезлеләр,—дип ул тагын куллары белән селтәнергә тотынды.—Артымнан пычак белән куып йөриләр... Китегез, кит!
—Тынычлан, тынычлан!—дидем мин. Синең тирәдә бернинди мөгезлеләр дә юк.
—Син дә минем хатын шикелле берни күрмисең икән!—Ул да, беркем дә күмый синең арттан, ди... Ә мин аларны күрәм ич! Әнә бит алар, әнә! Бөтенесенең кулында пычак! Барысы да шиксыз мөгезле!
—Артыграк жибәрдеңме әллә соң?—мин әйтәм.
—Артык дип... Яңа ел алдыннан гына башладым әле... Китегез моннан, китегез!—Ул як-ягына селтәнә-селтәнә йөгереп китеп барды.
«Ни булган соң бу адәми затка?—дип карап калдым мин аның артыннан. Нишләп күзенә женнәр күренә башлаганчы эчте икән?» Шунда кылт итеп исемә төште: Яңа ел бәйрәме ләбаса!

Килде-китте генә түгел, халкыбызга Дума бүләк иткән бәйрәм! Юккабарга түгел, Рәсәй бердәмлеге өчен эчәбез!

## Илдар Хәйруллин

Хәйруллин Илдар Шәмсулла улы 1958 елның 5 сентябрендә Кукмара бистәсендә туа. 1975 елны Кукмараның 1 нче татар мәктәбендә урта мәктәпне тәмамлап, Казан Дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә. 1977 елны көндезге бүлектән читтән торып укуга күчкәч, аны армиягә алалар. Ул ике ел һава-десанты гаскәрләрендә хезмәт итә. Демобилизациядән соң Түбән Каманың «Шин» берләшмәсендә эшли башлый. Әмма... язмыш еш кына мәрхәмәтсез: аяусыз чир аны аяктан ега (арка миенең зарарлануын, табиблар, парашюттан уңышсыз сикерү нәтиҗәсеннән дип баралар. Күңелсез анология: шагыйрьләр Ф. Яруллин, Р. Шәриповларның да гомерлек гариплеге армия белән бәйле).



Илдар Хәйруллин иҗат эше белән мәктәптә укыган елларда ук шөгыльләнә. Беренче хикәяләре 70 нче елларда матбугатта күренә башлый. 1973 елны «Яшь ленинчы» газетасы оештырган конкурста җиңеп чыгучыларның берсе була, ана махсус бүләк тә бирелә. Соңрак аның юмористик хикәяләре, юморескалары Кукмара, Түбән Кама төбәкләрендә чыгучы басмаларда, «Сабантуй», «Татарстан яшьләре» газеталарында, «Чаян», «Мәйдан» журналларында чыга. 1999 елда «Бүген—Беренче апрель!» дигән китабы «Матбугат йорты» нәшриятында дөнья күрә, ә 2004 елда «Юмористик хикәяләр» исемле икенче китабы («Сүз» нәшрияты) басылып чыга.

Илдар Хәйруллин, әйтелгәнчә, укучыларга юморист язучы буларак таныш. Ул әкренләп бу жанрның остасына әверелеп килә. Аның хикәяләрендә бүгенге тормышның кызык һәм гыйбрәтле хәлләре үзебезнең арада яшәгән төрле холыклы кешеләрнең кылган гамәлләре аша шактый ук тулы чагыла. «Язмаларым хәзерге авыр заманда бераз күңел күтәренкелеге янсә елмаю тудырса, мин чиксез шатмын», ди ул үзенең китабына язган кереш сүзендә. Бүгенге көндә яшь язучы Түбән Кама шәһәрендә яши һәм иҗат итә.

2006 елның 22 июнендә, Кабул итү коллегиясе карары нигезендә, Язучылар берлеге идарәсе Илдар Шәмсулла улы Хәйруллинны Язучылар берлегенә әгъза итеп алды.



*Замандаш бөек шәхесләр: композитор Рөстәм Яхин, сынчы Бакый Урманче. 1988 ел.*



*Габдрахман Әпсәләмов, Зәки Нури, Сибгат Хәким. Язучыларның иҗат һәм ял йортлары урнашкан «Аккош күле» янындагы урман аланында. Узган гасырның 70 нче еллары.*



*Булачак халык язучылары, шагыйрьләре. Сулдан уңга—Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин, Шәүкәт Галиев. Мәскәү. 1980 ел.*



*Дуслар җыелган җирдә. Җырчы Фән Вәлиәхмәтов, язучылар Рафаэль Сибат, Шаһинур Мостафин. Түбән Шөн авылы (Киров өлкәсе), 1996 ел.*



*Университетта укып чыккан күпсанлы журналистларның, язучыларның остазы—күренекле тел галиме Диләрә Тумашева. 1990 ел.*



*«Казан утлары» журналының 80 еллыгы уңаеннан уздырылган тантаналы кичәнең зал күренеше. «Казан» милли-мәдәният үзәк бинасы. 2002 ел.*

# «КАЗАН УТЛАРЫ»—2007

## *Тормыш язган хикәяләр*

*Быелгы 4 нче санда әнә шундый рубрика ачып җибәргән идек. Киләсе елда сезнең кулга 5-6 «иҗат ителмәгән, чын» хикәя барып ирешәчәк. Биредә шуларның икесеннән кыска өземтәләр бирәбез.*

**З. Зәйнуллин.** *Җиде юл чатында.*

«...Башта бер генә уй: «Кая барырга хәзер? Ничек итеп яшәп алып китәргә?..» Мин утырган җирдән берничә кабер аша бер хатын эшли—кабер ташлары юа... Менә ул минем янга килеп утырды.

—Сезнең бик зур кайгыгыз бар, ахрысы?

—Кайгы түгел бу. Минем тормышта катастрофа булды.

—Мин сезнең өчен чит кеше. Миңа сездән берни дә кирәкми. Мин бик акыллы еврейка. Мәскәүнең бик күп еврейләре минем янга киңәшкә киләләр. Сөйләгез миңа... катастрофагызны...»

**Р. Фәизов.** *Апаниләр сөйләде.*

«...Бездән, үзем кебек җинаятьче хатыннардан, штраф батальоны төзеделәр. Кулга мылтык бирделәр. Өч ай өйрәткәч, сугышка алып киттеләр. Кайсыдыр шәһәр янында, аны яклап, ут эченә кердек. Безнең арттан кулларына автомат тоткан ирләр керде, аларга, чигенә башласалар, атыгыз, диделәр... Немецлар белән йөзгә-йөз килдек. Исән калуга өмет тотып, ярсып, үз-үзебезне белештермичә сугыштык. Безне күргәч, фашистлар да каушауга төштеләр. Шул кадәр котырган идек. Мин үзем әзмәвердәй бер ирне штыгым белән чәнчеп үтердем... Без йөз кешедән нибары өч кеше исән калганбыз...»

*Мондый хикәяләрне сездән дә көтәбез, кадерле укучылар.*

---

# Авторлар игътибарына

Редакциягә кулъязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

# 2006 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге

## 1000 НЧЕ (№ 2, 2006) САН

Зөлфәт. Яшәр безнең журналыбыз! *Шигырь.*

**БАШ МӨХӘРРИР СҮЗЕ**

Фәйзуллин Р. Мең сан—миллион уй.

Шәймиев М., Вәлиева З., Мириханов Н., Метшин И., Закиров Р., Татарстан язучылары котлаулары.

**"БЕЗНЕҢ ЮЛ"**

"Безнең юл" идарәсеннән әдипләргә, шагыйрьләргә, гыйлем-әдәбият мөхибләренә (сөючеләргә) мөрәҗәгать.

Гомәр Л. Төп җитәкче Г. Ибраһимов иде.

Мансуров Г. "Безнең юл" турында.

Такташ Һ. Мәңгелек әкият. *Шигырь.*

Сабиров Р. Татарстан җөмһүриятенең икътисади хәле һәм ачлык.

Усманов Ш.. Краском мәхәббәте. *Хикәя.*

Җәлил М. Әсирлектә. *Шигырь.*

Ишморат Р. Татар скульпторы Мирзаҗан Байкиев.

Байчура Ш. Патша хөкүмәте вакытында Төркестанда татар мөгаллимнәре.

**"ЯҢАЛИФ"**

Көләкәй. Иске-москы. *Көлке.*

"Булат Батыр".

Яушев М. Боз кузгалды.

Контрреволюцион яшерен "Җидегәнчеләр" турында Татар совет язучылары оешмасы.

**"АТАКА"**

"Безнең юл" журналы укучыларына.

Кем нәрсә яза?

Пролетариат Язучылары Ассоциацияләре янындагы бөтен татар секцияләренә һәм бөтен татар пролетариат язучыларына.

Литфондның Татарстан бүлеге төзелде.

ТАПП оешмасында.

Иртуганов Җ. Донбасста татар матур әдәбияты.

Сәгыйди Г. Кавказ артында татар әдәбияты.

Язучылар өчен ял йорты булырга тиеш!

**"СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ"**

Совет язучыларының Беренче Бөтен Татарстан съезды.

Бәширов Г. Уйланулар.

Хәким С. "Гомер яңа башлана" дигән шигырьдән өзек.

Халык дошманнарының һәм аларның калдыкларының йөзен ахырынача ачарга!.

Салахов И. Тайгак кичү. *Роман-хроникадан өзек.*

Мәҗитов З. Шагыйрьнең яралы җаны.

Кәрим Ф. Кыр казы. *Шигырь.*

Нәҗми К. Мәҗит Гафури һәм патша цензорлары.

Гафури М. Татар егетенә. *Шигырь.*

Маннур Ш. Татар халкы. *Шигырь.*

Ключарев А. Татар халкының музыка иҗаты.

Кашшаф Г. Нигез ташларын салганда.

Шакир А. Гадел Кутуй белән бергә.

Кутуй Г. Сагыну. *Нәсер.*

Шамов А. Журналның бер нөсхәсе.

Госман Х. Мәче баласы. *Хикәя.*

Эренбург И. Татарлар.

Татар язмышына кизәнгән карар.

Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик әйтемнәрендә тарихилык һәм үткән белән хәзергенең чагылышы.

Татарстан Совет язучыларының гомуми шәһәр җыелышы резолюциясе.

Фәйзуллин М. Мирхәйдәр Фәйзи көндәлекләреннән.

Мөдәррис Ш. *Пародияләр.*

Туфан Х. Кайсыгызның кулы җылы. *Шигырь.*

Мостафин К. Ярамый шул... *Пародия.*

Юныс М. Безнең йорт өянке астында иде. *Хикәя.*

Яруллин Ф. Теләк. *Шигырь.*

**МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Җәлил М. Кичер, илем! *Шигырь.*

Симонов К. Бер камерада.

Җәлил турында совет язучылары.

Шагыйрь турында шагыйрьләр. Вургун С., Данилов С., Дудин М., Юзеев И., Галиев Ш., Баян Ә., Миңнуллин Р., Габдерәхим Ф., Сабиров И., Измайлова Н, Мирза М. *шигырьләре.*

Мостафин Р. Халык шагыйре, халык каһарманы.

Арагон Л.. Менә нәрсә булды Берлин шәһәрендә.

Шагыйрь исемендәге премия.

**"КАЗАН УТЛАРЫ"**

"Казан утлары" журналын "Почет билгесе" ордены белән бүләкләү турында СССР Верховный Советы Президиумы Указы.

Гази И. Тургай картаямы икән? *Хикәя.*

Dәwlәt N. "Kazanutlary" nyñ tatar mädäniyätenä kertkän öleþe.

Нәҗми Н. Татар теле. *Шигырь.*

Мәһдиев М. *Этюдлар.*

Ихсанова Л. Иң бәхетле чагым кебек...

Әйди Т. Яшерен васыять.

Афзал Г. Тәнкыйть сүзе. *Шигырь.*

Еники Ә. Гөләндәм туташ хатирәсе. *Кечкенә романнан өзек.*

Тимергалин А. Миллият сүзлеге.

Галиев М. Хикмәти сүрә.

Юныс Р. Меңьеллык Казан ни кайнатыр?

Журналыбыз турында.(Гали М., Әхмәтҗан Р., Хәким С., Гыйләҗев А., Өнәр М., Нури З., Әпсәләмов Г., Хөсни Ф., Туфан Х., Ахунов Г., Маликов Ә., Нәҗми Н., Афзал Г., Харис Р., Госманов М., Миңнуллин Т.).

"Казан утлары" архивыннан.

"Татар энциклопедиясе" битләреннән.

Берлекнең яңа әгъзалары.

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан.

## №1,3-12 САННАР

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ**

2006 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында. №5

«Татарстан Республикасы халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирү турында. №12

Россия Дәүләт премиясе лауреатлары. №7

Рухи галәмдә яшәргә. Президент Шәймиев М. белән шагыйрь Фәйзуллин Р. әңгәмәсе. №3

**ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Әмирханов М. И, кылган догам минем. Повесть №№1-3

Бадыйкшан Л. Тәкъдирем. Повесть-истәлек. № 7

Баттал Ф. Сатирик хикәяләр. №7

Галиев М. Шигърият рухы. Эссе. №10

Гыйззәтуллин Р. Төрмәче. Хикәя. №3

Гыйльманов Г. Соңгы сугыш. Повесть. №12

Кәрами. Р. Олы юл да сикәлтәле. Роман. №№ 8-11

Мәхмүди З. Һәркемнең үз юлы. Роман. №№3, 4

Мирхәйдәров Р. Үзем хөкем итәм. Роман. №№10-12

Муллануров Р. Бүре чагасы. Хикәя. №4

Нуриев В. Җиденче палата. Повесть. №11

Рахман Р. Сөннәтче әби. Хикәя. №8

Садриев Ф. Бәхетсезләр бәхете. Роман. №№8-10

Сиражи И. Гыйсметдин тәүбәсе. Хикәя. №1

Сиражи И. Күкләр никахы. Хикәя. №9

Фәизов Р. Карак. Хикәя. №5

Хәсәнов Ә. Ефәк пәрәвез. Хикәя. №8

Хәсәнов А. Җәнбәт ыруы. Повесть. №№5,6

Хөснияр З. Козгыннар йолдыз чүпли. Роман. №5, 6

Шәрифуллина Э. Уяну. Хикәя. №12

**ШИГЪРИЯТ**

Әгъләмов М. Ил җанына – шигырь какты. Шигырьләр. №10

Әхмәдиев Н. Дәрдемәнд. Поэма. №12

Әхмәтҗан Роб. Кичке тәрәзәләр. Шигырьләр. №12

Әюп Х. Төрле еллар дәфтәреннән. Шигырьләр. №8

Баян Ә. Җырлы, Тукайлы халык без... Шигырьләр. №4

Бәйрәмова Г. Мин бәхеткә барам – җәяүләп. Шигырьләр. №6

Булатова К. Яңа шигырьләр. №3

Габдерәхим Ф. Милли җанлы киңлекләрдә. Шигырьләр. №7

Гатауллин Г. Бездән сәлам булыр... Шигырьләр. № 10

Галиев М. Балбал түшендәге тустаганнан. Шигырьләр. №10

Гаташ Р. Гомер сәхифәләре. Шигырьләр №3

Гәрәева С. Биеккә чакыру. Шигырьләр. №11

Гыйззәтуллина Ф. Наз сурәте. Шигырьләр. №9

Зөлфәт. Моңнар моңы... Шигырьләр. №1

Иксанова И. Офыкларда – без белмәгән хаклык. Шигырьләр. №8

Кутуй Р. Ватаным дип елыйлармы? Шигырьләр (Р. Фәйзуллин кереш сүзе белән). №11

Латыйпов Х. Галәми гамь. Шигырьләр. №11

Маликов Ә. Гомер хатларыннан. Шигырьләр. №8

Маннап Ш. Җанымның тыюлыгы. Шигырьләр. №6

Мингалим Р. Минем белән яши хатерләүләр. Шигырьләр. №6

Миңнеханова Н. «Кызлар тавы»н йөгерепләр кичтем. Шигырьләр. №10

Мирза М. Робагыйлар. №3

Мөхияр Р. Уй керде – ай күрде. Шигырьләр. №5

Мөхәммәтшин Г. Мең төрле гамь... Робагыйлар. №6

Низами Р. Шәҗәрәмнең кан тамырын эзләп... Шигырьләр. №8

Рахман Р. Хәтер. Шигырьләр. №7

Рафиков Б. Эзләп тап. Шигырьләр. №12

Рәхимова Б. Ятимнәр. Шигырьләр. №11

Сафин Р. Шагыйрьгә. Шигырьләр. № 12

Сафина Н. Яшерен уйлар. Шигырьләр. №4

Сәгыйдуллина Л. Җирдә – чәчәк йолдызлыгы. Шигырьләр. №7

Сәлимгәрәев Р. Йолдыз атылганда теләк. Шигырьләр. №12

Солтан Ф. Баллы миләш һәм кош җыры. Шигырьләр. №9

Суфиянов А. Тоташыйм якты таңнарга. Шигырьләр. №10

Хәлим А. Татарлар, берләшегез! Шигырь. №10

Харис Р. Яңа шигырьләр. №1

Чанышева Ф. Туган көнем. Шигырьләр. №9

Шагыйрьҗан Л. Галәм кисәтүе. Поэма. №5

Шәрипов Р. Меңнән бер өлеш. Поэма. №9

Шәфигуллин Р. Чынлы тынлык. Шигырьләр. №12

Якупова С. Алма исле август йолдызлары. Шигырьләр. №8

Янсуар Л. Сөю кадәр сөю – мирасыбыз. Шигырьләр. №7

Яруллин Ф. Бер нәрсә дә булмый мәңгелек. Шигырьләр. №4

Җиһангирова Ш. Яраланган бер кош сыман. Шигырьләр. №3

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Әпсәләмов Г. Сары чыпчык. №6

Минский Г. Ана мәхәббәте. №9

Туктаров И. Үлем эшелоны. №1

Шәрәфи Г. Тәфтиләү. №7

### ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР

Вафин Т. Әмәйгел әби. № 4

Юныс М. Кунакханә маҗарасы яки рәшәткәле купе. №12

### ПУБЛИЦИСТИКА

Вәлиев М. Күңел тәрәзәбездә ут сүнмәсен. №5

Вәлиуллин М. Җәмгыять һәм мәктәп. №12

Гариф Н. Казан—Мәскәү арасы: гасырлар ярасы. №1

Ибраһимов И. Олы эшләр елы булыр. №1

Мостафин Р. Тормыш мизгелләре. №5

Хәким Р. Татар рухы. №№7-12

Шәмси С. Адәмне кем коткарыр? Тарихи-эзотерик бәян. №№5, 6

Юныс Р. Милек һәм ирек (Әхмәт Галиев белән әңгәмә). №8

### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Әхмәтҗанов М. Гамил Афзал иҗатында сәясәт. № 5

Вәлиулла И. Буыннар чылбыры өзелмәс. №7

Вәлиулла И. «Кай йөрәктән килә бу моң?» №10

Галиуллин Т. «Бәрелде җан, сугылды җан ярсып». №11

Зәйдулла Р. Саркылган эңгернең шәүләсе. №6

Ибраһимов И. Әдәби сүзнең көче. №6

Ишмиева Л. Символлар сере. №12

Кәримов К. Прозаның киштәдәге урыны. №6

Урманче Ф. «Фәрештәләр санап бара күз яшен...» №5

Фәйзуллин Р. Әйдәүче (Тәүфикъ Әйдинең күптомлыклары чыгу уңаеннан). №5

Хатипов Ф. Нахактан аралау юнәлешендә. №8

Хафизов С. Тамырлары үзебездә. №8

Хәсәнова Ф. «Мин елмаеп кына дөньяүзгәрерме?» №9

Шәмсутова А. «Сискәндереп гамьсез көнне...» №1

### ДИСКУССИЯ: «БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ»

Дискуссиянең кайбер нәтиҗәләре. №1

### ФӘН

Галиуллин Т., Йосыпов Ф. Дастан эзләреннән. №9

Гарипова Ф. Авылларыбыз тарихы. №№7-11

Зәйнуллин Җ. Амазиглар кемнәр алар? №7

Тимергалин А. Миллият сүзлеге. №№1-12

Фәйзуллин Р. Тел сагында тора солдат. №8

Фәттах Ф. Кемнәр ул скифлар? №1

Һадиев И., Мәрданов Р. Саба төбәгенең эпиграфик истәлекләре. №8

### ДУСЛАР СҮЗЕ

Бикбаев Р. Мәхәббәт дәфтәре. №10

### ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫ

Кәримов К. Татар кайчан көлгән яки Мәкәрҗә синдромы. №4

### ӘДӘБИ МИРАС

Әхмәт Р. Акын, чичән, шагыйрь... №12

Акмулла. Робагыйлар. №12

### СӘНГАТЬ

Арсланов Г. «Татар театрының атасы». № 5

Госманов. М. Сират күперендәге уйлар. №12

Нәҗмиев Т. «Туган җирем дә, туган көнем дә—икәү...». №12

Низами Р. Ерактагы йолдыз яктысы (Латыйф Хәмидинең тууына 100 ел). №8

Сәйдәшева З. Чын татарча милли көй. №10

### ТАТАР ТЕАТРЫНА 100 ЕЛ

Ач пәрдәңне, галиҗәнап Театр! (Г. Камал исемендәге театр директоры Ш. Закиров белән Р. Юсупова әңгәмәсе). №12

Гыйммранова Д. Сәхнәбез каһарманнары. №6

Сафиуллин Ю. Сәхнәбезнең өч йолдызы. №10

Солтанова Р. Татар театрының беренче рәссамы. №9

Шакиров Ә. Язмыш һәм узмыш. (Р. Юныс кереш сүзе белән). №11, 12

**ХӘТЕР**

Әмирхан Еники хатлары. №1

Әхмәтҗанов Г. Әти сагынып сөйли иде. №4

Госманов М. Беренче редакторым. №4

Госманов М. Гыйбрәтле язмышлар. №№5, 6

Госманов М. Сират күперендәге уйлар. №12

Кәримов К. Яңа ишан оныгы. (Атилла Расихның тууына 90 ел.) №9

Мәһдиев М. Көндәлек сәхифәләре. №№11, 12

Низами Р. Кешелекле, мәгърифәтле шәхес (Карл Фуксның тууына 230 ел). №9

Нуруллина Р. «Бер-береңезгә гыйззәт кыйлыңыз». №3

Хәмидуллин Л. Оренбургның фидакарь заты. №7

Хәлиуллин Й. Салмак аккан тирән фикерләр иясе. № 1

Юсупова Р. Ак сагыш иясе. Очерк-хатирә. №3

**ЮБИЛЕЙЛАР**

**ГАБДЕЛНАСЫЙР КУРСАВИНЫҢ ТУУЫНА 230 ЕЛ**

Мәрданов Р. Кыйммәтле ядкәрләр. №11

Курсави Г. Шигырьләр. №11

**ГАБДУЛЛА ТУКАЙНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ**

Әдәбият өлкәсендә Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары (1958—2005). №4

Галиуллин Т. «Дөньяда бик аз булыр чын шагыйрь». №4

Ганиева Р. Тукайның «Золым» шигырен укыганда. №4

Дәүләт Н. Чит илләрдәге татарлар һәм Тукай. №10

Миңнегулов Х. Еракта да якын Тукай. №4

Тукай Г. Туган тел. Шигырьләр. №4

Тукай турында шагыйрьләр. №4

Тукай турында олуг шәхесләр. №4

Хисамов Н. Шигъриятта Тукай феномены. №4

**НӘҖИП ХӘЛФИННЕҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ**

Хәлфин Н. 1913 нче елда татар шагыйрьләре. №11

**ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ**

Әмирхан Р. Яшәеш һәм иҗат колачы. №1

Галиуллин Т. Буыннар хәтере — милләт таянычы. №1

**ДЕМЬЯН ФӘТХИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Редакция мәкаләсе. №10

**САРА САДЫЙКОВАНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ**

Әхмәт Р. Сандугачтай Сара апабыз. №11

**ГАМИР НАСРЫЙНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ**

Редакция мәкаләсе. №1

**МИРЗА МӘХМҮТОВКА 80 ЯШЬ**

Редакция котлавы. №5

**ХИСАМ КАМАЛОВКА 80 ЯШЬ**

Маннапов Ш. Иҗатта табылган бәхет. №4

**САҖИДӘ СӨЛӘЙМАНОВАНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ**

Бәйрәмова Г. Җырланмаган җырлар ни сөйлиләр? №10

**ШӘҺИДӘ МАКСУДОВАГА 80 ЯШЬ**

Редакция котлавы. №11

**АДЛЕР ТИМЕРГАЛИНГА 75 ЯШЬ**

Рахмани Р. Фән һәм хыял канатында. №1

Тимергалин А. Әлифба, имла, фәнни истилах. №1

**АЛЬБЕРТ ЯХИНГА 75 ЯШЬ**

Гыймадиев А. Формулалы әдәбият. №11

**МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВКА 75 ЯШЬ**

Редакция котлавы. №10

**РОЗА ХӘЛИУЛЛИНАГА 75 ЯШЬ**

Редакция котлавы. №9

**ӘХМӘТ РӘШИТОВКА 70 ЯШЬ**

Мансуров З. «Мөмкин белән «түгел» арасы. №3

**КЛАРА БУЛАТОВАГА 70 ЯШЬ**

Миңнегулов Х. Шигърият һәм туган тел хадимәсе. №3

**ИЛДАР НИЗАМОВКА 70 ЯШЬ**

Редакция котлавы. №9

**ИНДУС ТАҺИРОВКА 70 ЯШЬ**

Редакция котлавы. №5

МИДХӘТ МИНШИНГА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. №9

ФАЯЗ ДУНАЙГА 70 ЯШЬ

Редакция котлавы. №1

ИЛДУС ГЫЙЛӘҖЕВКӘ 60 ЯШЬ

Гаташ Р. Җир китабын кемнәр яза... №1

Гыйләҗев И. Җир өстендә узган безнең еллар. Шигырьләр. №1

НАИЛӘ ВӘЛИТОВАГА 60 ЯШЬ

Редакция котлавы. №3

СОЛТАН ШӘМСИГӘ 60 ЯШЬ

Редакция котлавы. №1

НӘБИРӘ ГЫЙМАТДИНОВАГА 50 ЯШЬ

Зәйдулла Р. Барасы юллар озын. №10

ТАТАРСТАН КИТАП ПАЛАТАСЫННА 80 ЕЛ

Шакирова М. Татар китабының алтын сандыгы. №12

Мөхсинев З. Китап палатасы. №12

«МИЛЛИ КИТАП» НӘШРИЯТЫНА 10 ЕЛ

Һадиев И. Үз нәшриятыбыз. №12

КИТАП КҮЗӘТҮ

Әхмәдуллин А. Тормыштан алынганмы, язучы хыялында туганмы? №8

Әхмәтҗанов М. Тукай турында. №11

Закирҗанов Ә. Рухи биеклек. №5

Кәшфиева Л. Сагыш һәм моң тулы. №8

Низами Р. ...Яшисе килә. №11

Шәрәфиев Р. Югалтма, дөнья, шагыйрәңне! №1

Шәрәфиев Р. Бу нинди... сугышлы балачак? №10

ЮМОР-САТИРА

Бәдигый Х. «Дедовщина». Шигырь. №5

Галимҗанова М. Борын. Хикәя. №9

Кәримов К. Сансыз фиргавен. Кыйсса. №1

Нәҗмиев Т. Шаян көндәлек. №6

Сәгъди Р. Сихерче Виктория. №4

Сәгъди Р. Шикле машина. Хикәя. №9

Сафиуллин Ә. Ачыклык кирәк? Памфлет. №6

Сафиуллин Ә. «Бүген ничәсе?» Шаян хикәя. №12

Фәсхи Ф. Эпиграммалар. №9

БЕРЛЕКНЕҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ

Салават Юзеев. №1

Ибраһим Биектаулы (Нәфыйков). №4

Нурзидә Нотфуллина (Нурзилә). №6

Ринат Мәннан. №8

Наилә Миңнеханова. №9

Чулпан Зариф. №10

Илдар Хәйруллин. №12

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Гыйбадуллина Л. Ә очасы килә... Шигырьләр. №3

Җәлилова Э. Түгелер дә йөрәк... Шигырьләр. №3

Сәлахов Р. Идел ага... Шигырьләр. №7

Ситдикова Ә. Мин — бер инеш. Шигырьләр. №4

Шәех Л. Син—минем сеныр кыям... Шигырьләр. №5

Һадиева Э. Яшь хыял сурәте. Шигырьләр. №8

ОСТАХАНӘ

Рашат Низами. Каләм алдым кулыма... Эссе. №3

АК ҖИЛКӘН

Закирова Л. Шаян хикәяләр. №10

Миңнуллина Й. Шәһәр чаганнары. Шигырьләр. №11

Сәйфуллин И. Үсмерләр өчен шаян хикәяләр. №3

Таңгөл. Курьер. Хикәя. №9

Хуҗин И. Кызыл тәнлеләр юлбашчысы. Хыялый бәян. №7

СӘЯХӘТНАМӘ

Мушинский Ә. Яңгырлы Финляндия. №4

ШӘХЕСЛӘР

Гариф Н. Таныш тавышлы милләттәш. №3

Филиппов А. Гөргөри. №3

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. №№1-12

Укучы сүзе. №№1, 5, 7

Бер сорауга—бер җавап. №№6, 7, 8, 11, 12

«Казан утлары» архивыннан. №№1-12

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. №№1-12

### ТАРИХЫБЫЗ МУЗЕЕ АЧЫЛДЫ

Казан Кремле территориясендә «Татар халкы һәм Татарстан Республикасы дәүләтчелеге тарихы» дип исемләнгән музей-мемориаль комплексы ачылды. Шушы уңайдан оештырылган тантанада Президент Минтимер Шәймиев катнашты.

Яңа комплекс үз тарихлары һәм архитектуралары буенча бер-берсенә бәйле булган Сөембикә манарасын, элеккеге сарай чиркәвен һәм Татарстан Президентының рәсми резиденциясен берләштерә. Аның урыны Хан сарае һәм мәчетенең, шулай ук Казан ханнары зиратының тарихи урыннары нигезендә билгеләнгән. Комплекс экспозициясендә Казан ханнарының тәхет залы һәм хан мавзолее интерьерының реконструкцияләнгән аерым өлешләре, татар халкы дәүләтчелегенең борынгыдан алып бүгенге чорына караган уникаль экспонатлар һәм аларның күчермәләре урын алган.

Президент Минтимер Шәймиев, тантанада катнашучыларга мөрәҗәгать итеп, Татарстан Фәннәр академиясе хезмәткәрләренә һәм җитәкчелегенә, барыннан да элек, Тарих институтына, шулай ук «Казан Кремле» тарихи-архитектура һәм сәнгать музейтыюлыгы дирекциясенә, фәнни оешмалар һәм җәмәгатьчелекнең барлык интеллектуаль көчләренә музей-мемориаль комплексын булдыруга керткән игелекле өлешләре өчен ихлас күңелдән рәхмәт белдерде. Төрки каһанлык тарихын өйрәнү мәсьәләсенә тукталып, Илбаш: «Бу эш белән без шөгыльләнергә тиеш—әлеге бурыч, бер яктан, Татарстан һәм аның халыклары мәнфәгатенә кагыла, икенче яктан, Россия Федерациясе үсешен объектив тарихи бәяләү өчен дә ул бик мөһим,—дип искәртте.—Милли-территориаль бүленеш нигезендә революциядән соңгы дәүләтчелек оешу процессын да онытмаска кирәк. Шунысы да игътибарга лаек, әгәр мондый музей элегрәк оештырылса, аның әһәмияте өлешен, мөгаен, яңадан карарга кирәк булыр иде. Бүген без музейны зур объективлык шартларында, нинди дер догматик һәм идеологик басымнардан котылган хәлдә ачабыз... Әлбәттә, киләчәктә тарихи мәгълүматларны тулыландырып, баетып тору зарур, һәм аларны һәрдаим анықлап торудан да курыкмаска кирәк».

Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиева үз чыгышында музей-мемориаль комплексының Татарстан Конституциясе көнен бәйрәм иткәннән соң ачылуын искә төшереп үтте: «Бүгенге вакыйга әлеге дәүләти бәйрәм датасын ерак гасырлар, борынгы төрки цивилизацияләр тарихы белән бәйли»,—диде ул.

Музейда тагын бер үзенчәлекле зал бар. Ул—Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевка багышланган экспозиция. Биредә республика башлыгына бүләк итеп бирелгән медальләр, аның дөньякүләм танылган шәхесләр белән бергә төшкән фотосурәтләре, Президент булып эшли башлаган беренче елларында җитди документларга кул куйган алтын каләме дә урнаштырылган.

"Музей-мемориаль комплексын ачу тантанасында шулай ук Президент аппараты җитәкчесе Юрий Камалтынов, Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары Александр Гусев һәм Римма Ратникова, башка рәсми кешеләр катнашты.

### МӘГЪРИФӘТ УЧАГЫ

Республикадагы данлыклы уку йортларының берсе—Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты (элеккеге педагогия институты) үзенең 130 еллыгын билгеләп үтте. Ул Идел буе, Урал, Себер төбәкләре өчен югары белемле мөгаллимнәр әзерли. 2005 елның язында университет «Ел проекты» номинациясендә югары уку йортларының Бөтенроссия конкурсында лауреат дипломын, «Россиянең 100 вузы» номинациясендә «Европа сыйфаты» алтын медален алды. Бүген ТДГПУда 15000 студент белем ала.

ТДГПУ җитәкчелеген, укытучылар һәм студентлар коллективын бәйрәмнәре белән котларга Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин килде. Тантаналы утырышта катнашучылар алдында ясаган чыгышында ул уку йортының төп максаты милли элита тәрбияләү булуын искәртеп үтте һәм, телләр мәсьәләсенә тукталып: «Хәзерге заманда рус теле дә күбрәк игътибар сорый»—диде.—Әмма татар теленә мөнәсәбәт сездә башка вузлардагыдан үзгәрәк булырга тиеш... Татар теле укытучылары әзерләүнең сыйфатын күтәрергә кирәк. Балаларны мәктәптә укырга-язарга өйрәтә торган заманалар үтте. Укы-

тучы балада кызыксынучанлык тәрбияли белергә тиеш. Хәзерге мәгълүматлаштыру, компьютерлаштыру чорында балалар еш кына үз укытучыларыннан да уздыра. Без алардан калышмаска, алда булырга тиеш».

Гадәттә, бәйрәмдә бүләкләр була. Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин ТДГПУ студентларына автобус, яна бина алдындагы мәйданны чистартып торырга кар көрәгеч машина бүләк итте.

### ДАГОМЫС ЖУРНАЛИСТЛАРНЫ ҖЫЙДЫ

Сочи янындагы «Дагомыс» савыктыру комплексында «Бөтенроссия-2006» XI журналистлар фестивале булып үтте. Анда бөтен илдән ике меңнән артыграк массакүләм мәгълүмат чаралары вәкиле катнашты. Татарстан журналистлары делегациясенә «Татмедиа» агентлыгы генераль директорының беренче урынбасары Фәрит Шаһиәхмәтов җитәкчелек итте. Татарстан делегациясе сан ягыннан бүтән республикалар һәм өлкәләр арасында иң ишлесе иде.

«Дагомыс»та күргәзмәләр дә оештырылды. Биредә шулай ук Татарстан журналистлары да үз иҗатлары белән таныштырды. «Татмедиа» агентлыгы Сочига рус, татар һәм чуаш телләрендәге көндәлек басмаларны алып килгән иде. Күргәзмәнең иң үзәк өлеше «Казан утлары» журналына багышланды. Стендта журналның менәнче саны чыгу уңаеннан фестивальдә катнашучылар өчен кызыклы булырлык шактый материаллар куелган иде. Фестивальдә катнашучылар газета-журналлар белән генә түгел, стендлардагы буклетлар, открыткалар белән дә таныштылар. Фестиваль кысаларында «Заманча журналистика: һөнәри осталык критерийлары» дигән темага Россия журналистлары конгрессы да узды.

### ШАГЫЙРЬНЕ ОЛЫЛАУ

«Казан» милли мәдәният үзәгендә күренекле шагыйрь, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Мөдәррис Әгъләмгә 60 яшь, иҗади эшчәнлегенә 40 ел тулу уңаеннан «Халкын тапшырган каләм» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды.

Халык белән шыгрым тулы залда үткән әлеге кичә юбилей чарасы булудан ашып, чын мәгънәсендә иҗат бәйрәменә, татар шигърияте бәйрәменә әверелде. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның татар әдәбиятын үстерүдәге зур казанышлары өчен шагыйрь Мөдәррис Әгъләмгә «Татарстанның халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирү турында Президентыбыз Указын игълан итүен кичәгә җыелган тамашачылар алкышлап каршылады. Парламент җитәкчесе юбилярга әлеге исемнең таныклыгын һәм билгесен, шулай ук акчалата бүләк тапшырды, үзенең котлавында Мөдәррис Әгъләмнең һәрвакыт халык гаме белән яшәүче шагыйрь икәнлеген, ул иҗат иткән әсәрләрнең зур иҗтимагый-эстетик әһәмияткә ия булуын билгеләп үтте.

Премьер-министр Рөстәм Миңнеханов, шулай ук аның урынбасары—мәдәният министры Зилә Вәлиеваның котлауларын мәдәният министры урынбасары Айрат Җаббаров ирештерде.

Кичәдә бәйрәмдарны аның каләмдәшләре—Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Разил Вәлиев, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон һ. б. ларның тәбрикләүләре дә Мөдәррис Әгъләмнең халыкчан зур иҗатлы шагыйрь булуын тану буларак кабул ителде.

Юбилей кичәсе котлаулар, шигырьләр һәм җырлар белән аралашып барды. Шагыйрьнең әсәрләрен күренекле артистларыбыз Шәүкәт Биктимеров, Айрат Арсланов, Ирек Баһманов, Нәҗибә Ихсанова, Дания Нуруллина, Хәлим Җәләлов, ә җырларны Илһам Шакиров, Рафаэль Сәхабиев, Гөлзадә Сафиуллина, Бәширә Насыйрова һ. б. лар башкарды. Бу кичәдә тамашачылар иң яшь талантларыбыз Байбулат Батуллин һәм Нариман Сәхабиев чыгышларын тыңлап та сөенде. Зәй районыннан килгән якташларының чыгышын юбиляр үзе дә, тамашачылар да үзгә бер ихласлык белән яратып кабул итте. Кичәне язучы Рабит Батулла алып барды.

### КАМАЛЛЫЛАР—I ХАЛЫКАРА ФЕСТИВАЛЬДӘ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры күптән түгел үткәрелгән I Халыкара Үзәк Азия илләре театры фестивалендә катнашты.

Казакъстанның Астана шәһәрендә уздырылган фестивальгә камаллылар Нәкый Исәнбәт әсәре буенча режиссер Фәрит Бикчәнтәев сәхнәләштергән «Җирән чичән белән Карачәчсылу» спектаклен алып барган иде.

Фестивальдә шулай ук Әзәрбәйҗан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Төркмәнстан, Таҗикстан милли театрлары коллективлары да катнашкан. Спектакльләр Казакъ академия драма театры, Казакъ дәүләт академия яшь тамашачы театры һәм Дәүләт музыкаль комедия театры сәхнәләрендә куелган.

Казакъстанда гастрольләр белән Казан артистлары инде бик күптән, 1986 елда ук булганнар. «Җирән чичән һәм Карачәчсылу» спектакле—Г. Камал театры репертуарында аерым урын алып торган әсәр. Аның премьерасы 1999 елда узды, 2002 елда «Нәүрүз» фестивалендә «Иң яхшы режиссерлык эше» номинациясендә җиңү яулады. Ә 2003 елда ул Төркиядә үткән V Халыкара театр фестивалендә, 2004 елда «Истанбул-Простор-Театр» I Халыкара фестивалендә күрсәтелгән иде.

## БӨГЕЛМӘДӘ ӘДӘБИЯТ КӨННӘРЕ

Октябрь башында Бөгелмә районында татар әдәбияты көннәре үткәрелде. Әдәбият һәм сәнгать елының бер күркәм чарасы буларак оештырылган әлеге бәйрәмдә танылган язучылар, журналистлар, нәшрият хезмәткәрләре катнашты.

Кунакларны район чигендә ипи-тоз белән муниципаль район Советы башкарма комитеты рәисе вазыйфаларын башкаручы К. Гыйльметдинов, башкарма комитет рәисе урынбасарлары Р. Йосыпова, Л. Мөстәкыймова, мәдәният идарәсе башлыгы Р. Әхмәтов һәм башка рәсми кешеләр каршы алды.

Каршылау тантанасыннан соң әдәбият көннәрендә катнашучы каләм әһелләре, өч төркемгә бүленеп, район авылларына юл тотты. Язучы һәм шагыйрьләр Туфан Миннуллин, Разил Вәлиев, Марсель Галиев, Нәбирә Гыйматдинова һәм Асия Юнысова составындагы төркем Карабаш поселогында, Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, шагыйрьләр Роберт Миннуллин, Гәрәй Рәхим, Илсөяр Иксанова, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакировлар төркеме—Кодаш авылында, Әлмәт язучылар оешмасы житәкчесе Данил Салихов, шагыйрьләр Зиннур Мансуров, Шәмсия Җиһангирова һәм Рафис Корбан Татар Димскәе авылында мәктәп укучылары белән очрашты, шулай ук мәдәният йортларында үткәрелгән кичәләрдә катнашты. Каләм әһелләренең чыгышы һәркайда да зур игътибар белән тыңланды. Һәрбер очрашу махсус сценарийлар буенча әзерләнгән иде. Әдәбият бәйрәме барышында мәктәп укучылары һәм авыл үзешчәннәре башкаруында шагыйрьләрнең аерым әсәрләре һәм җырлары яңгырады, бөгелмәлеләр шулай ук драматургларның пьесалары буенча куелган спектакльләрдән өзекләр дә уйнап күрсәтте. Очрашу урыннарында Казаннан килгән язучылар турында стендлар һәм аларның китапларыннан торган күргәзмәләр дә оештырылган иде. Татарстан китап нәшрияты директорының үзе белән күп кенә яңа басмалар алып килүе әдәбият сөючеләрне бик куандырды.

Кичен Бөгелмә дәүләт рус драма театры бинасында әдәбият көннәренә багышланган зур тантана булды. Анда сәламләү сүзләре белән Бөгелмә муниципаль районы Советы башкарма комитеты рәисе вазыйфаларын башкаручы К. Гыйльметдинов һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов чыкты. Аннары бер-бер артлы язучы һәм шагыйрьләр чыгыш ясады.

Икенче көнне әдәбият көннәрендә катнашучы язучылар, шулай ук өч төркемгә бүленеп, шәһәрнең 1 нче мәктәбендә, 2 нче физика-математика лицеенда һәм 14 нче татар гимназиясендә укучылар белән очрашты, Ярослав Гашекның әдәби-мемориаль музеенда, кадет-интернат мәктәбендә, «Татнефть» ачык акционерлар җәмгыятенең Бөгелмәдәге механика заводында, шушы предприятиенең «Лилия» санаторий-профилакториендә булды. Кыскасы, очрашулар һәркайда югары дәрәҗәдә үтте, әдәбият көннәре Бөгелмә районы халкында да, язучыларның үзләрендә дә онытылмаслык тәэсирләр калдырды.

## МИНИСТР БЕЛӘН ОЧРАШУ

2 ноябрьдә Татарстан Язучылар берлегендә кызыклы һәм мәгънәле очрашу булды: әдипләрнең чакыруын кабул итеп, әңгәмәләшергә Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары—авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Готуф улы Әхмәтов килде. Ике сәгатьтән артык дәвам иткән бу очрашу язучылар күңеленә хуш килде. Марат Әхмәтов авылда туып-үсеп, бөтен гомерен авыл хуҗалыгы белән бәйләгән, җир белән эш итүнең нечкәлекләрен яхшы белгән зур җитәкче. Өстәвенә туган телебезне язучылар көнләшерлек дәрәҗәдә камил белә торган, образлы һәм тапкыр сөйләү куәсенә ия шәхес. Авыл язмышына бәйле сораулар күп булды министрга. Ә ул исә язучыларны уйландырырлык, иҗатларында файдаланырлык байтак мәгълүматлар бирде, актуаль мәсьәләләр турында үзенең фикерләрен әйтте. Татарстан язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов оешма исеменнән Марат Әхмәтовка рәхмәт белдерде.

## ИДАРӘ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Анда идарә рәисе Илфак Ибраһимов әүвәл соңгы ай дәвамында башкарылган эшләр турында сөйләде. Аннары балалар әдәбияты остаханәсе җитәкчесе Рафис Корбан хисап тотты. Утырышта катнашучылар соңгы вакытта остаханә эшчәнлегенең җанлануын, балалар язучыларының күптөрле әдәби чараларда актив катнашуын билгеләп үтте.

Идарә әгъзалары башкалабыз Казанның милли йөзе төссезләнә баруына, мәдәни мирас булып саналган тарихи биналарга, архитектура һәйкәлләренә саксыз мөнәсәбәт очракларының ешаюына, атап әйткәндә, Татарстан урамындагы атаклы «Болгар» номерлары—бөек шагыйребез Габдулла Тукай яшәгән йортның, шулай ук Бауман урамындагы Матбугат йортының киләчәк язмышына карата тирән борчылуын белдерде.

Утырышта 2007 елның беренче яртыеллыгына Язучылар берлегенең эш планы, әдипләрнең юбилейларын үткәрү тәртибе тикшерелде, каләм иярәре Хәнәфи Бадигый белән Ягсуф Шәфыйков Язучылар берлегенә әгъза итеп алынды, башка көнүзәк мәсьәләләргә игътибар юнәлтелде.

## ШАГЫЙРЬНЕҢ ГАМӘЛ ДӘФТӘРЕ

9 октябрьдә Казан милли-мәдәни үзәгендә танылган шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Харрас Әюпнен «Гамәл дәфтәре» дип исемләнгән иҗат кичәсе булып узды. Ул каләмдәшебезгә 60 яшь тулуга багышлап үткәрелде.

Харрас Әюпне шигърият сөючеләр дистәдән артык шигырь китаплары, радио аша яңгыраш тапкан «Биш вакыт намаз», «Көй эзләү», «Авыл җаны» кебек поэмалары, күп санлы лирик җырлары аша беләләр.

Кичәдә Татарстан Республикасының Мәдәният министры урынбасары А. Җаббаров шагыйрьгә Премьер-министр Р. Н. Миңнехановның котлау хатын тапшырды. Юбилярны шулай ук Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе И. Ибраһимов, Татарстан китап нәшрияты директоры Д. Шакиров котладылар һәм ана яна иҗат уңышлары теләделәр.

Шагыйрьнең бәйрәменә анын якташлары да килгән иде. Мөслим муниципаль районы хакимияте башлыгы Р. Хәбипов кичәдә чыгыш ясап, аны кайнар котлады, якташларынын иң изге теләкләрен җиткерде.

З. Хәйретдинов, З. Шаһбан, В. Усманов кебек сәнгать осталары һәм яшь башкаручылар шагыйрь сүзләренә язылган җырларны кабат яңгыраттылар, анын шигырьләрен күренекле артистларыбыз укыды.

## ШАГЫЙРӘ ЮБИЛЕЕ

17 октябрьдә күренекле шагыйрә Флера Гыйззәтуллина иҗатына багышланган «Язмышымның фалын ачам» дип аталган әдәби-музыкаль кичә узды. «Казан» милли-мәдәният үзәгендә үткән бу кичә шагыйрәнең 75 яшенә багышланган иде. Залга шагыйрәнең дуслары, туганнары, каләмдәшләре, якташлары күпләп җыелды. Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов шагыйрәне зурлап котлады һәм аңа Татарстан Президентының Рәхмәт хатын тапшырды, иҗатының зурлыгын, шигырьләренең, җырларының, 30 дан артык поэмаларының шигырь сөючеләрнең күңелендә икәнен искәртте. Котлауларны язучылардан В. Имамов, Ә Исхаков, якташлары—Азнакай вәкилләре, «Сөембикә» журналы хезмәткәрләре дәвам итте... Кичәдә шулай ук К. Тинчурин һәм Г. Камал театрлары артистлары катнашты. Җырчылардан Ф. Салахов, Г. Сафиуллина, Р. Закиров, А. Габдинов һәм башкалар шагыйрәне юбилее белән котлап, җыр аша шагыйрәгә хөрмәт хисләрен белдерделәр.

## ШАГЫЙРЬГӘ ЧӘЧӘКЛӘР

Шагыйрь Наис Гамбәр—әдәбиятта гына түгел, туган ягы Мөслим тарихында да якты эз калдырган шәхес, һәвәскәр рәссам Рәйхан Хантимеров белән берлектә, Мөслимнең туган як музеен оештыруда башлап йөргән, мәктәпләрдән, авыллардан бик күп экспонатлар туплауда зур тырышлык куйган эзтабар да ул.

2 октябрьдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов җитәкчелегендә бертөркем язучылар—Харрас Әюп, Шәмсия Җиһангирова, Марсель Галиев, Әлмәт язучылар оешмасы җитәкчесе Данил Салихов, Мөслимдә яшәп иҗат итүче каләм әһелләре Фоат Садриев, Мөҗәһит Әхмәтҗанов һәм Әхмәт Дусайлы, шагыйрьнең туган авылы Бүләктә булып, каберенә истәлек ташы кую мәрәсимендә катнашты.

Әлеге чарада муниципаль район башлыгы Ришат Хәбипов, башкарма комитет рәисе урынбасары Рушат Солтанов, район мәдәният бүлеге җитәкчесе Илсур Ялалов, матбугат үзәге директоры Мөдәмил Әхмәтов, мәрхүмнең хатыны Гөлфирә ханым, Наис Гамбәрнең туганнары, авылдашлары, ул укыган мәктәп укучылары һәм укытучылары катнашты.

## ӘДИПЛӘРГӘ БАГЫШЛАП

Санкт-Петербург Рәссамнар берлеге бинасында Габдулла Тукайның 120 һәм Муса Җәлилнең 100 еллыгына багышланган күргәзмә ачылды. Бу чараны шәһәрнең Татар милли-мәдәни мөхтарияте каршында төзелгән Татар рәссамнары берлеге оештырды.

«Рәссамнар—шагыйрьләргә» дип аталган күргәзмәгә егерме иҗатчының эше куелган. Анда Казан, Санкт-Петербург күренешләре, Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил әсәрләре буенча персонажларны күрергә мөмкин.


2006 елның 15 октябрендә озакка сузылган каты авырудан соң 76 яшендә язучы, публицист, дипломат **Вахит Закир улы Юныс** вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Рәшит Бәшәр**.

# Яңа китаплар




Ber keçe yazmışı: Təmamlanmağan avtobiografik povest' / **Əmrulla Agi**.—Qazan: Məğərif, 2006.-175 b.

Bu kitap—Yıraq Kənçığışta yəşəgən həm 1917 yıldan son Qıtayda məhacirlar xələndə qalğan tatarlarnın qatlawlı yazmışı xaqında. Avtor Qıtayda, Koreyada həm Yaponiədəge tatarlar tormışının kisken üzgəreşlər kiçerüen üz başınnan ütkənnər buyınça taswirlıy. Povest'nen Stalin lager'larında repressiələngən məhacirləmen açı yazmışı turındağı əleşlərə ayıruça tirən tə'sir qaldıra.

Kitap Watan tarixı həm tərki-tatar məhacirlərə yazmışına bitaraf bulmağan millətteşlərgə adreslana.




**Фатих Урманче**. Каһарманнар йолдызлыгы: Тарихи-фольклористик очерклар. — Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 2006. — 288 б.

Күренекле галим күп еллардан бирле төрки-татар эпосын һәм мифларын өйрәнә. Аның бу өлкәгә караган дистәләгән монографияләре, күпсанлы фәнни мәкаләләре бар. Галимнең бу китабына төрки-татар халыкларының дәүләти тормышында ифрат зур роль уйнаган атаклы каһарманнар (Атилла, Идегәй, Нурсолтан, Сөембикә...) турындагы тарихи-фольклористик очерклары тупланган. Китап Ф. Урманченың 70 яше тулу уңаеннан чыгарылган һәм анда аның иҗаты турында бай библиографик материал да бирелгән.

Китапның төзүче-мөхәррире — Хуҗиәхмәт Мәхмүтов.



Рәшит Бәшәр

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)